ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

6.2011



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## *2011 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирү турында*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләре комиссиясе тәкъдимен кабул итәргә һәм 2011 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен бирергә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премияләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Шаһиморатова Альбина Әнвәр кызына**—Көнбатыш Европа һәм рус композиторлары операларында вокаль партияләрне, татар композиторлары җырларын һәм романсларын, татар халык җырларын бик югары профессиональ дәрәҗәдә башкаруы өчен;

2) **Шакирҗанова Лена Галимҗан кызына** (Лена Шагыйрьҗанга)—«Божра вә Хөҗрә: Шигырьләр, поэмалар», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2002 ел, һәм «Сагынмалык: Истәлекләр, багышламалар», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2005 ел, җыентыклары өчен;

3) **Килдебәков Рөстәм Әхмәт улы** һәм **Килдебәкова Мария Семеновна** составындагы рәссамнар коллективына—Татарстан Республикасының җәмәгать бинаалары интерьеры һәм экстерьеры өчен бергәләп иҗат ителгән монументаль һәм декоратив-гамәли сәнгать әсәрләре һәм полотнолар сериясе: «Идел», «Татарстан» кунакханә комплексларында, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында һәм башкаларда «мозаика» һәм «сграфитто» монументаль әсәрләре; «Сәйяр Труппасы» гобеленнары, «Су анасы», «Сак-Сок», «Шүрәле» халык әкиятләре мотивлары буенча» триптихы; татар халкы мәдәниятенә һәм тарихына багышланган «Кукмара итекләре», «Шагыйрәләр», «Хаҗилар», «Кайту», «Биюче дәрвиш» һәм башка картиналар сериясе өчен;

4) **Ибраһимов Илфак Мирза улына** (Мөхәммәт Мирзага)—«Киек каз юлында», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2003 ел, «Тере су», Татарстан китап нәшрияты, Казан, 2007 ел, китаплары һәм «Адәм баласы» китабында басылып чыккан «Адәм баласы», Мәгариф, 2009 ел, шигырьләр циклы өчен.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р. Н. МИННЕХАНОВ**

*Казан, Кремль.*
*2011 ел, 25 апрель №ПУ-240*

# Казан утлары
# Qazan utları

2011

# 6
**(1064)**

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
***«ТАТМЕДИА»***
***ачык акционерлык җәмгыяте***

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Галиуллин, Марат Закир, Камил Кәримов, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**

*420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир—562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары—292-93-16.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-39-63.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.*
*Гамәли хезмәткәрләр—562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге—222-09-80.*
**Факс**—*(843) 562-11-28.*
**E-mail:** *kazanutlari@yandex.ru*

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Роберт МИҢНУЛЛИН. Ике тамчы каен яше. *Шигырьләр.* ... 5
Рабит БАТУЛЛА. Апуш–Тукай. *Кыйсса.* ... 10
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Тәрәзәм саен гөлләр. *Шигырьләр.* ... 45
Әхәт МУШИНСКИЙ. Һаваларда—ак күгәрчен... *Роман.* ... 50
Фәрит СУФИЯРОВ. Юлаучыга юлдаш булам. *Шигырьләр.* ... 97
Нурислам ХӘСӘНОВ. Золым. *Роман.* ... 99
Илдус ДИНДАРОВ. Ә гасаби уйлар бөтереп ала... *Шигырьләр.* ... 126

**САТИРИК ӘСӘРЛӘР КОНКУРСЫ**

ЧУЛПАН. Хөкем. ... 129
Солтан МОРАТ. Ил белән... *Шигырь.* ... 136
Мөдәрис МӨХТӘСИПОВ. Юкны бушка аудару. *Мәсәл.* ... 137

**ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН**

Габделхәй САБИТОВ. Хәвефле җәй. ... 140

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Шигъри җан бәяны. ... 144

**ФӘН**

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 148
«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ... 151

**ТОРМЫШ ЯЗГАН ХИКӘЯЛӘР**

Радик ФӘИЗОВ. «Күңелле поезд». ... 153

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рәфикъ ЮНЫС. Берләшик! ... 161

**АК ҖИЛКӘН**

Камил КӘРИМОВ. Бәләкәй Камил. ... 166
Зур Сәрдектән «Ак җилкән»гә иҗат сәламе. ... 170
Дания НӘГЫЙМУЛЛИНА. Гөнаһлы җиһан *Шигырьләр.* ... 173
Ким ШАКИРОВ. «Ишәкләр белән очрашмыйм!». ... 175

**ХӘТЕР**

Фәнис ЯРУЛЛИН. Хәтер төпләрендә утлы күмер. *Көндәлекләр.* ... 180

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Аяз ХӘСӘНОВ. НКВД күзе астындагы гомер *(Гарәфи Хәсәновның тууына 90 ел).* .. 187

«Казан утлары» архивыннан. ... 124, 178
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 190

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: романы Р. БАТУЛЛЫ «Апуш—Тукай» (прод.); А. МУШИНСКОГО «Шейх и звездочет» (прод.); Н. ХАСАНОВА «Насилие» (прод.); стихи Р. МИННУЛЛИНА, Э. ШАРИФУЛЛИНОЙ, Ф. СУФИЯРОВА, И. ДИНДАРОВА.
«Сенной базар». Конкурс сатирических произведений.
«Из сокровищниц татарских рассказов»: Г. САБИТОВ. «Тревожное лето».
«Книжное обозрение»: М. ВАЛИЕВ. Рецензия на книгу Х. Ширмана «От судьбы не убежишь».
«Память»: дневниковые записи Ф. ЯРУЛЛИНА.
«Наука»: Ф. ГАРИПОВА. «История наших деревень» (прод.).
Страницы из «Татарской энциклопедии».
«Рассказы из жизни» Р. ФАИЗОВА.
«Публицистика»: Р. ЮНУС. «Сплотимся!»
«Белый парус»: К. КАРИМОВ «Маленький Камиль»; стихи Д. НАГИМУЛЛИНОЙ.
«Наши юбиляры»: А. ХАСАНОВ. «Из книги жизни» (к 90-летию Гарафи Хасанова).
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятник Г. Тукаю в г. Москве; поэтесса Лена ШАГИРЗЯН.

# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and poetry»: novels by R. BATULLA «Apush—Tukay» (continuation); A. MUSHINSKY «Sheikh and astrologer» (continuation); N. KHASANOV «Violence» (continuation); poems by R. MINNULLIN, E. SHARIFULLINA, F. SUFIYAROV, I. DINDAROV.
«Hay Bazaar». Competition of satirical works.
«From treasuries of Tatar Stories»: G. SABITOV. «Troublous summer».
«Book Review»: M. VALIEV. Review on book be H. Shirman, «Fate of no escape».
«Memory»: diaries by F. YARULLIN.
«Science»: F. GARIPOVA. «History of our villages» (continuation).
Pages from Tatar Encyclopaedia.
«Stories from Life» R. FAIZOV.
«Journalism»: R. YUNUS. «Unite!»
«White Sail»: K KARIMOV «Little Kamil»; poems by D. NAGIMULLINA.
«Our jubileers»: A. HASANOV. «From book of life» (to 90th anniversary of Garafi Khasanov).
From photo archives of magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: monument to G. Tukay in Moscow; poetess Lena SHAGIRZYAN.

★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 01.06.2011, график буенча 01.06.2011.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Р–739. Тираж 4053.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтнең Татарстан буенча идарәсендә, 2010 елның 1 апрелендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ №ТУ 16-00337
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААҖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2011 ел



Роберт
Миңнуллин

# ИКЕ ТАМЧЫ КАЕН ЯШЕ

## Ярдәм ит миңа, Аллам!

**Бу дөньяның караларын
Мин генә агарталмам.
Каралган күңелләрне син
Ничек тә агарт,
Аллам!**

**Өстә куера болытлар...
Мин генә тараталмам.
Кап-кара болытларны син
Ничек тә тарат,
Аллам!**

**Туңган, өшегән җаннарны
Мин генә җылыталмам.
Җылыга мохтаҗ җаннарны
Ничек тә җылыт,
Аллам!**

**Таштай каткан бәгырьләрне
Мин генә йомшарталмам.
Таш бәгырьлеләр күбәйде,—
Ничек тә йомшарт,
Аллам!**

**Бу дөньяның бөкреләрен
Мин генә төзәталмам.
Синең генә кулдан килә—
Ничек тә төзәт,
Аллам!**

**Күпме генә тырышсам да
Дөньяны үзгәрталмам.**

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948)*—Татарстанның халык шагыйре, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар, шул исәптән 7 томлык «Әсәрләр» авторы. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

**Бу дөньяны яхшы якка
Ничек тә үзгәрт,
Аллам!**

**Исән чакта синең алда
Бурычлы булып калмам...
Дөньяны матурлыйк инде—
Ярдәм ит миңа,
Аллам!**

## Мулланур Вахитовка—
## һәйкәлгә һәм революционерга

*Казандагы Мулланур Вахитов һәйкәлен
башка урынга күчерергә җыеналар.*
(Газета хәбәрләреннән)

**Һәйкәлеңне алып атмакчылар
Ераккарак халык күзеннән.
Алып атмакчылар ул халыкның
Сорамыйча гына үзеннән...**

**Сиңа тагын кул күтәрмәкчеләр...
Кем хак түгелдер дә, кем хактыр?!
Сине бер кат аттылар бит инде,
Саттылар бит инде бер тапкыр.**

**Каберең чәчәк салыр идем,
Юк ичмасам синең каберең...
Кирәгең дә хәзер калмадымы?
Калмадымы тагын кадерең?**

**Һәйкәлеңне, димәк, үзеңне дә
Тарих чүплегенә ташлыйкмы?
Һәйкәлләрнең әллә калганын да
Шул чүплеккә ташый башлыйкмы?**

**Ул чагында бездән ниләр калыр,
Кемнәр калыр безнең милләттән?
Тарих безне тәк тә кыерсыткан,
Тарих безне тәк тә имгәткән...**

**Милләт өчен син бик кирәк идең,
Терәк идең безгә—татарга.
Сине менә алып атмакчылар...
Бу татарны кем дип атарга?!**

**Дәүләтчелек диеп, милләт диеп,
Татар каны күпме түгелгән...
Алып атсалар да һәйкәлеңне,
Алып аталмаслар күңелдән.**

**Егерме дүрт яшьлек һәйкәлеңә
Карап торам менә уйланып:
Милләтебез өчен горурланып,
Милләтебез өчен оялып...**

## Син көндез кил, Ирек, Казанга!

*Башкорт шагыйре Ирек Киньябулатовка*

**Син Казанга бик соң килеп төштең...**
**Андый хәлләр, әйе, булгалый.**
**Охшагандыр сиңа төнге Казан,**
**Төнге Тукай, төнге Кол Гали.**

**Төнге Сәйдәшне һәм Кол Шәрифне**
**Мин күрсәтми сиңа каламмы?**
**Төнге Казансуны, Кремльне,**
**Йә булмаса, төнге Кабанны...**

**Төнге Казан хәтерләтеп тора**
**Ханлык чәчәк аткан заманны.**
**Төнге Казан ул әкият кебек,**
**Яшерә ул күпме яманны.**

**Күпме хыял, күпме тылсым анә,**
**Күпме сагыш төн күзләрендә...**
**Төнге Казан—төнге Казан инде...**
**Казан гүзәл көндезләрен дә.**

**Бик популяр хәзер «Ирек» дигән**
**Синең исем Татар Илендә.**
**«Ирек» дигән сүз ул һәр татарның**
**Күңелендә һәм дә телендә.**

**Син кунакка килгәч, «ирек» сүзе**
**Ешрак кабатлана башлады.**
**«Казанга да Ирек килде» диеп**
**Пышылдады Казан ташлары.**

**Без иреккә хәтта һәйкәл салдык:**
**Була—барып башны исәк тә.**
**Син «Хөррият» дигән ул һәйкәлне**
**Үзеңә дә диеп исәплә!**

**Бездә хәтта Ирек мәйданы бар,**
**Яулап булмаса да ирекне.**
**Яулаган да кебек булган идек,**
**Шиңдерделәр бик тиз кикрикне...**

**Казан хәзер, юк, элекке түгел...**
**Ах, элекке булсын иде ул.**
**Татарныкы булып, татарымның**
**Моңы белән тулсын иде ул...**

**Тик барыбер безнең Казан әле**
**Татарныкы диеп атарлык...**
**Бик эзләсәң әгәр, аз булса да**
**Бар әле, бар бездә татарлык.**

**Мин шат булыр идем, Казаннан син**
**Татарлыкны күбрәк табалсаң.**
**Табарсың да әле—Казаныма**
**Башкорт күзе белән карасаң...**

Төннәрен дә, көннәрен дә күрдек—
Бар да килде безнең замангa...
Төнге Казан матур, ә шулай да
Син көндез кил, Ирек, Казанга!

## Бәйрәм

Бәйрәмнәрне көтү рәхәт,
Әзерләнү—ләззәт.
Көтәсең аны озаклап,
Көтәсең әз-әзләп...

Көн аралаш бәйрәм хәзер,
Бәйрәмгә без оста!
Тик шунысы, ни өчендер
Бәйрәмнәр бик кыска.

Юк, юк, озыннары да бар:
Атна, айлыклары...
Бәйрәмнәргә китеп бара
Илнең байлыклары.

Җырла да бие, күңел ач,
Аракыда коен!
Бәйрәм итүләре рәхәт,
Бәйрәмнән соң кыен...

Бәйрәм итәргә дигәндә,
Җаен без табабыз...
Бәйрәмнәрдән арынганда
Эшләп тә алабыз.

Иртән эшкә ашыгабыз
Торып көчкә генә...
Бәйрәмнәргә түзгән халык
Түзәр эшкә генә.

## Сандугачлар сайраганда...

Сандугачлар сайраганда
Кем шигырь яза инде?
Югыйсә, шундый матур таң,
Югыйсә, яз да инде!..

Сандугачларның телләрен
Ничек кенә аңларга?
Нигә өзгәләнә алар,
Нинди моң ул аларда?

Сандугачлар безнең иңгә
Килеп кунмас шул инде.
Сандугачны да уздырып
Язып булмас шул инде...

Сандугачлар сайраганда
Акылдан яза-яза,
Шагыйрьләр шигырь язалмый,
Шагыйрьләр телдән яза.

## Бездә...

*Кеше үзенең бөек икәнлеген*
*Каян белер иде үлмәсә...*

Ә. Атнабай

Талантларны яратмыйлар...
Сәбәбе бар, димәк ки.
Талантлылар болай да аз,—
Алары да кирәкми.

Талантлар талантсызларга
Комачаулый язарга.
Талантлылар бик күп булмый,—
Бирелә ул азларга.

Бездә бик талантлы булу
Тыйнаксызлык санала.

Бездә күбрәк урта куллар
Санлана һәм данлана!..

Бездә бит бар да бертигез,
Бар да «шәп», бар да «оста»!
Исәндә син талант түгел,
Ә үлгәч, пожалуйста!

Бездә үлгәннәр почетта...
Юк аның юлы башка:
Бик яраттырасың килсә,
Үләргә кирәк башта!

## Ике тамчы каен яше

**Үскәндә дә үстем бит мин**
**Каеннар кочагында.**

**Каеннар да минем кебек**
**Яшь иде ул чагында.**

**Малай чагым калды инде**
**Каен араларында,**

**Минем дә әрнүләрем бар**
**Каен яраларында...**

**Картайган инде каеннар,**
**Олыгайдым үзем дә.**

**Ике тамчы каен яше—**
**Минем ике күземдә.**

## Гөнаһ...

**Батып беттек гөнаһларга:**
**Тездән, билдән, муеннан!**
**Безнең бу гөнаһларыбыз**
**Узды бугай уеннан.**

**Гөнаһка баткан халкымны**
**Куям кайчак җәлләп тә.**
**Болай булса, озакламый**
**Татар калмас җәннәткә.**

* * *

**Сүзләрең көмеш булса да,**
**Дәшмәвең—мең алтын...**
**Шулай диеп өйрәттеләр**
**Безнең татар халкын.**

**Кирәктә дә дәшмәдек без,**
**Уйлап алдын-артын...**
**Күпме генә дәшмәсәк тә**
**Булалмадык алтын.**

## Бар бит ул!

**Бар бит ул Мәҗнүн шикелле**
**Ярата белүчеләр:**
**Мәхәббәт өчен берсүзсез**
**Утларга керүчеләр!**

**Утларда янган чакта да**
**Ярата алучылар,**
**Мәхәббәт утында янып,**
**Тарихта калучылар!**

**Мәҗнүндәй тагын берәрсе**
**Бар микән, дип сорагыз...**
**Әйтсәм әйтим: андый Мәҗнүн**
**Үзебез дип торабыз.**

*2009-2010*

Рабит
Батулла

# АПУШ—ТУКАЙ

КЫЙССА

**Чәйханә**

Чәйханә залы буш иде. Ишек катындагы өстәл янында ике ир кеше чәйханәче белән исәп-хисап өзеп маташа. Түрдә кеше күзеннән еракта, багана артындагы өстәл янында Тукай утыра. Аның алдында самавыр, кәләпүшен кырын салган приказчик сыман, чәйнеген кыегайтып куйган. Тукай куен дәфтәренә нидер яза иде. Башына берәр кызык фикер килсә, ул аны шундук кәгазьгә төшерә бара. Тукай бу чәйханәдә бик еш була, аның үз урыны бар, багана арты, чәйханәче ул урынга башкаларны утыртмый. Тукай урыны. Тукайның үзе яраткан ризыгы: бәрәңге сумсасы да сөтле куе чәй. Кайчакларда ул ялгызы гына кич буе шул урында утыра. Бер хәреф язмаган чаклары да күп була, кайчакларда ул самавыры суынып беткәнче яза да яза.

Шундый кичләрнең берсендә җенләнеп эшләп утырганда аны дуслары шушы чәйханәдә эзләп таптылар. Алар тыштан ук көлешә-сөйләшә, шаулап, чәйханәгә ишелеп килеп керделәр. Иң алдан Фатих әфәнденең арбасын этеп Мәхмүт, аның артыннан Сәгыйть Рәмиев, аның артыннан Исхак Бикчурин ияргән иде. Тукай эшеннән аерылып, кунакларга карады. Аның очлы күзеннән Сәгыйть Рәмиевтәге үзгәрешләр читтә калмады. Сәгыйть ябыккан, ул ике-өч көн кырынмаган, элеккеге фырт киенгән егетнең тасма муенчагы бөгәрләнгән, әллә ул бу арада чишенмичә йоклыймы? Шат күренергә тырышса да, Сәгыйтьнең елмаюы интегеп елмаю иде.

«Егетне эчтән нидер кимерә булыр!» дип уйлады Тукай.

Арттагы кеше—Исхак Бикчурин ишекне ябып керде. Анысы да әллә ничек интегеп елмайды кебек. Фатихның кәефе шәп иде, күренеп тора. Гомумән, авыру кешеләр кайчак сәламәтләреннән дәртлерәк, шатрак, үз күнелләрен үзләре юата беләләр. Дуслар Тукай өстәлен урап алды.

—Әйттем бит!—диде Фатих.—Аны йә чебенханәдән, яки чәйханәдән табып була, дидем.

—Малай!—дип кычкырды Сәгыйть.

Кухнә яктан чәйханәче чыкты.

—Тыңлыйм, әфәндем!—диде олан.

—Бер самавыр чәй!—диде Сәгыйть.—Монысы суынып беткән, алмаштырып китер!

*Ахыры. Башы 4нче санда.*

—Баш өсте, әфәндем!—дип малай Тукай алдыннан самавырны алды.
—Тагын барыбызга да талкыш кәләвә!
—Булыр, әфәндем!—дип олан китеп барды.
Беренче сүзне Сәгыйть Рәми кычкырды:
—Тукай!—диде ул, кочагын җәеп. Шагыйрь аның кочагына атылды.—Бөтен дөнья шаулый: имеш, Тукай хастаханәдә авырып ята. Ә Тукай җир җимертеп эшләп ята. Яшә, Тукай!
Фатих мәсьәләне шундук хәл итәргә теләгәндәй:
—Ул хәбәрне кем таратты икән?—диде.—Кем суккан андый телеграммаларны редакцияләргә? Уфага, хәтта Троицкига.
—Мин дә шул хәбәрне ишетеп йөгереп килдем,—диде Сәгыйть Рәми.
—Төкер башына!—диде Исхак Бикчура.—Кем сукса да, бер түгелмени? Ялгышкандыр... бәрәрсе...
Чыннан да, Исхакның бу сүзләре сөйләшүне, көрәшүне икенче якка борды. Сәгыйть кесәсеннән бер кочак гәзит-журнал чыгарып:
—Менә нәрсә җитми иде бу көннәрдә безгә!—дип кычкырды.—Менә нәрсә кирәк иде халыкка! Тукай кирәк иде. Усал Тукай кирәк иде. Әнә, гәзит-журналларга чират. Талаша-талаша алалар. Мин гомер буе татар талашканга каршы булдым. Ә менә бүген татарның талашканын күреп сөендем. Талаша татар, белем өчен талаша, фикер өчен талаша. Алалар, һәр санын зарыгып көтеп алалар. Болай булгач, яши халык. Без яшибез!
—Яшә, Зөбәйдә, яшибез без дә!—диде Исхак Бикчура ясалма тантана илә. Сәгыйть Рәминең «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин» пьесасына үзенә күрә бер тәнкыйть шикелле ишетелде бу сүз. Шуңа күрә, барысы да сагаеп калды. Урамда гына ияргән Исхак Бикчураның мәшһүрләр алдында шулай төртмә телле булуын Тукай өнәп бетермәде. Шулай да дәшмәде, чөнки Исхакның сүзе бетмәгән иде әле.—Үзегезне үзегез алдамагыз,—диде Исхак, ул бераз кызмача иде, ахрысы.—Шулкадәр дә беркатлы булмагыз сана, әфәнделәрем. Хаста адәм үләр алдыннан сәламәтләнгәндәй була. Торып йөри. Ашарга сорап ала. Ашый-эчә, сәламәтләндем, дип куана да... ятып үлә. Үлем җәрәхәте алган атны атып үтерәләр яки чалып калалар, әфәнделәрем. Бу—миһербанлылык. Хайванның сызлануын озакка сузмас өчен шулай кылганнар ата-бабалар. Ә сез гәзитләрегез, журналларыгыз белән үлем җәрәхәте алган татарны яшәтмәк буласыз. Интекмәсен, тизрәк үлсен милләт! Ябыгыз журналларны! Бетсен татар!
Исхак Бикчура бүлмәгә кергәндә ап-аек кебек иде. Бүлмә җылысы изрәттеме, ул бүген, гауга куптарырга теләгән кеше кебек, артык төртмә иде.
Аның ияргәненә урамда ук ризасыз булган Сәгыйть Рәми түзмәде, мәҗлес бозучы Исхакка карап:
—Ул гәзитләр синеке дә түгелмени?—диде.—Син кем соң? Яһүдме, урысмы, алманмы?
—Мин ваз кичтем бар нәрсәдән!—диде Исхак.—Юк без! Беттек. Ноль!
Фатих та бу сөйләшүдән канәгатьсез иде, ул:
—Милләт бетмәсен өчен эшләргә кирәк, җегетем,—диде.—Эшләргә, янарга кирәк. Сафсата сатып, җылап йөрүдән, аракы эчеп мескенләнүдән милләт тәрәккый итмәс. Татар халкының уллары синдәй булса, әлбәттә, милләт бетәчәк.
—Сез ни эш кырдыгыз соң әле, әфәнделәр!—дип кычкырды Исхак.—Сездәй уллар күп булганнан ни файда? Без тозакта. Без кире чыкмаслык тарлавыкта. Неужели сез шуны аңламыйсыз?
—Адәм соң чиккәчә үлем белән тарткалаша. Соң чиккәчә тормышка, яшәешкә тырнаклары, тешләре белән ябыша. Бу табигый. Халык та шулай. Үз эчендәге бөтен мөмкинлекләрен сарыф иткәннән соң гына халык үләргә

мәхкүм. Татар халкы, әфәндем, көрәшчеләргә бай. Син көрәшмәсәң, башкалары табылыр.

Фатих Әмирханның бу сүзләре Исхакны тагын да өстерде:

—Бай! Байлар бай!—диде ул.—Алары да берән-сәрән. Алары да надан. Алары да урыстан куркып, намазга тәһарәтсез йөри.

—Куй бу эшеңне, жегет!—диде Фатих.—Ташла җылавыңны. Синдәйләр коткы тарата. Синең кебекләр халык арасында курку өләшә. Без эшләгәннәрне сездәйләр юкка чыгара бара. Тугыз корбан суеп алган теләгебезне синең кебек мәми авызлар бетерә бара.

—Кем инде ул—сез? Бумы?—дип Бикчура Сәгыйть Рәмигә төртте дә ясалма көлә башлады:—Шушы сагышлы шагыйрьме? Беләбез... беләләр аның кем икәнен...—Исхак артык тирәнгә кереп киткәнен аңлады ахрысы, сүзне икенчегә борды:—Ул миннән дә җылаграк. Шигыре саен бер пот күз яше... Тукаймы? Тукай—ул Тукай. Бөек Тукай. Әмма аның бөеклеген күрсәтер өчен җирлек юк. Киң мәйдан юк. Халык юк. Зыялылар юк. Русиянең бөтен авыр эшен башкаручы ишәк-татарлар өере бар. Милләт юк. Булган зыялылар Төркиядә, Кытайда, Финляндиядә, Америкада...

Аның сүзләре дөрес иде, бар да тын калды, Исхак та йомшады, шәлперәя төште. Сәгыйть Рәми аның янына килеп, иң өстенә дусларча кагылып:

—Син бүген артык салгансың,—диде. Исхак инде кычкырмый, аның йөзе җитди, ул елар дәрәҗәдә иде.

—Коточкыч рәхимсез цензура!—диде ул хәлсез тавыш илә.—Матбугат мәче тырнагындагы тычкан кебек. Кыймылдарга да урын юк. Бу озакка бармас, дип уйлыйсыз. Бу катылык бер бушар, дисез. Беркайчан да татарга ирек булмаячак. Вакыт узган саен кысыш катырак булачак!

—Әфәндем Исхак!—диде Тукай кырыс итеп.—Бу бүлмәгә кереп, тагын бер тапкыр балавыз сыксаң, мин сиңа дус түгел!

Исхак кинәт айнып китте сыман, ул бер Тукайга, бер Сәгыйтькә, бер Фатихка карап:

—Карале, ни кыланасыз сез, ә?—диде.—Бусы миңа акыра. Тегесе миңа жикерә. Минем ни гаебем бар соң?

Фатих Әмирхан да кискенлеген киметеп, ярым юмалаган кебек:

—Кая китте синең дәртең, Исхак!—диде.—Кая соң синең яшьләрне әйдәп сөйләгән нотыкларың? Кайда ул Исхак Бикчурин? Элек, халык, халык, дип кычкырып йөрүчеләр авызларына су капты. Халык углының сыйфаты, зыялылыгын сынау дәвере бу, әфәнделәр. Рөхсәт булганда бар да кычкырды: татар—ул бөек милләт, татар халкының узганы шанлы, бүгенгесе—ренессанс, киләчәге—сәгадәт, диде. Кая очты ул дәрт? Менә хәзер эшләргә кирәк. Кычкырырга түгел, борын белән җир сөрергә вакыт. Гакылыңны, тәнеңне тулаем халыкка хезмәткә бирергә.

—Сез күп нәрсәне белмисез,—диде Исхак тыныч кына.—Шәһәр тулы шымчылар.

—Авылга кач!—диде Фатих.—Авылда да эш бетмәгән. Балалар укыт. Клублар оештыр.

—Һәр авылның бар үзенең Ишми ишаны,—дип, Исхак әкрен генә торды, беркемгә карамыйча гына:—Мин дә бит халык мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүче бәндә,—диде дә ишеккә таба атлап:—Их, сез, аңламадыгыз!—диде дә чыгып китте.

Бүлмәдә мәет чыккан кебек бер мохит урнашты.

—Җылап китте,—диде Сәгыйть Рәми.

—Җыласын!—диде Тукай кискен.—Аңа шул кирәк.

—Таркалабыз!—диде Фатих Әмирхан.—Тарката безне реакция. Дошманнарга, теге йорттагыларга безнең үзара талашуыбыз, таркалуыбыз бәйрәм.

Сәгыйть сүзне икенчегә борырга тырышып:

—Котлыйм, Тукай!—диде.—Син кин колач белән тагын эшкә тотындың. Көнләшәм мин синнән, дустым. Көчле шәхес син, Габдуллаҗан.

—Бер шәхес кенә берни дә эшли алмый, Сәгыйть,—диде Тукай.—Йодрык кирәк. Тыгыз, какшамас йодрык кирәк. Син дә читтә йөрисең. Авыруым турындагы ялган хәбәрне ишетмәгән булсаң, бәлки, килмәгән дә булыр идең.

Сәгыйть Рәми тирән итеп көрсенде дә:

—Их, Тукай...—дип сүзен өзде.

—Ни булды?—диде Тукай.

—Болай гына...—Сәгыйть янә тирән сулыш алды.—Читтә йөреп-йөреп тә еш килә башлаганнардан сак булыгыз,—диде.—Заманасы шундый...

Тукай Сәгыйтьнең эчтәге, яшерен исәбен сизенеп, ана ярдәм итәргә теләгәндәй, якын килде, иңнәренә кулын салды:

—Нигә язмыйсың син, дустым,—диде.—Син бит шагыйрь. Коеп куйган шагыйрь. Миңа синең шигырьләр җитми. Синең җәүһәрдәй камил, хисси шигырьләреңне сагынам мин. Хәер, мин генә түгел, халык сагына.

—Нигә кирәк? Кем әйтмешли, минем пессимистик шигырьләремнең кемгә кирәге бар?—диде Сәгыйть Рәми.—Халык аңламаслык шигырьләр язасың, дип мине ышандырдылар инде.

—Һәр өргән эттән курыккач, син чыннан да язма!—диде Тукай.—Үл син! Яки мулла булып, әнә Уфага кит.

Сүзгә Фатих Әмирхан кушылды:

—Халыкка ни кирәген беләме алар?—диде.—Андыйлар өчен Тукай да кирәк түгел. Яз син шигырь, аны бастыр. Бастыра алмасаң, астан тарат. Халык үзе сайлар, кирәкме аңар синең шигырең, әллә юкмы?

Сәгыйть калыкты, дусларының йөзләренә бакмастан, шулай башын игән килеш:

—Ярый, хушча калыгыз, дуслар!—диде дә чыгып китте.

Бүлмәдәгеләр сәер халәттә калды.

—Монысына ни булган тагын?—диде Тукай.

—Эчендә нидер бар җегетнең!—диде Фатих.

—Эче тулы сагыш аның. Шәп шагыйрь. Тукайдан алда әнә кем ул саф шагыйрь!—диде Тукай.

—Бөек түгел ул,—диде Фатих.—Бөек шагыйрь. Юашлатты аны заман... Ярый, күрше, мин дә кузгалыйм. Мәхмүт!

Мәхмүт, тәрәзә төбендә китап укып утырган җиреннән атылып килде дә, арбаны этеп, чыгып китте.

Тукай, бер ишеккә, бер түргә барып, җанын кая куярга белмәгәндәй йөренде:

—Бар да серле сөйли! Барысының да йөзендә хәвеф. Кемдер мине хастаханәдә күрергә тели. Мохитемдә ниндидер шомлы җәтмә үрелә түгелме соң? Бу турыда барысы да белә кебек. Белә, миңа гына әйтмиләр сыман...

## Серле гүзәл

Тукай дусларыннан аерылуга япа-ялгыз кала. Сәламәт чакта булса, ул дуслары килмәгәнгә пошына башлый. Ул аларны үзе эзләп чыгып китә. Авыруы килә башласа, дусларыннан качарга тырыша, ялгыз калуны мәгъкуль күрә иде.

Ул җиңелчә генә йөткереп алды, почмактагы кисмәктән су алып эчте... Ютәл тагын килде. Тукай шактый сизелерлек итеп ютәлли башлады. Ниһаять, ютәл китте, ул эшкә утырды, ләкин каләм аңа буйсынмады. Шул-

чак ишек шакыдылар. Рөхсәт ишеткәнче үк ишек ачылды, бүлмәгә чадра бөркәнгән бер хатын керде.

—Рөхсәт итсәгезче, Тукай әфәнде!—диде әлеге хатын.

—Узыгыз!—диде Тукай.—Сез Мәфрузә түти асравымы? Узыгыз!

—Юк!—диде чадралы хатын.—Мин Мәфрузә тутагыз асравы түгел. Мин бөтенләй башка зат. Сез көткән кеше түгел мин.

—Тыңлыйм сезне, туташ!—диде Тукай.

—Ханым!—дип төзәтте аны чадралы.—Ханым диеп дәшегез, Тукай әфәнде.

—Тыңлыйм сезне, ханым-әфәнде!—дип Тукай үз урынына урнашты.

Чадралы хатын шулай ишек катындарак кала бирде.

—Бу маскарадым өчен гафу итегез, Тукай әфәнде. Мин шулай бөркәвеч ябынып килергә мәҗбүрмен.

—Алайса, сез йә бик чибәр. Йөз нурыгыз минем икенче күземне дә сукырайтмасын, дип чадра яптыгызмы?—диде Тукай.—Яки сез—дөнья ямьсезе. Чыраемны күреп, кешенең коты очмасын, дип шулай яшерендегез.

Тукайның ярымшаяруы, кырыс шаяруы ханымга көчле тәэсир итте, ул:

—Аh, сез усал Тукай!—диде.—Өченче сәбәп мине яшеренергә мәҗбүр итә.

Чадралы хатын, бүлмәдә башка кеше юкмы, дигәндәй карангалап алды.

—Курыкмагыз,—диде Тукай.—Мин ялгыз.

Хатын түргә узмыйча, шулай читтәрәк кала бирде һәм сүзгә күчте:

—Тукай әфәнде,—дип башлады ул.—Зинһар, кызмагыз, ачуланмагыз бичара бер хатынны. Мин сезнең китапларыгызны кат-кат укыйм. Шигырьләрегезне укып егълыйм. Сезне күреп белергә ни гомер хыялландым. Әмма мин иректә түгел. Никахтагы хатын мин. Сезне күрү хыял була килде. Ниһаять, мин шушы ысул белән сезне күрү бәхетенә ирештем. Зинһар, шушы китапларга истәлек имзагызны салыгыз...

Тукай иркен сулап куйды. Йомыш ул үтәмәслек түгел иде. Ханым чадра астыннан китаплар чыгарды, өстәлгә куйды. Тукай китапларны алды, ул:

—Кемгә диеп языйм соң, ханым?—диде.

—Алтаң туташка, дип языгыз. Алтаң туташка.

Тукай яза-яза:

—Алтаң туташка, «Алтаң»—матур исем, әгәр дә...

—Борчылмагыз, Тукай әфәнде,—диде кунак хатын.—Алтаң минем сенлем.

Имзалар салынып беткәч, хатын рәхмәт әйтте, ләкин китәргә җыенмады. Тукай, соңгы имзаны куюга ук:

—Хушыгыз, ханым!—диде. Чадралы хатын өстәл янынннан кузгалмыйча:

—Килүемнең төп сәбәбе бу түгел иде...—дип куйды.—Имза алу сылтау гына. Зинһар, мине тынлап багыгыз, әфәндем. Мин сезнең иҗатыгызны читтән генә күзәтүче түгел, мин сезнең химаячегез булырга телим, Тукай.

Тукай урынында кала бирде, ләкин аның карашы да, тавышы да сагаюлы иде:

—Мин әле бернәрсә дә төшенмәдем.

Ханым Тукайдан бераз читкәрәк китеп, озын-олы сүз сөйләргә җыенган кеше кебек, бер позага басты:

—Сез зур талант!—диде ул.—Күп гасырларга бер генә туа ала торган даһи сез!—Ләкин сезнең кадерне белүчеләр юк. Булганнары үзләре кемнеңдер ярдәменә мохтаҗ. Сезнең талантыгыз үзегезнеке генә түгел. Сез тулаем халыкныкы. Шуңа күрә, сезне аеруча сакларга, иркәләргә, үстерергә кирәк. Сез Руставелилар, Фирдәүсиләрдән бер дә ким түгел, әфәндем. Нигә сезгә дә мәйдан тотмаска!

Тукай тамак кырып куйды. Ханым моны үзенчә шәрехләде: мин мәйдан тотам бит инде, димәкче иде Тукай. Ханым аннан алда өлгерде:

—Дөрес, сез мәшһүр! Ләкин татар халкы эчендә генә! Сез һичнинди мохтажлык күрмәенчә, ипи-тоз, торак-фатир турында уйламыйча, бары тик иҗат белән генә, бары тик әдәбият белән генә, бары тик халык язмышы белән генә яшәргә тиеш. Ташлагыз журналларда ми черетеп утыруыгызны. Ташлагыз пароход-сабын рекламаларыгызны. Сезгә заказчы хуҗа кирәкми. Сез үзегез хуҗа. Тукайның көчен юкка-барга сарыф итәргә кемнең дә хакы юк. Вак эшләрегезне йөртер өчен сезнең үз адвокатыгыз, йорт эшләрегезне карарга сезнең үз хезмәтчеләрегез булыр. Сез даһи шагыйрь, иҗат итегез! Калганы минем эш...

Үзенең каршысында шактый мәгълүматлы, шактый заманча тәрбия алган татар хатыны торганын Тукай аңлады, аның зиһен түрендәгеләрнең барысын да әйтеп салды бу серле ханым.

—Менә хәзер аңлый башладым инде, сез—Фон-Мек!—диде Тукай. Хатын җанланып алды:

—Котлыйм! Афәрин! Браво, Тукай!—диде ул шат аваз белән.—Мин ялгышмаганмын. Сез хәбәрдар шагыйрь. Дөрес, мин Фон-Мек кебек сезнең химаячегез булырга телим... Шикләнмәгез, Тукай. Менә, алайса, мин кемлегемне сезгә ачарга мәҗбүрмен,—дип ханым чадра астыннан Тукайга балдагын сузды, Тукай балдакны алып, андагы язуларны укыды:

—Могҗиза!—диде Тукай.—Сез тайный советник Әхтәмов кызы? Ханым:

—Тсс!—диде.—Бу балдак сезгә булган хөрмәтем һәм мәхәббәтем билгесе! Алыгыз!

Тукай балдакны тиз генә иясенә сузды:

—Кичерегез, ханым, мин бүләкләр алырга күнекмәгән!

Хатын теләр-теләмәс кенә балдакны Тукай кулыннан алды да:

—Сезнең тәкәббер икәнегезне мин яхшы беләм,—диде.—Балдакны кулыгыз белән алмасагыз, өстәлегезгә куям. Икенче балдак миндә кала. Балдакта тагын язу бар, укыгыз!

Тукай өстәлдәге балдакны әйләндереп бакты:

—«Мөгайдине ишетеп белүгә караганда...»

—«... күреп белү яхшырак»,—дип өстәде ханым.—Икенче өлеше бу балдакта, миндә калачак.

Тукай балдакны тоткан килеш аптырап утыра калды, ханым бу сөйләшүнең хуҗасы иде:

—Сезнең яраткан сүзегез: «тәсмагы бин Мөгайди хәйрен мин ән тәраһе». Мөгайдине күреп белүгә караганда ишетеп белү яхшырак. Ә мин ике балдакка бүлеп, үземчә: «Мөгайдине ишетеп белүгә караганда күреп белүең яхшырак», дип яздырдым. Дөрестән дә, сезне күрү минем өчен зур бәхет. Берсе сездә, берсе миндә калыр балдакларның. Мин чыгып киткәч, теләсәгез, тәрәзәдән атыгыз. Хәерчеләргә бүләк итегез, әмма минем алда кире какмагыз, зинһар... Бу—минем олы үтенечем. Мин сезнең дустыгыз...

Тукай һични әйтмәстән тик утыра калды, ләкин аның уй-фикерләре сабырсыз иде, ул пәрәнҗәнең йөз тирәсенә, күз турысына багып алды, челтәр пәрдә артындагы күзләр дә аны җентекләп күзәтә иде, бу каракучкыл караш шагыйрьне кыен хәлгә куя, пәрдә артында сер вә шом бар кебек. Котәргә кирәк иде, хатын әле сүзләрен әйтеп бетермәде.

—Уйламагыз,—диде ханым басынкы, әмма гайрәтле тавыш илә.—Мин ире өстеннән йөрүче хатын түгел. Ирем минем хөрмәткә лаек. Ләкин ул минем җанымны аңламый. Ул эш кешесе. Ул миллионер. Фәкать шик вә

шөбһә килмәсен күңелегезгә: мин ирем акчасына сезгә химаячелек итәргә җыенмыймын. Үз акчама. Тарсынмагыз, ярдәмемнән баш тартмагыз!

Ниһаять, Тукай сүз кыстырырга вакыт җиткәнен аңлады:

—Ханым-әфәнде,—диде ул сабыр һәм каты итеп.—Хатын-кыз хисабына яши торган сутенер түгел бит мин. Сез мине рәнҗетәсез.

Ханым алга омтылды, Тукайга якынрак килде дә, дәртле теләк илә:

—Зинһар, рәнҗемәгез. Чайковский рәнҗемәгән бит. Урыс музыкасының җаны, бөек Чайковский Фон-Мек хисабына иҗат итәргә тартынмаган, оялмаган,—диде.—Цель оправдывает средства. Иҗат азатлыгы кыйммәтрәк, тәкәбберлеккә караганда нәтиҗә кыйммәтрәк түгелмени, Тукай! Фон-Мек булмаса, Чайковский шундый бөек әсәрләр иҗат итә алыр идеме икән? Юк, әфәндем!

Озынга киткән бу сөйләшү инде Тукайның эчен пошыра башлаган иде, ул сүзне кырт кисәргә уйлап:

—Ханым, сүз бетте!—диде.—Мин сезнең тәкъдимегезне кабул итә алмыйм, кичерегез.

Тукай кискен рәвештә урыныннан торып, тәрәзә янына килде, таныш түгел ханымга аркасы белән басты. Ханым исә аңа таба бер-ике адым атлап, сүзен дәвам итте:

—Тукай җаным, сезнең каршыда җүләр хатын түгел. Миңа талант кына бирелмәгән, мин халыкның җаны булыр идем, мин максатлы хатын. Идеягә табынып, үзен-үзе корбан итә ала торган шәхес мин, Тукай. Халыкның җаны булган Тукайны саклый алам мин. Тукайны матди мохтаҗлыктан, вак мәшәкатьләрдән коткара алам. Кызганыч, капитал дөньясында бары тик капитал гына иҗат кешесенә азатлык бирә ала...

Бүлмә хуҗасы чакырылмаган кунагына һаман аркасы белән кала биреп:

—Капитал сүзен ишетсәм, үрле-кырлы сикерә башлыйм,—диде.—Юк, ханым-әфәнде, мин капитал белән бер союзда тора алмам. Аннан соң шул, мин акчага мохтаҗ кеше түгел, ханым. Дөрес, минем кесәмдә акча озак торырга теләми, чыга да кача. Капитал сөймәгәнгә күрә шулай озак тормый ул миндә. Бар чагымда мин бүредәй, юк чагымда шүредәй. Шулай яшәве рәхәт. Акчам бар чагында барчасын сыйлыйм. Булмаса, бурычка эзләп йөрмим.

—Альтруист сез, Тукай,—диде ханым.

—Дөрес, мин альтруист,—диде хуҗа да.

—Сездән акча алалар, кайтарырга онытыралар. Сез аны сорап йөрмисез. Бу бит ялкауларны, жуликларны узындыру. Сезнең бу яхшылыгыгыз комсызларны, кеше хисабына яшәүчеләрне генә арттыра. Алар сезнең акчаны ашап бетергәч, сезне сүгеп йөри башлый. Бүлмәгездән әйберләрегезне урлап саталар.

—Сатсыннар. Кара савытын гына урламасыннар. Кара савыты белән каләмемне алсалар гына җенем чыга.

—Кеше ярдәмен кабул итмәвегез һич кирәксез тәкәбберлек, шагыйрь әфәнде. Җинегез сез ул тәкәбберлекне. Җинегез дә рәхәтләнеп иҗатка чумыгыз. Сезгә берни комачауламас. Сезнең нинди малга яшәгәнегезне һичкем белмәс. Хатын-кыз химаячелеге сезнең ирлек горурлыгыгызга тисә, язып барырсыз. Үзегез акчалы булгач, кире кайтарырсыз.

Тукай бераз йомшады кебек, ул әкрен генә ханымга таба яны белән борылды, бу юлы шикле кешегә түгел, дустына әйткәндәй ышандырырга тырышып:

—Сез акыллы хатын,—диде.—Сез кешене ышандыра аласыз. Ләкин сез мине һаман аңламыйсыз кебек. Минем кире холкым моңа ризалаша алмый!

—Ә Чайковский?—диде ханым.—Потомственный интеллигент Чайковский, идея өчен, музыка өчен, горурлыгын җинеп, Фон-Мек химаясен кабул иткән ләбаса!

—Чайковский шуннан башка юл күрмәгәндер,—диде Тукай.—Ә минем юлым бар: халык юлы. Кичерегез, мине эшем көтә.

Тукай эш урынына барып утырды, каләм алган булды, ләкин һични яза алмаячагы көн кебек ачык иде. Ханым ишек катына кире килде, кинәт Тукайга йөзе белән борылды һәм каты, янаулы тавыш белән болай диде:

—Хатын-кыз үзе килеп, ир-егеткә тәкъдим ясаса һәм отказ алса, мәңге дә гафу итми, Тукай әфәндем! Хатын-кыз үч ала башлый. Хатын-кыз интрига кора белә. Мин тайный советник кызы, мин миллионер хатыны. Мин корган тозактан ычкыну мөмкин булмаячак!

Тукай кинәт көлеп җибәрде, алачага төренгән билгесез хатынның шундый янаулы сүз әйтүе көлке бер шәй иде, тайный советник кызы, ирдәге хатын Тукай кебек иректе-азат кешегә ни зыян сала алсын икән?

—Тәкъдимегез ихлас булса, сез беркайчан да пычрак эшләр белән шөгыльләнә алмассыз. Тәкъдимегез астында мәкер, шәхси бер дан ярату ятса, әлбәттә, отказдан соң сез җәтмә кора башлаячаксыз. Әмма, ханым-әфәнде, мине бернәрсә дә куркыта алмый. Ярлы кеше янудан курыкмый.

Хатынга нидер булып алды, ул ярсып:

—Сез мине җиндегез, Тукай!—диде дә бөркәвечен салып, Тукай ятагына ыргытты, бөркәвеч астыннан яшь, гүзәл бер хатын килеп чыкты. Аурупа хатыннары кыяфәтендәге бу ханымга саф энҗе-калфак аеруча бер үзенчәлек, шәрекълек-татарлык биреп, тагын да матурайта иде. Әкият каһарманы кеби Тукай соклану вә каушау халәтендә калды. Ханым «җиндегез» дисә дә, җинүче кыяфәтендә иде. Ул театраль бер позага басып, бераз өстәнрәк Тукайга бага, аның бу карашында: күр, Тукай, син нинди дөнья гүзәленә багу бәхетенә ирештең, дигән мәгънә чагыла кебек. Тукай соклануын яшерергә дә теләми иде, чөнки бу гүзәллеккә сокланмаган кешенең зәвекъ бизләренә ат типкән булмыш кирәк.

—Беләм,—диде Тукай.—Тайный советник Әхтәмов кызы Гәүһәршадны сорап хәтта генерал-губернатор үзе йөргән, диләр. Мин губернаторны бик яхшы аңлыйм. Сездән килгән отказ аны ярты бәхетсез иткәндер.

—Губернаторның энесе полковник Шаитовка!—диде ханым.

Тукай катлаулы халәттә иде. Алдында гүзәлләр гүзәле, бриллиантка, энҗегә төренгән яшь хатын басып тора. Кемгә эләгә бу могҗиза-и шәриф? Әмма ул гүзәл кеше никахында. Никахлы булмаганда да Тукай бу биеклеккә менәргә алынмаган булыр иде. Гомер кыска. Шуңа күрәдер дә, ул, кәнфитләнеп тормыйча, шактый кыю һәм төртмә халәткә күчте:

—Тукай губернатордан да, миллионердан да, полковниклардан да олырак булып чыктымыни?—диде, күзләре көлмәсә дә, ул ирен кырыйлары белән елмая иде.

—Көлмәгез, Тукай!—диде ханым ихластан.—Сез мине түбәнсетә аласыз, сез мине куып чыгара аласыз, ләкин ихласлыгыма шик белдерергә сезнең хакыгыз юк!—Ханымның тавышы кинәт калтыранып алды. Вакыйга җитди төс ала башлады бугай. Ханым Тукайга яны белән борылды, җин очыннан һава кеби җинел кульяулык килеп чыкты. Ханымның күңеле тулган иде.

Тукай аны юатырга да, төрттереп әйткән сүзе өчен гафу сорарга да белмәде. Ярый әле ханым беренче булып авыз ачты:

—Мин бит сезнең дәвамыгыз, Тукай. Сезнең шигырьләр миндә милли горурлык уятты. Мин бит гимназиядә, курсларда урысча тәрбияләнгән кыз. Мин, татар беркайчан да әдәбиятлы, мәдәниятле була торган халык түгел, дип үскән кыз. Аңсыз бер кыздан фида булган мөрәүвәтле бер җан ясаучы ул

сез! Бүгенге көндә мин татар халкының бүгенгесе, киләчәге турында уйланыр дәрәҗәдә сездән тәрбия алган хатын. Аны уянган, халык өчен хезмәткә атлыгып торган үз шәкертегезне сез читкә куасыз. Шушымы гаделлек, Тукай?

Тукай тагын аптыраштa калды, ханымның ихласлыгында аның шиге калмады. Ул бары тик башын аска иде. Ханым ярсып аңа таба атлады:

—Алайса, ни өчен, ни өчен кирәк булды сезнең ачыргаланып татар кызын, татар хатынын уятырга, шәхес итәргә тырышып кычкыруыгыз? Ни өчен? Сез мине дөньядан биниһая канәгать бер бай кызы, дип уйлыйсыздыр, мөгаен. Маена чыдаша алмыйча, үзенә бөек яр эзли чыккан, авызлыксыз хатын, дип уйлавыгыз да ихтимал. Ә мин укытучыма, остазыма ярдәм сорап килдем. Сез түгел, мин ярдәмгә мохтаҗ, Тукай. Мин дә, остазым Тукай кеби, татар халкы өчен хезмәт итәргә дип җан атам.

Ханым туктады. Тукай да уйчан халәттә иде. Хәзер соңгы сүз шагыйрьдә икәне ачык. Ханым күз яшьләрен Тукайга күрсәтмәс өчен борылды. Тукай, әкрен генә килеп, аның янына басты, ханымның иң өстенә кагылыр-кагылмас орынып, шик калдырмаслык итеп әйтте:

—Кичерегез мине, ханым-әфәнде,—диде.—Сезнең саф күңелле булуыгызда зәррә кадәр дә шигем юк. Әмма... мин сезнең химаягезне кабул итә алмыйм.

Ханым нидер әйтергә дип Тукайга борылды, ләкин хуҗа аның теләген кисте:

—Сорашмагыз, зинһар!—диде шагыйрь ачынып.—Сез моны тиздән аңларсыз. Ләкин үз телемнән әйттермәгез, үтенеп сорыйм сездән!

Тукай кинәт ханымнан борылып, янә тәрәзә янына китте. Ханым шагыйрь тавышында әйтеп аңлата алмаслык бер сагыш аһәңе тойды һәм, чыннан да, кабат сүз куертуның артык икәнен аңлады. Ул шагыйрь янына килде, нәкъ бая Тукай эшләгәнчә, кулын шагыйрьнең иңенә тигерде дә:

—Рәхмәт!—диде, аның тавышы сабыр, буйсынган, ризалашкан хатынныкы кебек иде.—Рәхмәт, Тукай! Ихласымны җиргә салмаганыгыз өчен рәхмәт, остаз!

Шулчак ханым икенче балдагын салып, Тукайга сузды:

—Алыгыз, Тукай!—диде ул.—Алыгыз, хәзер аның миңа кирәге калмады. Тулы җөмлә булып икесе дә сездә калсын: Мөгайдине ишетеп белгәнгә караганда күреп белү яхшырак!

Ханым балдакны өстәлгә куйды. Өстәлдәге китапларның берсен алып, янә Тукай тарафына атлады:

—Әрсезлегем өчен гафу итегез, Габдуллаҗан, бу китабыгызны миңа бирегез, зинһар,—диде ул.

Тукай аның кулыннан китапны алып, язу өстәле янына килде, каләм алды. Ханым:

—«Гәүһәршад ханымга» дип тутырып языгыз!—диде. Тукай яза-яза:

—«Хөрмәтле Гәүһәршад ханым-әфәндегә ихластан бәхет теләп калучы...»—дип имзасын куйды.

Китапны Тукай кулыннан алганда ханым сагышлы елмайды. Бу елмаю елауга бәрабәр иде.

—Рәхмәт!—диде ханым.—Хушыгыз, Тукайҗан... мәңгегә!

## Бәке

Чатнама суык кыш килде. Кабан күлен боз каплады. Ялтырап торган боз өстәндә бала-чага тәтке шуа, Татар Бистәсе ягындагы таучыктан чана шуалар. Тора-бара бозны калын кар каплады. Тәтке шуучылар юкка чыкты. Алар таудан чана шуарга йөри башлады.

Кабан күлендә бәкеләр күп иде, электр ыстансаны янында ике бәке, Мәрҗани мәчете каршында өч бәке, аргы башта тагын өч бәке ачканнар. Шул бәкеләрнең берсендә яшь килен кер чайкый иде. Нәни бала, яшь хатынның кызы булса кирәк, кер чайкаучыга ярдәм итә, чайкалган керләрне агач тагаракка пөхтәләп куеп бара. Эше беткәч, хатын белән кызчык тагаракларын кул чанасына салып, кайтып киттеләр.

Аларга каршы шул ук сукмактан иңнәренә көянтә-чиләк аскан тагын бер яшь хатын килә. Ул аргы бәкедән су алып, салмак кына өенә таба атлады.

Тауда бала-чага чыр-чу килә.

Ерак Кабан тарафыннан ике ир килә. Аларның берсе Тукай, икенчесе—Исхак Бикчурин иде. Алар икесе дә кызмача, кунактан кайтып килүләредер, мөгаен. Исхак артык кычкырып сөйләшә. Тукай исә аны тыңламый да кебек, ул тау шуучы балаларга бага, су ташучы киленнәрне күзәтә иде. Аһ, гүзәл киленчәк! Кара, бәбәйтәкле озын күлмәге астыннан ап-ак киез итекләре күренеп куя, бишмәте өстеннән сузылган толымнарында талир тәңкәләр атына, чөеп бәйләгән матур яулыгы иң өстен каплаган, битен суык үпкән, ут янып тора. Атлавына баксаң! Суның тамчысын да чайпалдырмыйча йөзеп бара иде киленчәк.

Исхак Тукайның ни белән мәшгуль булганын аңлап, ирен кырыйлары белән елмайды:

—Шәп! Шәп, шайтан алгыры!—диде Исхак Тукайның иңенә сугып.—Әмма да ләкин тегесе моннан да шәбрәк иде, каналья!

Тукай сагаеп калды:

—Син ни турында сөйлисең ул, Исхак?—диде.

Исхак сер әйткәндәй, киная белән:

—Теге...—диде.—Чадралы ханым, синең бүлмәңә килгән... Аһ, ул гүзәл!—Исхак кыткылдап көлде.—Аһ, ул яшерен күрешүләр... Маскарад-с, Тукай әфәнде! Комедия маск, извольте!

—Дәшмә, Исхак!—диде Тукай.

—Серле, сихерле дамалар... Крамскойның «Таныш түгел ханым»ыннан сикереп төшкән оригиналь натурщица...

—Шамакайланма, Исхак!—диде Тукай кырыс кына.

Исхак аклангандай әйтте:

—Йә инде, Габдуллаҗан!—диде үпкәләндәй авызын турсайтып.—Шаярырга да ярамый!—диде.—Зарланырга ярамый! Шаярырга ярамый!..—Исхак кинәт җитдиләнде, ул тирән көрсенеп куйды:—Нигә мине берсе дә сөйми? Мин кешеләрнең күңелен күтәрер өчен шамакайланам, биим... Мин ихластан сезнең арага керергә, үз булырга, дус булырга тырышам. Чүлмәкчедән күрмәкче мин дә шигырь яза башладым. Ләкин мин һаман сезнең арада чит, ятим. Һаман мин гаепле, һаман мине сүгәләр...

Исхакның күңеле тулды, аның тавышы калтыранып алды. Тукай дәшми торды, ул Исхак турында уйлый иде. Бу кеше сәләте чамалы булып та шагыйрь булырга алынып, барып чыкмагач, газит хәбәрчесе булып китте. Аны реальный училищедә укыган, дип тә әйтәләр. Нигә ул техника, математика өлкәсенә китмәгән, сәнгать, әдәбияткаябышкан? Үзеңнең бу өлкәдә сәләтсез икәнеңне үз вакытында аңлау—ул үзе талант.

—Димәк!—диде Тукай.—Синең мәсләгең юк, Исхак. Мәсләксез кеше—максатсыз кеше. Андый кеше көләсе урында җылый, җылыйсы урында көлә.

Исхакның сөмсере коелды, ул бәке кырындагы каткан кар кантарына утырды. Бәкедәге суда йөзеп йөри торган боз кисәкләренә карап, уйга калды. Җылап туктаган бала сыман сулкылдап куйды. Аннан соң ул үзалдына гына сөйләнгәндәй әйтте:

—Их, Тукай,—диде ул кайгылы тавыш белән:—Шамакайлансам да ярамый. Зарлансам да ярамый. Кем соң мин? Нигә соң мин? Нигә мине берәү дә сөйми? Яхшылык кылсам, шикләнәләр. Яманлык кылсам, сүгәләр...

Исхак бая шатлыклы бер кыяфәттә иде, ләкин соңгы сүзләрне ул шатланып түгел, кемгәдер үпкәләп, еламсырап әйтте.

Исхак тәмам җитдиләнде, көрсенеп, үзалдына сөйләнгән кебек сүз башлады:

—Их, Тукай дус, сиңа яшәве җиңелдер, синең мәсләгең бар. Ә мин кем? Мин Сәгыйть Рәмидән дә көнләшәм. Ул—шагыйрь. Синнән көнләшәм. Син—даһи шагыйрь. Ә мин кем?.. Сезгә өйрәтүе ансат... Яшисе килми, Тукай. Дөнья пычракка баткан. Ә мин шуның төбендә ятам. Яшисе килми...

Тукай аның фаҗигале тавыш белән сөйләнүеннән көлә башлады:

—Ни булган бу татар зыялыларына? Зарланалар, җылыйлар, мескенләнәләр. Син бит милләт байрагын тотып чыккан зат. Егылдың, ике чакрым да китмәдең. Бездә көч юк, без бетәргә мәхкүм, дисең.

Бу үгетләрне ишетеп Исхакның тагын ачуы чыкты, ул да мыскыллы елмаеп:

—Син үзең дә мәсләксез бит, Тукай,—диде.—Мәсләксез син дә. Шигырьләреңдә җылыйсың. Җыладың-җыладың да көлә башладың. Тиле кеше кебек. Хәзер тагын җылыйсың. Имеш, татарның узганы шанлы, тарихы бай. Болгары бар. Икенче санда ук укыйсың: татар халкы үләргә мәхкүм, татар черек милләт, татар надан... Өченче тапкырында Тукай яза, имеш: без бриллиант кашлар!..

Чыннан да, Исхак үзенчә дөрес сөйли кебек, ләкин ул мәсьәләне өстән генә аңлый яки аңламаганга салыша. Тукай зиһене белән аңлый, күңеле белән сизә иде: татар кешесен чабаклап уятырга кирәк. Чабаклап уятырга да көзгедән үзенә үзен күрсәтергә кирәк. Күрсен, оялсын, үзгәрсен, тәрәккый итсен. Рухы сыныкларның күңелен күтәрер өчен татарны мактарга, күтәрергә, үсендерергә кирәк. Көн нинди максат куя татар шагыйре алдына, ул шуны үтәргә тиеш.

Тукай Исхакка шуларны аңлатмакчы булды. Ләкин кире Исхак һаман тәртәгә тибә:

—Сез генә барысын да беләсез инде!—диде ул абыйсына үпкәләгән малай кебек.—Сез генә фидаиләр. Сез генә укымышлы! Халыкка ни кирәген сез генә беләсез. Ә мин—дивана, мин берни дә аңламыйм. Мин—эш-уңмас бичара Бикчура.

—Без дә алтын сарайларда яшәмибез, Исхак!—диде Тукай.

—Мәсләгеңне сатсаң, син алтында яши аласың,—диде юлдашы.—Ләкин синдә кирелек куәтле... Синең урында булсам, мин бәдрәфемне дә асылташлар белән бизәр идем...

Тукай бу сөйләшүнең дәвамын теләми иде. Исхакның да әйтер сүзе төкәнде бугай; ул, озак кына мышнап торганнан соң, Тукайга якын ук килеп, ачынып әйтте:

—Их, Тукай, төкерергә иде бу дөньяга, ә? Әйдә үләбез, Тукай. Үлик без. Яшәмик бу фани дөньяда, ә? «Калсын дөньягыз үзегезгә», дип язу калдырыйк та...

Тукай Исхакның бу сөйләнүен шаяруга алдымы, әллә төшенке хәлгә калган иптәшенә ярдәм йөзеннәнме, шаян-көр тавыш белән:

—Үлик соң!—диде.—Ә ничек итеп үләбез?

Исхакның шаярырга исәбе юк иде, ахрысы, ул һаман җитди килеш:

—Менә шушы бәкегә, кызлар кер чайкаган Кабан күленә, әле яңа гына

теге гүзәл кыз су алган бәкегә батып үлик,—диде.

Тукай иелеп бәке суына ике бармагын тыкты:

—У-у, суы салкын, кирәкми,—диде Тукай.—Бата калсак та, толып киеп батарбыз, җылырак булыр. Син, Исхак, чума тор, мин толыпка кайтып килим.

—Син шаярасың, Тукай,—диде Исхак.—Ә мин шаярмыйм...

Тукай аңа җавап бирмәде, ашыгып, сукмак буйлап атлап китте. Исхак теркелдәп аңа иярде. Тукайны куып җитеп, аның каршына төшеп, шагыйрьне туктатты, ике кулы белән ул Тукайның беләкләренә ябышты да ачык, салмак тавыш белән:

—Тукай!—диде.—Әгәр дә мин сатлыкҗан, шымчы, доносчы булсам, син ни әйтер идең?

Тукай Исхактан читкәрәк китеп, шөбһә белән:

—Таптың сүз!—дип кычкырды.

Тукайның җитди йөзен күреп, Исхак Бикчура кинәт үзгәрде, төшенке кыяфәте юкка чыкты, ул акырып көлә башлады, аның көлүе табигый түгел иде:

—Ха-ха-ха, куркып калдыңмы?—диде ул көлү аралаш.—Курыктың.

Алар салмак атлап Болгар кунакханәсенә таба атладылар.

Исхак тагын алышынды, ул кинәт җитди төс алды, авыр сулап:

—Син күз алдына да китерә алмыйсың шул, Туры Тукай, Беркатлы Сабый Тукай!—диде.

—Син бүген артыграк салгансың,—диде шагыйрь.

—Йөрәк янганда тагын ни кыласың?—диде Исхак, аны башка уй борчый иде, ул һаман баягыча шомлы итеп:—Син күз алдына да китерә алмыйсың, Тукай,—диде.

Боз бетте, алар электр ыстансасына килеп җитте, ыстансадан читтәрәк арзанлы ресторан тора. Ресторан ишеге төбендә бер исерек аунап ята. Ресторан янында городовой оясы күренә. Городовой үзенең кетәклеге тирәли йөренеп тора. Городовой кетәклегенең аргы ягында игъланнар мичкәсендә белдерүләр, гарәп хәрефле татарча, урысча игъланнар ябыштырылган. Урамнан извозчиклар, барабызлар, ара-тирә автомобильләр клаксоннарын кычкыртып уза. Өч пар ат җигелгән трамвай—«конка» шалтырап бара.

—Җылынып алабызмы?—диде Тукай, аннан соң: —Минем хисапка!—дип өстәп куйды.

Бикчура нидер әйтмәкче иде, сүзенең дәвамын ачмакчы иде кебек тоелды Тукайга, ләкин Исхак урамда сүз кузгатмастан:

—Җылынабыз!—диде.

Генерал кебек киенгән швейцар аларны сәламләде.

Залга килеп керүгә үк аларны половой каршы алды. Аларны буш куышка урнаштырды. Кечкенә күтәртмәдә бер маржа нindидер романс җырлап азаплана иде.

«Расцвели уж давно хризантемы в саду...»

Аның янында бер пеләш яһүд бөгелә-сыгыла аккордеон тарта иде.

Тукай аракы, тозлы кыяр, кәбестә сумсасы китертте. Дәшмичә генә эчтеләр.

Исхак һаман тынгысыз, ул һаман нидер әйтергә тели, ләкин аны нидер тоткарлый иде. Шулчак залга Сәгыйть Рәми килеп керде. Ул керүгә, Исхак тиз генә халәтен үзгәртте, шат бер кыяфәт алды да:

—О-о, бөек поэзия вәкиле килде!—дип хөрти актерларча тапталган позага басты.—Эш уңмас Бикчура китә! Хуш, Тукай!

Исхак ишек катына хәтле килде дә, тоткага тотынып артына, Тукайга йөзе белән борылып шигырь сөйли башлады:

Бәхил бул, дус, мин һәм тиздән менәм дарга,
Туйсын ашап җансыз тәнне козгын-карга;
Тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде!
Моңар чаклы торганмын мин гакыл тарга!

Исхак шигырьне юри генә, кызык өчен генә сөйләмәде, аның күзләрендә яшь иде, сөйләнгән шигырь дә тәэсирле булды. Сәгыйтьне, Тукайны шулай тәэсирле килеш ташлап, Исхак тиз генә чыгып китте.

Тукай ни әйтергә белми, өстәл арасында басып тора.

—Ни булган аңа?—диде Сәгыйть Рәми.

—Салган ул!—диде Тукай.

Сәгыйть ябылып бетмәгән ишекне ачып тышкы якка карады да ишекне катырак тартып куйды:

—Салуын салгандыр, сак бул син аннан,—диде.

Тукай фаҗигале аһәң белән укылган фаҗигале шигырь тәэсиреннән кинәт аерылгандай булып сорап куйды:

—Нигә алай дисең?

—Сак бул!—дип кабатлады Сәгыйть Рәми.

Тукайның кәефе китте. Ул хәтта Сәгыйтькә ачуланды кебек.

—Аннан шикләнә, синнән шикләнә, миннән шикләнә!—дип кычкырды.— Язмаска, сөйләшмәскә, дәшмәскә, көрешмәскә! Дөньямы бу, әллә төрмәме?

Сәгыйть тә сәер-серле иде бүген. Ул Тукайның ачуын кабартмаска тырышып, сак кына сүз башлады:

—Сизмисеңмени соң син, Габдуллаҗан? Синең турыда җыен юк-бар хәбәрләр тараталар. Синең тирәдә шикле кешеләр йөри.

—Ишек ачык. Кем тели, керсен. Акча кирәк булса, алсын. Ашарга кирәк булса, казы бар, алсын. Тик кара савытым белән каләмемә генә кагылмасыннар.

—Синең күңелең бөтен нәрсәгә сизгер, дустым. Гап-гади, ап-ачык нәрсәләрне син күрмисең.

—Нәрсә, әллә Камалдан да, Фатихтан да, үзеңнән дә шикләнергә кушасыңмы?

Тукай кызганнан-кыза бара иде. Аңа каршы төшеп, сүзне дәвам итсәң, бу бәхәс ызгышка әвереләсен Сәгыйть яхшы аңлады, шулай да Тукайны кисәтеп кую аның максаты иде.

—Дустым,—диде Сәгыйть.—Олы шәхесне дошманнары сата алмый, бары тик дуслары гына сата ала.

—Теләмим!—дип кычкырды Тукай.—Ишетергә дә теләмимен! Син мине үземнән дә шикләнергә өндисең. Син курку таратасың! Шом җәясең дуслар арасына. Монда кергән бер генә кешедән дә мин шикләнмим, шикләнергә теләмим. Үзем аңа шигырь укып, аны чәй белән сыйлап утырганда мин: әһә, кабахәт, син мине сатарга йөрисең, дип эчтән сасып утырыйммы! Юк! Юк!

Тукай Сәгыйтькә генә түгел, бөтен дөньясына ачулана иде.

Сәгыйть Рәми дустының бераз тынычланганын сабыр гына көтте, аннары сәгатенә карап алды да урыныннан торды:

—Их, дускай-җанашкай,—диде ул.—Сәгать ике икән инде. Мин киттем. Вакытым чыкты. Хуш. Сау бул! Сак бул теге җегеттән!

Сәгыйть чыгып киткәч кенә Тукай ишек катына атылып килде:

—Кая киттең, Сәгыйть, ераккамы?—дип кычкырды, ләкин Сәгыйть инде ресторанннан чыгып киткән иде.

Бу сәер сөйләшү Тукайны тәмам чыгырыннан чыгарган иде, ул бичарадан-ничара тагын салып эчте.

Половой белән исәп-хисапны өзгәч, ул да ресторанннан чыкты.

## Яңа дошман

Соңгы вакытта Тукай бик борчулы иде. Аны ниндидер хәвефле авыр уй бастымы, әллә авыруы көчәеп киткәнгәме ул шулай күңелсез. Юрганына төренеп, ул бүлмә буйлап йөренә-йөренә дә, ятагына килеп утыра, аннан тагын торып, йөренергә тотына. Аннан тагын ятагына килеп ята. Башыннан аягына капланып яткан гына иде, бүлмәгә Хөсәен Ямаш керде. Кәрә-керешли ул:

—Тукай, син өйдәме?—диде дә кочагын җәеп Тукайга таба килә башлады. Тукай ютәлләп алды да, кискен кул хәрәкәте белән:

—Якын килмә, Хөсәен, миндә грипп!—диде.

—Гриппттан курыккан юк, башкасы булмасын!—диде Хөсәен.

—Башкасы да ерак йөрмәс бездән!—диде Тукай.

Хөсәен Ямашның сүз озайтырга исәбе юк иде, ул нидер тоткан, нидер эзли иде.

—Ни булды, Хөсәен?—диде Тукай.

Бер төенчек күрсәтеп, Ямаш:

—Менә моны тиз генә яшерергә кирәк!—диде.—Мин чыгып киту белән тәрәзәдән урамга ыргыт... Артка койрык тагылган иде. Шуннан качам. Яшә, Тукай! Шәп язасың! Халыкка син елмаю-өмет өләшәсең! Яшә, дускай! Рәхмәт! Синең бу эшең—бомба, беләсеңме, Тукай, бомба! Тукай исеме халыкның гимны икәнен аңла да күп яшә, Тукай!

Хөсәен төргәген Тукайга калдырып, үзе чыгып йөгерде. Тукай тиз генә тәрәзә янына килеп, аска карады да төргәкне ыргытты. Аста аны кемдер алып, каты чабып китте. Шулчак коридорда аяк тавышлары ишетелде.

Хөсәен Ямашны аулыйлар, мәлгуньнәр! Ямаш! Менә кемнәре бар милләтнең. Чибәр, мәһабәт. Теләсә кайда рәхәт сөрердәй акыллы зат. Җылы өен ташлап, халык бәхете өчен төрмәләрдә черергә әзер фидаилары бар татарның. Менә кемгә һәйкәл куярга кирәк Казан уртасында!

Ул, артына борылмыйча да, таныш хәерчесе Шәүлә бүлмәгә кергәнен белә иде.

—Бәлки син әйтерсең, Шәүлә!—диде Тукай тәрәзәдән аерылмастан.— Минем тирәдә ниндидер серлелек. Дусларым ишарә, киная белән генә сөйләшә. Әйтергә телиләр, әйтә алмыйлар. Эт шикелле күзгә карап торалар-торалар да чыгып йөгерәләр.

Шәүлә дә тәрәзә янына ук килеп, Тукай караган тарафка багып:

—Дөнья бит бу!—диде.—Ишарәсез, кинаясез тормыш булмый...

Тукай, тәрәзәдән аерылып, ятагына барып утырды, Шәүлә, чын күләгә кебек, аның артыннан өстәл янына килде.

—Йә, ни-нәрсә борчый сине, дустым?—диде ул.

Аннан соң өстәлдәге күмәчне алып ашый башлады:

—Рөхсәттер бит,—дигән булды үзе.

—Син дә нәрсәдер беләсең, әйтмисең генә,—диде Тукай үпкәләгәндәй итеп.

—Без, базар хәерчеләре, бөтен нәрсәне белеп торабыз,—диде Шәүлә.— Ләкин белгәннәребезне беркемгә дә сиздермибез. Сиздерсәң, белгәнеңне пычак белән каерып алачаклар. Пычак булмаса, сатып алачаклар сереңне. Үзең беләсең, Тукай, мине акча кызыксындырмый. Бу мәсьәләдә синең белән бертуган, ә пычактан үләсе килми. Шуңа күрә, мин белгәнемне белгертмим.

Тукай ютәлли башлауга ук Шәүлә тотып алды:

—Синең бик еш ютәлләгәнеңне беләм... Синдә...

Тукай ютәл аша:

—Яп, авызыңны, Шәүлә!—дип кычкырды.

Аның ютәлдән, ачудан күзләре акайган, куркыныч иде. Шәүлә шиңеп төште:

—Ябам-ябам!—диде ул иелә-бөгелә.

—Ишекне дә теге яктан яп, мәлгунь,—диде Тукай.

Шәүлә чыгып өлгермәгән булса, Тукай ыргыткан сыңар ката һичшиксез аңа тигән булыр иде, ката нәкъ әле яна гына юк булган Шәүлә урынына барып тиде.

Тукай Шәүлә киткәч озак ютәлләде. «Хәерче тәре», дип сукранып та алды. Шәүлә аның нинди авыру белән авырганын әйтергә теләгән иде. Әйтә алмый калды, аның «туберкулез» дигән сүзен Тукай кисте.

Бу вакыйгалардан соң берничә көн узгач, Тукайның кәефе яхшыргач, аның бүлмәсенә Фатих Әмирхан бер кәттә кыяфәтле татар баен алып керде.

—Тукай, синең янга!—диде Фатих, арба артыннан ияргән кешегә ишарәләп.

Исәнлек-саулык сораштырганнан соң, урындыкларга урнашканнан соң гына кунак сүз башлады:

—Йомыш бар иде!—диде ул.

Фатих Әмирхан Мәхмүткә ишарә итте, янәсе, чыгабыз.

—Юк, юк,—диде кунак.—Сез комачауламыйсыз, әфәндем. Утыра калыгыз.

Мәхмүт янә, тәрәзә төбенә барып, китапка тотынды.

—Башлагыз, әфәндем!—диде Тукай.

Кунак бастуннан тектерелгән өчлек костюм кигән, башында җирән каракүлдән эшләнгән кырпулы бүрек, өчлек камзулы кесәсеннән алтын чылбыр асылынган, кулында юан шар башлы слюда таяк, бармагында кара таракан зурлыгындагы асылташлы йөзек иде. Кунак һич тарсынмыйча Тукайны, аннан бүлмәне караштырып чыкканнан соң:

—Шушы сезмени инде ул Туры Тукай?—диде.—Ни гаҗәп, ни гаҗәп.

—Нигә гаҗәпләнәсез, бай әфәнде?—диде хуҗа.

—Номер юньрәк икән!—диде кунак. Тукайның якыннан таныш булмаган бу татарга мөнәсәбәте кызыксынуга гына корылган иде. Ул аңа дошман да, дус та түгел, шуңа күрә ул кунакны сабыр гына каршылады. Инде керер-кермәстән бүлмәдән гаеп табып утыруы Тукайның җәя кереше кебек киеренке сеңерләренә китереп сукты: ул астына хәтәр зәһәр салынган бер җөмлә әйтте:

—Сез яхшырагын тәкъдим итәргә килдегезме, Мөхәммәтгали углы Хисаметдин Сираев әфәнде?—диде.

Фатих Әмирхан шушы бер җөмләдә булачак сөйләшүнең оеткысын күрде. Сөйләшү бай файдасына да, Тукай файдасына да булмаячак. Тукай байны беренче сүзеннән үк ошатмады, тәртәгә типте.

Ләкин Хисаметдин бай һични сизмәде, рәхәтләнеп көлә башлады:

—Ха-ха-ха, сез сизгер кеше, Тукаев әфәнде,—диде ул көлеп туктагач.—Дөрес, мин Хисаметдин Сираев буламын. Мин сезгә язу белән кешемне җибәргән идем инде, сез аны кабул итә алмагансыз икән... Ялгышлык, ялгышлык, Тукаев әфәнде... Ие, татар халкының бөек шагыйре үз иҗатына тәңгәл шартларда яшәргә тиеш. Бу безнең намусыбыз эше, әфәндем. Без, финанс магнатлары, милләт кайгысын кайгыртмаса, кем кайгыртыр? Иҗат-сәнгать сездән, матди як бездән. Мин эш кешесе, әфәндем. Кыскасы, мин яңа журнал ачам. Управадан рөхсәтем дә, поручением дә бар. Аллага шөкер. Сезне, Тукаев әфәнде, шул журналга баш итеп куймак булып йөрмеш көнем.

Сез шигырь юлына күпме аласыз әле?.. Дөрес, ие, башка шагыйрьләргә юлы биш тиеннән, Тукаевның юлы илле тиен көмештән түләнә. Минемчә, Тукаевның шигъри юлы алтын. Мин сезгә алтын белән түләрмен. Ә журнал хезмәте өчен аерым. Аерым, Тукаев әфәнде! Сез министр акчасына яшәячәксез. Үзегезгә аерым йорт, асраулар булыр...

Тукай утырган жирендә кыбырсып куйды: ул байның сүзе өстенә менеп:

—Ярый, Мөхәммәтгали углы Хисаметдин Сираев әфәнде, мин риза...

Хисаметдин сикереп торып ике кулын Тукайга сузды:

—Һай, галәмәт, сөбханалла-машалла...

Тукайның да сүзе өзелгән булып чыкты, ул басым ясап:

—... риза булдым да ди. Нindирәк журнал инде ул, ягъни мәсәлән? Минем вазифам анда нидән гыйбарәт булачак?—диде.

Бай туры гына җавап бирмәде, читләтеп һәм акланган сурәттә озын нотык башлады:

—Хәзер катлаулы заман, ие, авыр заман, әфәндем. Ялгышып куюың да бар, Алла сакласын. Бүген ордым-бәрдем кычкырырга ярамый. Хәзерге көндә түрәләр турында да, зыялылар турында да, татар милләтенең узганы, киләчәге турында да дәшмәскә кирәк, дип уйлыйм мин, әфәнделәр. Бигрәк тә урыс түрәләре хакында, дим. Замана аларныкы, күсәк аларда, гаскәр аларда, закон аларда. Без аларга ялварырга гына хокуклыбыз. Бәс, халыкка дин турында язарга. Диннән тыш мәгыйшәт мәсьәләләре, мәхәббәт, жир-су, табигать һәм кызганыч бәетләр бирергә була. Халык газитә-журнал, китаптан бизмәсен. Укый торсын. Сәясәткә катыштырмыйк без халыкны. Надан калмасын өчен әнә шундый рисаләләр бирә торыйк без аларга. Милләтне-телне саклап калу—безем олуг максадымыз, әфәнделәр. Еллар узгач, җае чыккач, аннан соң мөмкинлек туса, хет патшаның үзе турында кәмит яз! Ә?

Фатих Әмирхан елмайды, елмаюдан соң аның авызыннан:

—Мантыйк бар, Тукай!—дигән сүз чыкты.

—Бар!—диде Тукай.—Ләкин формаль мантыйк.

—Дөрес сөйлисез, бай әфәнде!—диде Фатих.—Форсат чыккач кына патшага, стройга каршы хәтәр әсәрләр яза башларга, дисез инде.

—Валлаһе әгъләм, дөрес аңлагансыз, әфәнделәр!—диде бай шатлыгын яшерә алмыйча.

Фатихның елмаюы юкка чыкты, ул:

—Кем соң ул форсатны безгә әзерләп куяр, бай әфәнде?—диде.

—Только без түгел!—диде Хисаметдин бай.—Без-татарлар эше түгел инкыйлаб. Әнә урыслар ясасын революция. Урыслар үз дәүләтләрендә, үзләре теләсә нишләсен. Без катышмыйк.

—Урыс революция ясагач, революция сыртына атланып, шовинистларны кыйнап йөрикме?—диде Фатих.

Тукай кыты-кыты көлә башлады. Хисаметдин бай башта аңламады: ни өчен көлә Тукай, моның ни кызыгы бар? дип уйлады булса кирәк, ул аптырап бер Фатихка, бер Тукайга карап алды.

—Күз алдына китерәм!—диде Тукай тыела алмыйча.—Ат өстендә Мөхәммәтгали углы Хисаметдин Сираев әфәнде милләт кылычы Зөлфекарне айкый... Бай әфәнде, сезгә моны берәр кеше өйрәттеме, әллә үзегез уйлап чыгардыгызмы?

—Үзем, үзем, әфәндем. Журнал чыгарырга рөхсәтем дә бар. Тоткарлык юк,—диде Хисаметдин куен кесәсеннән калын гына акча янчыгы чыгарды. Аркылы җеп белән бәйләнгән бер капны Тукайга сузып:

—Сезгә, Тукаев әфәнде, аванс!—диде. Тукай көлүдән ютәлгә күчә бара

иде, аның йөзе көлүдән түгел, авырту һәм ачудан чалшайды. Ул:

—Вон моннан!—дип кычкырды.—Вон моннан, Мөхәммәтгали углы Сираев!

Кунак, аптырап-каушап, тораташ булып калды, ул ни әйтергә белмәстән:

—Нәрсә?—диде.

—Чыгып китегез!—диде Тукай ютәл аша.

—Сез ни сөйлисез, Тукаев!—диде кунак.—Мин сезгә яхшылык белән, ә сез... сез...

—Күземә күренмәгез, Сираев!—дип Тукай котылгысыз ютәлгә дучар булды.

Хисаметдин хәлне инде аңлап алган иде, ул акчасын кесәсенә тыгып, таягын алды:

—Мин сезне хәерчелектән йолып алмакчы булам...—дип ул ишеккә таба атлады, әмма ишек катында кинәт борылды, һәм, горур кыяфәт алып:

—Аш белән атканга таш. Сез минем өстән бөһтан язып чыккан идегез теге вакытта. Анда да мин сезнең ул мальчишествогызны оныттым. Ярый, дидем, миннән булсын яхшылык. Мин сезне, Тукайны, халык өчен, киләчәк өчен, хөр милләт өчен саклап калырга теләгән идем. Хәзер аңладым: сездә иманның «и» хәрефе дә юк икән. Сез рәхимсез, миһербансыз, сез игелексез бер бәндә, тәрбиясез үскән бичара ятим икәнсез. Хак! Сезнең эчтә яман чир ята. Шул чир сезне усаллата. Мин, атаклы докторлар яллап, сезне тәрбия кылырмын, дип тә килгән идем. Сез үзегезнең вәкарьлегегез белән үзегезне үтерәсез! Чабаталы морза баласы Тукаев! Хушча калыгыз!

Хисаметдин бай таягы белән ишекне ачып чыгып китте, ачык калган ишектән аның дөп-дөп атлап китеп барганы ишетелә иде.

Бүлмәдә ютәл тавышы гына хөкем сөрә. Аспириннар каба-йота, салкын чәй эчкәли-эчкәли Тукай бераз тынычлана төште. Ул хәл алгач, Фатих үзалдына:

—Сирай бай моны онытмаячак,—диде.—Мәңгегә ул сине гафу итмәячәк, Тукай. Син үзеңә бик зур дошман әзерләдең...

Тукай дәшмәде.

—Беләсенме, Тукай,—диде Фатих.—Синең бер гүзәл вә мәһабәт гадәтең бар: көн туса, син үзеңә яңа бер дошман ясый беләсең. Моны Туры Тукай гына эшли ала.

—Һәй,—диде Тукай үкенүле тавыш белән.—Турылыгы корсын ул Тукайның. Кешенең чыраена бәреп әйтәм дә соңыннан үзем үкенеп йөрим. Дөресен әйттем, яхшы әйттем, әмма тупас әйттем. Ипләп кенә дә шул ук сүзне әйтеп була иде бит инде... Их!..

Тукай, кулын селтәп, өстеннән хатасын алып ташламакчы булды кебек:

—Йә, ярар, узган эшкә салават. Шәп әйттем, кабат алай әйтмәм. Алар бит, хәерче, йолкыш Тукайны сатып алып була, дип уйлый. Сатып алгач, үз мәнфәгатьләренә җигәргә уйлый...

Тукай тагын калтырана, ютәлли башлады.

—Карале,—диде ул.—Шул байга ачудан бөтен тәнем ут яна...

Мәхмүт аны урынына яткызып, өстенә юрган япты. Тукайга хәзер җылылык һәм тынычлык кирәк иде. Тукай йокыга киткәч, алар бүлмәдән чыкты.

## Шәүлә

Шул көннән соң Тукайның хәле кискенләште. Ул еш ютәлли, ютәле озакка сузыла, ютәл килмәгәндә дә, ни өчендер, кәефе булмый иде. Аны борчымас өчен дуслары да сирәгрәк килә башлады. Тукай көннәр буе әнә

шулай ятагында бөгәрләнеп ята бирде. Баштарак ул иптәшләренең килеп йөрүеннән канәгатьсез булса, хәзер аларны ник куып чыгарганына, нигә якты чырай күрсәтмәгәненә үкенеп туя алмый иде. Килсеннәр, керсеннәр, ичмасам, бүлмәдә җан иясе булыр. Аның теләге фәрештәнең «амин» дигәненә туры килде бугай, ишек шакыдылар.

—Керегез!—диде Тукай.—Ишек ачык.

—Йоклыйсыңмы, Тукай?—диде кергән кеше.

—Кем ул?—дип Тукай башын калкытты.—Ә-ә, синмени, базар пәйгамбәре! Ник йөрисең шәүлегәндәй тавыш-тынсыз?

—Язмыш куып йөртә, Тукай, язмыш!—диде Шәүлә.

Тукай Шәүлә кергәнгә сөенде кебек, сөйләшергә хет җан иясе бар.

—Синең эш рәхәт,—диде Тукай,—уч төбенә карыйсың да тамак туйдырасың. Иртәгесе өчен кайгырмыйсың.

Шәүлә кете-кете көлде:

—Бичара Тукай, син шигырьләреңнән гайре берни дә аңламыйсың...

Тукай сикереп торды да, Шәүләнең якасыннан алып:

—С-син, карачкы!—дип кычкырды.—Әйтмә миңа «бичара» дип!

Шәүлә курка калды:

—Ярар, ярар, әйтмәм лә, һай Аллам,—диде.

Тукай Шәүләнең тынлаучан булуын күреп, сүрелә төште, ул борын астыннан гына мыгырдана иде:

—Бичара Тукай, ятим Тукай, мескен Тукай, фәкыйрь Тукай... Фәкыйрь түгел мин!—ул янә тавышын күтәрә төште.—Әнә, ал кирәк хәтле!

Шагыйрь өстәлдәге бер уч акчаны таратып җибәрде, акчаларның берничәсе идәнгә очып төште. Шәүлә кабалана-кабалана идәндәге акчаларны җыя башлады.

—Ал тагын!—диде Тукай.—Печән базарындагы бөтен йолкышны сыйла. Кайдан алдың, дип сорасалар, үзем таптым, диген.—Шәүлә идәннән алган акчаларның икесен үзендә калдырып, калганнарын өстәлгә, тегеләре янына куйды.

—Юк,—диде ул шушы эшен тәмам иткәннән соң,—күп акча кешене боза ул. Миңа шушысы да бик җиткән, әфәндем. Моңа әллә ничә тапкыр күрәзә карармын әле мин сиңа.

Тукай әле һаман үз уйлары белән мәшгуль иде, ул:

—Ятим түгел мин! Күп миллионлы халкы булган шагыйрь ятим буламыни? Бөтен Россиядә урыстан кала икенче милләт баласы. Идел буендагы егерме биш миллион мөселманы булган, Урта Азиядә, Себердә, Уралда, Кырымда тагын шулкадәр укучысы булган шагыйрь мескен буламыни? Алтын эчендә яши алам мин бу халкым белән. Ләкин аңа вакыт тар, Шәүлә. Халкым биргән байлыкта яшәргә минем хакым бар, Базар әүлиясе!—дип Тукай янә ятарга җыенды.

Шәүлә үзенә тигән акчаларны кесәсенә сала-сала:

—Булды, ярар инде,—диде.—Бер сүзне өзми дә куймый да... Сузма инде... Якадан алдың бит инде, житәр, кирәксә артыма тибеп чыгар тагын.

Чыннан да Тукай хәерчегә артыграк бәйләнгәнен сизде:

—Кичер, дускай,—диде ул сабыр гына.—Кызган чакка эләктең.

—Ташла!—диде Шәүлә.—Соныннан гафу сорау сиңа килешми. Мин үпкәләмим. Үпкәли башласаң...

Шәүлә Тукайга сиздермичә генә бүлмәне караштыргалап чыкты.

—Йә, күрәзәче,—диде Тукай.—Бер-бер күрәзә кыл әле. Бу юлы ничек алдарсың икән?

Шәүлә аның сүзләрен ишетмәгән кеби:

—Монда Сәгыйть Рәми булган икән, аңлашылды...—диде серле итеп.

Тукай, сагаеп, билен турайтты:

—Булды шул, каян белдең?—диде ул гаҗәпләнүен яшермичә.

Шәүлә шат тавыш белән:

—Шуны да белмәгәч, күрәзәче булып йөрүең ни пычагыма кирәк!—диде.—Уһу, елак милләтче Бикчура да булып киткән икән,—дип сөйләнә-сөйләнә, Шәүлә иснәнә, тикшерә иде.—Бикчура иртәрәк чыгып тайган булырга тиеш... Монда Фатих Әмирхан арбасы торган икән... Ә-ә, бай әфәнде Сираев та килдемени? Ул сиңа бик каты ачуланып чыгып киткән!

Тукай балаларча шатланып көлә иде. Көлүе тагын ютәлгә күчте. Ютәле көчле булмады, Тукайның шатлыгы сүрелмәде.

—Шайтан икәнсең син, Шәүлә,—диде ул кул чәбәкләп.—Каян беләсең син боларны?

Шәүлә бөкрәйгән килеш һаман нидер эзли иде. Тукай аның бу серле-сырлы кыланышын елмаеп күзәтә.

—Мантыйк инде, мантыйк, дускай!—диде Шәүлә.—Дедуктив алым вә мантыйкый фикерләү, күзәтүчәнлек вә янә дә күнел сиземләве вә дәхи борынымның ис сизүе. Бу таяк балдагы; Сирай байныкы төшеп калган... Бу таякны ул Париждан кайтарткан иде. Беркайчан да кыршытмаган таягыннан алтынсу балдак төшеп калырлык итеп суккач, монда зур бәхәс булган, дип уйларга туры килә. Син аны куып чыгаргансың. Әмирханның монда булуы табигый. Ул синең янга көненә биш-алты тапкыр керә, чыга. Аның арбасы, гадәттә менә шушында була. Чөнки идән тигез, арба тәгәрәп китми бу төштән. Җылак милләтче Бикчура һәркөн саен сиңа кереп чыга. Ул төрек тәмәкесе тарта. Ул булган җирдә шундый ис кала. Ул ис айлар буена бетми тора. Сәгыйть Рәми әфәнде бик борчулы булган. Әнә, өстәлдәге кәгазьгә нидер сызгалаган, рәсем ясаган. Рәсемнең логикасы юк. Ул кешенең эчендә ниндидер бер кайгы булырга тиеш.

Тукай тагын кул чәбәкәйләп:

—Син Шерлок Холмс, Шәүлә!—дип кычкырды.—Нигә син хәерче булып йөрисең? Эшлә син частный детектив булып. Син бөтен җинаятьләрне ачып бетерер идең.

Шәүләне сагыш басты, ул:

—Их, Тукай җаным,—диде.—Кайгым шул гына булса икән... Да, кстати, ә менә син нигә бу бүлмәдә яшисең, ә? Күселәр, тычканнар... Суык, бәдрәфе дә урамда. Яшә модерный номерларда.

Тукайның өстенә тагын бер чиләк салкын су койдылар; ул тагын турсайды:

—Яп авызыңны!—дип кычкырды.

Шәүлә шундук ана буйсынды:

—Ябам, ябам!—диде, сонра тагын шелтәле рәвештә:—Шулай шул, Тукай,—диде.—Миңа да иректе булып йөрүе кыйммәтрәк. Менә мин турысын әйтәм, иеме. Мин беркемнән дә курыкмыйм. Беркем дә миңа ачуланмый. Мин теләсә кемгә теләсә нәрсә әйтәм. Шул сүзләрне мин бай кеше буларак әйтсәм, дөнья тулы дошманым булыр иде. Хәерче сүзен чынга алмыйлар. Исерек адәм патшаны акырып сүгеп бара. Аңа берни дә юк. Ә менә син сүгеп кара патшаны!

—Сиңа сүз табалмассың!—диде Тукай.

Шәүлә кызыксынуын дәвам итә иде:

—Тагын кемнәр булды монда?—диде Шәүлә.

—Кем белә инде аларны,—диде Тукай.—Минем ишек ачык тора бит. Кем кергәнен, кем чыкканын күрми дә калам кайчакларда. Йә көзгемне чәлдерәләр, йә кара савытымны алып чыгалар, денсезләр.

—Байлыгың булса, бикләр идең әле бик,—диде Шәүлә.

Тукай эчтән генә бу базар шәүлегәненә якынлык та тоя иде кебек. Сәер

хәерче иде бу Шәүлә!

—Чын исемен кем синен, Шәүлә?—диде Тукай дусларча.

— Кем белә инде аны?—диде хәерче.—Базар хәерчеләренен үз исемнәре булмый, Тукай, аларнын кушаматлары гына була.

—Шулай да,—диде Тукай.

Тукайдан болай гына котылып булмасын Шәүлә аңлады һәм:

—Ни әйтсәм дә ялган булыр,—диде.—Габделмән улы Фәррах Зөлфикаров, дидем ни дә, Ильминский Иван Николаевич, дидем ни...

Тукай балаларча үпкәләде, кеше аннан чынлап сорый, ул ләкләкә сата.

—Әйтмәсән, әйтмә!—дип, ул урынына ятты.

Шәүлә тавышын күтәрә төшеп:

—Әйттем бит инде, сиңа ни кирәк тагын?—диде.

Тукай янә сикереп торды да:

—Син, малай, минем белән алай сөйләшмә. Минем ачуым яман!—дип кычкырды.

Шәүлә бер дә исе китмичә генә әйтә куйды:

—Ачуланганга селкенмим дә мин, Тукай. Якамнан алганыңа да үпкәләмим. Ул яканы күп умырдылар инде. Әле умырасылары күпме булыр. Артыма тибеп чыгарсаң да ачу сакламам мин сиңа.

—Нигә әле син гел үзеңне кыйнатырга гына йөрисең, ә? Синдә мазохизм авыруы бармы әллә?

—Андый авыру юк!—диде Шәүлә дустанә.—Әмма шөһрәт ярату чире бар миндә. Тукай аягы тигән җир тәмугта янмас. Шуңа күрә, тәмугта янмасын дисәң, син мине кыйна, салып тапта. Әгәр дә син мине кара янмаган җиремне калдырмыйча таптасаң, мин бәхетлеләрнең бәхетлесе булыр идем. Син үлгәч... ә син әбизәтелне миннән алда үләчәксең... син үлгәч, мине очрашудан очрашуга гына йөртерләр иде...

— Ни өчен?—диде Тукай.

—Менә бу төшемә Тукай аягы тиде, Тукайның йодрыгы менә бу җиремә тиде, дип мин халыкка артымны да, алдымны да күрсәтер идем. Тукай аягы тимәгән җире юк моның дип, мин үлгәч, гәүдәмне катырып музейга, мавзолейга куярлар иде.

Тукай башта көлүен тыеп карады, чөнки көлү артыннан һәрвакыт ютәл килә, юк, эчке кытыклану куәтле иде, көлү тышка бәреп чыкты, Тукай урынында ауный-ауный көләргә тотынды. Ул көлү арасында:

—Тилергән Шәүлә!—диде.—Әгәр дә киресе булса? Тукайны эттән алып, эткә салып сүгә башласалар?

—Исең киткән!—диде Шәүлә.—Аннан миңа ни зыян? Миңа барыбер почет булачак... Менә бу кешене кабахәт Тукай кыйнаган, измәсен изгән бичараның, дип тагын мине халыкка күрсәтеп йөртерләр иде.

Бусы Тукайны тагын да катырак кытыклый иде, Тукай инде буылып, сызгыру тавышлары чыгарып, эче катып көлә:

—Житте, Шәүлә!—диде ул көчкә-көчкә.—Үтерәсең син мине. Миңа бит көләргә ярамый.

Шәүлә шаян халәттән кинәт житдигә әйләнде:

—Ярамый? Ярый! Үзең көләсең, Тукай, каһкаһә белән көләсең. Әллә ниләр бастырып, кемнәрдәндер көләсең. Сатира! Һөҗү имеш. Шул сатираң, шул һөҗүең синең башыңа житәчәк тә. Белеп тор. Җүләр балык син, Габдуллажан. Печән Базары корольләре белән нигә кирәк сатулашу? Печән Базарын мин беләм, син түгел. Печән Базарының аның үз жандармериясе, үз шымчылары, үз палачлары бар. Тели икән, Печән Базары сине кыптылый, бетте-китте. Нигә кирәк сиңа муллалар, Дума депутатлары белән алышу?

Мулла булса да, милләтче булса да, алар сине полковник Старосветовка сатарга биш куллап риза. Тукайны тончыктырырга дигәндә милләтче белән шовинист җан дус була. Тын кал! Дәшмә, Тукай! Янә дә килеп, нигә кирәк булды сиңа властьларга кусәк күтәрү? Хакимен булса ишәк, килмешәк! Татарга һәрвакыт ишәк белән килмешәк түрә булачак. Оек кебек кайтарылып чыкса да татар үзенә үзе хуҗа була алмаячак. Губернаторга барып җитмәс, дип уйлама син. Барысы да барып җитә тора. Губернаторың, әнә, татарча өйрәнеп ята. Татар халкының теленә гашыйк булганнан түгел, татар халкының азатлыкка омтыла торган идеяләрен буар өчен өйрәнә ул татар телен, ышанмый үзенең шымчыларына. Оригиналдан укырга тели Тукайны, кабахәт. Болытлар куера, Тукай. Болыт кына түгел, зур-зур ике кара болыт. Үзеннең кандашларың, милләтчеләр синең өстә ясин чыгарга җыена. Икенче кап-кара болыт—Судебная палата прокуроры ягыннан.

Тукай сәер халәттә иде. Ул аптыраган, йөдәгән, шүрләгән, шикләнгән һәм базар хәерчесе Шәүләнең гаҗәеп мәгълүматлы, акыллы икәнен күреп, ни уйларга белми, ни әйтергә белми иде. Ул бары тик сак кына:

—Ә син каян беләсең әле мондый тәфсилле нечкәлекләрне?—диде.

Шәүлә дә кинәт шәлперәйде, үз хәленә, хәерче хәленә кайтты, ул:

—Мин күрәзәче, күзәтүче, Тукай,—диде.—Мин Печән Базары шымчыларын яхшы беләм... Тукаевны Уголовное Изложениенең биш статьясының сигез параграфы буенча җавапка тартырга...

Тукайның эченә шом инде һәм ул күрәзәчедән котылырга кирәк икәнен күңеле белән сизеп алды.

—Китте!—дип кычкырды Тукай.—Яп авызыңны! Дәшмә!

—Дәшмим!—диде Шәүлә.—Ләкин мин синнән зинһарлап сорыйм, тынып кал, беразга гына дәшмә, Тукайҗан! Алла хакы өчен, син дәшмә!

—Тынмасам?—диде Тукай.

Шәүлә шактый тәэсирле итеп:

—Тынмасаң, юллары күп аның, Тукайҗан,—диде.—Йә татар милләтчеләре кыптысыннан узарсың. Йә урыс шовинистлары харап итәр үзеңне, һич югында сине үтерә торган гайбәт таратачаклар.

—Гайбәтләр күп булды инде, түзәрбез анысына. Тукай эчә, Тукай фәкыйрь, Тукай сукыр...

—Монысы каршында алары чүп кенә...

—Нинди гайбәт таратырга мөмкин инде? Бөтен булган-булмаганнарымны чәйнәп бетерделәр бит инде... Димәк, син беләсең? Әйт, Шәүлә!

—Әйтмим!

—Әйт!

Тукай сикереп торып Шәүләнең якасыннан алды.

—Буам, әйт, хәерче!—дип ачынып кычкырды Тукай.—Әйтәсеңме, юкмы?

Шәүлә, көчкә генә Тукай кулыннан ычкынып:

—Әйтәм,—диде, ул алак-йолак карангалап алды да, ярым пышылдап сөйли башлады.—Тегенди авыруы бар икән, шуңа күрә өйләнә алмыйча йөри икән, диләр...

Тукай агарынып, ачуыннан буылыр дәрәҗәдә:

—Кабахәт! Юга-ал!—дип кычкырды.

—Бу сүз таралмаган әле, мин аны тараттырмаячакмын, Тукай!—диде дә Шәүлә ишеккә ыргылды.

—Кит, карачкы!—дип Тукай аның артыннан калай кружкасын томырды.

Шәүлә чыгып ычкынды, кружка ачык ишек авызыннан коридорга очып чыкты; калай тавышы бөтен катны уятты. Шулчак ишектә Фатих Әмирхан

пәйда булды. Мәхмүт арбаны тиз генә бүлмәгә этеп кертте дә, кружканы эзләп табып, ишекне япты.

—Нигә кычкырышасыз?—диде Фатих Әмирхан.

—Йолкыш, Базар каргасы!—диде Тукай.

—Берәр нәрсәне чәлдергәнме әллә?

—Чәлдерүен чәлдермәгән, әмма теле кеше үтертер, валлаһи.

Фатих Әмирхан Мәхмүткә ишарәләде, тегесе кулындагы кәгазьне Тукайга сузды.

—Сиңа телеграмма бар,—диде Фатих.

Тукай Мәхмүт кулыннан телеграмманы алып укый башлады:

«Тукай, кичер, саубуллаша да, бәхилләшә дә алмадым. Минем арттан күзәтүчеләр күп иде. Ни булса да мине ярлыка. Сагышлы дустың Сәгыйть».

Тукай телеграмманы кат-кат укыды, аннан соң Фатих Әмирханга багып:

—Нәрсә бу, Фатих?—диде.

—Казаннан китте ул,—диде Фатих. Тукай әле күптән түгел генә Сәгыйть Рәми белән булган сөйләшүен-көрешүен исенә төшерде булса кирәк, тирән уйга калды.

—Кинәт кенә... Серле генә...—диде Тукай үзалдына.

—Син белмисеңмени, Абдуллаҗан?—диде Фатих.

Тукай үпкә катыш-ачу белән:

—Юк, белмим. Мин бернәрсә дә белмим. Сез генә беләсез, миңа әйтмисез!—диде.

—Сине сатмас өчен качты ул Казаннан!—диде Фатих.

—Ничек, кемгә сатмас өчен?

—Сагышлы Сәгыйть охранка агенты иде...

Фатих Әмирхан бу сүзләрне бәрәңге ашау, чәй эчү кебек гап-гади нәрсәләр турында сөйләгән кебек итеп әйтте, Тукай ялт итеп аңа карады, Фатих йөзендә шаяру билгеләре күренми иде.

—Фатих!—дип кычкырды Тукай.—Уйный торган сүз түгел.

Фатих үтә тыныч иде:

—Мин уйнамыйм, яшьтәш!—диде Фатих.—Ул охранка белән бәйләнештә иде.

«Синең тирәдә шикле кешеләр йөри. Сак бул син аннан, Бикчурадан»,—дигән иде Сәгыйть.

—Бу бит башка сыймый, Фатих! Ничек! Ни өчен?—дип ачыргаланды Тукай.

—Китереп кыссалар сыя ул, дустым,—диде Фатих.—Охранканың җәзалау, куркыту, шантажлау ысулларын белмисең шул син, Тукай.

—Аның охранкада икәнен син белә идеңме?—диде Тукай.

—Белә идем.

—Миннән яшереп, монда әллә ниләр эшләнә, бары тик мин генә белмим!

Тукай телеграмманы өстәлгә ташлап, Фатихка аркасы белән борылды.

—Үпкәләмә, дустым!—диде Фатих аклангандай.—Иң якын дустыңа да бар белгәнеңне сөйләп булмый торган замана бу.

—Рәми монда ни сөйләнсә, шуны җиткереп торганмы?

—Юк! Озак тарткалашты ул китереп кыскач, әнә качты. Тукайны сатмас өчен, вөҗданын пычратмас өчен барыбыздан да качты. Охранкага шул кирәк тә иде. Әләкләп торса да аларга файда, качса да аларга тынычлык. Олы бер шагыйрьсез калган Казанда охранкага эш кими.

—Коточкыч Казан!—диде Тукай.—Нинди мәмләкәттә яшибез соң без?

Дус дусны сата. Татар башын татар ашый.

Икесе дә тынып калды. Мәхмүт кенә битараф рәвештә рәсемле китап актарып утыра. Тукай ике учы белән йөзен каплап, терсәкләрен өстәлгә терәп, нидер уйлый. Фатих Әмирхан сул кулындагы йөзеген бертуктаусыз бөтерә, йөзек кашындагы асылташны беренче күргәндәй тикшерә, өйрәнә иде. Ул Тукайга нидер әйтергә җыена иде, ләкин Тукайның шушындый уйчан, хәсрәтле халәтен күреп, ашыкмый, форсат көтә. Ниһаять, ул тәвәккәлләргә булды.

—Икенче яңалык...—диде дә Тукайга карамыйча гына.—Исхак Бикчура... асылынган,—дип өстәде.

Тукай әле Сәгыйть Рәми турындагы уйларыннан аерылмаган иде, күрәсең.

—Ни дидең?—дип сорады.

—Бикчура асылынып үлгән,—дип кабатлады Фатих.—Әнә, язуы.

Мәхмүт куен кесәсеннән чыгарып, Тукайга бер язу бирде. Тукай аңсыз хәрәкәт илә язуны алды, аның күз аллары томанланды, ахрысы, ул Мәхмүткә язуны сузып:

—Укып бир әле, энем, күзем күрми,—диде.

Мәхмүт язуны алды, ләкин язуга карамыйча гына: «Үзегезгә булсын дөньягыз!»—диде.

Тукай ике күзен учы белән каплап, мендәргә ауды. Елавы идеме шагыйрьнең, әллә күзе авыртуны басар өчен шулай капландымы, ул ачынып:

—Исхак җаным!—диде.—Әле күптән түгел генә монда булды. Шушы сүзләрне миңа әйтте. Мин аны усал шаяру буларак кабул иттем. Нигә? Ни өчен? Бер аңа гына түгел, тормыш барыбызга да авыр.

—Тормыш авырлыгыннан асылынмыйлар,—диде Фатих басынкы усал тавыш белән.—Ике аягы, ике кулы, ике күзе булмаганнар да тормышка ябышып ята. Вөҗданы саф булмаган, димәк.

Тукай мендәрдән калкып, күзенә сөлгесен каплады.

—Сәгыйть әйтте бит, биш-ун тапкыр әйтте: сак бул син аннан, диде. Димәк, алар бергә эшләгән?.. Менә сиңа ике югалту... Сәгыйть белән Исхак ни өчен жандармериягә ялланган? Аңлый алмыйм!

—Ялланмаган!—диде Фатих.—Яллатылган... Ялланырга теләмәгәннәрнең язмышы белән таныштыргач, әллә кемнәр яллана, яшьтәш дустым... Поезд астына кергән, мәрхүм. Исерек килеш катып үлгән, бичара. Печән Базары рәтчеләре кыпты белән чаппахлаганнар.. Андый алымнар мең төрле, дус. Инквизиция һаман яши, инквизиция һаман чәчәк ата...

Тукай сөлгесен карават башына элеп куйды, ике кулы ике тез арасында ихтыярсыз кала бирде.

—Сагышлы шагыйрь,—диде ул үзалдына сөйләнгәндәй әкрен тавыш илә.—Кеше ышанмаслык эшләр бит бу... Бичара Бикчура... бүрек ташлап бүредән котылып калырга уйлаган...

Бәхил бул, дус, мин һәм тиздән менәм дарга;
Туйсын ашап жансыз тәнне козгын-карга;
Тормыйм инде, бу дөньядан туйдым инде!
Монар чаклы торганмын мин гакыл тарга.

Димәк, Исхак Бикчурин намуссыз кеше булмаган. Намуссыз булса охранка акчасына рәхәтләнеп дуслар сатып яшәгән булыр иде. Бәхиллә безне, Исхак. Икейөзле булып яшәүдән котылгансың.

Исхак Бикчуринны җирләргә Тукай да барды. Исән чакта Исхакның Тукай артыннан, тагын әллә кемнәр артыннан шымчы итеп ялланганын белүчеләр

аптырады, Тукай нишләп йөри монда, янәсе. Исхакның җәсәден гүргә индерергә ул да сикереп төшмәкче иде, җинелчә генә хәрәкәт белән аны бу теләгеннән туктаттылар. Кабергә Габдерахман Мөрсәлим сикереп төште.

Җеназачылар таралып беткәч тә Тукай зираттан чыкмады. Ул ялгыз калырга теләп, ыгы-зыгы вакытында тын гына читкә китте. Максатсыз гына каберләр арасында уйланып йөрде, әйтерсең лә ул үзенә урын сайлый иде. Шулай байтак йөргәннән соң, ул кайтыр якка борылды, зират капкасы төбендәге теләнчеләр, кулларын сузып, аннан хәер эстиләр. Ул кесәсендәге бар акчасын теләнчеләргә өләшеп бетергәч, кызурак атлап китте. Хәерчеләр сугыша-талаша артта калды, ләкин араларыннан берсе Тукай артыннан иярде. Тукайның акчасы беткән иде, ул адымын тизләтте, ләкин хәерче дә тизрәк атлый башлады. Бөкре йолкыш аны тиз куып җитте дә:

—Мияү!—диде.

Тукай бу сәер тавышка борылып караган иде, Шәүләне танып алды.

—Перес, хайван!—дип кычкырды Тукай.—Сиңа клоун буласы гына калган, Шәүлә. Кырык кыяфәткә керә беләсең.

—Мин—актер!—диде Шәүлә турая төшеп.—Мин—гений перевоплощения. Сәхнәдә әверелеш даһие мин.

Алар янәшә атлап китте, Тукай бераз алдарак, Шәүләнең яннан теркелдәп баруы читтән караган кешегә хуҗасы артыннан ияргән эт кебек күренгән булыр иде.

—Син зерә укымагансың, Шәүлә,—диде Тукай.—Синнән менә дигән театр белгече чыгар иде. «Актерское перевоплощение» гыйбарәсен ничек матур тәрҗемә иткәнсең. Актерның сәхнәдәге әверелеше. Бәлки, алмашынышыдыр?

—Алмашынуның башка мәгънәсе бар, әфәндем: акылдан язу.

—Ә «герой любовник»ны ничек әйтер иден?

—Мәхәббәт каһарманы!

—Дөрес бит, әй!—диде Тукай көлә-көлә.—Ә героиня?

—Мәхәббәт гүзәле!—диде Шәүлә.

—Афәрин!—диде Тукай.—Дөрес бит. Безнең театр тәнкыйтьчеләре «әсәрнең төп герое, героинясы» дип авыз суы корыталар.

—Наданнар!—диде Шәүлә һаман теркелди-теркелди.—Әйттем исә кайттым, әверелеш сәхнәдә генә түгел, тормышта да гел булып тора ул. Сине дә зур әверелешләр көтә, Тукайҗан. Кайгы көтә сине, шагыйрь.

Тукай туктады. Шәүләнең иңбашыннан умырып тотты да:

—Нинди кайгы?—дип сорады. Шәүлә бер дә исе китмичә генә:

—Беренчесе-соңгысы түгел, кайгырма!—диде.

Тукай Шәүләне каты итеп үзеннән этеп җибәрде дә:

—Бәгырьсез син, Шәүлә!—диде.—Кешегә кайгы килүен каркылдыйсың.

Шәүлә янә Тукайга елышты, кесәсеннән бер төргәк гәзитә чыгарды.

—Минем囗 эштә бәгырь комачаулый гына ул, Тукай,—дип, ачып бөкләнгән бер гәзитәне дәшмичә генә Тукай күзләренә якын китерде.

Тукай гәзитәдәге таныш рәсемне күреп, туктады, гәзитәне тартып алды, укый башлады. Уку дәвамында ул агарды, хәле китте, артка таба чигә башлады.

—Тукай!—дип кычкырды Шәүлә.—Тукай, сиңа ни булды?

Шәүлә Тукайны култыклап алды, да якындагы калку җиргә утыртты.

— Кабахәт син, хәерче!—диде Тукай.

—Кабахәт, кабахәт, килешәм!—диде Шәүлә.—Тик син егылма гына.

Тукай, бераз хәл җыйгач, тагын гәзитәгә бакты, бераз укып карады.

—Хөсәен Ямаш вафат!—дип ыңгыраشты.—Хөрмәтле Хөсәен дустыбыз үлгән... Ничек үлгән? Ни өчен?

Тукай гәзитәне тәфсилләп укыр дәрәҗәдә түгел иде, Шәүлә ипләп кенә аның кулыннан гәзитәне алып, салмак кына укый башлады:

«... мәшһүр революционер Хөсәен Ямашев әфәнде вафат булды. Хөсәен Ямашевның гаять серле һәм шикле шартларда вафат итүен гәзитә идарәсе әгъзалары бәян итә. Үләргә ике минут кала мәрхүм почмактагы лавкадан бер стакан җимеш суы эчкәнлеген әйткән. Бу шикле эшне тикшерү өчен докторлар китертелде һәм җимеш суы сатучы янына тикшерүчеләр озатылды...»

Тукай инде Шәүләне тыңламый иде. Бетә, кырыла татар зыялылары. Күз алдында ничә кеше китте. Берсе дә үз үлеме белән түгел. Хәзер кемгә чират? Тукайгамы? Фатихкамы? Божра кысыла, тарая. Канатларын җәя ике башлы Каракош. Сәер үлемнәр, сәер җинаятьләр берлә тулган Казан.

—Беләм мин аны,—диде Шәүлә.—Ул революционер иде.

—Уйларыма кермә, Шәүлә!—диде Тукай.

—Үлгән артыннан үлеп булмый, дим... Бүген син бар, иртәгә юк...

—Каркылдама, карачкы!—дип кычкырмакчы булган иде дә, Тукай кинәт ютәлли башлады. Ютәл аша ул:—Күземнән югал! Эттән туган дуңгыз баласы, син яман хәбәр белән генә йөрисен, кит!—диде.

Ләкин әрсез хәерче китмәде. Киресенчә, ул Тукайның ике култык астыннан тотып торгызды да:

—Әйдә, өйгә кайтабыз, монда салкын, җил,—диде.

Әле генә Шәүләгә нәфрәтле булган Тукайның аңа буйсынмыйча хәле юк иде. Алар икәүләп әкрен генә шәһәргә таба кузгалды.

Эттән күбәйде дошманнар... Нишли алар? Нишли халык? Халык упкынга бара, саф гакылларга богау салалар кабахәтләр. Күпме калгандыр гомер? Шул мизгелләрне тулысы белән файдаланып калыйм дисәң, төрле яклап изәләр. Кая барыйм? Нинди мохит бу? Кайда шат-тәбәссемле хәят? Авыр уйлар сытты гакылымны. Агуланган тәнем җир куенына тарта. Артыма борылып карасам, сызланам. Юк майтарган эшем. Алга карыймын да үксеп җылыйм. Бетте көчем...

Зират дымлылыгымы, җәяү кайткандагы салкын җилме, әллә бер-бер артлы ишелеп төшкән кайгыларммы аны изде, Тукай тәмам хасталанып урынга ятты. Бер атна өзлексез ютәлләп, ашамый-эчми, саф һава күрми бүлмәдә аунаганнан соң ул әкренләп торып йөри башлады. Бераз рәтләнде. Шул көннәрнең берсендә аның бүлмәсенә Зәйтүнә туташ килде. Тукай эчтән генә бер сөенде, бер көенде. Зәйтүнәне күрү бәхет булса, шушы зәгыйфь кыяфәттә кызлар алдында утыру читен хәл иде.

Туташ бүген аеруча гүзәл иде. Ул матур итеп киенгән, кулына чәчәк бәйләме тоткан.

«Гаҗәп, дип уйлады Тукай, кыш азагында бу тере чәчәкләрне кайдан ала икән бу туташ».

—Минем сөенчем бар!—диде туташ Тукай каршына утыргач.—Сөенчем шул, соңгы вакытта матбугатта сезнең шигырьләрегез бик еш басылды. Гаҗәп истидатлы әсәрләр, әфәндем. Бер яктан куәтле сатирагыз, шаян әсәрләрегез халыкның рухын күтәрә. Икенче якта мәхәббәт лирикагыз гаҗәеп бер омтылыш белән яшьләрнең күңеленә кереп урнаша. Алар бер укуга күңелгә сеңә.

Тукай тарсыну кыяфәтендә иде, ул теләр-теләмәс кенә сүзгә кушылды:

—Сез укыйсыз, алар сезнең күңелгә хуш килә, халыкның бер өлеше шул әсәрләрем өчен мине каргый.

—Сез андыйларга игътибар итмәгез!—диде туташ.—Кизәнгәнсез икән—сугыгыз. Суккансыз икән—үкенмәгез. Кәефегез юкка шул гына сәбәп булса, ташлагыз. Сезгә курку харам...

Туташ туктады. Тукай дәшми. Сөйләшергә яңа тема кирәк иде.

—Мин атам белән анама сезнең белән һәр күрешү хакында сөйли барам,—диде туташ.—Борчылмагыз, минем алардан яшерен серем юк. Алардан сер чыкмый. Беләсезме, җәй уртасында мин сезне авылга алып китәрмен. Кызык булыр. Безнең якта кымыз да бар. Кызык та бар. Казы да бар. Кубыз да бар. Кыз да бар.

Зәйтүнә туташ яңгыратып көлә башлады. Тукай да елмая иде. Нинди самимилек. Хәтта сабыйлык, дияргә була. Бу сафлыкка карап сөенмәү мөмкин түгелдер ул. Тукайның кәефе күтәрелә башлаганын күреп, туташ тагын да җанлана төште, ул ак чәчәк алып, Тукайның күкрәгенә кадап куйды.

—Матур!—диде туташ.—Сезгә килешә. Тукай да савыттан зәңгәр чәчәк алып, туташның түш якасына беркетте.

—Кайгыларымны таратучы зәңгәрсу чәчәк!—диде Тукай, ләкин ул инде тагын сагыш эченә чумган иде.—Чәчәк үзенең көче җиткән вак кайгыларны гына тарата ала. Кичерегез, туташ.

Тукайның кәефе киткәнен күреп, туташ хафага төште:

—Сезгә нәрсәдер булган, мотлак, ни дә булса булган, Тукай әфәнде,—диде туташ.—Сөйләгез, әфәндем, сөйләгез. Мин аңлармын. Зинһар, яшермәгез миннән!

Тукай эчтә нindidер олы карар кабул итте кебек, ул савыттагы чәчәкләргә карап, сүз башлады.

—Аландагы чәчәкләр өстендә, пәрәвездәге бихисап асылташларны мин тагын күрдем бүген. Әз генә ятып торган идем. Йокыга китәргә дә өлгермәдем шикелле, тирә-юнем мең төсле асылташлар белән тулды. Җыеп, сезгә бүләк итәрмен, дип үрелгән идем, күктән ике башлы каракош килеп чыкты да, канатлары белән давыл чыгарып, сәйләннәрне коеп бетерде... Туташ!—Тукай кинәт аягүрә калыкты, гадәтендә булмаганча, туташның күзләренә туры карап, кычкырыр дәрәҗәдә көчле тавыш белән:—Туташ... зинһар... безнең танышлыкны онытыгыз!—диде.

Туташ тораташ булды. Ул бераздан:

—Мин һич нәрсә аңламадым, Тукай әфәнде!—диде.

Тукай сабырлана төшеп:

—Кичерегез дорфалыгымны, зинһар,—диде.—Мина рәнҗемәгез. Мин алга таба сезнең белән күрешә алмыйммын!

Туташ әле һаман Тукайның тел төбен аңламый иде.

—Берәр яры китәсезме? Әстерханга яки Җаеккамы?—диде.

—Ераграк, туташ!—диде Тукай.

—Ерактан да кайтырсыз. Тагын Питербургамы? Хат язарсыз. Мин дә сезгә язармын.

Бу аңламау, яки аңламаганга салышу Тукайның ачуын чыгарды, ул турыдан-туры әйтте.

—Кавышмаган килеш безгә аерылышырга кирәк!—диде.

Ниһаять, Зәйтүнә туташ башына барып җитте, ул чарасыз калып башын иде һәм салмак кына:

—Ни-нәрсә үзгәрде шушы арада?—диде.—Без икебез бер җан кебек идек бугай...

Тукай инде авызлыкны тешләгән, аны туктатыр көч бу бүлмәдә юк иде.

—Ул сезнең фантазиягез, туташ, ул сезгә шулай тоелган гына. Ялган романтика! Без икебез ике кеше, ике аерым җан. Юллар аеры безнең, юллар...

Туташ, аягүрә басып, кинәт каты тавыш белән:

—Ышанмыйм!—диде.—Туры Тукай ул вакытта алдамады. Икесенең берсе ялган! Күземә карагыз, Тукай. Туры карагыз! Сезгә гайбәт ишеттергәннәр... Шулаймы? Сез мине Тукайга тиң санамыйсыз!.. Минем турыда гайбәт булалмый. Алайса ни сәбәп?..

Туташ кызганнан-кыза бара иде, ул инде әдәп-итагать сакларга тырышмый, ул үзенең мәхәббәте өчен соң мәртәбә көрәшкә атылды.

—Беләм, Тукай,—диде ул яшьләрен чак-чак тыеп.—Беләм, миңа сезнең белән яшәү бик кыен булачак. Сезнең холкыгыз фәрештә холкы түгел. Дошманнарыгыз күп. Сезгә яшәве көннән-көн кыен булачак. Сезгә дә, сезнең белән яшәүче хатынга да, беләм... Белгәнгә күрә, мин сезне сөямен!

Тукай үкереп елардай, шашып көләрдәй сәер халәттә иде, тагын бер-ике сүз әйтсә, Тукай туташның аягына егылачак һәм икесе дә харап булачак. Тукай кинәт аягүрә басып, каты тавыш белән:

—Мин сезне сөймим!—дип кычкырды.

Мең көзге ватылгандай, һава чәлпәрәмә килде, чәлпәрәмә килде дә бүлмәдә табигый булмаган тынлык урнашты. Тукай кычкыруы өчен гафу үтенгәндәй, сабыр тавыш белән әйтте:

—Шуны аңладым менә шушы вакыт арасында, Зәйтүнә туташ,—диде.

Туташ та инде сабыр иде.

—Туры Тукайның беренче һәм соңгы ялганы!—диде ул.

Шулай диде дә туташ тәвәккәл атлап чыгып китте. Тукай ул киткәч тә байтак кына хәрәкәтсез утырды. Аннан соң өстеннән олы йөк төшкәндәй әйтте:

—Хуш, бәгърем, мәңгегә бәхилләә бу ялганымны!—диде.—Мәхәббәт шигырьләремнең илһамчысы, хуш, бәхил бул! Әл-аман, туташ, әл-аман. Әлвидаг, туташ, әлвидаг!

Ул мендәренә капланды, аның арык җилкәсе җиңелчә генә калтырана иде: ютәллиме Тукай, әллә җылыймы?

Фатих Әмирхан Зәйтүнә туташның Тукай бүлмәсендә икәнен белә иде. Ул ике яшь йөрәкнең бергә кушылуын бөтен җаны-тәне белән тели, Аллаһка ялвара иде. Туташ белән Тукай сөйләшеп бетергәнче Кабан күле буйлый әйләнеп кайтырга булды. Мәхмүт арбаны коридорга алып чыкты, инде киттек дигәндә генә Тукай бүлмәсенең ишеге ачылып китте, аннан Зәйтүнә туташ килеп чыкты, кеше күзенә күренмәскә тырышып, битен кечкенә сумкасы белән каплап, туташ йөгерердәй булып, тиз атлап беренче катка төшеп китте. Фатих Әмирхан аның белән исәнләшергә дә, туктатып сораштырырга да өлгермәде. Мәхмүт аңлады, арбаны урамга түгел, Тукай бүлмәсенә таба этәргә кирәк иде.

—Тукай, бу ни эшең?—диде Фатих бүлмәгә кереп җитмәстән.—Туташ тыела алмыйча җылый-җылый, битен каплап китеп барды. Синме аны рәнҗеттең?

Фатихның бу эшкә килеп катышуын Тукай өнәп бетермәде, ул канәгатьсезлеген яшермичә:

—Синме булдың адвокат!—диде.—Юат, син бит высший круг кызларын юатырга өйрәнгән!

—Тукай әфәнде!—дип кычкырды Фатих Әмирхан.—Минем белән шундый тонда сөйләшергә кем рөхсәт итте? Извольте аңлатырга? Нигә җылый кыз бала? Аның ни гаебе бар?

—Мин җыламыйммы, Фатих!—диде Тукай.—Күр! Мин аннан да катырак җылыйм, ләбаса. Минем күз яшьләрем аныкыннан мең кәррә әчерәк.

Булды, икесе дә бер-берсенә кычкырды. Җитте. Инде сабырланырга вакыт. Фатих Әмирхан, киеренкелекне киметер өчен, Тукайга якынрак килде.

—Ни өчен ачуланыштыгыз?—диде.—Хәер, татуланышырсыз әле.

Тукай да үзен бераз гаепле саный иде Фатих каршында. Ул сабыр гына әйтте:

—Без ачуланышмадык, Фатих,—диде.—Кушылмыйча аерылдык. Шулай мәгъкуль. Кем мин? Ул әйтә, күземә туры кара, ди. Ә миндә...—Тукай ун

күзенә уч төбе белән сугып алды.—...печать проклятья! Ул—назик хисләр иясе. Ул—нәфислек алиһәсе. Мин—чир баскан, шик баскан бер буйдак.

Фатих Әмирхан дустының холкын бик яхшы белә иде. Юкка кимсетә Тукай үзен. Ул беркемнән дә ким түгел. Ул әйләнә-тирәдәгеләрнең барысыннан да югары кеше. Аның бу сүзләре хәйлә генә булырга тиеш. Туташ белән ара өзүнең башка бер җитди сәбәбе булырга тиеш. Аның уйларына җавап шикелле Тукай сүзләре ишетелде:

—Шул фәрештәгә өйләнеп, аны бәхетсез итимме? Ул гүзәлләр гүзәле, ул газәлләр газәле, олуг бер мәхәббәткә ия булырга лазем.

Чынлыкта Зәйтүнә туташ өчен Тукай мәхәббәтеннән дә олуг мәхәббәт юк иде. Туташ Тукай белән бәхетсез булуны бәхет саный иде кебек.

—Кире кайтарыймммы?—диде Фатих арбасын ишеккә таба борып.

Тукай кискен рәвештә:

—Юк!—диде.—Юк, уйнама, Фатих! Киселде, мәңгегә киселде бу җеп. Киселде бу бәгырь. Киселсен. Бәгырем киселгәндә мәхәббәтнең сагышлы бер кылы өзелеп зың-н-ң итте. Их, Фатих дустым, шушы сөюем мине бәхетле итә дә, әнә шул өзелгән кылның сызылып-сызылып зыңгылдавы әче бер ләззәт тә бирә. Белмисез шул сез яшерен сөюнең, тормышка ашмас мәхәббәт газабының ләззәтен. Белмисез!

—Алайса, нигә кирәк иде туташ белән бу көрешүләр?—диде Фатих Әмирхан.

—Бүген генә, хәзер генә аңладым,—диде Тукай.—...мәңгегә кисәргә кирәк икәнен... Туташка өйләнүем зур гөнаһ булыр иде. Башкага мин өйләнә алмыймын. Өйләнер идем, куркам. Кем булып чыгар минем хатын? Чорт белә! Өйләнерсең—бала-чага. Үстер, укыт, тәрбия кыл. Хатын көенә бие. Туганнары белән талаш. Мин бала яратам, хатынны чит күрмәс идем. Юк! Минем өчен түгел андый тормыш. Мин тулаем халыкныкы, Фатих! Башым, иҗатым, авыруым белән мин халыкка кире кайтарып алмаслык итеп тапшырылган зат. Мин гаиләдә вакланып бетсәм, халыкка ни калыр? Шуңа күрә, мин беркайчан да өйләнмәскә уйладым.

—Хәйләкәр Тукай!—диде Фатих юри бармак янап.—Дәлилләр уйлап чыгарырга син оста. Ләкин боларның барысы да сылтау гына. Сәбәп тирәндәдер.

—Әйттермә, Фатих!—диде Тукай кискен рәвештә.—Мин туташны сөйгән кебек берәү дә сөя алмый. Шушы арык тәндә тауларга сыя алмаслык гыйшык дәрте ята. Ләкин туташны бәхетсез тол итәсем килми!

—Тукай!—диде Фатих ачынып.—Син...

—Дәшмә!—диде Тукай, аны бүлдерде.—Башына китер, ять-яшь, гүзәл тол хатын. Аягүрә әрәм булачак. Мин үлемгә хөкем ителгән, Фатих. Дәшмә! Шулай! Син генә бел! Ә хәзер кит! Ялгыз калыйм!

Фатих Әмирхан кыйнап ташланган кебек иде. Ул инде чарасыз. Тукай ике сөйләшмәячәк. Чыгып китү хәерлерәк булачак иде. Алар артыннан ишек ябылгач, Тукай арлы-бирле йөренеп алды да чәчәкләргә карап:

—Менә шулай җинелрәк булыр, Апуш!—диде.—Тукайга әверелә барган саен йөгең авырая. Шулай кысты сине, Апуш, кысты язмыш. Дөньяда үз мәхәббәтеннән качкан берәү булырмы? Үз мәхәббәтен табалмыйча үлеп киткән бичаралар бихисаптыр. Ә мин мәхәббәтемне таптым. Сөйдем. Сөйгеле булдым. Үз кулларым белән, үз сүзләрем белән кире эттем. Әйт, син, Апуш, бер мизгел мәхәббәт ләззәте өчен корбан итә ала идемме мин туташны? А-а, юк! Үкенмә! Кылган батырлыгыңа үкенмә!

Зәйтүнә туташ белән соңгы сөйләшү вә аның сагышлы нәтиҗәсе Тукайны бөкте. Ул инде хаста рәвешен ала бара иде. Әнә шулай авырып яткан көннәрнең берендә аның бүлмәсенә тагын Шәүлә килеп керде. Аны

күрүгә Тукай ризасызлык илә кычкырды:

—Мин өйдә юк! Мин авырыйм! Йөрмә монда, карачкы Шәүлә!—диде.

Ләкин Шәүлә аның кууына исе китмәде, ул бүген бөтенләй башкача кыяфәттә иде, бөкрелеге дә әллә кая киткән, йөреше дә городовойныкы кебек иде.

—Монысында без синнән сорап тормаска булдык, Тукаев әфәнде!—диде Шәүлә түргә уза-уза.

—Кем инде ул «сез»? Николай патшамы?—диде Тукай.

—Без!—диде горур хәерче.—Николай патша булмасак та, жандармерия идарәсенең өченче бүлеге әһелләре!

Шулчак бүлмә эчендә могҗиза булып алды. Шәүлә үз өстендәге әләмә-сәләмәләрен салып ыргытты. Элеккеге йолкыштан мәһабәт бер кешегә әверелде. Тукай, циркта утыручы тамашачы кебек, авызын ачып карап тора иде. Ул әле һаман Шәүләнең бу әверелешен аның бер кәмите генә дип уйлый иде, ахрысы.

—Чираттагы әверелешеңме, күрәзәче Шәүлә?—диде хуҗа.

—Юк!—диде кәттә кыяфәтле ир.—Чираттагы эшемнең ахыргы нәтиҗәсе, Тукаев-әфәнде. Күрәсез ки, мин үз эшемне шактый оста башкарам. Бу операциягә нокта куярга вакыт җитте!

Ул Тукай йөзенә ниндидер бер катыргы төртте. Тукай барысын да аңлады.

—Аһ, шулаймыни?—диде ул.—Елан тек елан...

Тукай көлә башлады.

—Рәхмәт, әфәндем,—диде кунак.—Бу миңа бик зур комплимент. Мәдхия!

Тукайга көлүдән башка чара калмаган иде. Ул һаман елмаеп Шәүләгә карап тора, үзе сөйләнә:

—Хәшәрәт! Казы белән сыйладым бит мин бу хәерчене, кызганып. Күрәзә караган саен берәр сум көмеш бирдем бит шул сатлык җанга.

Шәүлә бу сүзләргә җавап бирмәде, әмма әйтте:

—Беләсенме,—диде ул.—Барыбер мин сине яратам, Тукай. Сүксән дә, типкәләсән дә, яратам.

—Сөя-сөя суясың, ярата-ярата таркатасың, юха елан,—диде Тукай.

Шәүлә Парижларда гына тектерелә торган костюм кигән, ап-ак крахмал якадан, кыйммәтле ефәк муенчак бәйләгән, ике кулында ике балдак елкылдый, кулында нәзек, затлы таяк уйный. Оста уйната ул таягын, ике бармагы белән өзлексез әйләндереп тора ала. Әйтерсең лә ул Тукай алдында цирк номерлары күрсәтергә килгән. Осталыкларын күрсәткәннән соң, ул назлы тавыш белән Тукайга эндәште:

—Син, Тукай, бик тә сихерле кеше бит,—диде.—Синең артыңнан шымчылык итәргә алынган агент үзеңне ярата башлый. Синең өстән язарга теләми, сине яклый башлый. Сагышлы Сәгыйть Рәми качты. Бикчура асылынды. Полковник Старосветовтан миңа боерык булса да, мин сиңа кагылмадым. Мин сине харап итәр урында саклап йөрдем. Әйе, әйе, мин булмасам, сине әллә кайчан бетерәләр иде. Үзегезнекеләр үк. Яңа Бистә, Печән Базары әһелләре сине мең тапкыр үтерә иде. Мин аларның юлын кисә бардым. Тукайга кагылсагыз, бөтенегезне кырып бетерәм, дидем. Кагылмадылар.

—Рәхмәт инде!—диде Тукай мыскыллы елмаеп.—Үзең үтерер өчен башкалардан саклап калганыңа күрә, мең шөкер. Хезмәтең өчен әнә, өстәлдә сынык казы белән илле тиен бакыр бар, ал!

Шәүлә рәхәт көлә башлады.

—Тукай һаман Тукай булып кала!—диде чакырылмаган кунак.

—Хәзер сәбәбен әйт инде, Шәүлә!—диде Тукай.

—Тукай—мәшһүр, Тукайга тартылалар!—диде Шәүлә.—Тукай миңа жим буларак кирәк иде. Алдавыч жим—ул Тукай. Государственный преступник Хөсәен Ямашевны розыск ничә еллар тота алмады. Ә мин тоттым. Әһә, минәйтәм, бу хәйләкәр төлке Хөсәен Ямашев Тукай дигән жимгә килми калмас, һәм хак, чиертте Ямаш Тукай дигән жимгә. Килде Хөсәен Тукайга, һәм тотылды... Авыр туфрагы җиңел булсын. Менә ни өчен мин Тукайны җаным кебек сакладым.

—Революцияне буучы палач син!—диде Тукай нәфрәт илә.

Ләкин Шәүләнең ачуын чыгарып булмый иде. Ул елмая-көлә сүзен алга сөрде:

—Ялгышма, Тукай!—диде ул усал елмаю аша.—Чын революцияне яклаучы мин. Революция ясаучыларның туксан проценты надан була. Биш-ун хыялыйның идеясенә котырып, наданнар баш күтәрә. Баш күтәрү вакытында акыллылары үлеп бетә. Революция юлы уртасында шыр наданнар гына торып кала. Баралар наданнар, кая барганнарын белмиләр. Кая барабыз соң без, барабыз да барабыз, дип сораганнарны әлеге наданнар революция исеме белән кырып ташлыйлар. Зыялылар бетә, аек фикерлеләр атыла, шиклеләрне асалар. Алай-болай булмагае дип, һич гаепсезләрне дә төрмәләргә тыгып бетерәчәкләр. Илне шом, деспотизм шаукымы басачак, һәр палач, гөнаһсыз башны чапканда, «Бисмилла» урынына: «Яшәсен революция!» дип акырачак. Менә нәрсә ул революция. Ямашев Хөсәен хыялланган революция ул революция түгел, ул ирексезләү, көчләү хәрәкәте генә булып калачак. Әгәр дә Ямашлар җиңә калса, Русияне «грядущий хам»—тупаслык, әдәпсезлек басачак. Русия әле чын революциягә әзер түгел. Мин менә шуннан куркам, Тукайҗан. Әнә шундыйлар, Ямашлар, Лениннар Русия халыкларын ялгыш юлдан алып китмәгәйләре дип, бөтен көчемне, талантымны җигеп көрәшәм.

—Революция җиңсә, революцияне буып торучы Шәүлә ни кылыр икән?—диде Тукай.

—Сабый син, валлаһи,—диде Шәүлә.—Һәр хөкүмәткә өченче отделение кирәк булачак. Любой власть алмашыначак, без алмашынмабыз. Без яңа властька да хезмәт итә алабыз бит. Без, Тукай әфәндем, принципсызлыкны принцип итеп алган бәндәләр. Даһиларны даһи иткән—без. Без булмасак, сезнең кадер булмас иде...

Тукай үз гомерендә сафсата сатучыларны күп күрде, ләкин әле кабахәтлекне бөеклек дип, һәр караны ак дип әйтүчеләрнең мондыен очратканы булмады. Ул аптырашта иде.

—Кыенлык күрмәгән шәхес зур шагыйрь була алмый,—диде Шәүлә.—Шагыйрьне биографиясе бөек итә. Ә сезнең биографияне без ясыйбыз, туган. Сезгә кыенлыклар тудыру һәм сезне бөек итү безнең төп максатыбыз. Булгарин булмаса, Пушкин булмас иде. Булгарин—стимулятор. Булгарин—катализатор. Дошманнары булмаса, Пушкин Пыскын булып кына калыр иде. Пушкин дошманнарына үч итеп, Булгариннарга ачу итеп, аларны таланты белән, әсәрләре белән күмеп ташларга теләп иҗат итә, сугыша, эпиграммалар яза, ягъни үзенә һәйкәл әзерли. Моцарт булмаса, Сальери, шулай ук Сальери булмаса Моцарт була алмас иде. Кем соң ул Герострат? Изге храмга ут төртеп, дан яуламакчы булган бер бәндә. Ә исеме чыннан да тарихта калган бит. Ә мин кем соң? Бер шәүлә. Әмма ләкин Тукайны даһи итәргә алынган шәүлә. Тукай белән беррәттән минем шәүләм дә еллар, гасырлар буе ияреп йөрер...

—Никадәр көч сарыф итеlә, никадәр акча түгелә. Барысы да бер Тукайны бетерер өчен,—диде хуҗа.

—Ялгышасың,—диде Шәүлә.—Тукайны гына түгел, татар халкын бетерер өчен.

—Татар халкы белән Тукай тәнгәлмени?

—Урыс халкының иң зур дошманы—татар. Ә шул татарның жаны син—Тукай!

—Татар халкы урыска дошман түгел.

—Тукай һәр урыс әйберсенә дошман. Диненә, культурасына, халкына. Син татар халкын да урыска каршы котыртасың.

—Мин Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам. Толстойны егылып укыйм, Шаляпинның сәнгатенә гашыйкмын.

—Пушкин да, Лермонтов та монархиягә каршы. Шаляпин да күзәтү астында. Ул да маевкаларда катнашкан жинаятьче. Шуларга теләктәшлек белдергәнең өчен генә дә синең муеныңа кызыл камыт кидерергә була.

—Димәк, татар урыс халкына тулаем каршы түгел!

—Татар дошман урыска, һәр фетнәнең башында татар тора. Разин, Пугачевлар артыннан сиксән процент татар күтәрелде хөкүмәткә каршы. Бүген дә татар халкы Пугачевны көтеп ята. Син Пугачев белән Разиннан да куркынычрак хәзер самодержавие өчен. Менә ни өчен Тукайны изеп бетерү кирәк иде!

—Петрның Персиягә походында да, Наполеонга каршы да, Порт-Артур сугышларында да бихисап татар халкы урыс жире өчен һәлак булганлыгын сез күрмәмешкә салышасыз, әфәндем. Татар фетнәче түгел, тыныч вакытта ат кебек, ишәк кебек Русиягә эшләп, сугыш чыкса, жаны-тәне белән Русияне дошманнардан саклаучы тугры эт ул татар, әфәндем. Татар булмаса, урыс халкы нишләр иде икән тарихта! Халыкка каршы халыкларны сез котыртасыз. Сез бөтен фетнәнең башында.

—Менә монысы дөрес, фетнәләр башында мин. Бикчураны мин шул хәлгә китереп житкерүче... Дөрес, сагышлы Сәгыйть Рәми качты. Бездән алай гына качып котылып булмый. Ул анда озак тора алмаячак. Театрларын, журналларын ябып бетергәч, өненә егерме чиләк су салган әрләндәй, ул өскә калкачак. Дөрес, Хөсәен Ямашны да... урыны жәннәттә булсын... без юк иттек.

—Хәзер чират миңамы?

—Хәзер чират синеке, Тукай!—диде Шәүлә кесәсеннән кәгазь чыгарды.—Менә сине алырга ордер! Ләкин мин сиңа кагылмаячакмын.

—Ни өчен? Казы белән сыйлаганыма күрәме?

—Юк!—диде Шәүлә һәм артык житди итеп өстәде:—Син үлемгә хөкем ителгән инде!—диде.

Тукай жәһәт кенә Шәүләгә бакты. Юк, Шәүлә шаяртмый иде.

—Мин докторлар белән сөйләштем. Беләм. Бөтен жиргә телеграммалар сугучы да мин. Һәм Хөсәен Ямашны шул телеграмма чакырып кайтарды. Синең соңгы сәгатьләрең, Тукай! Шуңа күрә, мин сиңа бөтен нәрсәне ачык сөйләргә тиешмен. Тагын бер хәбәр бар синең өчен...

Шәүлә юри туктап сүзен өзде, ул Тукайга соңгы үлем жәрәхәтен әзерли иде. Тукай сагайды, шомланды.

—Нинди хәбәр ул? Әйт тизрәк! Мин барысына да әзер!—диде ул.

Шәүлә серне озаграк тотып торырга тырышып, бүлмә буйлап йөренеп алды да кылыч белән чәнчегәндәй хәрәкәт ясап:

—Моннан чыгып киткән туташ үзен-үзе суга ташлаган!—диде.

Тукай сабыр иде:

—Ялган!—диде ул тыныч кына.

—Хакыйкать, Тукай!—диде шымчы. Тукай үзен-үзе белештерми Шәүләгә ташланды да:

—Ялга-ан!—дип кычкырды.

—Туташ үзен-үзе суга ташлаган!—дип кабатлады Шәүлә.

Тукай, чыннан да бәгыренә пычак чәнчелгән кебек, сыны катып торды, аннан соң бөгелеп төште. Шәүлә каушап калды, ул моны көтмәгән иде,

ахрысы, ишек ягына карап:

—Әй, кем бар анда?—диде.

Ана җавап бирүче булмады. Ул, бөгелеп төшкән Тукай янына килеп, ин өстенә кулы белән кагылды.

—Тукай, сиңа ни булды? Мин юри әйттем, Тукай,—диде җасус.

Тукай әкрен генә аягына басты, турайды, күкрәк тутырып сулыш алды да шашкандай көлеп җибәрде:

—Шүрләденме, Шәүлә?—диде.—Үлде бу дип курыктыңмы? Юк, мин үлмәдем әле. Мин акылдан да язмадым, курыкма... Мин үләсемне докторларга кадәр дә, сиңа чаклы да яхшы беләидем. Син мине үлем белән куркыта алмыйсың хәзер. Үлемгә мин җырлап барачакмын. Чөнки мин беләм, без түккән тирләр, койган каннар бикяр булмас! Безнең көрәш файдасыз калмас, иншалла. Мин үлсәм, татар дөньясында Әмирханнар, Рәмиләр, Карилар, Сәхипҗамаллар, Камаллар кала. Барыбызны да үтереп бетерә алмассыз. Татар бетсә, урыс ни ашар? Кемне ашар?

Тукай иркен, көчәнүсез, рәхәт көлә иде.

—Соң шулай булгач, мине үлем куркыта аламы, дивана Шәүлә! Базар карачкысы, жандарм күсесе. Әгәр милләт мине, илтифат итеп, искә алса, шул минем максатым, теләгем һәм бәхетем...

Кыйналып-суелып бетмәгән, Шигъри динем, исән бул!

Изелеп-кырылып үлмәгән, Татар халкым, исән бул!

Шулчак ишектә Мәхмүт күренде:

—Тукай абый, аста сине җигүле атлар көтә!—диде.

Тукай ачык ишеккә таба атлады һәм Шәүләгә борылып, басынкы, катгый тавыш белән әйтте:

—Татар халкы ул—алабута, Шәүлә! Алабутаны бетерер өчен аны йолкыйлар, йолкыганда алабута орлыклары читкә чәчелә, икенче елны шул урынны тагы алабута баскан була. Алабута үрчетәсең килмәсә, аңа кагылмаска гына кирәк. Кагылмагыз татарга!—диде.

Тукай чыгып киткәч, бүлмәгә хуҗа булып Шәүлә калды, ул ашык-пошык актарына башлады. Менә ул Тукай ятагын туздырып ташлады. Ятак тактасына олы гына хач-тәре ясалганын күреп ул шаккатты. Аннан соң ул язу өстәленнән ашъяулыкны тартып төшерде. Өстәлдә дә аркылы-торкылы сызык—хачны күреп шаша язды. Почмакта торучы тартма өстеннән китапларны сибереп түкте, тартмага да хач сурәте ясалган иде. Шәүлә кинәт шашып көлә башлады:

—Тукай гомере буе хач-тәре өстенә ятып яшәгән, хач-тәре өстенә басып иҗат иткән ләбаса!

## Соңгы юл

Казан өстендә азан тавышы:

—Аллаһу әкбәр, Аллаһу әкбәр...

Мәчетләр манзарасы. Мәһабәт манаралар, айлар балкый... Мөселманнар мәчеткә бара.

Бер теләнче:

—Ишеттегезме әле, Тукай вафат булган!—ди.

—Әстәгъфирулла!—ди икенчесе.

—Тукай үлгән!—ди бер кеше.

—Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун вә иннә ила раббина ләмүн калибун,—дип дога кыла башкалары.

Казан язны каршылый иде, Казан Тукайны соңгы юлга озата иде. Казан шәһәре өстендә азан тавышы яңгырый, Казан өстендә чиркәүләр чаң кага.

Гәзитәчеләр хәбәр тараталар.

—Сенсация, сенсация! Пырхавай заводы шартлаган, пырхавайда шартлау булган!

—Конка юлдан чыккан, ике кешене таптаткан.

—Бөек татар шагыйре Габдулла Тукаев вафат!

—Мәрхүмнең җәсадын Клячкин хастаханәсеннән алып чыгачаклар!

Ксенинский гимназиянең югары сыйныфында борчулы көн. Гимназия формасы кигән кызлар ике кызны урап алганнар да юатырга тырышалар иде. Уртада җылаучы ике кызның берсе атаклы мәгърифәтче Шаһбазгәрәй Әхмәровның төпчек кызы Заһидә, икенчесе мәшһүр нәсел Терегуловларның кызы Бибиәсма иде.

—Тише!—диде дежур торучы кыз:—Нина Владимировна идет!

Укучыларның барысы да үз урыннарына барып басты. Ишек ачылып китте, урта яшьләрдәге укытучы ханым килеп керде.

—Хәерле иртә, балалар!—диде укытучы.

—Хәерле иртә, Нина Владимировна!—диделәр кызлар.

Нина Владимировна кызларга бакты. Ул Заһидә белән Бибиәсманың җылаудан кызарган күзләрен күреп әйтте:

—Ни булды сезгә, Захидэ Гиреевна. Сезгә ни булды, Фатима Ибрагимовна? —диде.

Заһидә туташ әйтте:

—Шагыйребез Габдулла Тукай үлгән,—диде.

Заһидә тагын җылый башлады.

—Нина Владимировна!—диде Бибиәсма.—Зинһар, безне дәрестән җибәрегез әле, без Тукайны соңгы юлга озатышыр идек.

—Мир праху его!—диде укытучы.—Барыгыз, Ахмерова, Терегулова...—Аннан соң өстәп куйды:—Кем татар шагыйре Тукайны озатырга тели, китә аласыз.

Кызлар рәхмәт әйтеп, бүлмәдән чыкты, аларга тагын ике кыз иярде.

Генерал Старосветовның резиденциясендә бүген бәйрәм рухы хөкем сөрә иде. Көндез булуга карамастан, зур, якты залда йөзләгән шәм яна. Алтын белән йөгертелгән креслолар, диваннар... Старосветовка ватан алдында күрсәткән казанышлары өчен генерал дәрәҗәсе бирелде. Аның мундирында эполетлар белән рәттән алтын укалы генерал погоннары балкый. Бу погоннарны ул бүген беренче тапкыр тагып эшкә килде. Аның кәефе бик тә яхшы иде. Ул бик канәгать кыяфәттә ике кулын арка тарафында кушырып, тәрәзәдән урам якка карап тора иде.

Камердинер керде.

—Майор Саблуков килде, генерал әфәнде!—диде камердинер.

—Керсен!—диде генерал.

Камердинер юкка чыкты, Шәүлә керде.

Генерал тәрәзәдән аерылып Шәүлә тарафына йөреп китте. Ул Шәүләгә урын күрсәтте. Үзе өстәле арасына кереп басты.

—Рәхим итегез, Михаил Давыдович, утырыгыз! —дип генерал үз урынына утырды.

Шуннан соң гына Шәүлә үзенә күрсәтелгән креслога урнашты.

—Сез, чамалыйсыздыр шәт, ни өчен мин сезне чакырттым?—диде генерал.

—Юк, генерал әфәнде!—диде Шәүлә.

Генерал көлемсерәде:

—Сез чамаларга тиеш, Михаил Давыдович... Сезнең профессиягез шундый... Эчке сиземләвегез сезгә әйтергә тиеш иде... Сезгә, бер йолдызны

сикертеп, полковник дәрәҗәсе бирелде!

Шәүлә сикереп торып во-фронт басты да:

—Господин генерал!—диде.

Генерал өстәл тартмасыннан алып, погоннарны Шәүләгә сузды:

—Алыгыз, господин полковник!—диде генерал коры-житди тавыш белән.—Алыгыз да сейфыгызга яшереп куегыз! Бар шундый бер профессия, господин полковник, ул профессия кешеләренә алтын погоннар тагып, кеше алдына чыгарга ярамый... Котлыйм!

Шәүлә погоннарны сумкасына салып:

—Россия империясенә хезмәт итәм, генерал әфәнде!—диде.

—Утырыгыз!—диде генерал.—Нәрсә анда тышта, урамда, полковник?

—Матәм гамәле! Похоронная процессия, генерал әфәнде.

—Әйтерсең лә, бер әүлияне, пәйгамбәрне җирлиләр!.. Тоташ агым булып халык кая бара? Кемне шулай җирлиләр?

—Габдулла Тукайны, татар шагыйрен җирлиләр, генерал әфәнде.

—Ә-ә, исемә төште, сез бит аның эше белән шөгыльләнгән идегез... Татарның Пушкины, дигән иде миңа попечитель. Тәки мин шуны аңламадым: нәрсәсе белән ул бөек, нәрсәсе белән ул безнең Пушкинга тиң?.. Яки университеттагылар әйтә: имеш, Исхакый ул татарның Толстое! диләр.

—Тукайның бөеклеге турында урамдагы кеше ташкыны сөйли, господин генерал... Казанның бөтен үзәк урамнары да озатучы халык белән тулган. Тукай бөтен Казанны үз янына килергә мәҗбүр иткән. Эшчеләр дә, укытучылар да, балыкчылар да, татарлар да, руслар да, чувашлар да, башкортлар да шунда... Барысы да жылый...

—Аңламыйм, аның бөеклеге, аның мәшһүрлеге нидән килә? Ничек итеп ул безнең Пушкин белән рәттән тора ала?

—Дөресен генә әйткәндә, генерал әфәнде, мин ул чагыштыруларны яратмыйм. Тукайны Пушкин белән, Исхакыйны Толстой белән чагыштырган булалар. Андый чагыштырулар Пушкинны да Тукайны да кимсетә кебек. Аларны чагыштырып карарга ярамый, генерал әфәнде, алар икесе ике бөеклектә. Әгәр дә Пушкин белән Толстой каһарман икән, Тукай белән Исхакый ике тапкыр каһарман.

—Шулай укмыни? Ни өчен?

—Чөнки Пушкин белән Толстой үзләренең империясендә, үз дәүләтендә яшәп иҗат иткән, кайдадыр ки, аларны дин өчен эзәрлекләмиләр. Телләрен бетерергә тырышмыйлар. Пушкин белән Толстойны рус телен, христианлыкны яклаганнары һәм пропагандалаганнары өчен каторгага җибәрмиләр. Тукай белән Исхакый ике кат милли изү астында яшәп, иҗат иттеләр. Россиядә христианнар тарафыннан татар халкыннан җыелган акчага төзелгән 14 000 мәчет җимерелгән. Татарлар мәгариф өчен патша казнасыннан сукыр грош та алмыйча, мәктәпләр төзегән. Пушкин белән Толстойга шовинистларның һөҗүме янамый. Тукай белән Исхакый туганнан бирле дискриминация куркынычы астында яши.

—Тукай белән якыннан аралаша торгач, сез, полковник Саблуков, татар милләтчесе чирен йоктыргансыз, ахрысы. Мондый фикерләрегез өчен сезнең погоннарыгызны кире алуым да бар.

Генерал тәрәзә янына килде. Полковник та аягына басып, тәрәзәгә якынайды.

—Мин чын рус патриоты, генерал әфәнде, мин татар милләтчесе була алмыйм. Ләкин мин сезгә хакыйкый вәзгыятьне әйтергә тиешмен. Чөнки сез үзегез үк бу турыда мәгълүмат туплыйсыз. Халыкларның милли холкын, милли йөзен, аларның яшәү рәвешен белми торып, милләтчелеккә каршы

көрәшеп булмый. Башка халыкларның канын түгеп кенә без берни дә кыра алмаячакбыз. Миңа Ильминский якынрак.

—Озакка сузылган процесс...

—Аның каруы иң дөрес юл!

—Гаҗәп күп халык. Аларны монда куып китермәгәннәр бит...

—Даһиның сере, генерал әфәнде. Чахоткалы, чирле, кеп-кечкенә бөек Тукай пушкалардан да куәтлерәк.

—Сез азат, полковник!—диде генерал кырыс кына.

Көн пыскый, юеш, салкын. Гимназия укучылары Заһидә белән Әсмабикә җитәкчелегендәге туташлар Клячкинга килеп җиттеләр. Алар халык аша уза алмыйча, бер кырда туктап калдылар.

Хастаханә янында халык тыгызланганнан тыгызлана бара иде. Монда каракүл бүрек кигән татар зыялылары да, малахай кигәннәр дә, фуражкалы кызылавызлар да, картуз кигәннәр дә бар. Ак чалмалы муллалар да бик күп иде. Бер кырда хатын-кызлар тора. Курсисткалар, Яңа Бистә, Бишбалта хатыннарны, зыялы татар ханымнары, студенткалар. Күбесе җылый иде.

—Үпкә чире белән...

—Питербурда аны атаклы докторлар караган икән дә, ул операциягә риза булмаган.

—Коткара алмадылар...

—Барысы да Аллаһ кулында...

Халык арасында Шәүлә күләгәсе дә чалынып китте. Төркемнән читтәрәк Зәйтүнә белән аның ахирәте басып тора. Зәйтүнә җыламый. Аның дус кызы җылый. Зәйтүнәнең күзе беркемне дә, берни дә күрми, ул Тукай белән булган сөйләшүләрен күзалдына китерә иде.

Казан урамнары буйлап матәм агыла. Мәрхүмне озатырга килгән кешенең очы-кырые күренми. Монда дин әһелләре дә, шәкертләр дә, курсисткалар да, жандармнар да, францча киенгән ирләр дә бар.

—Кемне җирлиләр? Бу кем җеназасы?

—Тукай! Габдулла Тукай үлгән!

—Тукай үлмәс! Тәне үлсә дә аның җаны, аның иҗаты үлемсез!

—Иннә лиллаһи вә иннә иләйһи раҗигун вә иннә ила раббина ләмүн кабилун!

—Урынын җәннәттән әйләсен!

—Амин!

Тукайның кабере өстенә куелган чәчәкләр тау хасил итте. Җирләүчеләр кайтып киткәч, шул чәчәк тавы янына биш кыз килде, алар кулларындагы чәчкәләрен чәчәк тавына куйдылар. Аларның берсе Зәйтүнә Мәүледова һәм аның ахирәт кызы Өммегөлсем, өченчесе Гәүһәршад Әхмәтова белән тагын гимназиядә укучы ике кыз: Заһидә Әхмәрова белән Әсмабикә Терегулова иде...



Эльмира
Шәрифуллина

# ТӘРӘЗӘМ САЕН ГӨЛЛӘР

## Ишек

Ата-баба нигезендә
Туар балам бишеге.
Туар балам бишегендә
Туган илем ишеге.

## Терәк

Йөрәгемә ялкын кирәк,
Көн итәргә халкым кирәк.
Илһам өчен сөю кирәк,
Мәхәббәттә—бөтен терәк.

## Киная

Бирә җирем: маен, күмерен,
Алтын-көмеш, күкерт, тимерен,
Биргән саен таләп зурая—
Комсызлыкка бераз киная.

## Димә

Бала-чага гына димә,
Замана баласы ул,
Безнең буыннарны узып
Яшәргә каласы ул.

## Дәрман бир

Үсендер, туктатма, Аллам,
Башлаган эшләремнән.
Калышмаска дәрман бир син,
Яшьтәш, дус-ишләремнән.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА—*шагыйрә; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Яңгыр җиле», «Сөюемнән мин бер чибәр идем», «Мәхәббәтнең җиде төсе» һ. б. китаплар авторы. Казанда яши.*

## Элек һәм хәзер

Онык белән бармак төртеп
Сөйләшү фарыз икән.
...Әбием дәверләренең
Җаны бар, теле исән.

## Мөнәсәбәт

Утлы була күршеләр,
Хутлы була күршеләр.
Ут сузса—дуслык кыза,
Ут сызса—дуслык туза..

## Аралыйсы иде

Төбе-тамыры белән йолкып алып
Битарафлык дигән чирне,
Аралыйсы иде—ваемсыздан,
Намуссыздан газиз жирне!

## Тел тешләү

Йолдызсыз караңгы төн...
Сөйлим сиңа серемне.
Ямьсез сүзең йөзне ертты
Һәм тешләтте телемне.

## Уйласаң

Үз өеңдә үги булып яшәү,
Кимсетелеп яшәү, һай, авыр...
Җыр-моңнарым башны «ашады»мы?
Уйлый китсәң, өзелә эч-бавыр...

## Югалту

Син килгәнсең. Күрми калдым,
Үз-үземне тиргәдем.
Бер минутта югалтканны
Гомер буе эзләдем.

## Ысул

Җаен тапты, яла якты,
Тынычландырды җанын.
Кирәксезне читләштерү
Ысулы бу—дөньяның.

## Йокысыз җил

Керфекләремне көйдереп
Мәсхәрәле ут дөрли...
Минем кебек йоклый алмый
Бәргәләнеп җил йөри.

## Хаксыз-хокуксыз

Табынырга вәкаләт юк,
Кагылырга юк хакым.
Хаксыз-хокуксыз дөньяда
Кая бакма—тол хатын...

## Өмет

Әнкәем теләк теләде—
Кулдә пар кош кагына.
Туры килсен фәрештәнең
«Амин» дигән чагына.

## Сыену

Сыенамын анама:
Бүген җан иңгән сәгате
Карынымдагы балама.

## Түзеп кара

Елауны кем дә белә.
Иренең тешләп түзеп кара,
Күз яшең түкми генә.

## Дәвалау юлларын эзләү

Бу дөньяның чир-чорлары,
Сырхаулары ай-яй күп.
Намуслы кеше икәнсең,
Дәва эзләп тирең түк.

## Яңгыр җиле

Яңгыр җиле исә, әй изге җил!—
Сулыш алулары рәхәт.
Дым исе дә, җиләс җылылык та,
Эш-хәрәкәт анда, бәрәкәт.

## Их, сез!

Шартлап сына өметләр.
Кыйналганны кыйныйсыз бит,
Их, сез, «батыр» егетләр!..

## Акланмаган өмет

Дер селкетте дөнья...
Тынычландым:
Кагылмас шәт, миңа яңадан.
...Язмышыңны уңга борыйм дисәң,
Кабат туу кирәк анадан!..

## Әнкәемә

Мин оҗмахка сине күрер өчен барачакмын,
Сине шунда,
Фәкать шунда табачакмын!

## Киресе килү

Шундый якын, кадерле син,
Хыялдагы яз сыман...
Яз көткән тол тормышында
Никтер бик еш көз туган...

## Хәлгә керү

Табынырга теләгәнем
Табан астына салды.
Хисләремне кызганудан
Тапталган гөлләр янды.

## Җирнеке

Кара керфегемнең дымсу җиле
Күзләреңә чумып сер үпте.
Никахыбыз күктә укылса да
Сөю газаплары—җирнеке.

## Бул чыдам

Ян чырам, гомер чырам,
Минем кебек бул чыдам!

## Киртә

Имән чөй белән имәнне яру,
Үз кулың белән үзеңә—табу.

## Өлгерү

Җитү кыз булып үскән—
Алсу кура җиләккәе
Кебек балланып пешкән.

## Күк җимеше

Күгелҗем болытлар
Күкнең бер җимеше.
Кар яву, су агу—
Кояшның көлмеше.

## Бетми икән

Чәрдәкләнеп сынган гомеремнең
Син дәвасы идең, дәвасы.

Ничек кенә юма, бетми икән
Акка тамган тапның карасы.

## Иске өй шикелле

Сипләп кергән иске өй шикелле
Тынчу уйлар телә йөрәкне.
Тол хатыннар йөз кат артык белә
Баласына ата кирәкне.

## Каралтма

Каралтма мине, каралтма
Ялган табып үзеңә.
«Кара» дип, телең әйтсә дә
Ак күренәм күзеңә.

## Килсәң кил

Килсәң кил син якты күздә,
Тәрәзәмә ут элгәнче.
Әйтеп калдыр чын сүзеңне
Башыңа ят уй кергәнче.

## Үчтә—көч

Син үч аласың,
Мин көч аламын,
Рәхмәт!

## «Чуан»

Тулды...
Тулды да төпләнде,
Сызлады, сызландырды.
Сөям дидем,
Ялган диде,
Яндырды, хурландырды.

## Суыңны кызганасың

Көләсең, кызыкмы сиңа
Кеше елаган чакта?
Бер йотым су кызганасың,
Кемдер бал бирә ятка...

## Сөенү

Давыл төяп кургаш болыт
Каршыма чыкты.
Кисәтми килгән кайгымны
Упкыны йотты.

Әхәт
Мушинский

## ҺАВАЛАРДА—АК КҮГӘРЧЕН...

РОМАН

Николай Сергеевич сугыш ветеранының үзенеке белән килешмәгән фикерен, һәрвакыттагыча, әдәп белән тыңлап торды да, кешелек тарихының яңадан борылыш чорына килеп җитүен расларга кереште.

Гайнан абый, әңгәмә белән гадәттән тыш кызыксынуын күрсәтергә теләп, маңгаен җыерып куйды, ә үзе күз кырые белән Пичуганы күзәтте. Һәм шунда аның да ничек итеп уйнавын күрде: үзе Йолдызчыны тыңлаган һәм сүзләрен хуплаган да кебек, шул ук вакытта, сизелеп тора, мие белән башка нәрсә турында уйлый. Хәер, ни турында уйлавы ачык инде. Күзен алалмаган нәрсә турында уйлый. Саквояж тынгылык бирми аңа. Имән язу өстәле астындагы кыйммәтле открыткалар белән тулы сары саквояж. Жбаннан намуслы фронтовикның караклык белән шөгыльләнүдән баш тартуы турында белеп алган да, менә хәзер, бу коллекцияне ничек итеп кулга төшерергә соң, дип борчыла, баш вата. Коңгыз! Ә сүзләре ничек түгәрәк булып агып чыга! Әйтерсең алар земснарядтан коелган шома, түгәрәк ташлар. Аның авызыннан сибелеп кенә тора. Ни әйтәсең, чыннан да интеллигент, профессор малае! Ә үзенең күзе һаман шунда—имән өстәл астында.

Пичуга, халык китапханәсендәге кебек, үзенә фәнни-популяр китап сайлап алганнан соң китәргә җыенгач, Гайнан абый да урыныннан күтәрелде.

—Эшләр, эшләр...

Һәм кухняга чыккач, «эшлекле» портфеле артыннан тиз генә үз бүлмәсенә кереп китте.

Пичуганы исә, очраклы гына сыман, ишегалдында куып җитте.

—Сиңа кайсы якка?—дип сорады ул ваемсыз гына.—Бригантинагамы?

—Юк,—дип аннан да ваемсызрак итеп җавап кайтарды Пичугин.

—Менә миңа да—юк. Димәк, юлдашлар.

Икәү өченче кеше яныннан чыккач, гадәттә бу икәү шушы өченче турында сөйләшә. Гайнан абый белән Пичугин да моннан искәрмә түгел иде.

—Яши ир-ат булыр-булмас нәрсәләр арасында,—дип сөйләнде Гайнан абый, учында аксыл вак акча уйнатып,—мескенгә үз бүлмәсендә аяк басар урын да юк, ә чүплеккә бер фантик кисәген дә ташламый. Бер газеталары

*Ахыры. Башы узган елның 12нче санында*

гына күпме анның! Эверестлар, Джомолунглар... Мәктәпкә макулатурага илтеп бирсән, пионер дружинасы шундук беренче урынны алыр иде. Юк, череп, чүп-чарга әйләндереп бетермичә бөтен иске-москысын үзендә тотачак.

—Алай димәгез, Гайнан Фазлыгаллямович,—диде Пичуга.—Бу Эверестлар арасында, беләсезме, күпме кызыклы нәрсәләр бар?

—Нәрсә булырга мөмкин инде анда?

—Сезнең инде унтугызынчы гасыр башында ук басылып чыккан беренче Казан газетасын күргәнегез бармы? Юк? Ә «Мурзилка»ны? Безнең пионерлар өчен булган комсомол органын түгел, ә революциягә кадәргесен? Һәм ул журналдагы Носовка хәтле бик күптән яшәгән Знайканы, Незнайканы? Менә минем дә күргәнем юк иде, ә менә бүген анда күрдем. Һәм Николай патша вакытында чыккан «Огонек», «Вокруг света»ларны да...

—Бәхәсләшмим, аның иске-москысы арасында кыйммәтле нәрсәләр дә җитәрлектер. Һәм барысы да аяк астында диярлек бит... Менә бу монеталар тагын... —Гайнан абый учындагы ялтыравыклы акчаны чөеп җибәрде дә тотып алды һәм учын язды.—Екатерина бер тәнкәлеге, чист-а-а көмеш. Идәндә ята. Ал да кесәңә сал. А-ля, ма-фо... Алып тордым әле менә вакытлыча гына.

Гайнан абый үзенең караклыгын ачып салырга да оялмады. Чөнки инде аңа Пичуганың күп сөйләнүче Киләле аша цирк склады мөдиренең удар сыер ите фронты турында белүе, шуңа күрә Жбан аркылы, оятсыз рәвештә Жбанның үз пистолеты өчен открыткалы саквояжны таләп итүе дә ачык иде. Хәйләкәр дә инде бу егет. Ләкин бу хөрмәтле стратег беренче карашка, бәлки, шулай булып күренгән Гайнан Субаевның чынында андый ук ангыра түгеллеген белеп бетерми әле. Юк, кешеләрнең акыл сәләтләре мәктәп билгеләре һәм медальләре белән бәяләнми шул. Шулай ук тышкы кыяфәтең һәм үз-үзеңне тотышың белән дә билгеләнми ул. Ә тормыш белән билгеләнә ул, тормыш белән! Тормыш—соңгы инстанциядәге имтихан алучы да һәм хөкем чыгаручы судья да. Менә бит, уч төбендә яткан шушы акча шикелле ачык. Үзе сары саквояжга ия булырга тели, ә үзе алда нәрсә буласын белмичә фикер йөртә. Аз белемле склад мөдиренә акыл өйрәтә һәм аны открыткалы саквояжны алып чыгарга ничек мәҗбүр итәргә кирәклеген чамаламый. Һәвәслек, һәвәслек... Нинди генә җинаятьләр ясалмады аның байрагы астында. Әй, бу коллекционерлар! Нигездә нәрсә җыярга һәм җинаятькә нәрсә өчен барырга? Акча туплау өченме яисә открыткалар өченме—аерма юк бит. Миллионерлар да—чынында шул ук коллекционерлар инде алар.

—Карарга рөхсәт итегез,—дип Пичуга акчага үрелде.—Искиткеч!—Ул аны учында үлчәп карады.—Унсигезенче гасыр. Нинди зур! Ә мин нигәдер аның иске акчаларын күрмәдем.

—Әллә никадәр алар анда!—дип елмаеп куйды Гайнан абый.—Өстәл өстендә дә яталар, өстәл астында да ауныйлар. Төштеме, югалды диген. Әгәр синең өеңдә бер тиенлек акчаң идәнгә төште икән, димәк, ул чагында синеке дип әйтеп булмый инде аны. Менә шулай. А-ля, ма-фо...—Ул Пичуга кулыннан акчаны кире алды да кесәсенә салды.—Сүз җаенда гына әйтүем, анда, өстәл астында, теге саквояж да тузан җыеп ята бирә...

—Нинди теге саквояж?—дип, аңламаган шикелле, Пичуга иннәрен сикертеп куйды һәм кинәт йөзе агарынып китте. Бу нәрсә Гайнан абыйның ябышкак карашыннан читтә кала алмады. Ул, үзенең оппоненты физиономиясенә ясалган мизгел эчендәге беренче реакциясенә карап, пистолетның чын хуҗасына карата булган фаразына ачыклык кертергә теләгән иде бит. Гайнан абый Анатолий Жбановның пистолетны мичтән табуы турындагы сүзләренең дөреслегенә ышанды. Нинди дә булса әйбернең

хуҗасы да һәм шул ук вакытта кемнендер колы булу да бик мөмкин нәрсә.

—Сары,—дип бик теләп аңлатты Гайнан абый,—сары саквояж. Шуның аркасында мин Толя белән килешә алмаган теге саквояж.

—Мин менә шушында яшим,—диде инде йөзе гадәти төс алган, ләкин биек, матур маңгае җыерылган Пичуга. Әйтерсең Гайнан абый аңа үзе тарафыннан зарыгып көтелгән саквояж турында түгел, ә аның яшәү урыны турында әйтте. Алар ике катлы бүрәнә йорт баскычы төбендә туктап калдылар.—Миңа керәбезме?

—Бик теләп,—дип җавап кайтарды Гайнан абый,—таныш булмаган җиргә аяк басарга яратам мин.

Ләкин алар өсте ярым түгәрәк итеп эшләнгән тәрәзәле иске бүрәнә өйнең баскычына аяк басмады, ә бер-берсенә бер катлы берничә фәкыйрь өй сыенган ишегалды аша үттеләр дә иң кырыйдагы, иң-иң мәсхәрәле алачыкка килеп керделәр. Исе аңкып торган керосинкалар куелган гомуми кухняны үтеп, кысан коридорга килеп чыктылар. Пичуга шунда, караңгыда күренмәгән ишекне ачарга теләп, ачкычлары белән чылтырады. Ниһаять, ишек биреште һәм алар көтелмәгән бик җайлы, стеналары «Советский экран» һәм тагын чит ил хәрефле башка журналлардан алынган елмаюлы кинойолдызлар рәсемнәре белән ябыштырылган бүлмәгә килеп керделәр.

—Ычкындырган... Ж-жбан-Жбанович, кабахәт!—дип нәфрәт белән әйтеп куйды шунда Пичуга.—Беркемгә дә ышанырга ярамый. Утырыгыз! Чәйме сезгә, әллә какаомы?

—Аракы яхшырак булыр, мөгаен.

—Аракы юк...—дип югалып калды Пичуга.

—Нинди ир соң син ул чагында?!—дип көрсенеп куйды да, Гайнан абый портфелен ачты һәм аннан ике бармагы белән ярты литрлы «Московский» шешәсен тартып чыгарды.—Танышлыкны чәй белән юмыйлар аны!

—Танышлыкны?

—Әйе, әйе, чын танышлыкны.—Гайнан абый шешәнең авызындагы бөкесен ачты.—Кая, савыт бир!

Эчеп җибәрделәр дә, артыннан кабымлык каптылар. Гайнан абый Жбан белән кирәкле юнәлештә барган сөйләшү турында әйтеп бирде.

—Сиңа сылтады ул. Янәсе, пистолетның хуҗасы син.

—Мин пистолет хуҗасымы?!—дип гаҗәпкә калды Пичугин.

—Юкка борчылма ла син!

—Кара син аны, ә! Корал яшереп саклау турында эш тегеп куярлар да, булыр аннары «борчылма».

Гайнан абый рюмкаларга икенче мәртәбә салды.

—Тынычлан, Сашенька. Сиңа һаман аңлашылмыймыни соң: мин бит сиңа бары тик яхшылык белән генә... Ир-ат ир-ат янына килгән шикелле. Ә безнең синең белән эшлекле сөйләшү урынына, хатыннар арасындагы сыман, нииндидер аңлашылмаучылык, сагаю, шикләнү, ишәнү. Әгәр дә сиңа каршы ни дә булса эшләргә теләсәм, мин сиңа килер идеммени? Син минем бар нәрсәдән дә хәбәрдар икәнемне яхшы беләсең. Мин дә сине яхшы беләм һәм аңлыйм да. Гомумән алганда, син үзеңнең Алмалыда гына түгел, ә бөтен Идел буенда ук булмаса да, менә шушы шәһәрдә бик тә билгеле, бай һәм күркәм коллекция булдыруны максат итеп куйган изге операциян хакында белүче кешеләр тирәлегеп киңәйтергә теләмисең. Ләкин нишләмәк кирәк, бу турыда мин дә хәбәрдар инде. Килешәбезме? Син миңа, элеккеге фронтовикка, яшьлегем истәлеге булган—пистолетны, ә мин сиңа—Жбанга тиешле илле сум белән саквояжны. Үзебезнең тынычлык хакына, безнең үзара килешүебез турында ул такылдыкка белгертергә кирәкмәс, минемчә. Имеш,

син дә открыткаларны алмагансың, минем дә бу эшкә бернинди катнашым юк. Ул чагында Жбан да ут белән уйнаудан читләштерелә, шуның өстенә әле аңа кыска теле өчен тундырмалык түгәрәк кенә сумнар да эләгә...

Монда үзенә—Раинька белән гомуми булган бу бүлмәгә, әле Сашаның башка беркемне дә алып кергәне юк иде. Хәтта аның ничек яшәп ятуын үз әнисенең дә күргәне юк. Бер мәртәбә бабасы уңайлы сылтау белән (иске адреска юлланган хатын алып килде) аның яшәгән урынына үтәргә тырышып караган иде дә, ләкин Саша аны очраклы рәвештә ишегалдында очратты. Һәм, рәхмәт әйтеп, хатын алып калды, ә әдәп белән өйләренә чакырмады.

Гайнан абый аның өйләнгән тормышында әле беренче генә кунак иде.

Ике рюмкадан соң кунак үзенең күршесе Николай Сергеевич Новиков турында сүз башлады.

—Шикле шәхес безнең Йолдызчы. Һаман нәрсәдер яза да яза. Эшенә атнасына бер генә мәртәбә барып килә...

—Гаҗәпләнерлек нәрсә юк монда,—диде аңа Пичугин.—Галим кеше бит ул. Аларның эшләре шундый.

—Сугышта да булмаган, бар намуслы совет галимнәре репрессия тәгәрмәче астында шытырдаганда, утыз җиденче елны да бернинди зыянсыз сикереп үткән. Мин дә дөбердәдем бит анда. Кырык бишенчедә. Ирләр—дембельгә, аларны чәчәкләр белән каршыладылар, алар—каһарманнар, коткаручылар, ә мин—Себергә, каторгага. Мин шулай төкереп пычратылган килеш көнчыгышка, Урал артына берүзем генә тыкырдадым дип беләсеңме? Тулы эшелон иде анда!

—Тоткыннар эшелоны—куркыныч нәрсә, качып бетүләре бар. Аннары азмыни тагын нәрсә булырга мөмкин. Бу—конвой күзлегеннән караганда.

—Ышанмыйсыңмыни? Димәк, мин тел бистәсе?

—Тел бистәсе түгел, Гайнан Фазлыгалләмович, тик ялгышырга мөмкин идегез, ул вакытта япон фронтына бик зур күчерүләр булды бит.

—Мин кая барганымны белмәдем димени?

—Сез—әйе, тик бөтен эшелон ничек инде?..

—Әй, яшьләр, яшьләр! Барыгыз да акыллы булып беттегез. Шундый укымышлылар, сугыш турында фронтовикларның үзләреннән дә күбрәк, барысы турында да шаһитлардан да артык беләсез. Хәер, кем белә аны, мөгаен, шулай дөрестер дә бу. Кая, бир әле...— Гайнан абый, бик сак кына, ашъяулыкка тамчы да тамызмыйча, рюмкаларны тагын тутырды.—Зур акыл ияләре, хакыйкать—шәрабтә, диләр. Алле—ап-п!

Рюмкадагы нәрсә былт-былт иткән тавыш чыгарды да, фронтовикның иренен дә чылатмыйча, көрәк сыман киң галстук астындагы «жир астына» төшеп юк булды.

—Гомумән алганда, мин эчмим,—дип елмайды Пичугин, хәзерге атказанган цирк эшлеклесе һәм үткәндә гаепсездән зыян күргән бу фронтовик-майорның осталыгын күзәтеп.

—И-их!—дип каршы килгән сыман тамак кырып куйды Гайнан абый.

—Ә эчкән чакта...—дип дәвам итте Пичугин үз фикерен,—ике рюмкадан артык түгел...

—И-их!

— Ләкин сезнең белән...—Пичугин рюмкасын күтәрде дә, авызын чәй эчкәндәге кебек чапылдатып, аны бушатып куйды.— Карале! Безнең тозлаган кыяр бар бит, ә без ипи иснәп утырабыз!

Өстәлдә ипидән башка әле консервалар, яна помидор, пешкән бәрәнге,

сельдь балыгы, тагын нәрсәләрдер өелгән иде. Ләкин Пичугин, назлы хуҗабикә сыман, мескенгә салышты.

Гайнан абыйга тозлаган кыяр ошады һәм ул:

—Саша, ә син шундый итек щеткасы булган Жбанны ничек кулга ияләштерә алдың?—дип сорады.

—Мин? Жбанныммы?

—Син, Саша, син, мин аның синең авызыңа гына карап торганын күрәм бит.

—Сизгәнем юк, алай да кызык бу.

—Алай да сизмәдең, димәк?—дип сораганда чиктән тыш төбәлүдән Гайнан абыйның күзләре пыяла сыман булып калды.

—Йә, сиздем, сиздем, әлбәттә. Әгәр эш алайга китсә, миңа, Аллага гыйбадәт тотучылар иконага баккан шикелле, бөтен малай-шалайлар да бәбәкләрен териләр.—Пичуга карашын шешәгә төшерде, чөнки Гайнан абыйның таркау, төрле якка юнәлгән күзләренә каравы уңайсыз иде. Болай бер күзенә карыйсың, ә синең арттан әкрен генә икенчесе күзәтә шикелле.

Гайнан абый шешәне кулына алды да рюмкаларны кырыена тикле, мөлдерәмә итеп тутырып куйды.

—Бәлки, ул шулайдыр да, барысы да сиңа иконага табынган шикелле кебектер дә... Ләкин үзләренең шәхси әйберләреннән файдалану өчен аларның барысы да синең рөхсәтеңә мохтаҗ түгел бит.

—Аңламадым.

—Әллә пистолет «вальтер« Жбановныкы түгел, ә шулай да синекеме?—дип Гайнан абый катып калган күзләре белән яңадан Пичугага карап тора башлады. Тегесе исә шунда, чәнчә бармагын тырпайтып, ике бармагы белән рюмкасын күтәрде.

—Гайнан Фазлыгалләмович, сезгә ул пистолетның кемнеке икәнен шулай бик белергә кирәкмени соң? Сезне аннан битәр безнең Жбан белән үзара бәйләнешебез борчыймыни? Әллә сезнең белән без бөтенләй әһәмияте булмаган икенче дәрәҗәдәге нәрсәләрдән башка гына килешә алмыйбызмы? Минем аңлавымча, без инде асылда сүз барган мәсьәлә буенча килештек тә бугай? Без бит ангыра кешеләр түгел. Мин сезгә нәрсә кирәген беләм, ә сез минем ни белән кызыксынуымны беләсез... Мин сезгә Жбандагы һәм аныкы булган нәрсәне бик ансат кына эшләп бирә алам, ә сез, аңлавымча, миңа—үзегезнең галим күршегез өстәле астында аунап яткан әйберне. Кызык, тегесе дә, монысы да аларның хуҗаларына, сезнең белән безгә кирәк шикелле үк кирәк түгел, Гайнан Фазлыгалләмович. Саквояждагы открыткалар бер дә кирәкмәскә менә инде ярты гасыр диярлек тузан җыеп яталар, ә «вальтер» булдыксыз малай кулында бәлагә генә алып килергә мөмкин. Ярар, ул бүген каргаларга ата ди. Ә иртәгә? Аннан соң ул пистолетка бөтен законлы хокукларыгыз бар, сезнең өчен ул югалган истәлекле, изге әйберне, реликвияне кайтару бит.

—Менә бу ир-атлар сөйләшүе!—дип җанланып китте Гайнан абый.

Алар эчеп җибәрде.

Пичуга эчүне күрә алмый иде, чөнки мондый агу аның яшь, чыныктырылган организмына да, аның тәртипле акылына да кирәк түгел. Әмма шул ук тәртипле акылы бу юлы йомшаклык күрсәтте. Янәсе, эш өчен берничә грамм нәрсәне генә эчәргә мөмкин. Ә берничә рюмкадан соң инде организмы да каршылык күрсәтми башлады. Ачы, күңел болгандыргыч исле эчемлек җиңел китә башлады, тормозлар йомшарды, ә кунак икенче шешәне чыгаргач, кемдер әйтмешли, үзенең дә газга басасы килде. Кунак исә үзенең сизгерлеге һәм акылы буенча сирәк әңгәмәче булып чыкты. Ә

шактый ук исергән Пичуганы «газ» инде бөтен тизлектә алып китте. Ул мактана башлады, моңарчы беркайчан да һәм бернинди компаниядә дә эшләмәгәнне, үзе язган берничә шигырен дә укып алды, шкафтан футбол тубын чыгарып, өстәл янында ук искиткеч бер яңа финт ясап күрсәтте, аннары соңгы вакытларда ия булган уникаль, бик тә сирәк открыткалар теркәлгән калын альбомын алып килде.

—Кара, күз сал бу нәрсәләргә,—диде Пичуга, яна союзнигының иненнән дусларча кочып һәм аның белән «син»гә күчеп. Ул үзенең байлыгын күрсәтер өчен альбомы битләрен үзе ачып-ачып торды. Аннары тагын берничә альбом алып килде.

—А-ля-мафо, мадера-фигус-краба!—дип тантаналы рәвештә кычкырып куйды Гайнан абый, сүрәнләнгән карашын диванга, урындыкларга, идәнгә җәеп салынган һәм ачылган уннарча альбомнар буенча йөртеп.—Искиткеч! Шигырьләрне дә син үзең яздыңмы?!

—Билгеле, үзем.

Пичугин бутала-бутала тагын шигырьләрен укырга тотынды.

Азакта түзә алмады һәм бер мәртәбә ул ничек кече йомышы белән мәктәп ишегалды артындагы авышып беткән, биге тотмый торган сасы бәдрәфкә килеп кергәч, анда бөгелеп онанизм белән гөнаһланып маташучы Жбанга юлыгуы турында сөйләп бирде.

Пичуга, йөзен җыерып, моны хәтта сурәтләп тә күрсәтте.

Гайнан абый шаркылдап көлеп җибәрде.

—Менә нинди кармак җебендә тотып торасың икән син ул китны!—диде ул.

—Ха, нинди кит булсын ди ул! Килька ул, кит түгел.

Сөйләшеп, көлешеп бетерергә туры килмәде, эштән арып-талып, нервыланып хуҗабикә кайтып керде. Һәм Пичуга, бик төшенеп җитмичә, үзенең гаиләле тормышында беренче тиргәшен кабул итте. Ул хатынын үзенең яңа дусты, ышанычлы, искиткеч кеше, сугыш ветераны, культура хезмәткәре белән таныштырырга теләде. Ахырында гап-гади интеллигентлыкка чакырып-өндәп карады. Ләкин боларның бернинди нәтиҗәсе күренмәде. Ул кайтып кергәнче Пичуга бер-ике сүз белән сөйкемле, киң күңелле дип тасвирлаган Раинькасы, үз-үзен белештермичә, ул беренче исерек ирен өйдән шундый ук икенче исереккә тап булу өчен куып чыгармавы турында кычкырынды.

—Нинди интеллигентлык турында бытылдыйсың син?—дип акырды ул иренә.—Үзеңә көзгедән кара да аннары үзеннән культуралы дустыңның тирләп чыккан йөзенә күз төшер... Анда барысы да язылган.

Иртән Пичуга табынның ни белән тәмамлануын начар хәтерли иде. Хатыны Раинька Гайнан Фазлыгалләмович кайтып киткәнче кайтып кердеме, әллә ул аларның икесен бергә туры китердеме икән? Әгәр туры китергән булса, алар өчәүләп ни турында сөйләшкәннәр? Бер чынаяк чәй эчкәннән соң ул коса башлады. Ул көнне институтка да һәм кичен күнекмәгә дә бара алмады.

—Үләм, Раинька,—дип пышылдады ул, юынтык су тасын кочаклап.

—Азрак эчәргә кирәк,—дип җавап кайтарды аңа Раинькасы.

## УНЫНЧЫ БҮЛЕК

### Шугалакта

Дөньяда Яңа ел бәйрәменнән дә күңеллерәк һәм яктырак бәйрәм булмаса да, инде күнегелгән календарьдан соңгы битен ертып алуы барыбер кызганыч. Инде син бу елны кыска гына тормышың әйләнешендәге

кайсыдыр көнен яисә датасын раслауны таләп иткән берninди графаларга да кертә алмыйсың. 1961 ел минем хәтеремдә шундый юк-бар нәрсә булып калды да. Симметрик, түгәрәк цифрны сурәтләүче таяк, тугызлы, алтылы һәм тагын бер таякны кирегә әйләндерсәң дә, алар барыбер шул ук цифр—таяк, тугызлы, алтылы һәм тагын бер таяк булып кала бирәләр. Хәтерлим, бу чын, ясалма булмаган гармонияне ахырындагы ниндидер чит икеле белән бозуы кызганыч иде.

Ләкин елның соңгы көне яңа елның беренче көне белән алышына.

Бетмәс-төкәнмәс икенче уку чирегенең соңгы көннәре котеп алган кышкы каникуллар белән алышына. Уку елы—каникул вакытының күнелсез тәнәфесе, диләр.

Ул яңа елның кышы суык һәм карга юмарт килде. Көннәр буена югалырга иде Уйсулыкта, шуып төшәргә иде чаңгы белән тын кысылырлык тау битләреннән, коштай очарга иде трамплиннардан, юк шул, кышка таба без кинәт кенә балигъ булдык.

Мең дә тугыз йөз алтмыш икенче яңа елның гыйнварына безнең Бермуд өчпочмагындагы (Шәех—Юлия—мин) беренче һәм шуңа күрә бик тә урынлы булган мәхәббәт фронтындагы хәлләр, төрле кайнашу-бөтерелүләрдән туктап, үзеннән-үзе басыла төште. Минем конкурентлык сәләтем нигезсез булып чыкты. Шуннан соң, валлаһи, иннәремнән таш төшкән шикелле тоелды. Менә ул мәхәббәтнең эгоистлык асылы: сине сөймиләр икән, шулай булгач, син дә аларга: «Хуш, сау булыгыз!» Ләкин мин һич тә артык, өченче кеше булып йөрмәдем. Киресенчә, безнең дуслык ныгыды. Һәм ике яктан да тигез булып ныгыды. Алар ягыннан миңа карата да, минем яктан аларга—минем сабыр, үзара яратышкан дусларым Юлия һәм Шәехкә карата да. Кайчак минем кирелек белән алар арасыннан читтәрәк булырга тырышуыма да карамастан (гашыйкларга ялгыз калырга да кирәк бит!), алар мине үзләре белән һәр жиргә алып йөрделәр. Кышкы каникул көннәрендә М.Горький исемендәге Үзәк культура һәм ял паркына шугалакка алып бардылар. Миңа анда ошады һәм инде соңыннан, алар катокка жыенса, мин дә алардан калмаска тырыштым.

Ул елларда Үзәк парк шугалагы кичке шәһәрнең йөрәге иде. Анда халык төркем-төркем булып агылды. Алар арасында бар жиргә дә өлгерә торган бала-чага да, спорт башлыгы кигән ак чәчле пенсионерлар да һәм, хәзер әйткәнчә, утыздан узганнар, дип йөртелә торганнарның барысы да, әлбәттә, ул чактагы безнең алтын яшьтәшләр дә бар иде.

Парк шугалагында һәм аның тирәсендә бигрәк тә каникул вакытында бик бәйрәмчә була. Бөтен яктан ялтырап торган боз мәйданы тирәли чыршылар, төрле төстәге утлар гирляндасы, кызылайган йөзле кар бабайлар... Репродуктордан ул чакта бик тә модада булган жырлар янгырый: «Де-смо-мо-до-града...» Аңлашылмый. Ләкин дулкынландыргыч (бу сүзне шәхсән үзем яратмыйм, ләкин монда нигәдер кулланасым килде). Һәм, һичшиксез—мәхәббәт турында. Шәех белән Юлия, кулга-кул тотынышып, мәйдан көзгесен «канад» һәм «фигурка» тимераяк йөзләре белән кисәләр, чуар киемле шуа белмәгәннәрне узып-узып китәләр. Ә алар, минем дусларым, шуа беләләр иде. Шәех ничек миннән яхшырак шуарга өйрәнгән соң әле?! Без аның белән һәрвакыт Уйсулыкта бергә югала идек бит. «Багдад Шәехе» кызарып чыккан, күкрәге шыр ачык, муены озындыр үзенең. Юлиягә нидер әйтә, ә тегесе бәхетле елмая... Гомумән, бу мизгелдә алар икесе дә бәхетле иде. Ул яңа елга аларның беренче мәхәббәт күләгәсендәге аралашулары бөтенләй ачыкланып бетте. Аларның үзләре өчен генә түгел, тирә-юньдәгеләр өчен дә. Гыйнварның беренче көннәрендә Шәехкә уналты яшь тулды һәм ул тагын миннән бер яшькә олы булып калды. Юлия туган

көнендә ана үзенең акварелен —кышкы иске шәһәр урамнары сурәтләнгән пейзажын бүләк итте. Әлбәттә инде, безнең Алмалыныкы иде ул урам. Сыкылар сарылган агачларның ботаклары арасыннан ярым кирпеч, ярым бүрәнәдән салынган, нык капкалы өй күренә, ә аның түбәсендәге кызыл торбасыннан ак багана булып чыккан төтен салкын күкне терәп тора сыман, терраса һәм иске койма артындагы сарай өстеннән күгәрчен кетәгенең авыш лавасы күккә ашкан. Менә шундый пейзаж. Картинаның һавадай җинел, андагы сурәткә бик тә ятышып торган рамасы— гади уемнар белән бизәлгән усак борыстан. Аны Кыям абый ясаган. Бабасы белән оныкасы ул рәсемне Шәехкә, аны үзләренә нәкъ үзенең туган көнендә, кайчандыр Кыям абый сүз кузгаткан «Балтика» радиоалгычын төзәтергә кирәк, дигән хәйлә белән чакырып, өйләрендә тапшырдылар. Ул көнне Семён Васильевич та өйдә юк—эштә, шулай ук Роза апа да каядыр чыгып киткән иде. Ә Шәех аларга үзенең «ассистенты», ягъни минем белән килде. Һәм шунда без беренче мәртәбә ачыктан-ачык шәраб белән сыйландык. Кыям абый безгә бирәр рюмка татлы, Мәскәү кремленең рубин якут йолдызы төсендәге «Абхазия нектары»н салып бирде. Уналты яшь... Шул мизгелдә безгә гомер һич тә бүләк, очраклы нәрсә түгел, ә законлы закончалык, якты һәм мәңгелек объектив чынбарлык булып тоелды. Ул мәңгелек хәтта безнең аркаларыбыз артында да сизелә кебек иде, чөнки, ни әйтсән дә, уналты яшь! Ләкин алай да алда әле ул күпме иде!! Безгә Юлия белән Кыям абыйда яхшы иде. Шәех белән безнең әле монарчы бер генә бәйрәмне дә, бер генә Яна елны да, бер генә туган көнне дә үзебез теләгәнчә, бар нәрсәне дә күрә торган әти-әниләр күзеннән башка гына үткәргәнебез юк иде. Ул көнне «Балтика»ны төзәтергә вакыт булмады. Икенче мәртәбә махсус керергә вәгъдә бирдек. Шәех кышкы пейзажны Николай Сергеевич стенасына элеп куйды. Чөнки үзләрендә, стеналары һәрвакыт даими рәвештә үги әтисенең махмырлы күзләре белән айкалган өйләрендә, эләргә теләмәде. Кичен Шакировларга нindидер туганнары, нindидер кунаклар килде. Шәех исәнлеге өчен эчтеләр, аның әнисе өчен, ә аннан соң хөрмәтле Гайнан Фазлыгалләм улы өчен... Тик бер рюмка да чын әтисе хакына эчелмәде, әйтерсең ул дөньяда бөтенләй булмаган да. Икенче көнне Гайнан абый, башы авыртуы сәбәпле, эшкә чыга алмады. Иртән үк Шәехкә бәйләнде. Янәсе, синең саулыгың өчен артыграк эчелгән, шешә артыннан йөгер, үзенең бер дә көче юк, имеш. Шәех ике төрле анлашылмаслык итеп карышты, хәтта каты итеп кундыру өчен инен куйды һәм аннары, артыннан ишекне каты ябып, урамга ук чыгып китте. «Түбәтәйле, киселеп бетмәгән татар баласы, кер, кабахәт!»—дип үги әтисе аның артыннан чыкты. Ләкин Шәех аның бу мыскыллы сүзләренә борылып та карамады. Кичке алтылар тирәсендә ул миңа сарайдан безнең эчке телефон буенча: «Әйдә шугалакка»,—дип шалтыратты.

Мин туңган кулларымдагы кайнар пирожки белән басып торам.

—Юлия, Шәех, озак әйләнәсезме әле тагын? Пирожкиларны ашап бетерәм бит мин,—дип кычкырам мин аларга.

Алар шундук шуып килеп җиттеләр. Сулышлары тыгылган, йөзләре кызарган. Мин аларга ливер эчле пирожкиларны сузам һәм буфеттагы ыгы-зыгы турында сөйләнеп алам. Алар мине дә, пирожкины да мактыйлар, бик тәмләп чәйниләр, көлешәләр. Нигәдер барлык гашыйклар да көләргә яратучан булалар бугай.

Зур әйләнә буенча шуабыз. Әле тагын уннарча кечкенә әйләнәләр бар, аларда җирле виртуозлар искиткеч осталыкларын күрсәтәләр, «штат» киемле хоккейчылар юана, кәкре аяклы кыю дилетантлар кайнаша, үз юлларындагы бар нәрсәне һәм барысын да себереп, турбореактив үкерүе белән ун-унбиш кеше бергә тотышкан «кытай стеналары» узып китә.

Без кулга-кул тотынышып, ашыкмыйча гына шуабыз: Юлия—уртада, зур әйләнә буенча уң якта—Шәех. Суык безнең янакларыбызны чеметә, ә аякларны инде күптәннән сизмибез дә. Кырыйдагыларны, безне—минем белән Шәехне узып китүчеләр дә, артта калучылар да, егылучылар да һаман этәләр, төртәләр... Ешрак Шәехкә эләгә, ләкин ул тимераякта дагалы ат шикелле, юкка гына куркынычрак ягыбызда тормый ул.

Әлбәттә, Жбан белән Киләле дә ялт итеп килеп чыкты. Алар артыннан—кавалерист (кәкре аяклы дип укы) Титя. Алар гомуми хәрәкәткә каршы, кыеклап, безне тимераяклары астыннан чыккан боз валчыклары белән коендырып, борын төбеннән ук ыжгырып китәләр. Элегрәк булса, кагылып үтәргә, аяктан егарга да тырышкан булырлар иде, ләкин кайсыдыр вакыттан бирле Юлия белән Шәехкә бәйләнү алар өчен кызык булмый башлады. Әллә Шәех күз алдында тәнгә кинәт һәм шактый саллы гына ныгып калды, әллә үзләре тирәсендәгеләр белән һич тә кызыксынмаган бу пар үз чиратларында үзләренә карата да кызыксыну уятмый идеме. Ә бәлки алар Юлиянең үткен теленнән шикләнә башлаганнардыр? Яисә аның соңгы вакытта усалланып киткән абыйсыннанмы? Барысы да булырга мөмкин. Йә әйтегез әле, кемнең, шул урында, күп халыклы мәйдан уртасында үзенә дә бәхете белән култыклашып йөрүе мөмкин булганда, читләр бәхетенә карыйсы килсен? Кемнең үзенең мәхәббәт фронтында банкротлыкка чыгуы турында үз-үзенә артык мәртәбә хәтерләтәсе килсен? Юлиягә карата бик зур кызыксыну күрсәткән һәм хурлыклы рәвештә берничә мәртәбә кире кагылган Жбангамы әллә? Юк. Юлияне куркытып яныннан сызгырып үтеп китте, үзен, чиктән тыш җитез лихач икәнен күрсәтте дә дуслары белән юкка чыкты. Тагын буфетка китмәдеме икән? Буфетта пирожкига чиратта торганда, дөресрәге, минем янга чиратсыз кысылганда, ул малай-шалай нигәдер «Калач» дип йөрткән Гайнан абый белән дуслыгы һәм аның аны бушлай циркка алып баруы турында мактанып алды. «Фартовый ир,—дип пышылдады ул минем колакка.—Читлекләрдәге тигрларны күрсәтте, өйрәтүчеләр белән таныштырды. Беләсеңме, шул өйрәтүчеләрнең берсенең билендә—барабан белән револьвер!» Мин нинди барабан икәнен аңладым, алай да: «Ә барабаны нәрсәгә? Кагаргамы?»—дип сорап куйган булдым. Жбан минем юри чәнчеп алуымны аңламады, ярсулы тавыш белән аңлатып бирде: «Револьвер барабаны белән, аңгыра баш. Калач әйтә, аңа да пушка тиеш, ди». Гәрчә «аңгыра баш» өчен, револьверлар барабансыз булмый, дип җавап бирә алсам да, дәшмәдем. Шунда Жбан: «Ишетәсеңме, сезнең рәттәге сарайларның дүртенче ишеге Йолдызчы утынлыгымы?»—дип сорады. «Сиңа нигә ул?»—дидем мин аның соравына каршы сорау белән. «Болай гына»,—дип каушап калды кинәт Жбан. Мин, акыллы баш, ул чагында моңа һич тә әһәмият бирмичә: «Әйе, дүртенче»,—дидем.

Шудык, шундый озак шудык, чак кына аякларыбызны өшетмәдек. Чишенү бүлмәсендә утырабыз. Шәех Юлиянең аякларын уа, борчылып аларны үзенең курткасының күкрәк өлешенә тыга. Юлия исә яшь аша көлә. Мин бертөрле генә тавыш белән буфеттагы сугышка охшаш ыгы-зыгы турында сөйләп бетерәм һәм анда Жбан белән булган сөйләшү хакында да әйтеп бирәм. Тигрлар турында да, револьвер турында да искә алам... Ә менә утын сарае турында әйтергә онытам.

Төнгә каршы суык гайкаларын тагын да катырак бора төшә. Салкын ай һәм чәнечкеле йолдызлар астында зур-зур көртләр белән тулган шәһәр урамы буенча йөгерәбез. Шәех, быел сигезенче класстан соң элемтә техникумына керәм, ди.

—Анда аларның гомуми тораклары да бар. Стипендия дә алачакмын...

Беренче урында аның, әлбәттә, гомуми торак. Ул инде сигезьеллыктан

соң өендә яшәмәячәге турында беренче генә мәртәбә әйтми. Без Юлия белән каршы килеп карадык. Үз почмагың үз почмагын инде ул, янәсе.

—Хәзер Алмалыда минем үз почмагым юк,—диде ул төрпә генә.—Җәй буе сарайда булган идем, инде аны да басып алдылар. Ит кибетенә әйләндерделәр.

Кышын Шакировлар фатирындагы һава шартлау куркынычы булу чигенә тикле житте. Шәех һәм үги әтисе, сүз белән бәрелешләрен санамаганда, бер-берсе белән сөйләшмәделәр дә. Шәех инде яна елга кадәрле үк берничә мәртәбә үги әтисендә Николай Сергеевичныкы булган көмеш акчалар, төрле борынгы вак-төяк бизәнү әйберләре күреп алды һәм анын караклыгын кешеләргә әйтәм дип куркытып, аларны кире хуҗасына кайтаруын таләп итте. Ләкин тегесе тешләрен генә ыржайтты һәм ул әйберләрне ул түгел, ә анаң алган дип җавап бирде.

—Менә кара, бу бизәнү әйбере минем кесәдә түгел, ә синең әниең кәржинендә иде...—диде ул, ана шуны күрсәтеп.

—Берни дә раслый алмассың,—диде аңа Шәех.— Оятыңнан шәһәрдән чыгып качсан да.

—Ә син аны берәр аулак урында кыс та финкаң белән кытыкла,—дип тәкъдим иттем мин дустыма, уенын-чынын бергә кушып.

—Ярамый,—диде Шәех, житди итеп.—Минем финка корал да, куркыта торган әйбер дә түгел, ә эш инструменты.

Йөгерәбез, чәнечкеле чатнама суык һава сулыйбыз, йомшак пар итеп тын чыгарабыз. Юлия техникум турындагы хәбәрне эшкәртеп, аннан:

—Ә аннары Мәскәү физика-техник институты белән ничек була соң инде?—дип сорап куйды.

—Аларның берсе икенчесенә комачауламый,—дип җавап бирде Шәех.

—Нәкъ профиль буенча,—дидем мин, абруйлы итеп.

—Ә күгәрченнәр кетәге белән нәрсә була?

Шәех бу сорауны көтмәгән иде, ахрысы.

—Ә күгәрченнәр кетәге?—дип тагын кабатлады Юлия.

Шәех аяк астындагы боз кисәгенә тибеп куйды. Ул исә, чылтырап, юл буенча очты да, шактый алда кар көртенә кереп чумды. Юлиянең бу соңгы соравына җавабы юк иде анын.

Кар өемнәре өстеннән безнең ярым кирпеч, ярым бүрәнә булган йортыбыз калкып чыкты. Бөтен тәрәзәләрдә дә утлар яна. Анда—суык төрле рәсемнәр төшереп бетергән пыялалар артында, җылы, мичләр гүелди, табалар чыжылдый...

Ә монда, урамда, ачы суык. Тик ишегалдында күрше Милочканың гына:

—Мурка, Мурка!—дигән тавышы ишетелә.

Аерылышасыбыз килми.

—Кереп җылыныйк,—диде Шәех. Ул Юлиягә үзе күтәреп кайткан тимераягын бирми тора, аны озатып куярга да жыенмый иде бугай. Юлиягә дә, миңа да ачык: ул безне үзенә түгел, ә Николай Сергеевичка алып кермәкче.

—Сон инде,—диде нишләргә дә белмәгән Юлия.

—Мич янында чәй эчәрбез,—дидем мин, дустымны яклап.—Сездә мич юк бит, батареяләр, торбалар гына.

Ахырда Юлия биреште.

Өйалдының шыгырдавыклы баскычы буенча өскә таба күтәреләбез дә, үз ишекләребезне калдырып, Николай Сергеевичныкын шакыйбыз.

—Мөмкинме?

Һәм, казлар сыман тезелешеп, кухня караңгылыгыннан яктыга, җылыга,

тоткарсыз сыеныр урынга керәбез. Николай Сергеевич урындыгыннан сикереп тора, авторучка тоткан кулын, салют биргәндәй, югары күтәреп куя:

—У-у, менә алар, тимераякта йөгерүчеләр! Урамда утыз чамасы бугай. Өшемәдегезме? Чишенегез тизрәк һәм—мич янына! Инде мин монда борчылып беттем, ә сез һаман юк та юк.

Без аның сөенүенә шатланабыз, ләкин уңайсызланып та калабыз. Чөнки бүлмәсендә үзе генә түгел икән ул. Язу өстәле янындагы кәнәфидә утырган профессор Семён Васильевич Пичугин, кулындагы китабын читкә куеп, күзлеге өстендәге кашларын югары күтәрде.

## Йолдызлар яңгыры

Кайчак миңа Шәех ул мин үземдер шикелле тоела. Һич тә булмаса, ул минем үземнең аерылгысыз өлешем. Кайбер вакытта мин физик рәвештә икегә— Шәехкә һәм үземә аерылам сыман, ләкин еш кына мин аның белән бер зат булып береккән кебек. Без бергә булган ул вакыттан бирле инде бик күп сулар акты, тик мин, олыгая барган саен, аның белән безнең куш булып берегүебезне көчлерәк сизенәм. Еллар үткән саен һаман, һаман, дуслык—ул аралашуның үзе түгел, нindидер матди нәрсә дә түгел, акча җыеп бергә алган шәраб тә түгел, бергә тарткан хезмәт арканы да түгел, буйсынучыга начальниктан яисә киресенчә—начальникка буйсынучыдан килгән файда да түгел, ә боларның барысыннан да зуррак, шундый, ничектер рух дип әйтеп була торган нәрсә икәненә инана барам. Синең дустың һәрвакыт—синдә, ә син—анда. Мәхәббәт, әйе, янәшә булуны таләп итә. Дуслык—юк. Ул тән эгоизмыннан күпкә югарырак. Шуңа күрә дә ир-ат белән хатын-кыз арасындагы чын дуслык рухы белән сугарылмаган мәхәббәт ахыргы чиктә җимерелүгә дучар була. Уйлап карагыз, ни өчен, мәсәлән, хатын-кыз турында «тормыш иптәше» диләр, ә «сөяркә» сүзе үзенең беренчел мәгънәсен югалтты? Ә борынгы заманда «сөяркә» сүзе сөекле дигән мәгънәне аңлаткан булган бит.

Ул кичтә Шәех Юлияне озак озатты. Алар кызның әтисен подъездда көтеп алырга теләгәннәр иде. Юлия әтисе өчен борчылды, чөнки ул берүзе, төнлә... Аны тәрәзәдән күреп алырга да аерылышырга иде исәпләре. Юлия—өенә, Шәех исә, аның әтисе белән аймылыш булу өчен, бер катка өскәрәк күтәрелеп торырга...

Көз көне гаиләдә килеп чыккан орыш-талаштан һәм әтисенең йөрәк өянәгеннән соң Юлия аңа карата үзгәреп калды. Ул безгә ничектер: «Кешене рәнҗетү, аннары аннан беркайчан да гафу итүен, кичерүен сорый яисә сорарга өлгерә алмавынны, шулай итеп, аның алдындагы гаебеңне төзәтә алмавынны төшенү куркыныч нәрсә»,—дигән иде. Әтисе янына хастаханәгә ул һәркөн чапты. Һәм теге курку хисе гел аның белән бергә булды. Ул элек һич тә кичермәгән хисләр кичерә, әнисе, бабасы, абыйсы өчен курка, элек курыккан һәм яратмаган әтисе өчен дә борчыла башлады.

Семён Васильевич соңарды.

Шуңа күрә Шәех белән Юлия дә бер-берсе янында тоткарландылар. Алар, кайнар батарея янында җылына-җылына һәм тәрәзә артындагы кар дисәң кар булмаган нindидер җисемсез ялтыравыклы җиңел тузанга карап соклана-соклана үбешteләр. Күк айлы да, йолдызлы да иде.

Әтисе кайтып килмиме икән дип карарга урамга чыктылар. Каты кардан мәктәпкә кадәр атладылар, аннары, туңып, тагын кире кайнар батарея янына ашыктылар.

Әле күптән генәме беренче үбешүләр, кыюсыз гына аңлашулар, әле күптән

генәме киләчәкләре салават күперендәй матур һәм чәчәкләргә күмелгән кебек тоела иде. Ләкин тормыш бер дә проблемасыз гына булмый шул. Хәер, бәлки, бераз вакыт булып та ала торгандыр, тик озакка түгел. Шәех моны таныргa теләми иде. «Проблемалар юк,—дип ул инде ничәнче тапкыр үзе мәсьәләсендә, үзе турында Юлияне ышандырырга һәм тынычландырырга тырыша иде.—Өйдән китү зур бәламени! Башым—урынында, инемдә, аяк-кулларым исән-сау, югалмам».—«Син мине гаҗәпкә калдырасың»,—дип Юлия инде ничәнче мәртәбә аның ваемсыз булуына, үз-үзенә чамадан тыш ышанучанлыгына гаҗәпләнә. Ләкин шул кичкә, үгетләү рәвешендәге булышуы өстенә, Юлиянең башында практик фикер дә барлыкка килде.

—Шәех, минем бер үтенечемне үтәргә сүз бир,—диде Юлия, үбешүдән читләшеп.

—Тыелган алым кулланасың,—дип көлемсерәп куйды Шәех.

Ләкин алым инде кулланылган иде, һәм Шәех, сүлпән генә карышканнан соң, бирелергә мәҗбүр булды:

—Бирәм... Валлаһи,—диде.

Юлия чыгып торган аксыл, юеш чәчләрен ак, дымлы калфагы астына кыстырып куйды да, кулларын аның иңнәренә салды.

—Мин бабам белән киңәшкән идем... инде бу турыда ин элек кайсыбызның сүз башлавын да хәтерләмим... Хәер, монысы алай мөһим дә түгел, кыскасы, без сиңа яшәргә безгә күчеп килергә тәкъдим итәбез. Хәзергә...—Шунда кыз учы белән Шәехнең авызын каплады.—Хәзергә сиңа техникумда яисә башка җирдә гомуми торак бирә алмаслар. Бездә яшәп торырсың. Мин сиңа үземнең бүлмәмне бирәм. Үзем әнинекенә күчеп торам.

—Син ни сөйлисең?!—дип Шәех, ниһаять, битен Юлия бармакларыннан азат итеп.—Мин? Сезгә? Кем сыйфатында? Асрау булыпмы?

—Сез өчәүләп бер бүлмәдә яшисез бит, Шәех,—дип тиз-тиз сөйләп китте Юлия, ә без дүртәү—биштә! Бу гаделмени? Әнә Сашаның бүлмәсе бөтенләй буш тора. Ләкин мин сиңа үземнекен тәкъдим итәм. Дуслар сыйфатында тәкъдим итәм, курыкма, —дуслар!— кәләш буларак түгел.

Шәех, башын артка ташлап, шаркылдап көлеп җибәрде.

—Мин сезнең ул зур өегезгә рәхәтләнеп нәкъ менә кияү сыйфатында килеп керер идем. Ә болай нәрсә—башкода да түгел, туган да, фатирдаш та түгел. Синең абыеңа фатирыгызда урын җитмәде, ә миңа җитәргә тиешме?

—Тукта, син Саша белән килеп чыккан хәлнең асылын беләсең бит. Ул бүленергә теләде, әти моңа каршы, монда минем дә, әнинең дә, бабамның да бернинди катнашы да юк.

—Ә мине куып чыгара башлаганда барыгызның да катнашы булырмы? Әллә Семён Васильевичның катнашы булмасмы? Фатирыгыз бит, дөресен генә әйткәндә, аңа бирелгән, профессорга. Ә сез хәл итәсез...

—Министр булса да, бер кешегә андый фатир бирелми.

—Сезнең биш бүлмәле,—дип төгәллек кертте Шәех.

—Берсе үзебез ясаган аның,—диде Юлия, тәрәзәгә таба борылып, һәм инде ваемсыз гына дәвам итте:—Фатир безнең барыбызга да, шул исәптән, сугыш ветераны, инвалидка да, шул исәптән, миңа да бирелгән ул...

—Ачуланма, Юлия, мин теләмәгән идем,—дип Шәех аны кочып алды да карашын тәрәзәгә, аның артындагы әле һаман явып торган кар дисәң кар булмаган ниндидер җисемсез ялтыравыклы җинел тузанга юнәлтте. Күршеләр, үзара килешкән шикелле, аларның ялгызлыгын бозмадылар, гадәттәгечә, анда-монда кереп-чыгып йөренмичә, үз фатирларында тыныч кына утыра бирделәр.

—Мин дә теләмәгән идем...—дип пышылдады Юлия.—Яхшы булсын дигән идем.—Тынып калдылар.—Ә алай да син биргән сүзеңдә тормадың.

—Нинди сүздә?

—Минем үтенечемне үтәргә дигән.

—Йә, Юлия, килештек бит инде,—дип ялынды Шәех.—Ярар, рәхмәт сиңа. Ләкин син мине дә аңла. Минем урында син үзең нишләр идең?

—Минме? Мин килешкән булыр идем, чемоданымны җыяр идем дә һәм: «Исәнмесез! Кабул итегез!» Ләкин мине беркем беркая да чакырмый.

—Килер вакыт—чакырырмын. Әгәр берәрсе алданрак чакырмаса,—дип Шәех кашларын җыерып куйды.— Беләсеңме, Юлия, минем дә бер үтенечем бар сиңа. Үтәргә вәгъдә бир.

—Бирәм,—дип Юлия, кызыксынып, Шәехкә таба борылды.

—Әгәр миннән туйсаң, шундук әйт, ярыймы? Шундук... мин сиңа бер минутка да авыр йөк, мәшәкать булмасын өчен.

—Вәгъдә бирәм,—диде Юлия.—Ләкин син дә вәгъдә бир, әгәр мин сине туйдырсам, син дә шул сәгатьтә үк...

Араларны ачыклауны ишегалдында пәйда булган кара, бөкшәйгән, тайгак бозлы кар катлавы өстеннән курка-курка гына атлаган Семён Васильевич фигурасы өзде.

Юлия белән Шәех, алдан уйлап куйганча төрле якка чабып китмәделәр, ә аның каршысына бергә килеп чыктылар.

Ул бездән сәгать уникенчедә китте. Моңарчы гомерендә үзенең бусагасыннан ары беркемне дә озатмаган Николай Сергеевич кадерле кунак артыннан иярде һәм аны мәктәпкә тикле озатып куйды, ә аннан профессор өе кул сузымында гына инде. Мин аларның чыгып киткәннәрен ишетеп тордым. Кухняда, өйалдында алар үзләренең әле сөйләшеп бетермәгән сүзләрен дәвам иттеләр. Хәзерге шикелле хәтерлим, ул без шугалактан Николай Сергеевичка кергәнче башланган, ә без чыгып киткәч дәвам ителгән булган.

—Җитәр үткәннәрне искә төшерү,—диде Николай Сергеевич. Ул һәрвакыт каты итеп сөйләшә иде.

—Мин синең алда, Николай, бөтен күңелемне, гаебемне ачып салдым.—Профессорның тавышы акрынрак, ләкин нык иде. Анда бер үк вакытта озын, йокысыз төннәр буе уйланулар ачысы да, күңелен җәберләп торган ниндидер авыр йөктән котылу татлылыгы да һәм шуннан соң килгән аныклык та бар иде.

—Семён...—дип сүз кыстырырга тырышып карады Николай Сергеевич, ләкин булдыра алмады.

—Торып тор әле, Николай, торып тор... Минем тормышымның кайбер битләрен яңадан язу мөмкинлеге өчен никадәр күп нәрсә бирәсемне белсәң икән. Нинди хаталар җибәрелгән ул битләрдә, күпме ялгышлар! Ничек кырыс бу язмыш үзенең кире кайтмаслыгы белән!

—Семён...

—Торып тор әле, Николай, торып тор...

Алар, шулай сүз көрәштерә-көрәштерә, картларча әкрен генә безнең гел җырлап-шыгырдап торган өйалды баскычы буенча аска таба атладылар. Аннары бозланган болдырдан төштеләр, ишегалдының тактадан җәелгән бозлы юлыннан шыгыр-шыгыр килеп урамга юнәлделәр.

Мин кече йомышым белән бүлмәдән чыктым. Николай Сергеевичның ябып бетерелмәгән ишегеннән кухня идәненә авыш ут яктысы төшеп тора. «Тагын бүлмәсен бикләмичә калдырган»,—дип уйлап алдым мин. Бер мәртәбә шулай әти-әни дә минем арт сабагымны укыткан иде. Ул чакта фатир (фатир түгел, әлбәттә, ә бүлмә) ишеген бикләмичә калдырганмын, ә

алар кайтканнар да бөтен өске киемнәрне яшереп куйганнар. Мин мәктәптән кайтып керсәм, әти: «Безне басканнар» ,—ди. Мин—шкафка, ә ул—буш. Бары тик кичкә генә, миңа мораль укып туйгач, бөтенләй куркытып бетергәч кенә, яшерелгән әйберләрне кире урыннарына чыгардылар. Алар хаклы иде—ишеккә йозак бикләр өчен куела ич. Ләкин менә инде күпме еллар узды, ә минем гаепле башымнан узган ул чактагы тантаналы алдау, үзара күз кысышу һәм чукраклар өчен булган кул хәрәкәтләре белән тәрбияләп кыланулар өчен рәнҗү хисе шушы көнгә тикле күңелгә сеңеп калды.

Мин йомышымны үтәп килгәндә, инде Николай Сергеевичның ишеге ябылган, хәтта ныгытып ябылган иде. Мин моңа әһәмият бирмәдем, ләкин шунда мине кухня түрендәге ниндидер кыштырдау тавышы сагайта төште. Мин: «Кем бар анда?»—дип сорадым. Берәү дә җавап бирмәде. Шунда кухняның безнең яктагы утын яндырдым. Ләкин безнең лампочканың көче Шакировлар юынгычына тикле генә житә, ә арырак, чыгып-кереп йөри торган төп ишеккә табарак, тагын кап-караңгы. Йокларга ятар алдыннан мин үземнең борчулы шикләремне язу өстәле янында химик формулалар белән чуарланып беткән кәгазь дингезе өстендә бирелеп эшләп утырган абый белән уртаклаштым. Әти-әни шкаф артында йоклыйлар иде. Абый миңа игътибар белән карап куйды, янәсе, шаяртмыйммы, аннары, бармакларын шартлатып алды да (яшьлектән үк шундый гадәте бар иде аның), әкрен генә торып, кинәт тигр шикелле, омтылышлы ике йомшак сикерү белән кухняга ташланды. Мин—аның артыннан. Абый берсе артыннан бер-бер артлы өч утсүндергечне дә кабызып, безнең дүрт гаиләгә булган гомуми кухняны карап чыкты, Николай Сергеевичка да карады. «Беркем дә юк, Сергеич кайда йөри икән соң?»—дип гажәпләнде. Аннары төрле иске-москы белән тулган «парад подъезды» ишегендәге асылмалы авыр йозакны тотып карады һәм уртача көч белән минем маңгайга әчкерсез генә бер тапкыр чиертеп алды. Йокларга вакытында ятарга кирәк, шулчак күз алдына төрле нәрсә килмәс, янәсе.

Шәех белән Николай Сергеевич бергә кайттылар. Ләкин инде мин башка урын-җирдән тормадым.

Абый, аларның тавышларын ишетеп, лампа астыннан:

—Безнең галим күршебез коммунизмда яши— ишеген дә бикләми, ә үзенең әллә нәрсәләре бар,—дип куйды.

Һәм башы белән үз эшенә чумды. Анда нәрсәдер сызды-бозды да, ул битне йомарлап, идәнгә ташлады, үз алдына яңа бит кәгазь алып салды.

## ӨЧЕНЧЕ КИСӘК

### УНБЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### Авыру түшәге янында

Язга таба Кыям абый авырып китте. Бөтен гәүдәсен ниндидер көчсезлек басып алды, башы әйләнде, күкрәгендә йөрәге йә суыкта тунган куян койрыгы сыман калтыранды, йә, бөтенләй туктаган шикелле, тынсыз калды. Ничек кенә чыдарга тырышмасын, аңа урын өстенә ятарга туры килде һәм, инде моннан соң ул тора алмас, үләр, аның көчләре март аендагы кар кебек эри бара, дип белдерде.

Ул елны март бик елгыр булып килде. Алмалы, ул көннәрдә миңа география дәресендә сүрән генә җавап бирергә туры килгән ярсулы, йөз тармаклы Янцзы елгасы шикелле, каршы торып булмаслык язгы сулар белән хәрәкәткә килде. Мин, әлбәттә, тәрәзә артындагы язга карап йөздем һәм һичшиксез «икеле» эләктердем. Аның, инде шактый карт булган, аяклары

белән көчкә атлап йөргән безнең ул география укытучысының исемен дә хәтерлим әле: Валентина Оттовна. Ул, кәефе китеп, күңелсезләнеп, ә бәлки үзенең элеккеге укучыларына һәм үзенең кире кайтмаслык булып үтеп киткән еллары өчен үкенептер, миңа: «Ә синең абыең географияне яхшы белә иде...»— диде. «Ул аны хәзер дә белә»,— дип җавап бирдем мин. Һәм тәрәзә янында Шәех белән янәшә булган урыныма килеп утырдым. Без аның белән бер партада утыра идек. Дәресләрдән дә бергә качып киткәләдек. Географиядән соң без бүген Кыям абый янына барырга җыенган идек.

Безнең йөнтәс баш чүмечебезне яңадан җылы кояш җылыта һәм малайлар, туктаусыз чәрелдәүләре белән тирә-якны яңгыратып, яңадан урам буенча үзләренең кәгазь кораблары артыннан йөгерешә. Дәрес чамадан тыш озакка сузылгандай тоелды безгә. Дүшәмбе...

Авыру янында тәүлек буе диярлек аның кызы—Роза апа утыра. Аннары аны Юлия алыштыра.

Кинәт Юлия үзендә гадәттән тыш авыру янында утыручы-караучы няня сәләте барлыгын сизде. Тик бәла шунда гына, ул татарча начар аңлый иде. Кыям абый исә, көче бетә барудан бик тә зәгыйфьлеккә калып һәм кайчак аңын югалтып, туган телендә, анда да чак кына ишетелерлек итеп, мыгырдана-мыгырдана ята. Юлия аның: «Эчәсем килә», «аны бир», «моны китер»—дигәннәрен генә аңлый иде әле, ләкин бабасы үзенең күңеле түрендәге ниндидер яшерен уй-фикерләре белән бүлешә, җинел булмаган үз тормышының кайбер мизгелләрен хәтерли башласа, оныкасы үзен бик тә уңайсыз сизә. Ул үзенең аны аңламавы белән авыручыга өстәмә газап китергәнен яхшы төшенә һәм шуның аркасында тагын да күбрәк гасабилана иде.

Шулай бер тапкыр, бабасының авырган вакытында төссезләнеп, уңып калган күз бәбәкләре яңадан каралып калгач һәм мәгънәле игътибар белән ялтырап куйгач, Юлия аның салкын, бетәшеп калган кулын үзенең җылы учларына алды да, аны уалап, әйтерсең бабасы суыктан кергән дә, ул аның кан тамырларында туктап калган канын тарата алган кебек:

—Дәү әти, терелгәч, мине ничек тә татарча сөйләшергә өйрәтерсең әле,—диде.—Килештекме?

—Яхшы,—дип җавап бирде бабасы,—мондый үтенеч өчен тереләм, әлбәттә.—Ул хәтта елмаеп куйды, ләкин күзләре, алардагы өмет тудырган җанлануга карамастан, хәрәкәтсез калды.

Авыру бабасы янына оныгы Саша ике мәртәбә килде. Александр аннан хәле турында сорашты, ә тегесе, көчсезлеге белән көрәшә-көрәшә, оныгыннан аның гаилә тормышы хакында белергә тырышты. Кыям абый борын астында матур йөнтәс мыек йөрткән оныгы Александрның ярым-йорты җавапларыннан, ярым-йорты баш кагуларыннан аның Раинькасы белән аралары ул үзе күрсәтергә тырышканча бик үк яхшы түгеллеген чамалап алды. Саша сораулардан читкә китәргә, аларга туры җавaптан читләшергә, сүзне башкага борырга, хәтта шаяруга әйләндереп калдырырга тырышты. Алай да ахырда, икенче килүендә, теленнән шайтан тарткан шикелле, ул, берниен дә яшермичә диярлек, бабасына барысын да чыгарып салды.

—Туйдырдым мин аңа. Әнә шулай туп-туры: «Туйдырдың, сөрхәнтәй, миңа синең белән кызык түгел, күңелсез,—ди. Хатын-кыз буйсыңырга ярата, куркырга ярата, көчне ярата, ә син нәрсә?»—ди. Ягъни мин булам инде...

—Кыйна алайса син аны, шуннан соң куркыр ул.

—Мин сиңа житди итеп, ә син!..

—Мин дә житди. Кирәк бит, ә-ә? Мәхәббәт ул—коллык, ә?

—Бәлки, юләрлеге бетәр дә акылга утырыр, аңлар? Ярата иде бит...

—Кычыткан сабагында мәк чәчәк атмый, улым,—диде Кыям абый һәм, терсәгенә таянып, урыныннан күтәрелә төште.—Кире кайт! Хатын-кызга барысын да эшләргә рөхсәт итәргә мөмкин, тик һич тә үзенне кимсетерергә ярамый.

—Яратам мин аны, менә эш нәрсәдә,—диде Пичуга әкрен генә, бармаклары белән үзенең аксыл мыегын нервыланып сыпыра-сыпыра.—Ансыз хет элмәккә кер.

—Бу сүзләренне авызыңнан җил алсын!—дип Кыям абый кинәт кенә көрсенеп куйды.

Сизә иде картның күнеле оныгының мәхәббәт фронтындагы эшләре бик яхшы булмаганын, сизә иде. Әлбәттә, ничек була инде бу?! Саша бу Раинькасы белән инде күпме бергә тора, ә ул хатынның бер тапкыр да үзенә чакырганы да юк, үзенең дә күренгәне юк! Нишләп оныгы бабасы янына берүзе, ансыз гына килә? Яраткан кешеңә карата нинди мөнәсәбәт бу? Аның әти-әнисенә карата нинди мөнәсәбәт? Сораулар күп, ә җавап бер генә... Һәм бу җавап аңа асылда Саша сөйләвеннән соң тәмам ачыкланып калды. Оныгы бу хатын кулында уенчык кына булган. Яңа, матур, үзенә тартып торган уенчык. Менә хәзер уйнап туйган да ташлаган.

—Ә футбол белән ничек?

—Ташладым...

—Ә уку?

—Стипендиясез генә...

Кыям абый башын мендәргә төшерде дә күзләрен йомды. Аңа кабат начар булып китте. Ул Сашаның үзе яныннан ничек китүен дә белми калды.

Аның янына беркайчан беркемгә дә бармаган-йөрмәгән Николай Сергеевич та килеп китте. Галим авыручының урын-җире янында утырды һәм аның диагнозы әлегә тикле ачык билгеле булмаганга бик нык кайгырды.

—Нинди билгесез, танылмаган авыру соң инде бу?!—дип гаҗәпләнде ул.—Ә табиблар нәрсә ди? Нишләп җитди тикшерү үтү өчен стационарга салмыйлар икән?

—Өйдә үлүен яхшырак,—дип җавап бирде Кыям абый.

Николай Сергеевич кулларын җәеп җибәрде дә башын иненә сыендыра төште.

—Ай-яй, нинди начар кәеф! Ярамый алай, ярамый! Сезнең белән безнең, Кыям Әхмәтович, җирдә кул тимәгән күпме эшләребез бар әле! Ә үлем... Үлем ул—иң зур гаделсезлек. Һәм безгә аңа ирек кую килешми. Хәзер үзеңне ничек хис итәсең?

Сау-сәламәт һәм күнеле көр чакта «Тормышың ничек? Эшләрең ничек?» ише мондый сорауларга Кыям абый гадәттә: «Коточкыч...» дип җавап бирә һәм аннары: «...яхшы!» дип, янсә: «Көч юк... бу бәхеткә түзеп торырга!»—дип өстәп куя торган иде.

Әмма алтмыш икенче елның мартында аның хәле шаярырлык түгел иде.

—Начар, начар,—дип җавап бирде ул Николай Сергеевичка.—Туктаусыз күңел болгана, берни дә ашый алмыйм, бөтенләй аппетит юк.

—Лимон ашап карагыз, мин монда килограмм чамасы алып килгән идем.

—Рәхмәт, рәхмәт, ләкин булышмый шул ул.—Һәм кинәт:—Мин сезнең «Яшьлек эликсиры»н укып чыктым. Озын гомерле булып яшәве коточкыч икән, коточкыч, Ходай күрсәтмәсе-е-ен!—диде.

—Эш шунда, безнең барыбызга да озак яшәргә кирәк, ул чагында

коточкыч булмас.

Шәех белән без Кыям абый янына еш барып йөрдек. Һәм бервакытта да аның яныннан тизрәк ычкыну уе белән килмәдек. Бер тапкыр, кояшлы март көннәренең берсендә, география дәресеннән соң, аның янында бик тә озак утырдык. Аңа теге «Балтика»ны төзәтеп бирдек, бергә-бергә радиотыңлаучылар соравы буенча бирелгән концертны тыңладык. Роза апа өйдә юк иде—даруханәгә һәм кибетләргә дип чыгып киткән. Хуҗабикә урынына Юлия калган иде.

Авыручы үзен «коточкыч яхшы» сизә иде, хәтта урын-җиреннән урындыкка да төшеп утырды. Ул елларда бик модада булган буй-буй сызыклы пижамада, таралмаган, укмашып беткән, төпләре агарып торган (димәк, күптән буятмаган) чәчләренә караганда, ул башка кемгә булса да, бары тик оригиналь жанр артистына, бары тик рәссамга һәм, инде әйтеп тә торасы юк—Доваторның кавалерия корпусы сугышчысына һич кенә дә охшамаган иде. Ләкин без аның тышкы кыяфәтенә демонстратив рәвештә бер дә игътибар итмәдек. Шәех радиоалгыч янында утыра. Инде аны төзәтсә дә, аннан аерыла алмый, нидер боргалый, әйләндергәли. Мин—Юлиянең хуҗалык эшләре буенча урынбасары. Безнең төп максат—сүз арасында, эш барышында әкрен-әкрен генә өйдәге атмосфераны тормышчан рух белән баету, авыручыны сүрән уйлардан арындыру.

Тәрәзә төбендә чәй розасы гөлләре чәчәк атып утыра. «Балтика»дан әкрен генә курай моңы агыла. Тәрәзә артында калай кәрниздәге күк канатлы күгәрченнәрнең тыпырдау тавышлары ишетелә, алар күкрәктән чыккан тавыш белән гөрләшәләр. Аларның тавышлары бу минутларда бигрәк тә ачык ишетелә иде.

Юлия аларга челтәрле пәрдә аша карап:

—Алай да болар ирекле кошлар, ә синекеләр, Шәех, матур булсалар да—тоткыннар,—диде.

—Нишләп тоткыннар булсын?—дип каршы килде аңа Шәех.—Мин аларны гел чыгарам бит, алар үзләре кайтып керә.

—Әзер азыкка.

—Ул әзер азыкны башта әзерләргә кирәк бит әле аны,—дип тавыш бирде Кыям абый.—Моннан берничә ел элек син мәче баласы алып кайттың, ә аны ашатырга, астындагы комын алыштырырга миңа туры килде.—Ул шунда үзен көзгедә күреп алды да, чәчләрен төзәткәләп куйды.—Ә син аларны кышын да чыгарасыңмы, Шәех?

—Әлбәттә, Кыям абый, күгәрченнәр очмыйча торса, бик тиз арада тавыкларга әйләнә—тазаралар. Һәр көн очырам мин аларны.

Кыям абыйның карашы почмактагы өстәл-верстак янында ятим сыман боегып торган чеканкага төште. Анда эш кайсы төштә өзелгән, шул килеш тора бирә иде. Без дә карашларыбызны аның күп хезмәте кергән бу эшкә таба юнәлттек. Калае икенче, Шәех биргән түгел. Анысы бозылган, караламага киткән. Инде картинасы да башка. Алмалы, Кремльле туган шәһәр, елгалар, күлләр, каналлардан, бөтен җир шарыннан башка хәзер—күгәрченнәр һәм алар кетәге өстендә—Аккош, Аждаһа, Җидегән йолдыз, Арыслан йолдызлыклары, аларга исә, күгәрченнәр өере очышын дәвам иткән сыман, күп мачталы фантастик кораблар омтылган. Монда да Николай Сергеевич йогынтысы. Ләкин без бу турыда авыз да ачмадык.

—Тәмамлап бетерә алмам бугай,—дип көрсенде Кыям абый.

—Ә миңа ул тәмамланган шикелле тоела,—диде Шәех, чеканка янына килеп.

—Юк, өлгерә алмам инде,—дип кабатлады рәссам.

Без бер-беребезгә карашып алдык: «Ул тагын...»

Кыям абый радиоалгычка үрелде дә аны сүндереп куйды.

—Шәех, туганым, зинһар «Кара урман»ны жырла әле!—диде ул кинәт. Моны ул татарча, кулын, үтенгән шикелле, күкрәгенә куеп әйтте.

Мин, анын үз әтисенен кышкы урмандагы һәлакәте турындагы хикәятен искә төшереп: «Сез бу жырны тынлый алмыйсыз бит»,—дип әйтергә теләдем, ләкин телемне тешләдем, әйтмәдем.

Кыям абый Шәехтән, бу жырны беләсенме, дип сорамады, ә жырлавын үтенде. Ул ярты сәгать кенә элек радиоалгычны төзәтеп маташканда яшь дустынын борын астыннан гына бу жырны көйләгәнен ишетте. Мантыйк гади: көен белә икән, сүзләрен дә белергә тиеш. Жырны үзе өчен белә икән, башкалар өчен дә белергә тиеш.

Шәех кыстатырга яратмый. Йә шундук кискен рәвештә баш тарта, йә шул ук сәгатьтә үтенечне үтәргә керешә. Эшне аннарыга калдыру бөтенләй анын гадәтендә түгел иде. Калдырган чакта эш иксез-чиксез вакытка чаклы сузыла торган була.

Ләкин жыр—эш түгел. Жыр өчен бугаз төене комачауламый. Жыр күнел өчен—форточка. Минем дус бу сүз-такмазаларны кайчандыр—әле әнисе кияүгә чыкканчы ук—үзенен житез, булдыклы гармуны мехларын тарта-тарта кабатларга ярата иде. Әле ул тагын еш кына: «Кем күнелле жырлый, шул күнелле яши»,—дип тә әйтә иде.

«Кара урман»—сузып жырлый торган жыр, шомлы жыр. Шәех йөткереп куйды да, булдыра алганча тавышын түбән-түбән итеп, жырлап жибәрде:

—Ка-ра ур-р-ман...

Ул жырнын бер куплетын да жырлап бетермәде, шунда ишек ачылып китте дә, артсыз туфлие белән паркет буенча кыштыр-кыштыр килеп, бүлмәгә ияаклары кызарып-янып торган (әле генә урамнан) Семён Васильевич йөгереп килеп керде.

—Шулды-булдыны жырлыйсызмы?!—дип гажәпләнде ул.

Әйтерсен әле генә жыр янгырамаган да иде.

Кабер тынлыгы урнашты.

Аны Кыям абый бозды. Ул мәжүсиләргә, потка табынучыларга, Алланын әмерен житкерүче пәйгамбәр Мөхәммәт тавышы белән әкрен, ләкин анлаешлы һәм тәэсирле итеп, әле минем монарчы беркайчан да ишеткәнем булмаганча, әйтеп салды:

—Үземнен сонгы көннәрем белән ант итәм, безнен бу кабиләдәш юлдан язган...—Аннары рус сүзләрен татарча белән катнаштырып, пышылдап диярлек, дәвам итте:—Турылыклы юлдан. Юлдан язган һәм адашкан. Ана ничек тә ягып жибәрү өчен таш һәм кешеләр хезмәт итә торган утта янарга язмасын иде. И-и, Аллам, юлдан тайпылу ничек жинел дә сон!

Семён Васильевичнын кызарган йөзеннән кыюлык шундук юкка чыкты. Һәрвакыт ихтирамлы һәм йомшак каенатасынын бернәрсәгә дә охшамаган чыгышы аны хәйран калдырды. Профессор бер-ике секунд бозлы су белән коендырылган шикелле басып торды.

—Түбәнчелек белән гафу итүегезне сорыйм,—диде ул, ниһаять, исенә килеп.—Мин жырчыны да, жырны да, анын милли мөнәсәбәт ягын да хурларга теләмәгән идем. Жыр, кайсы телдә генә жырланмасын, ул халыкларны якынайта. Ләкин, ышанам, сез, бу кыргый яналыкны ишеткәч, минем зур булмаган һәм ирексездән килеп чыккан әдәпсезлегемне кичерерсез. Николай Сергеевичны талаганнар!

—Ничек т-талаганнар?—дип калтыранып куйды Кыям абый.

—Ничек икәнен мин күз алдыма да китерә алмыйм, бары тик сизенәм генә, ләкин талаучыларнын ниләр урлаганын әйтеп бирә алам. Көмеш акчалар коллекциясен, открыткалары сакланган саквояжын һәм утын

сараеннан борынгы иконаларын алып чыкканнар...

—Шулай берьюлы акчаларын да, открыткаларын да, иконаларын да?! Һөҗүм иткәннәрмени? Аңламыйм,—диде Кыям абый, урындыгыннан авыр гына күтәрелә төшеп.—Тиешенчә аңлатып бирегез!

—Тиешенчә... Николай үзе дә белми,—дип тагын да бөкрәя төште Семён Васильевич.—Монеталары белән открыткалары югалуын кичә кичен белгән. Ә бүген иртән утынга дип чыкса, утынлык ишегенең йозагы ватык ди. Иконалар салынган әрҗә, ди ул, күренә торган урында иде. Яшермәгән булган ул аны, әрҗәне. Менә ул да түтү! Сәер кеше бит ул, читкәрәк алып куеп, иске-москы белән каплаган булса иде. Юк. Монысы гына аз, хәтта бу турыда милициягә дә җиткермәгән, юләр! Бер генә тамчы да үзгәрмәгән ул. Әһә. Мин әле хәзер генә—аннан. Ә сез нәрсә, дуслар, беренче генә ишетүегезмени?—дип профессор карашын Шәех белән безгә күчерде.

—Беренче мәртәбә,—дип, бу яңалыкка Кыям абыйдан ким аптырамаган без баш селкеп куйдык. Бер көн элек без бөтен кичне Хәниф абыйда, аның өч аяклы корыч юргасын дагаларга булышып, аның сараен үзгәртеп корган гаражында үткәргән идек. Иртән иртүк тагын Хәниф абыйга, тагын гайка ачкычлары һәм шөрепборгычлар белән аның чыгышы ягыннан немецныкы булган сугышчан дусты янында маташтык. Алар техникасында барысы да—алды-артка бит. Ләкин бик тә ышанычлы машина үзе, бер генә буынга түгел, гасырларга чыдарлык итеп ясалган. Шулкадәр маташтык, чак кына мәктәпкә соңга калмадык. Мәктәптән соң менә Кыям абый янына килдек.

—Ярар, мин хәзер милициягә шалтыратам,—дип Семён Васильевич салмак адымнар белән бүлмәдән чыгып китте. Чыгышлый әллә безгә, әллә үзенә, әллә күнелендәге уен кычкырып әйтеп:—Талаучылар Николай Сергеевичка чит кешеләр түгел, кереп-чыгып йөрүчеләр булырга тиеш,—диде.

—Утын сараена барасыңмы хәзер?—дип сорады аннан Юлия. Семён Васильевич кызының бу соравын колагы кырыеннан гына үткәрде. Аның аягыннан туфлие төшә, ул аны аягы белән эләктерә, иелеп тормыйча гына төзәтеп куя һәм борылып карамыйча гына:

— Юлечка, миңа кер әле, минем сиңа әйтәсе берничә сүзем бар,—диде.

—Хәзер үкме?

—Юк, кунакларны озаткач.

Профессор үзе артыннан ишекне тавышсыз гына һәм тыгыз итеп ябып куйды.

Кыям абый «каһәр суккан жуликлар», «искелек калдыклары», «үтерелеп бетмәгән элементлар» адресларына тиргәү сүзләре яудырды. Нервлы ярсыну аңа көч бирә, ул бер почмактан икенчесенә таба йөренә, борылганда аны читкә таба каерып куя, ләкин ул, куллары белән мебельгә тотынып, аягында торып кала иде. Юлия аның артыннан борчылып күзәтеп тора. Шәех белән без кырын-кырын гына—ишеккә таба... һәм саубуллаша башладык.

## Сиңа бу турыда авыз ачарга иртә әле

Картлык көнендә профессор Пичугин яңа тормыш башларга уйлады. Хәер, хәзерге заман үлчәүләре буенча бу нинди картлык булсын ди? Аңа алтмыш та юк иде ич әле.

Семён Васильевич, үзенең кайчандыр иректе-ирексез рәвештә ясаган барлык гөнаһларын йолу өчен, калган көннәрен чиста, турылыклы һәм гадел яшәп бетерергә уйлады. Ә булдымы соң алар—гөнаһлар? Профессор,

табигый хәл, Ходайга ышанмый иде, ләкин Библияне хөрмәт итә һәм Соломонның гыйбрәтле хикәяләреннән, сүз жае килгәндә, мондый бер нәрсәне хәтерләп калган иде... Янәсе, кешенең барлык юл-сукмаклары да үзенең күз алдында чиста. Менә ничек! Ләкин тәнре төшеп калганнардан түгел бит, ул жанны үлчи, дип өсти Соломон. Ә Семён Васильевичның жаны күп вакытлар буена—инде берничә дистә еллар гына да түгел— тынычсыз, эч пошыргыч, нииндидер авырлыктан ул аның үз урынында түгел сыман тоела иде. «Гөнаһлар, гөнаһлар жыелды,—диде профессор соңгы вакытларда үз-үзенә,—таш булып жанны әнә шулар аска тарта». Ул «тарта» диде, ә гадәттә әйтергә күнегелгәнчә, «басып тора» димәде, чөнки ул үзенең жанын бишеккә охшаш итеп, эченә известь, кабырчык һәм тагын шуныңише башка нәрсәләр белән чолганып-ябышып каткан таш эләккән жәтмәгә охшаш итеп күз алдына китерә иде. Имеш, әнә шундый таш аның жанын аска тарта. Һәм, калган тормышында барлык суднолар да әйләнмәсен һәм һәлак булмасын өчен, ничек булса да шул таштан котылырга кирәк иде. Һәм менә ул, үзен озак вакытлар уйларга салып аптыратып бетергән бу адымының дөреслегенә шикләнеп йөри торгач, ниһаять, бар булган шикләрен читкә алып ташлады да, үзенең фикеренчә, юк, ышануынча, аның хәлен әле бу дөньяда ук жиңеләйтә ала торган бердәнбер кеше янына китте.

Ә тегесе исә үзенең дустының берниндн гөнаһлылыгы турында да белми иде. Әллә шулай кыланды гынамы? Юк, Николай икейөзлеләнә белми иде, ул аның килүенә шатланды. Аңа беркайчан да берниндн явызлык эшләмәде, үч тотмады ул. Шул исәптән, Таня Родимцева өчен дә. Ярым чаларган чәчле Николай таңды, әйе, ул Родимцеваны яратты. Яратты, ләкин ул бер секундка да гаилә тормышына, мәхәббәт хакына үз-үзен корбан итүгә әзер икәнен тоймады, женси дәртлелек катнашмаган саф, платоник хисләрне физиологик хисләргә алыштыруны, идеяләр, фән һәм шигърият дөньясын гадәти көнкүреш дөньясына алмаштыруны күз алдына да китермәде. Ләкин аның бу сүзләре Семён Васильевичны канәгатьләндермәде һәм шуна күрә ул аның алдында жанын әйләндереп салды, аңа үзе университет идарәсе әгъзасы булып торган чагында, вузның бик сәләтле студентларының берсе булган студент Новиковны «аз өлгерешлелек» өчен университеттан куганда һәм, куып, озак еллар буе үзенең законлы хокукында торгызмыйча яман атын саткан чакта үзенең куркаклык күрсәтүе хакында сөйләп бирде.

—Ләкин мине кире торгызмыйча аптыратып йөрткән вакытта син университетта юк идең бит инде...—диде Новиков, профессор Семён Васильевич алдында студент Семённы яклап.

—Аның каравы куып чыгарганда бар идем. Һәм тавышка куйганда битараф булып калдым. Таня белән сез мин идарә утырышын авыру сәбәпле калдырган, дип уйладыгыз, ә мин анда булдым, катнаштым бит. Ректорның шәхси үтенече буенча килдем һәм шунда синең язмышыңа битараф булып калдым...

—Күпчелеккә кушылып, «кире торгызмаска» дип тавыш бирмәгәнсең бит. Һәм аннары, Семён, синең тавыш берни үзгәртә дә алмый иде. Тарутин булып ул, университетта нинди абруйлы шәхес, Покровский тагын, Яковлевлар да булдыра алмады... Анда, мин шулай күзалдыма китерәм, кеше акылына да, мантыйкка да буйсынмый торган нииндидер иблис көчләре катнаштырылган иде. Шуңа күрә үзенне-үзең син гаепле булмаган нәрсәдә гаепләп газаплама. Мин бит үзем кайчандыр кайдадыр синең алда берәр жәнжал сәбәпчесе булдым, ахрысы, дип уйлап йөрдем. Ленинградтан минем хатларыма да жавап бирмәдең, аннан кайткач кермәдең дә...

Ләкин Семён Васильевич аклануга мохтаж түгел, аның жаны гафу итүгә сусаган, гөнаһларын кичерүне сорап айкала иде. Һәм аларның әңгәмәләре

бер-бер артлы һаман шул баштагы ноктасына әйләнеп кайта торды.

Өйдән чыгып Бригантинага якынлашып килгәндә дә алар икесе дә бер үк нәрсәне, һәр икесе дә үзенекен сөйләүне дәвам иттеләр.

Күп елларга сузылган аерылып торуларын тудырган сәбәпләр турындагы фикерләре уртак бер гомуми ваклаучыга китерелмәүгә карамастан, Семён Васильевич күнелендә барыбер бөек чистарыну сизде, һәм ул бу чисталыкны үзенең соңгы көннәренә тикле сакларга уйлады. Изге гамьсезлектә түгел, ә якыннары өчен яхшылык эшләп сакларга булды. Беренчедән, дустының «Пушкин—декабрист» дигән кульязмасы белән яхшылап танышырга кирәк дип санады. Әгәр ул фәнни кыйммәткә ия икән, аны бастырып чыгарырга булышырга; икенчедән, Родимцева (ул башка кияүгә чыкмады) янына барып, дуслыкны яңадан торгызу, аерылмас өчлек дуслыгын реставрацияләү, ягъни кире кайтару өчен, аны Николай янына алып килергә иде; өченчедән, Николайның барлык кульязмаларын—фәнни эшләрен, романнарын, повестьларын, шигырьләрен карап чыгарга һәм бастыру өчен сайлап алырга; дүртенчедән, бишенчедән... Хәер, зур тынычлыкны саклау планының пунктлары бик күп иде әле.

«Яңа тормыш» системасында гаиләдәге, эштәге үзара бәйләнешләрне яхшы якка үзгәртү дә каралган иде... Профессор, институт директоры, депутат, ир, әти, кияү, күрше, шәһәрдә яшәүче, җитмәсә, каената да бугай бит әле, ул моннан соң кешеләр, үзенең әйләнә-тирәсендәгеләр турында риясыз кайгырту, әдәпле, игътибарлы мөнәсәбәттә булу хисе белән янарга тиеш. Хәтта үзенең шәхси мәнфәгатьләренә зыян килерлек булса да, шәхси симпатия һәм антипатияләренә, кәефләренә һәм үз-үзенең хәл-әхвәлләренә каршы килсә дә.

Яңа тормышның башы өметле иде. Бар гыйнвар, февраль һәм менә инде март Семён Васильевич Иисус Христосныкы рәвешендә һәм аныкына охшашлы тормыш алып бара иде. Ул үз кабинетыннан «халыкка» чыкты, бик игътибар белән, көнкүреш проблемаларын да кертеп, үз гаиләсендәге хәлләр белән кызыксынды, кызының мәктәптәге өлгерешенә игътибар итә башлады. Аннары Саша белән очрашу, аның белән тигез һәм үзара хөрмәтләшү платформасында сөйләшүне билгеләп куйды, Раинькаңы күрәсе килү теләге барын белдерде. Берничә мәртәбә хәтта эштән кайтышлый өйгә азык-төлек йөге— казылык, хәлвә, макароннар белән авырайган хәлдә кайтып керде... Кыскасы, яңа тормыш зур хисап буенча тәгәри башлады. Инде ана ул мона, мондый тормышка түзәр, алга таба да, айдан-айга, елдан-елга да шулай дәвам итәр шикелле тоелган иде. Әлбәттә, бик җиңел түгел иде бу рәвешле тормыш. Бер мәртәбә һәм гомерлек дип сайлаган туры һәм кырыну пәкесе сыман үткен булган хакыйкатьтә тотынып калу өчен һәр көн, һәр минутта тупланганлык таләп итела, һәрдаим үз-үзенә караштырып алу һәм үз-үзенне тыңлап карау, даими ачык, юк, ачылган булу һәм шул ук вакытта күңеленнең чип-чиста, берникди тапсызлыгы зарури иде. Башкача берничек тә мөмкин түгел.

Ул яңа тормышы яхшы гына бара башлаган вакытында әнә шулай уйлады. Ә уңышсызлыкка дучар булгач исә, үзенә икенче төрле әйтте. Ул чакта ул үзенә: «Үз табигатенә-холкыңа үзең йөгән кидерә алмыйсың!»—диде.

Бу хәл мартның соңгы атнасында булды. Николайны талаулары турында белгәч һәм бу турыда алдан кайбер нәтиҗәләр ясап алгач, милициягә шалтырату өчен ул өенә йөгереп кайтты да, өстеннән пальтосын салып атты, аягына өй туфлиен киеп алды һәм менә шунда каенатасы бүлмәсеннән тыныч кына агылучы Шәех улавы ишетелде. Җырлыйлармы? Монда шундый эш, ә алар җырлап утырамы? Бу турыда белә торып, кемдер менә шулай җырлый аламы? Ә анда әле бу турыда белмәүләре турында өлкән

Пичугин күз алдына да китерә алмаган иде. Шәех Николайның янәшә күршесе, хәтта дусы шикелле иде дә бит әле, житмәсә...

Семён Васильевич кабинетын үзенен авыр адымнары белән үлчи-үлчи авыру каенатасы янына жыелган төркем өстенә үзенең малайларча ташлануын тәнкыйть күзлеге белән башыннан кичерде. Чәпчеп китте бит, каһәр, ике айлык әхлаклы кеше, икенче подъездның Иисус Христосы шундый бер мизгелдә сабын куыгы шикелле шартлады да куйды!

Ишек шакып, Юлия килеп керде.

—Син миңа нәрсәдер әйтмәкче, әллә кушмакчы идеңме, әти?—диде ул.

—Әһә, кызым. Утыр,—дип Семён Васильевич аңа язу өстәле янындагы урындыкка күрсәтте, үзе кәнәфигә урнашты.—Синең белән сөйләшергә телим. Элек мин сезнең тәрбия эшенә тыкшынмадым. Синең белән дә, Саша белән әниең һәм бабаң шөгыльләнде. Мин исә, шулай әйтергә яраса, гаилә белән гомуми идарә эшен алып бардым... Шулай әйтергә яраса, безнең гаилә бригантинасы белән... Ә син беләсеңме, безнең өйне дә бригантина дип йөртәләр икән бит?

—Беләм.

—Әйе, монысы сүз арасында гына. Менә нәрсә... Син ник алай карыйсың?

—Ничек?—дип Юлия иңбашларын жыерып куйды.

—Шикләнеп.

—Юк, игътибар белән, әти.

Семён Васильевич кызына карап алды да вакытның ничек шулай тиз агышы турында уйлап куйды. Күптән генәмени әле аны, шушы елак кызны, төргән килеш балалар тудыру йортыннан алып кайтканнар һәм ул аның бостон чалбарын юешләгән иде? Ә менә хәзер ул аның алдында утыра һәм син аңа ничек якын килергә, ничек сүз башлап жибәрергә икәнен дә белмисең...

—Менә шулай... Минем әниең һәм бабаңның тәрбия сферасындагы эшчәнлегенә катнашмавымның, ягъни, шулай әйтергә яраса, ышанычымның нәтиҗәсе нинди булды соң? Ә нәтиҗәсе гади, ул күренеп тора һәм, игътибар белән анализлаганда, гажәп тә түгел. Саша, мине—гаиләне туендыручыны хурлап, мыскыл итеп, ишекне каты ябып, өйдән ниндидер Рая янына чыгып китте... Ә ул хатын аңа әнисе урынына ярый, дип сөйлиләр, һәм мин, ягъни аның каенатасы, алар менә инде ярты ел бергә яшәсәләр дә, аны, ул хатынны, бер тапкыр да күргәнем юк. Син мине аңларга тиеш, Юлия, менә шулай итеп мин сине дә югалтырга теләмим. Мин әдәп буенча моңарчы сезнең мөнәсәбәтләргә катнашмый килдем, әмма бу Шәех, Юлия, миндә артык ышаныч тудырмый. Әнисе ишегалды себерүче, әтисе... Аны мин барлыгы ике мәртәбә генә очраттым һәм ул икесендә дә исерек иде. Хәзер—менә сиңа мә!—юаш, һәркем өчен дә бөтен яктан ачык булган Николай Сергеевичны таладылар. Ә Шәех—Николай Сергеевичның бик якын дусты. Ул үзен шулай дип атый, ә менә шушындый вакытта күңелле генә итеп жырлар жырлап утыра. Бу хәл сиңа, йомшак кына итеп әйткәндә, сәер тоелмыймы?—Семён Васильевич, жавап көтеп, бераз тынып торды. Жавап булмады.—Нигә дәшмисең?—Семён Васильевич үзендә һич тә Христосныкы булмаган ярсу барлыкка килүен сизде.

—Тоелмый,—дип жавап кайтарды, ниһаять, Юлия сабыр гына. Ул шунда әтисен: «Шәехнең әнисе ишегалды себерүче булып эшләми инде, Гайнан Фазлыгалләмович Шәехнең әтисе түгел, ә үги әтисе. «Кара урман» исә бер дә күңелле жыр түгел һәм ул һич тә кунак теләге буенча жырланмады»,—дип төзәтергә теләгән иде. Ләкин аннары, бик әһәмияте булмаган мондый

аңлатмалар белән нигә сүз озайтып торырга, дип уйлап алды. Тагын әллә нәрсәләр әйтеп куярсың... Ә этисенең йөрәге авыру...

—Минем талауда кемнән дә булса шикләнерлек турыдан-туры берниндги нигезем дә юк,—дип дәвам итте Семён Васильевич.—Ләкин шунысы ачык: Николай Сергеевич фатирында аны яхшы белгән һәм аның бүлмәсендә гамьсез күршесенең ишеген бикләмичә чыгып китүен саклап торырга мөмкинлеге булган субъект үзе теләгәнчә йөргән. Бар Николай Сергеевичның гамьсезлек гадәтендә җинел акыллылык, бар. Ул, күрегез аны, Космос Коммунистик Цивилизацияләр Союзына ышана, хәтта боларның барысын да зур хәреф белән яза. Ә үзе әле коммунизмның җирдә дә юк икәнен онытып җибәрә. Ә бит аның хәрбиеннән башкасы булмаган да һәм юк та! Әйтик, хәрби коммунизм... Менә бит, Совет власте таңында бу ике сүз берләште. Ике сүз, аларның берсен иптәш Новиков түзеп тора алмый, ә икенчесен балалар беркатлыгы белән илаһилаштыра.—Семён Васильевич бераз хәл алды да, уйланып, кабатлап куйды:—Космос Коммунистик Цивилизация Союзы...—Һәм үз фикерен дәвам итте: — Ярар, безнең Сен-Симонны аның идеясе һәм хыяллары өчен гаепләмик, ә тирәякка караныйк һәм әкиятне чынлыкка әйләндерү өчен барган көрәштә безгә тагын кемнең комачаулавын ачыклыйк.—Шушы сүзләреннән соң профессор үзендә ярсулыкның кимеп калуын сизде, йөрәге гадәти, элеккеге сау-сәламәт режимда эшли башлады. Ул кәнәфиеннән торды да артында яз хакимлек иткән тәрәзә янына килде, егетләрчә хәрәкәт белән аркасыннан бөкшәюен алып ташлагандай булды.—Юлия, минем сүзләремә аңлы караштa бул һәм аларны яшьлеккә хас һавалык белән юкка чыгарырга ашыкма. Кызыксын әле син, бәлки, Шәех яисә Ренат ул вак акчаларны яки открыткаларны карарга, кемгәдер күрсәтергә дип вакытлыча гына алып торганнардыр? Болай гына, аны-моны уйламыйча гына. Бәлки, бу гомумән, талау да түгелдер... Һәм монда борчылырлык урын да юктыр. Әһә, Юлия?

—Яхшы,—диде Юлия тыныч кына.—Ләкин мин Шәех белән Ренат, Николай Сергеевичның дуслары булып саналып, аның дуслыгына лаеклылар, дип әйтергә телим, эти. Чит әйберне, хәтта кыска гына вакытка да, сораусыз алу алар кагыйдәсендә түгел.

—Аларның кагыйдәләре бармыни?

—Бар, эти. Алар намуслы кешеләр. Һәм мин аларның берсен—кемне икәнен син беләсең—яратам да.

—Нинди мәгънәдә?

—Туры мәгънәдә: я-ра-та-ам...

Семён Васильевич кызының әдәпсез һәм оялмыйча ачыктан-ачык белдерүеннән тончыгып калгандай булды.

—Сиңа бу турыда авыз ачарга иртә әле. Иртә! Мин аңлыйм: дуслык мөнәсәбәтләрен саклау бер нәрсә. Ә болай—яратам, имеш. Минем шикләрем турындагы сүзләрдән соң телең ничек әйләнә шулай дияргә! Билгеле, мин синең аның белән, ничек әйтелә әле ул сездә... йөрүенне беләм. Бу турыда бөтен тирә-юнь гайбәт сата. Шуңа күрә катнашам да мин. Миңа синең язмышың барыбер түгел бит, аңла шуны! Мин синең дә абыең батырлыгын кабатлавыңны теләмим. Аның өчен үстермәдем мин сезне. Һәрхәлдә Шәех белән Рая өчен түгел—аның фамилиясен белмим. Менә кая килеп чыктык, яши торгач!—дип Семён Васильевич, аппаратны чак кына идәнгә төшереп җибәрмичә, телефон трубкасын эләктереп алды да саннар җыйды.—Милициями? Петр Изотыч? Дубов, синме?

—Миңа китәргә ярыймы, эти?—дип сорады Юлия.

—Бар, бар... Һәм яхшылап уйла.

### «Катнашучылар»

—Мин открыткалары белән саквояжны кем чәлдергәнен беләм. Акчаларны да, иконаларны да,—диде Шәех, без аның белән Пичугиннардан, дөресрәге, авыручы Кыям абый янышнан чыккач.—Гайнан абый ул... Бу аның эше. Һичшиксез.

—Син аны куралмыйсың, шуңа күрә генә...

—Юк, Ренат, минем анда инде элек тә берничә көмеш акча күргәнем булды. Һәм аны, дәшми калмаячакмын, дип кисәтеп тә куйдым. Ләкин ул... Син аны белмисең, аны беркем дә белми, ул шундый тирес коңгызы, шундый коңгыз... Аны коры кул белән генә алып булмый. Һәм ул, хәшәрәт, шуның белән файдалана, күзгә карап мыскыл итә, әшәкелек эшли, урлый, эчә һәм көлә бирә. Күрәсеңме, ул шул акчаларны Николай Сергеевичка кире кайтарып бирү түгел, әнә тагын нәрсә эшләп ташлаган. Төкереп бирә ул минем кисәтүләргә. Әй, ничек котырынды аның аппетиты, әй, ничек котырынды.

Юл уңаенда без Коля Титенконы очраттык. Ул яңалык җиткерде: Алик Насыйбуллин «Очкын» осталар командасында күнегүләр үтә башлаган, аның каравы Сашка Пичугин футболны бөтенләй ташлаган икән.

—Ә бит класслы футболчы чыгарга мөмкин иде аннан,—диде Титенко.—Хатын-кыз аркасында башын югалтты!

Титенко тагын бераз вакыт телен кашыган булыр иде дә, ләкин без аның шатлык һәм күңелсезлекләрен уртаклашмадык.

—Сау бул, Коля, без ашыгабыз,—дидек тә китеп бардык.

Беренче чара итеп, алай да, хәлне ачыклау, эшнең ничек торганын, коллекциясе югалуын кайчан һәм ничек белүе, соңгы вакытта аңа бездән башка кемнәр кергәнен ачыклау өчен, Шәехне Николай Сергеевич янына керергә күндердем. Килешеп өлгермәдек, тыкрыктан безнең янга тилергән сыман Киләле килеп чыкты.

—Жбанны милициягә алып киттеләр!—диде ул.

—Ни өчен?

—Сорочка базарында ниндидер иконалар аткарган ди.

—Барысы да ачык.

—Нәрсә ачык? Әйдә Хәниф абыйга керик әле, ул безнең дус бит, булышсын. Жбан бурычлы булып калмас,—диде Киләле.

—Барысы да ачык,—дип кабатлады Шәех.—Менә, димәк, утынлыкка кем кергән. Киттек, Ренат!

—Сез нәс-тә, егетләр? Ә Жбан белән ничек?

—Синең Жбаның—сарык ул...—Шәех тагын нәрсәдер өстәргә теләгән иде, ләкин тиз генә кирәкле сүзләрен таба алмыйча, кулын селтәп куйды да без китеп бардык.

—Их сез, тавыклар,—дигән сүзләр очты безнең арттан.—Сезне Жбан аз тукмаклаган икән әле!

Шәех борылып карады, ләкин Киләле үкчәсен «майлаган» иде инде. Ничек тиз килеп чыкса, шулай юк та булды.

Без Николай Сергеевичны күрүен күрдек, ләкин аның белән сөйләшә алмадык. Ул ишегалдында иде. Йортыбызның бар кешесе өер булып ишегалдына җыелган. Хәтта кешеләр белән аралашмаучы Милочка да шунда. Кулына мәчесен дә тоткан. Бары тик Рәшидә апа гына юк, ул узган атнада авылга киткән иде.

Ачык капка янында, тротуарга менеп, зәңгәр-кызыл милиция «бобигы» тора.

—Соң, менә бит ул,—дип күрсәтте Гайнан абый Шәехкә, хром итекләре

белән аяк очыннан үкчәсенә күчә-күчә шыгырдап. Ул ике милиционер белән пальтосыз, пинжәктән генә янәшә басып тора иде. Кунаклар да өске киемсез.

—Шакиров Шәехме син?—дип ачыклады Шәехтән киң җилкәле, мундиры белән береккән шикелле тыгыз гәүдәле капитан.—Киттек әйдә.

Дустым шунда Гайнан абыйга карап алды, аннары карашын яннарына авыр кобуралар тагылган, аныкы шикелле үк итекләр кигән җәмәгать тәртибен, гражданнарның социалистик куркынычсызлыгын һәм шәхси милкен саклаучылар вәкилләренә юнәлтте. Ләкин капитанның итекләре чамасыз, хәтта гаҗәеп зурлар һәм инде тәмам искереп беткәннәр. Алар—капитан белән Гайнан абый, сүрәнләнеп, катып калган йөз белән аларга үтәргә туры килгән зур, авыр юллар турында сөйләшеп торалар иде. Гайнан абыйның хром итекләре ялтырап тора.

Шәех ваемсыз гына иңнәрен җыерып куйды да конвой алдыннан машинага таба атлады. Мин аның үзгәрмәс кискенлеген беләм, ул хәвеф-хәтәр яисә файда турында—кечкенәме алар, яисә зурмы—фаразларга яратмый. Ләкин минем аны менә болай ваемсыз рәвештә беркайчан да күргәнем юк иде бугай әле. Ә монда—ниндидер салкын ваемсызлык, ис китмәүчелек. Эссе дә түгел аңа, суык та. Әйтерсең, яхшы дуслары озатуында җәмәгать транспортына утырырга бара.

—Иптәшләр, ниндидер аңлашылмаучылык килеп чыкты!—дип халык арасыннан «бобик»ка таба Николай Сергеевич якынлашты.—Мин шалтыратмадым, милициягә хәбәр итмәдем, мин беркемнән дә шикләнмим. Нишләп зыян күрүченең фикерен искә алмыйсыз? Бу нинди башбаштаклык?! Без кайсы вакытта яшибез?

—Борчылмагыз, Николай Сергеевич!—дип борылып карады Шәех, машинага кергәндә.—Барысы да үз урынына басар.—Һәм күзе белән ялтыравыклы хром итекләр белән зөбәрҗәт төсендәге галифены эзләп табып, әйтеп куйды:—Очрашканга кадәр, әтикәй!

—Оревуар, улым,—диде йомшак тавыш белән Гайнан абый, аңа кулын селтәп. Читтән караганда, кайгыртучан әти кеше үзенең сөекле малаен пионерлагерьга озата, дип уйларга мөмкин иде. Юк, яше буенча, ниндидер спорт лагерена озата иде кебек. Әгәр дә монда опер-«бобик» булмаса, әлбәттә.

Машина кузгалып кына китте, шулчак Юлия йөгереп килеп җитте.

Машина артыннан буылдыргыч газ исе генә калды. Без—Николай Сергеевич, Юлия, мин—сирень куагы янындагы эрегән кар астыннан чыккан ишегалдындагы эскәмияле өстәл янына үттек. Кешеләр таралышты. Хәер, без аларга текәлеп карамадык та, чөнки аларда эшебез юк иде. Гайнан абый, безнең янга килергә җай эзләп ишегалды буенча әйләнде-бөтерелде, төтенләде-тартты, ләкин нишләптер килергә үк кыймады, аннары әкрен генә юк булды.

Бу безнең иң кыска очрашуыбыз, иң кыска, яшен тизлегендәге сөйләшүебез булды булуын. Николай Сергеевич тирәсенә җыелган безнең төркем кайчан шулай тиз очып таралыр иде? Хәер, тулы мәгънәдә төркем дигәне дә юк иде аның. Чөнки монда Шәех юк иде. Киләчәктә ул да булсын өчен ашкынып эш итәргә кирәк. Юлия белән без туп-туры, юл аша, Хәниф абый өенә таба атладык. Николай Сергеевич, мөнәсәбәтләрен ачыкларга, үзара аңлашырга, соңгы көннәрдәге бөтен бу хаосны ниндидер бер логик җепкә тезәргә, дип, Семён Васильевичка китте. Әмма Семён Васильевич өйдә юк иде. Кыям абый аны көтеп торырга кыстаган иде дә, тик утырып торырга аның вакыты булмады. Николай Сергеевич туп-туры профессорның эшенә китте, ләкин аны анда да туры китерә алмады. Ә телефон белән ул гомерендә дә файдаланмады дияргә була.

***

Милициягә килү белән капитанны ашыгыч рәвештә каядыр чакырып алдылар. Шуна күрә ул, бүлеккә дә кермичә һәм киенеп тә тормыйча, шул ук машинада китеп тә барды. Шәехне тимер белән тышланган ишек артындагы тәрәзәсез, түшәмендә кечкенә генә мунча лампочкасы янып торган бүлмәгә алып керделәр. Соңыннан аңлашылганча, тиешле ишек артына түгел, чөнки анысында «җинаятьтә катнашучы» Анатолий Жбанов утыра икән. Ләкин ялгыштан беркайда да хали түгелләр—һәр җирдә дә кешеләр эшли бит...

Йодрыклары белән башын терәп утырган Жбанов ачылып киткән ишеккә игътибар итмәде. Аннан башка ике катлы сәкеләрдә тагын икәү урнашкан. Аларның берсе икенче «кат»та тәмле итеп гырылдый, икенчесе аста, Жбан каршында, тырышып тырнагын кимерә иде.

—Ә-ә, син...—диде ул, Шәехнең төртүенә җавап итеп.—Нинди җилләр белән син монда?

—Минә сине чит утынлыкка нинди җилләр китереп кертте? Хәер, нәрсә инде... Барысы да синең стильдә. Йозакны утын пүләне белән ватып ташлагансың ... Синең моны ничек эшләгәненне күргәнем бар. Аннары иконаларны култык астына һәм Сорочкага! Әйе-е... Шундый борынгы иконаларны туп-туры базарга, халык арасына алып бару уе, мөгаен, синең башка гына килергә мөмкиндер. Ә открыткалар белән саквояж кайда? Көмеш акчалар?

—Ташла,—дип турайды Жбан,—син миңа башкалар эшен ябыштырып маташма!

Шәех саквояж белән акчаларның Жбанов эше түгел икәнен үзе дә аңлый иде. Ләкин Киләле белән сөйләшкәннән соң, беренче булып башка килгән, бердәнбер талаучы— Гайнан абый, дигән фикер расланмагач, Шәех күңелендә шик дисәң шик түгел, ә шулардан башка сөйкемле үги әтисен стенага терәп булмаган төгәл мәгълүматларга зарурлык туды. Жбан ул, гәрчә барысын булмаса да, күп нәрсәне белергә тиеш. Чөнки ул Йолдызчының, элеккеге «сәүдәгәр»нең сизелеп торган «иксез-чиксез байлыгы» тирәсендә бөтерелүче, ә майлы калҗа күргәч, авызларыннан селәгәй чыгарып һәм яланып кына канәгатьләнеп калмый торган өердәгеләрнең берсе бит.

—Әгәр син түгел икәнсең, саквояжны кем чәлдерде соң ул вакытта?—дип сораштырды Шәех, янәшәсендә тырнагын кимереп утыручының алар сөйләшүенә игътибар итүенә исе китмичә. Шәех Жбаннан сорау алса да, аның әчкерсезлегенә бик ышанмады, алай да аннан Гайнан абыйга карата барлыкка килгән шикне аз гына булса да раслый, ахырында читләтеп булса да сиздерә торган вак-төякне тартып чыгару мөмкинлегенә ышана иде. Үги әтисе чамадан тыш ап-ачык һәм оятсыз рәвештә кылана. Ничек инде, аның өчен табигый булган уяулыкның күләгәсен дә сакламыйча, төрле кыңгыр эшләрен, турыдан-туры алдашу-урлашуларын раслаучы, исбат итүче әйберләтә дәлилләр белән шулай ачыктан-ачык мактанырга, элеккеге кара эшләре турында сөйләп йөрергә мөмкин? Ул, әлбәттә, сөйләнүен ачыктан-ачык сөйләнеп йөри... Ләкин шаһитлар булмаганда. Андый сүзләр шулай ук шаһитларсыз, аның авызыннан күралмаган үги малае янында гына түгел, тагын кемнәрдер алдында да чыгарга тиеш иде бит. Мәҗбүри рәвештә. Һәм иң беренче чиратта ул якынча гына булса да үзенә охшаш һәм котылгысыз рәвештә бергә эчеп утырган кеше алдында ачылырга тиеш иде. Ә монда Жбан да соңгы кандидатура түгел.

Жбан классташының үз өстенә ташлануыннан сүлпән генә кул селтәп утырды-утырды да, кинәт кенә аның эчендә моңарчы күздә тотмаган, күңелендә каралмаган нәрсәдер сынган шикелле булды. Башта ул аны

бик ерактан әйләнеп киткән шикелле, хәтта бөтенләй икенче даладан сыман тоелды. Кинәт Пичугага, аның сүзләре буенча, химикка, юынтык су сибәргә тотынды. Янәсе, ул үзенең якыны артында химия белән бик житез шөгыльләнә. Һәм төкерә ул хәзер аңа үзенең чиркәү манарасыннан. Тигез жирдә түмгәк табылган! Ул аннан, очсыз шантажчыдан, кишерем дә курыкмый.

—Күрербез, нәрсә авыррак—минем йодрыкмы яисә аның шакшы телеме! Күр син аны, эләктергән, имеш, фраер, әйтерсең моның белән астыртын гына үзе шөгыльләнмәгән!

—Нәрсә белән?—дип сорады аның үз-үзенә нык раслау белән агылган сәер тиргәвеннән аптырап калган Шәех.—Ни сөйләвең?

—Ни сөйләвең, ни сөйләвең... Менә шул!—дип Жбан үзенең култыкса баганачыгына охшаш кыска аякларына торып басты һәм, тавышын әкренәйтә төшеп, ләкин ачык итеп теш арасыннан сыгып чыгарды:—Ә шул: саквояж—Пичугада.

—Пичугада?

—Ес ай ду, сары саквояж сэр Пичугада. Бу аның, профессор малаеның хәйләле эше. Ә бөтен күркәне миңа аударырга булганнар. Тапканнар юләрне. Нindидер сарай кисәге аркасында... Мин болай гына, гомуми шау-шу астында гына... Ә менә ничек килеп чыкты...

Ниһаять, күренмәс радиосхема чылбыры тоташты: Пичуга—открыткалар коллекцияләүче—открыткалар белән саквояж—аларны Николай Сергеевичтан алыштырырга, сатып алырга, теләсә нинди юл белән кулга төшерергә омтылу... Схема төгәл ачык, инде хәзер штепсельне розеткага тыгарга да мөмкин.

Жбан идәнгә какырып куйды да аны ботинкасы белән ышкып алды.

—Әй, туйдырды мине бу Пичугалар! Берсе, кызлары, утырып жаныма бушанды, икенчесе минем жанымнан бау ишәргә алынды. Майлы кәжә тоягы сезгә! Жбан сезгә тумран агачы түгел, аның да үз горурлыгы бар.

Шәех аны тыңлады да, тыңламады да. Ул Николай Сергеевичның урланган милкенең ничек бүленүе турында уйланды. Берәүгә—иконалар, икенчесенә—акчалар, өченчесенә—саквояж. Ләкин аны Пичуга ничек алган икән соң? Бу турыда ул, ярсулы сафсата сатуын бүлдереп, Жбаннан туп-туры сорады да.

—Син нәкъ прокурор шикелле,—диде аңа Анатолий Жбанов, ачу ялкынын сүрелдерә төшеп.

—Әгәр шулай булса икән...—дип көрсенде Шәех.

—Юри утыртылган үрдәк түгел, димәкче буласыңмы?

—Мин дә сак астында, синең шикелле үк,—диде Шәех һәм: «Тик ни өчен икәнен генә белмим»,—дип өстәмәкче иде дә, ләкин тыелып калды.

Жбан, үзенең сары-яшел күзләрен кыса төшеп, лампаның тоныкъ яктысында классташына нindидер шик белән төбәлебрәк карап торды да, бармагы белән икенче катның тактасына төртеп шундый итеп, хәтта гырылдаучы гырылдавыннан туктап калды, ә тырнагын кимерүче бармагын авызыннан алды, бөтен камераны яңгыратып:

—Ул чагында, Багдад шәехе, синең урының менә монда,—дип көлеп жибәрде.

## УНИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### Сишәмбе—авыр көн

Сишәмбе көнне Гайнан Субаев эштән гадәттәгедән иртәрәк, төшке ашка кадәр үк ерткычларча ачулы килеш кайтып керде. Беренчедән, аның теше— сул ягындагы өске казык теше сызларга тотынды. Икенчедән, сулга

җибәрергә дип әзерләп куйган итен тигр ашаган иде...

Бу вакыйга цирк буфетында иртәнге ашны ашап алгач килеп чыкты. Склад мөдире үзенең каптеркасына сыерның сум итен алып кына килде, кинәт шунда черегән һәм бераз какшаган тешеннән башына ток суккан шикелле китереп бәрде, бик каты сызлый башлады. Каһәр суккан баллы кофе! Ул диванга ауды, аякларын бөкләде дә ничектер сизмичә йоклап та китте. Үзен кемнендер иснәвен тоюыннан уянып китте. Шунда Гайнан үзенең беркайчан да алдамый торган алтынчы тоемы белән ниндидер яман нәрсә булганын сизеп алды, ләкин сикереп тормады, ә бары тик бер, куркыныч килгән якка каравы җайлырак булган сул күзен генә бераз ача төште һәм шунда коты алынды. Танавы белән аның тезенә «Мыеклылар, буй-буйлылар— уссурийныкылар» аттракционыннан «Малыш» исемле иң зур тигр төртелә иде. Ничек килеп чыккан ул читлектән, ишеге тышка ачыла торган, бикле шикелле дә булган каптеркага ничек килеп кергән? Склад мөдире шунда хәтта сулыш алудан туктап калды, ул үлде, тигр өчен ул бөтен күзәнәкләре белән үле иде. Йөрәге дә катып калды, тамырларында кан йөрүе дә туктады бугай. Уссурий кунагы үлгән кеше итеннән авыз итәргә теләмәде һәм, борылып, бүлмә буенча йөреп китте. Тагарактагы сыер ите яңа гына ит комбинатыннан алып кайтылган иде. Ерткыч ырылдады, авызын чапылдатты... Гайнан абый астыннан тизәк исе килүен сизде һәм бу көтелмәгән хәл куркуына яңа көч өстәде. Бәлки, кинәт аңа тигр игътибар итәр? Тигр, аның уйларын сизенгән сыман, аңа якынрак килде дә, борынын югары күтәреп иснәнеп алды, аннары канәгатьсезлек белән ырылдауга охшаш ниндидер аваз чыгарды. Шуннан соң инде Гайнан аның ничек чыгып китүен дә, үзенең ничек ашык-пошык кына юынып алганнан соң ниндидер нервылы кызулык белән каядыр чыгып чабуын да хәтерләми калды.

Колхоз базары янында гына исенә килде ул. Шунда мичкәле сыра алып эчте, бераз тынычлана төште, аннары тартып җибәрде. Инде бүгенге көнгә әзерләп куелган куркыныч хәлләр бетте дип уйларга да мөмкин иде. Ләкин шул вакытта кинәт, җир астыннан калыккан шикелле, алдына алар—озын буйлы, нык гәүдәле, куян тиресеннән тегелгән колакчын бүреген баш чүмеченә таба җибәргән малае белән Марийка килеп басты. Монда ике фикер булырга да мөмкин түгел иде: нәкъ үзе, чәченә тикле үзенеке һәм күзләре дә шулай ук икесе ике якка караган... Бер мизгелгә Гайнан абыйга ул үз-үзе белән, тик бик яшь, үсмер, еракта калган сугышка кадәрге чагы белән очрашкан шикелле тоелды. «Әллә курыкканга күзгә күренәме соң бу?—дип уйлап алды ул күңеленнән.—Эчмәдем дә бит кичә, йокы алдыннан җибәргән бер стаканны санамаганда».

Юк, Гайнан абыйның күзенә генә күренми иде.

Картайган, ямьсезләнгән Марийка аның пальтосы җиненнән эләктереп алды да шатлыгыннан:

—Ваня, кадерлем, исәнме!—дип кычкырып җибәрде.

Ничек рәхимсез бу вакыт кешеләргә! Ул, әле хәзер дә мәһабәт, күренекле ир-ат, ул, Гайнан Фазлыгалләм улы Субаев, кайчандыр менә шушы бөкрәеп беткән, кыяфәте буенча мәңгелек карчык белән чыннан да дуслашкан булган микәнни? Аның өстендә аны беренче тапкыр очраткан чагындагы шул ук озын җинле сырма, ул да чит кеше иненнән төшкән кебек асылынып тора. Юк, шул ук түгел, әлбәттә, ләкин ул минутта аңа шул ук сыман тоелды, хәтта өске, бик еш төймәләнә-чишелә торган төймәсенә тикле элеккечә соңгы җебендә көчкә эләгеп тора. Башында укмашып-киезләнеп беткән, көяләр тишкән һәм вакытлар кырган шәл... Нихәтле күптән булды болар! Шундый күптән, хәтта хәзер ул дөрескә дә охшамый сыман иде инде.

Гайнан җиңел, табигый хәрәкәт белән генә үзенең кулын алырга тырышкан иде, ләкин Марийка аның драп пальтосының җиңенә каерып алып булмаслык итеп ябышкан иде.

—Бу синең әтиең бит, улым,—дип елады ул,—менә шатлык!

—Сез нәрсә, гражданка, акылдан яздыгызмы әллә?—дип телгә килде Гайнан абый.—Нинди Ваня булыйм ди мин сезгә? Мин—Гайнан Фазлыгалләмович Субаев, паспортымны күрсәтә алам.

—Беләм, беләм, паспортыңны да күрсәтә алганыңны...—дип ярсулы тәтелдәвен дәвам итте Марийка.—Малаеңа күз сал, Ваня,—дип һаман бирешергә теләмәде хатын.—Карап үстердем бит, саклап калдым мин аны...

Әтисе итеп танытмакчы булган таныш түгел ир-ат җиңеннән әнисе кулын малае каезлап алды.

—Булды, әни, җитте, өйгә киттек,—диде ул.

Әйе, күренеп тора: аныкы, аларның малае. Ләкин циркның склад мөдире, элеккеге фронтовик, ә тыл күсесе булмаган Субаев сугышның иң кызган чагында тирән тылда әфтәрләгән токымының муенына асылына алмый иде бит инде! Азмыни алар аның Рәсәй-анакай буенча! Сугышта дошманнарны кыйнамады, аның каравы Ватанның баш исәбен арттырды. Бу бер үк нәрсә түгелмени?

Ә Марийка берничек тә бирешергә теләмәде. Ул улы кулларында тыпырчынды, ычкынды, ә малае гафу үтенде:

—Гафу итегез, иптәш, әни авыру, ул үз-үзен белештерми, ялгыша, ул сугышта хәбәрсез югалган ире дип белгән кеше бер сез генә түгел,—диде.

Гайнан абый каракүлдән тегелгән кепкасының козырегын күзенә табарак төшерде дә, йөз сиксән градуска борылып, сүзсез генә китеп барды. Малае аны танымады. Гәрчә бер мәртәбә күргәне булмаса да, менә ул аны таныды. Ләкин кайчандыр ул үзе дә шундый иде, ә менә малае аның кебек карт түгел шул. Шуңа күрә танымады да. Күзе үткенрәк булса, танырга да мөмкин иде.

Улы кулларында котырынган хатынның соңгы сүзләре, яшь охшашының исеме дә Иван булуы турында иде. Мескен Марийка баласы әтисенең чын исемен дә белми иде.

Гайнан абый, яшергән урыныннан пистолетын алырга да теләмичә, өендә сызлаган теше белән икәүдән-икәү генә калып утыра бирде. Кап-кара, авыр «вальтер» гадәттә аны төрле хәлләрдә дә тынычландыра, уйнаклаган нервыларының теләсә нинди тирбәлеш амплитудасын да юкка чыгара торган иде. Тик теш сызлавын түгел шул.

Гайнан абый бу пистолетны көзен үк кулга төшергән иде, гаугалы өстәл янында утырганнан соң ук, Пичуганың дус хатыны вакытсыз кайтып кереп кунакны бернинди артык дипломатиясез куып чыгарды. Ә хуҗаның—хәер, нинди хуҗа булсын ди ул? Чүпрәк!—ул чакта бушка килгән аракыдан инде теле дә әйләнмәде. Ләкин шуңа карамастан, сүзендә торды. Берничә көннән соң Гайнан абый кадерле «вальтер»ны кулына алган иде инде.

Ярты ел эчендә ул пистолетка күнекте, аңа ышанычлы һәм үзенә тугры дусты кебек иярләште. Шуның өстенә (монысы да бик әһәмиятле) телсезгә, ләкин кирәк чакта сүзен бирәгәйле, бер генә мәртәбә һәм мәңгелек итеп әйтергә мөмкин булган телсез дустына...

Өендә беркем дә булмаган чакларда Гайнан абый бикләнә дә, үлек камин авызы өстендәге яшерен урыныннан пистолетын тартып чыгара. Карап туймаслык шул уенчыгын сүтә, чистарта, майлый, яңадан җыя, обоймадагы көзгедәй ялтырап беткән сигез патронны бер-бер артлы берәмтекләп барлап, бәрхет белән ашыкмыйча гына тагын бер кат сөртеп чыга.

Ә анын өчен ул бирергә тиешле сары саквояж белән эш сузыла килде. Аны урларга һаман ничектер җае чыкмады. Йә язу өстәле астында тузан җыеп яткан ул әйбернең хуҗасы бүлмәсен калдырып чыкмады, йә чыкса да, берниндн сәбәпсез анын ишеген бикләп куйды. Ә кечкенә йозак кисәге белән маташасы килмәде. Әлбәттә, маташырга кирәкми дә, гади генә әйткәндә, керәсе, аласы һәм ялгыш кына эләктереп чыгасы гына иде. Андый мөмкинлек, һичшиксез, туарга тиеш иде. Һәм андый мөмкинлек ике ай элек, гыйнвар башында барлыкка килде дә. Бер тапкыр Йолдызчы, кичен соң гына һәм өстенә яхшы киенеп, үзенең бүлмәсеннән кунагы профессор Пичугинны озатырга чыкты. Ашыгуыннан ишеген бикләмичә, хәтта бераз ачык та калдырды. Вакыт соң, күршеләр йоклый һәм, бүлмәгә кереп, кирәк нәрсәне алып чыгу авыр эш түгел иде. Гайнан абый саквояж буш килеш калганчы, открыткалары белән бергә юкка чыкса яхшырак булыр дип уйлады. Кулына, Новиковның бик начар янып китә торган мичен дөрләтеп җибәрер өчен дигән булып (менә нинди кайгыртучан кеше ул Гайнан Фазлыгалләм улы!), коп-коры агач кисәкләре яткан капчыгын тотып кергәннән соң, ул тиз генә шул капчыгына кирәк нәрсәне алып салган гына иде, күтәргәндә аны берочтан тагын нәрсә дә булса эләктерү теләге биләп алды. Буфетның шыгырдавыклы ишеген ачса, агачтан уеп-сырлап эшләнгән күләмле генә шкатулка күзенә чалынды. Кызыксынудан янып, Гайнан абый анын капкачын ачып карады һәм аны сиземләве алдамады. Шкатулка бүлемнәре патша һәм хатын-кыз императорларның профильләре төшерелгән көмеш акчалар белән тулы иде. Аларга карап хозурланырга вакыты юк иде, әлбәттә. Шуңа күрә чынлаган көмеш акчаларны шул ук капчыгына бушатты да тиз генә чыгып китте. Ниһаять кирәкле эш эшләнде! Инде үзенең юынгычы янына килеп җиткән иде, кинәт үз бүлмәләреннән кухня караңгылыгына таба күршеләре, кече Әһлиуллинның атлавы күренде. Аңа бу кечкенә малай нәрсәнедер сизенгән сыман тоелды, шуна күрә сагаеп калды. Ләкин шунда теге малай, иске өй туфлясе белән кыштырдап, тагын хәрәкәткә килеп, үз ишекләрен ачты да, шунын артында юк булды. Гайнан шакшы су тасына түкереп куйды һәм хатыны гырлап йоклап яткан бүлмә ишекләренә төртте. Үги малае кайдадыр йөри иде. Ә ул өйдә булса, капчыкны өйалдына, йә булмаса сарайга алып чыгарга туры килгән булыр иде, ә бу инде өенә кайтып килүче Йолдызчы яисә үги малае белән очрашу куркынычы белән яный. Ә болай карават астына куйдың да эшең бетте. Һәм иртәнге якты таңга тикле тыныч кына ят та йокла.

Гайнан абый иртән иртүк капчыгын, элеккеге парадный баскыч янына алып килеп, иске-москы арасына яшерде. Алай да тыелып калырга түземлеге житмәде, товарны сатып алучы коллекционерларга күрсәтер өчен дип, берничә көмеш акчаны кесәсенә салды. Аларны, шундук чүпрәккә төреп, җөе сүтелгән кесәсенең төбе аша пальтосы итәгенә төшереп җибәрде. Үги малаенын күзеннән ерактарак ятсын, янәсе. Инде ул малай болай да элегрәк очраклы рәвештә генә алган бишләп акча өчен дә милициягә җиткерү белән янады.

Менә хәзер шунда ук үзе килеп эләкте. А-ля-мафо! Якынына чокыр казыма, үзең барып төшәрсең! Менә шулай була ул!

Ул, кулы белән черек теше аркасында сызлаган яңагын тотып, йортта һәм үзендә ниләр барын белергә теләп колак салып утыра бирде. Аек, көннен кискен борылышлары һәм теш сызлавы азапламаган эчке тавышы аңа шунда, берничә акчаны һәм бер-ике открытканы, һичшиксез, милициягә илтеп бирергә кирәк, дип искәртте. Янәсе, менә шулай, шулай, үги малайның өстәленнән очраклы рәвештә генә табып алдым. Аннан соң утырталар да утырталар инде ул елан баласын!

Ләкин авыртуы тәмам теңкәсенә тиде, аның аек акылы сыегаеп калды. Гайнан абый бүлмәләренең бер почмагыннан икенчесенә йөренергә тотынды. Аны бары тик өске казналыгының сул өлешендәге сызлау гына җәберли идеме соң?

Тып-тын гына йөргән мескен, зарарсыз Йолдызчы күгәреп-саргаеп беткән открыткалар салынган ниндидер иске, әллә кайчангы саквояж өчен шундый тавыш күтәрер дип кем уйлаган? Бүгенме, иртәгәме, тентү ясарга дип, милиция дә килеп житәргә мөмкин бит, болай булгач. Бу исә бернинди яхшылык та вәгъдә итми иде. Беренче чиратта документларны тикшерә башларлар... Һичшиксез, гомуми парад баскычының да астын өскә әйләндерәчәкләр инде, әлбәттә. Һәм сарайда центнер чамасы суытылган итне табып алу да берни тормый аларга. Нигәдер каминдагы пистолет өчен генә тыныч иде Гайнан абый. Ул утынлык турында, иконалар турында, үзе инициатива күрсәткән, хәзер КПЗда утыручы Жбан хакында да милициягә зыян күрүче үзе түгел, ә профессор Пичугин шалтыратуын белми иде.

Көмешләрне чәлдерергә кирәкмәс иде, мөгаен, беркая да китмәс иде әле алар. Бөтенесен берьюлы алырга теләде шул. Фраерларны, гадәттә, комсызлык харап итә, комсызлык! Аннан соң ул бу юлы стратегик ялгыш та җибәрде. Йолдызчының дөнья рәхәтеннән ваз кичкәнлек филантропиясенә, аның Толстойныкы шикелле җавапсызлыгына ышанды, ә баксаң...

Үзенең теш сызлавы аша Гайнан абый нәкъ төш вакытына Пичуга белән күрешү турында сөйләшенгәненен исенә төшерде. Ерак Уйсулыкта, күлгә борылган җирдә, ниһаять, ул открыткаларны яңа хуҗасына бирергә тиеш иде. Сузды ул бу эшне, шактый озакка сузды... Башта вакыты булмады, ә соңыннан: «Ә нигә бирергә?»—дип уйлап куйды. Аларны икенче бер коллекционерга да сатып җибәрергә мөмкин иде ләбаса! Бу очракта да Пичуга тын да чыгармаячак. Ләкин ахырында үзенең намусын чиста килеш калдырырга булды. Әмма берничә мәртәбә аның белән килешенгән очрашуларның берничәсенә тагын бармады. Йә бу вакытта кичектергесез бүтән эшләр килеп чыкты, йә онытып җибәрде, бүгенге шикелле, хәтереннән чыкты. Хәер, бүген онытырга да мөмкин иде, чөнки үтереп теше сызлый. Бу—нигезле сәбәп. Ләкин гаҗәеп рәвештә килеп чыккан көтелмәгән, әлегә кая алып барасы да билгеле булмаган хәлләр аның артыннан этәрә иде. Һәм менә ул открыткаларны һәм акчалар белән тулы ике кечкенә күн янчыкны үзенең шактый әйбер сыешлы склад мөдире портфеленә салды да, шулай ук Шәехнең саперлар күрәген куенына тыгып, Уйсулыкка юнәлде. (Зур сары саквояжны ул кыш ахырында ук бер эквилибристка сатып җибәрде һәм теге аны ил буенча гастрольләргә алып китте. Бар, табып кара аны хәзер!)

Ул сөйләшенгән урынга ярты сәгать алдан килде һәм, вакытлыча саклау өчен, күн янчыкларның икесен дә кар өеменә күмеп куйды. Ходайга шөкер, коры елгада кар җәйгә кадәр эреп бетмичә тора дияргә була. Күмеп куйганнан соң бераз тынычланып калды һәм Пичуганы көтә башлады.

Исеме генә яз быел: ул бер урында катып калды сыман. Пичуга күренмәде. Теше тагын да ныграк сызларга тотынды. Гайнан абый тагын бераз урынында таптанды-таптанды да, кечкенә капчыклары янәшәсенә, кардан ясалган саклык кассасына портфелен дә күмеп куйды.

Өенә кайтып барышлый башына бер яхшы уй килде. Кар сберкасса гына түгел, менә дигән суыткыч та лабаса! Анда сыер ите дә саклана алыр иде бит.

Ит чабарга һәм егерме килограмм чамасы ит салынган биштәр белән биш мәртәбә марш-ыргылыш ясарга сәгать ярымнан чак кына артыграк вакыт китте. Төп-төгәл ундүрт сәгатьтә арыганлыктан тәне ниндидер бер рәхәтлек белән сулкылдаган шат күнелле Гайнан абый, болдыр култыксасына таянып,

тартып җибәрде. Ишегалдында бер кеше дә юк. Бары тик Милочканың ике мәчесе генә күгәрченнәр кетәге астында йөриләр. «Менә җибәрергә иде аларны шунда кертеп!»—дип уйлап алды ул һәм үзенең малайлар уеннан үзе үк көлеп куйды. Ә нәрсә, әгәр башка шундый хулиганнарча уй килә икән, димәк, җаны исән әле аның. Ул тирән итеп үзенең яраткан «казбегын» суырып куйды һәм шунда кинәт тешенең сызлавыннан туктавын да сизми калды. Барысы да дөрес, авырту ул башланганда гына бик сизелүчән була.

Йортта элеккечә үк тын иде. Кешеләр кем кайда—кайсы эштә, кайсы ялда, кемдер, һм-м, төрмәдә...

Кухнядан үтеп барышлый Гайнан абый галим ишегендәге йозакның юклыгына игътибар итте. Димәк, Йолдызчы өйдә. Көр күнел белән аның ишеген шакыды, чөнки аның кем белән булса да эчен бушатасы килә иде.

## Анда серләр, монда серләр

Юлия белән без Хәниф абыйны фәкать икенче көнне генә туры китердек. Без аңа ярдәм сорап килгән көнне ул мотоциклы өчен кирәк булган аракатлам (прокладка) алыр өчен Дәрвишләр бистәсендәге дустына барган булган икән.

Шул ук көнне кич белән әтисе белән Юлия арасында җитди сөйләшү булды. Әтисе кичергән йөрәк тотуыннан соң Юлиянең үзен гипслаган шикелле катырып куярга теләгән мәрхәмәтлелек, түземлек, барысын да кичерә белү хисләре бер селтәнүдә җимерелде дә төште һәм читкә алып ташланды. Кыз аңа, берникди кереш сүзсез, бер дә читләтеп-нитеп тормыйча, Шәехнең аның яласы буенча тоткарлануы, аның тирә-ягында һаман законсыз эшләр эшләнүе, аның—әтисенең, үрмәкүч кебек, танышлык-белешлек пәрәвезе белән чолганып алынуы турында йөзенә бәреп әйтте. Шуңа күрә, янәсе, ул да абыйсы белән килешә: шуннан соң нинди әти булсын ди ул аларга!? Янәсе, ул үз сүзләрен башка кире алмаячак һәм моннан ярты ел элек булган шикелле үкенмәячәк, моннан соң ул аңа тик паспорт буенча гына әти булып калачак.

—Шәех намуслы, ачык кеше һәм кабахәтлеккә сәләтле түгел. Мин хакыйкатьне табачакмын, аны чыгарырлар. Һәм аның белән без бу каһәр суккан шәһәрдән китәчәкбез, еракка китәчәкбез һәм—гомергә!

Кыз төн буе йоклый алмады. Аның өчен моннан да озынрак һәм интектергеч төннең булганы юк иде бугай әле.

Мин дә таңны көчкә генә көтеп алдым.

Әле март төненең каралыгы да бетеп җитмәгән, әле урам фонарьлары һаман яна бирә һәм шул караңгылыктан әле яңа гына дымлы аксыл март томаны күтәрелеп килә иде, ә Юлия белән без, тимерчыбыкка асып куелган агач тоткалы бик борынгы звонокны тарткалавыбыз ни белән бетәр икән дип көтә-көтә, Хәниф абый ишеге төбендә басып тора идек инде.

Бу юлы безгә бәхет тәтеде, Хәниф абый өйдә булып чыкты.

Бер-беребезне бүлдерә-бүлдерә без ни булганын аңа сөйләп бирдек. Ул дәшмичә генә тыңлап торды. Аннары сүзсез генә аягына итекләрен, аннары кизүгә чыкканда гел кия торган курткасын киеп алды да, каешларын кысып эләктергәннән соң, безне ишегалдына алып чыкты. Бер минуттан аның ике цилиндрлы машинасы инде безне йокылы урамның иртәнге бозлы юлыннан Шәехне коткарырга җилдертә иде.

Юлия белән без милиция бүлегенә кермәдек, мотоцикл янында калдык. Хәниф абый Хәкимов атакага берүзе генә кереп китте. Аның өчен моның ни торганын без ул чакта белми идек әле. Шәех өчен көрәшкә ул үзенең

явыз дошманы—җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгы, бүлекнең тәҗрибәле хезмәткәре, закон саклау һәм ил куркынычсызлыгының кыргый үгезе—зубры саналган капитан Дубов Пётр Изотовичка каршы чыккан икән. Әмма үзенең рухи сыйфатлары ягыннан башлык аңлашылмый торган ир-ат булып күренә. Кайчак бөтен барлыгы белән солдафон—тупас гаскәри ул, кайчак ачык, эчкерсез кеше шикелле. Опер булып, мөгаен, Феликс Дзержинский вакытыннан бирле эшләгән, диярлек, кайчак кеше сөймәс, караңгы чырайлы, ә кайчак итекләрен дә салып тормыйча, туп-туры җанына үтә торган зат... Ул—майор йолдызы, күктәге Җидегән Йолдыз шикелле үк, беркайчан да ирешә алмаслык булып тоелган мәңгелек капитаннар һәм инде гаилә тормышы куркынычы күптәннән янамый торган буйдаклар токымыннан. Хәниф абый белән аның мөнәсәбәте бик тә ачык иде: капитан өлкән лейтенантны иске агач төбе үзендә үсеп килүче яшь үсентене күрә алмаган кебек күралмый. Турысын әйтик, Хәниф абый—хезмәтендә эше бик тә артык унучан, бигрәк тә уңышка ирешүчән кеше. Һәм бу нәрсәләр эчке тәртип буенча бөтен участок милиционерлары да буйсынган бер җинаятьчеләрне эзләү бүлеге башлыгын гына ярсытмый иде. Хәер, әйтегез әле, сезгә йә медаль тапшыралар, йә сез министр кулыннан исемле сәгать аласыз икән, йә сезнең турыда газетада язалар, йә радиодан сөйлиләр икән, кайсы коллективта сезне кулларында күтәреп йөртерләр? Хәниф абыйны да эшендә сәнәктән көрәк булган кеше, сикергәк, дип санныйлар. Дөресен әйткәндә, ул чынында да шулай иде. Ул, автобустан атылып чыгып, батучы карчык артыннан суга сикерә, ул... Хәер, мин инде аның акыллы штатскийлар массасы арасыннан гына түгел, ә җәмгыять тарафыннан куркыныч һәм батырлыкка махсус чакырылган, моның өчен алдан әзерләнгән, өйрәтелгән, коралландырылган кешеләр арасыннан да өстен чыгуы, аерылып торуы турында кыскача сөйләп киткән идем. Ә капитан Дубов исә үзенең органнардагы ярты гасырлык диярлек хезмәте өчен, чамадан тыш тырышуына карамастан, кулына песнәктән башка берни дә тота алмады. Һәм яшь буйсынучысының тыелгысыз даны аның эчен пошыра, чөнки ул үзенең аңына, әнисенең сөте белән, орган хезмәткәре эше хакына күзгә ташланмый торган, хәтта кайдадыр бернинди үзенчәлексез шәхес булырга тиеш, дигән мәсләкне сеңдергән. Янәсе, чекист—кино йолдызы түгел, аңа ялтырарга-җемелдәргә, алга чыгарга кирәкми, ул бөтен көчен биреп, намус белән ышанычлы рәвештә дәүләткә хезмәт итәргә тиеш. Ә өйләнгәннәргә, имеш, бөтен көчен эшкә бирү дигән нәрсә кайдан килсен? Гаилә аталарында? Һаман ничек булса да хезмәттән өйләренә чыгып сызу ягын гына карыйлар, янәсе. Шул ук Хәкимовның ике яшь баласы бар һәм менә-менә тагын берсе көтелә. Гади генә әйткәндә, яшь әле ул, шуңа күрә дә уйлап та тормыйча чаба да, гаиләсе турында, аның бердәнбер туендыручы икәне турында да уйламыйча, курыкмыйча чаба. Ярар, еллар үтә-үтә уйланыр, акылга утырыр әле... Юк, дәүләт үзенең ышанычлы органнарыннан, моны үзенең гаилә мәшәкатьләреннән азат, дуслар белән бәйләнеше булмаган тормышы белән ул, капитан Дубов, тулысы белән раслаганча, үз-үзеннән бөтенләй ваз кичүне таләп итә. Ләкин дәүләт хезмәте шундый нәрсә... Ул кайчак синең күңеленә ятышып бетмәгән, хуш килмәгән нәрсәләр үтәргә дә мәҗбүр итә. Мәсәлән, син кул астыңдагы кешене күралмыйсың ди, тик шул ук вакытта аңа үз кулларың белән мактау кәгазе тапшырырга да, аның погонын яңа йолдызлар белән алтынларга да тиешсең... Һәрвакытта да, теләсә нинди җитәкчелек кулы астында да хәрбиләштерелгән үз хезмәтен дәүләт организмының җаваплы органнарында бөтен авырлыкларны һәм кыенлыкларны чыдамлы итеп башкарган һәм үзенә буйсынучылардан да шуны ук—аскетлык, тыйнаклыкны таләп иткән

капитан Дубов Хәнифнең халыкка килүен—гади кешеләр арасындагы абруен авыр һәм начар кичерде, моңа көч-хәл белән генә түзде. Ләкин түзде, чөнки капитан тәртипле офицер иде. Әмма һәр түземнең дә чиге була: бу сикергәк, бу каһарман Алмалыдан булган, караклыкта тотылган үсмер Шакировны чыгаруны таләп итте. Янәсе, аны кулга алырлык бернинди дә дәлил юк, моңа прокурор да рөхсәт бирмәгән һәм, район бүлегендә яшәп килгән тәртип буенча, участок милиционеры, ягъни ул, анын кызуканлылык белән белдерүенчә, Алмалыдагы барлык малайларны да биш бармагы шикелле белгән Хәкимов тә бу эшне хупламаган. Әрсез, авызында анасынын сөте дә кипмәгән нәрсә! Борын-борыннан бирле җинаятьчел, ә кайбер чорларда районның, әгәр шәһәрнеке үк булмаса әле, сәяси бәла-казасы да булып килгән Алмалы өчен кем гарантия бирә ала?! Ләкин яшь әрсез болай дөрес сукалый үзе: профессор Пичугин шалтыратуын искә алмаганда, үсмерне кулга алырлык нигез юк иде шул. Хәкимов бу шалтырату турында кайдан белгән, чөнки профессор аңа кизү торучы милиционер аша түгел, ә турыдан-туры шалтыраткан иде бит! Һәм капитан Дубов үз-үзен тыеп кала алмады, үти торган вазифасы һәм чины буенча үзеннән кече булган хезмәткәренә кычкырынды: «Яшь әле син, салага, кемне өйрәтергә телисен! Менә пенсиягә киткәч, минем кәнәфигә утырырсың да, шул чакта...»

Хәкимов аны:

—Соң, күптән вакыт инде. Белмим, нигә утырасыздыр,—дип бүлдерде.

Капитан шундук тирләп чыккан муенын кульяулык белән сөртеп алды да үзгәргән, башлыкларча түгел, ә хәтта ничектер эчкерсез итеп:

—Их, туганкай, син миңа яшь чагымда эләккән булсаң икән!—диде.

—Ул сезнең булмады да бит...

—Кем?

—Яшь чагыгыз.

—Ни өчен?

—Чөнки сез һәрвакыт үзгәрешсез—яшь чакта да, олыгая төшкәч тә.

—Аңламадым.

—Ә нәрсә аңларга, сез, иптәш капитан, безнең кер юу урынындагы үтүк шикелле. Мәңгелек һәм бер дә үзгәрми торган кеше сез!

—Белмим, мин кер юа торган урыннар буенча йөрмим. Ә үтүкләр, синең исеңә төшерәм, даими рәвештә үзгәреп тордылар. Мин әле үз вакытында анын күмерлесен дә кулландым.

—Ләкин аларнын басу, үтүкләү максаты үзгәрмәде.

—Кая анда! Элек кенә басты-үтүкләде алар, ә хәзер бары тик сыпыралар гына. Йә, ярар соң, костюм искергән, җыерчыкланган икән—басарга да туры килер.

Капитанга, үзенең тормышында әле беренче генә тапкыр файдаланган образлар белән фикерләве ошады, ул үтүкләр, аларнын гомумдәүләт көнкүрешендә, һичшиксез, мөһимлеге турындагы сүзен дәвам итәргә дип авызын ачмакчы гына иде, ләкин Хәкимов, сөйләшүне башлангычына кайтарып, аны яңадан бүлдерде. Капитан икенче мәртәбә бик каты ачулана алмады, әкренләп эченә җыелган пары да чыгып бетте. Аннан сон, уйлап карасаң, нәрсә аркасында соң әле бу әрепләшү?

Хәкимов исә бу әрепләшүнең нәрсә аркасында икәнен яхшы белә иде. Ул, Әмәт станциясе янындагы көзге урман янында бандитлар өере белән бәрелешкә барган сыман, анын шәхси кабинетында үзенең башлыгына таба «атлады...» Ул үзе өчен тырышмый иде ич. Шуңа күрәдер, мөгаен, арыган тәртип сагы үгезе-зубры ваемсыз гына бирелде. Ни әйтсән дә, бу җиңүчегә орден тапшыру да, кечкенә генә кысан өйдә яшәп ятучы Хәкимов

инде кайчаннан бирле боз өстенә чыгарып ташлаган балык шикелле сорап аптыраткан фатирга ордер бирү дә түгел ләбаса. Харап булган, бераз хәленә керү—малайны шәһәрдән беркая да чыгып китмәү турындагы язу бәрабәренә һәм анын, өлкән лейтенант Хәкимовның шәхси җаваплылыгы астында чыгарудан дөнья җимерелмәс.

***

Без Шәехне, шатланышып, милиция баскычы төбендә каршы алдык, кочаклаштык һәм өйгә кайтып киттек. Хәниф абый эшендә калды.

Мин һәм Юлия тантана иттек, ә безнең дус сәер рәвештә уйчан иде, теләмичә генә сөйләште. Авызында гел «әйе» дә «юк» иде, җитмәсә, азат булуына сөенмәгән сыман, һаман чыраен сытты.

Алмалыга килеп чыккач, Шәех Юлиягә, аңа анның абыйсын күрергә кирәклеге турында әйтте.

—Нигә кирәк ул сиңа?—дип кызыксынды кыз.

—Кирәк.

—Өлгерерсең әле аңа, башта безгә керәбез, сине бабам күрергә тели.

—Нигә?—дип сорады үз чиратында Шәех.

—Кирәк,—дип җавап бирде Юлия.—Син аңа бик, бик ашыгыч кирәк.—Һәм шаяртып алды:—Без бит сиңа чыгару билетын да шуның өчен генә яздырдык.

Кыям абый үзенең яшь дустының милициядә кунганын белми иде. Гадәттә авыру кешене тискәре тәэсирләрдән төрлечә саклыйлар. Бер көн элек кич белән ул, гәрчә аны әле көндез генә күргән булса да, үзенә Шәехне чакыруларын сорады. Авыручының теләге—янында утыручы өчен закон. Ләкин Шәех артыннан җибәрелгән Юлия, әйләнеп кайткач, аның өйдә юклыгын әйтте. «Бәлки, кая булса да киткәндер, бүген безнең каникуллар башланды бит»,—диде ул.—«Кая киткән?—дип борчылып куйды авыручы.—Ул китүе турында берни дә әйтмәгән иде». Һәм оныкасын иртәгә иртүк аның артыннан тагын барып килүен сорады. Юлия икенче көнне караңгы таңнан ук тагын аның янына китте, ә төштән ары соң гына әйләнеп кайтты. Аның каравы үтенечен үтәп, Шәех белән бергә!

Әмма алардан алда бабасы янына онысы килгән иде.

Саша фатирларына моннан кәләшенә (хатынына, бергә яшәүчесенә—хәзер аның ничек дип йөртелүенең әһәмияте юк бугай) алып киткән бөтен әйберләре белән кайтып керде. Чемоданнар, кечкенә чемоданчыклар, спорт сумкалары ишек катында Монблан тавы кадәр җыелды. Ул бу йортны, безгә элек Юлия белән бабасы әйткәнчә, үзе белән берни дә алмыйча гына ташлап чыгып китмәгән икән бит!

Әнисе улын сугыштан яисә данлы космик очыштан әйләнеп кайткан каһарман шикелле каршы алды. Әтисе өйдә юк иде.

Бабасы аны урыныннан тормыйча гына сәламләде:

—Картина «Юлдан язган оныкның әйләнеп кайтуы» дип атала,—диде ул, көлемсерәп.

—Әйе,—дип килеште оныгы,—аз-аз гына ялгыш җибәрдем.

—Андый нәрсә һәркем белән дә булгалый инде ул,—дип гадәттәгедән катырак көлеп куйды аның әнисе һәм тизрәк гадәти көндәгедән аермалырак булган берәр тәмлерәк нәрсә әзерләп алу өчен кухняга ашыкты.

Бабасы оныгы белән алай озак сөйләшеп тормады. Нигә һаман бер нәрсәне чәйнәргә дә чәйнәргә! Барысы да шушылай булып бетәргә тиеш иде. Икесе дә—өлкәне дә, яше дә, ярты ел эчендә ялыкканнар. Берсе—көтеп, кайгырып, борчылып, икенчесе—гомере буенча кулга-кул тотышып яшәргә уйлаган кешесе белән көрәшеп.

Бүлмәне, сәхнәне прожектор утлары яктырткан шикелле, кояш нурлары кискәләде һәм аларда, бернинди гаилә драмаларына карамастан, җинелчә бүлмә тузаны бәйрәмчә йөзә иде. Кухнядан нәрсәдер пешергән-кыздырган тәмле исләр килә башлады. Сашаның инде күптән әнә шундый исләр килеп торган ризыклар белән сыйланганы юк иде. Ул бабасына карап елмайды да үз бүлмәсенә кереп китте. Бабасы эченнән генә: «Яшьлек хаталары ничек тиз төзәлә!»—дип уйлап алды да авыр керфекләрен йомды.

Көн инде төштән соңга авышты, ә Юлия белән Шәех һаман күренмәде.

Алар ул көтмәгәндә йоклап киткәч кайтып керделәр. Кыям абый күзләрен ачты да, әйтерсең бер дә йокламаган, көтеп армаган сыман, Шәехтән:

—Ничек соң каникулда, яхшымы?—дип сорады.

—Яхшы,—дип җавап бирде Шәех, берни дә булмаган шикелле.

—Теләсә нинди кыштан соң яз килә,—диде сырхау, тәрәзәдәге алтынланган зәңгәрлеккә күз салып.

—Дөрес,—дип килеште аның белән Шәех, аңлый алмыйча. Кыям абый аны «бик-бик ашыгыч» шушы әңгәмәгә—яз һәм каникуллар турында сөйләшү өчен чакырдымы икәнни?

—Саша кайтты,—диде бераз дәшми торганнан соң Кыям абый.

—Ничек? Бөтенләйгәме?

—Бөтенләйгә.

—Кайда соң ул?

—Үзендә.

Шәех тик хәзер генә Юлиянең янында булмавына игътибар итте.

—Мин хәзер, Кыям абый, ярыймы?—дип Шәех ишеккә таба атлады.—Миңа бер генә минутка Саша кирәк иде.

—Бер-бер нәрсә булмагандыр бит?

—Һич юк, хәзер мин.

—Тик озак торма син анда, Шәех, минем дә синең өчен бик кирәкле яналыгым бар.

Кыям абый тагын күзләрен йомды, чөнки арып өлгергән иде.

Юлия абыйсында утыра иде. Аларның тавышлары бераз ачык калган ишектән, кухнядан килгән бик тәмле ис кебек үк, бик ачык ишетелеп тора. Алар абыйлы-сеңелле гадәттә озак күрешми торган туганнар арасында була торган гап-гади, мәҗбүри булмаган әңгәмә алып баралар.

—Яңа тормыш башлыйм,—диде Пичуга. Бу аның соңгы сүзләре иде.

Шәех шакыды да бүлмәгә килеп керде.

—Юлия, син абыең белән безне бер-ике минутка гына калдыра алмассыңмы?—диде ул.

—Мөмкин,—дип гаҗәпләнде Юлия һәм чыгып китте.

—Бәлки, алай да башта исәнләшербез?—диде Пичуга, бармакларын көймә сыман ясап, күрешер өчен кулын сузды. Шәех артык җәелеп китәргә җыенмый иде, аның ана, кабахәткә, бер генә соравы бар. Ләкин шунда нәрсәдер, ирләрчә күрешү өчен, Шәехнең учын язарга мәҗбүр итте. Пичуганың кыяфәтендә аңлатып та булмаслык нindидер сизелмәс үзгәреш бар кебек иде. Аңа хас булган ялтыравык, купшылык юкка чыккан, аның картина шикелле йөзендәге балкыш сүнгән. Ябыккан, төссезләнгән, зәңгәр күзләрендә—каушап калу галәмәте. Шәех, ачуын баса төшеп:

—Бер сорау сиңа: открыткалы саквояж синдәме?—дип сорады.

Пичуга, Шәех көткәнчә, аның бу соравына бер дә гаҗәпләнмәде, талчыккан тавыш белән:

—Юк, миндә түгел,—дип җавап бирде.

—Ә миңа, синдә, диделәр.

—Кем әйтте аны?
—Монысы мөһим түгел.
—Юк шул, мондә түгел.
—Ул чагында кемдә соң?
—Әй, син, Ходаем!—дип, Пичуга сузып көрсенеп куйды.
—Кемдә?—дип катгый итеп кабатлады Шәех.
—Синең үги әтиеңдә.
—Дөресме бу?
—Дөрес.
—Ничек алай?!
—Монысы икенче сорау инде...—диде Пичуга. Шунда аның күзләрендә элеккеге салкын утлар кабынды. Шәех нервыланып тынлаусыз маңгай чәчен яткырырга тырышты, ләкин ул, кулын алу белән, яңадан тырпая торды.
—Барысы да ачык.
—Ачык булгач, нигә сорашып маташасың соң?
—Синнән раслатырга теләгән идем.
—Нәкъ миннән?
—Нәкъ менә синнән.—Шәехнең күкрәгендә, бугазы астында моңарчы таныш булмаган, сизелмәгән ачуның чәнчүле йомгагы барлыкка килде һәм ул, тончыгып, бүлмәдән йөгереп чыгып китте, стенадагы портретлар, шарлавыклар, тавислар яныннан ишек катына, чыгу юлына таба ашыкты. Ләкин шунда аны кинәт кенә аңында кабынып киткән ут-ялкын туктатты. Ул монда Пичуга өчен түгел бит!.. Хәер, Пичуга да кирәк иде...
Кыям абый кабартып куйган мендәрләрдә ярым утырып тора. Ул буй-буйлы пижамадан, янәшәсендә ачылмаган яңа газеталар өеме ята.
—Утыр,—диде ул аңа, урындыкка күрсәтеп.—Мин менә нәрсә әйтергә телим...
Шунда Юлия килеп керде.
—Хәзер пироглар әзер була,—диде ул.
—Юлия... Кызым, безгә Шәех белән сөйләшергә кирәк,—диде Кыям абый, гафу үтенгән сыман тавыш белән.
—Нәрсә соң инде бу, тегендә серләр, монда серләр!—дип иреннәрен турсайтты кыз. Алай да чыгып китәргә мәҗбүр булды.
—Мин сиңа менә нәрсә әйтергә телим... Хәтерлисеңме, мин синең үги әтиеңне кайда күргәнемне берничек тә исемә төшерә алмаган идем.
—Хәтерлим.
—Менә... искә төшердем мин аны.
—Кайда?
—Военкоматта, кырык дүртенчедә. Шул чакта ул мине, часовойны, башыма сугып...
Шәех әкрен генә урыныннан күтәрелде.
—Утыр, утыр...
—Ялгышмыйсызмы соң?
—Юк, ялгышмыйм. Бу типны онытырга—әйе, мөмкин, ләкин хәтерләп ялгышырга—юк. Мин шундук хәрби комиссариатка, милициягә шалтыратмакчы идем дә, аннары башта сиңа әйтергә, бергә киңәшергә кирәктер, дип уйладым...
—Шалтыратмагыз, мин үзем.
—Син нишләмәкче буласың? Ә-ә?
—Барам...
—Кая? Аңа? Аһ, ничек вакытсыз авырып киттем мин, ничек вакытсыз!
—Авыру беркайчан да вакытлы булмый.

—Ашыкма, Шәех, монда бик сак кирәк... Мин дә синнән башка берәр карарга килгән булыр идем дә, ләкин ул синең... Ул синең әниеннең ире бит...

—Андый ирләрне...

—Ул чагында мин сиңа киңәш итәм: бер дә тоткарланмыйча Хәниф Хәкимовка бар әле син! Ул төпле, акыллы кеше һәм,барыбызга караганда да, ин дөрес юлны тапса да ул табар. Хәниф синең турыда бик яхшы фикердә. Син таныштырганнан соң, күп мәртәбәләр сөйләшеп утырдык без аның белән. Бик тә, бик тә нигезле-төпле кеше. Йә бергә миңа керегез. Ләкин кара аны, Гайнан кебекләр сизгер һәм мәкерле була, чак кына берәр нәрсә сизсә дә, аны бернинди эт тә эзләп таба алмас...

—Шулай эшләрмен, Кыям абый, тик сез борчылмагыз гына, сезгә дулкынланырга ярамый,—дип Шәех өлкән иптәшенең күкрәгенә куелган кечкенә һәм салкын кулларына кагылып алды.—Киттем, эшне сузарга ярамый. Ә сез, сорыйм, хәзергә беркемгә берни дә әйтмәгез!

## Дөньяда бер генә ышанычлы җан калды

—Сез өйдәмени?!—Авыр «сишәмбе хезмәте»ннән соң Николай Сергеевич янына кергән Гайнан абый йөзенә гаҗәпләнү билгесе сытып чыгарды.—Аһ, әйе, сез бары тик дүшәмбе көннәрендә генә эшлисез.

—Нишләп?!—дип гаҗәпләнеп сорады Николай Сергеевич үзенең «биеклеге»ннән. Ул, гадәттәгечә, яткан килеш нәрсәдер яза иде.— Мин көн саен һәм һәр кич саен эшлим. Менә бит, хәзерге вакытта да эшләп утырам. Иртәгәге конференциягә докладымны тәмамларга тырышам, тик начар килеп чыга әле, фикеремне туплый алмыйм. Ә сез нигә эштә түгел?

—Теш сызлап китте, шайтан алгыры. Әй, гомер, гомеркәй... Гел газаплар гына анда! Анысы да ничек бит әле: бүген бар син, ә иртәгәсен—кем белгән... киттең-бардың...—Гайнан абый кәнәфигә килеп чумды, тавышлы гына итеп борынын сеңгереп алды да, никтер кульяулыгын әйләндергәләп карап, чираттагы афоризмнарының берсен әйтте:—Гомер ул —кичерә күр, Алла-бисмилла!—чынбарлыкны тизәккә әйләндереп чыгаручы иттурагыч.

—Юк,—хәтергә,—диде Николай Сергеевич, аның белән килешмичә,— хәтергә һәм тарихка.—Ул кушеткага утырды.—Шәехне ни өчен кулга алдылар икән?

—Кулга алмадылар, ә тоткарладылар. Аерма зур монда.

—Минемчә, бернинди аерма да юк. Йә, ни өчен?

—Сезне таладылар бугай бит, Николай Сергеевич, сезне... Әллә мин ялгышаммы?

—Ләкин аның монда ни катнашы бар?

—Бар, бар... Сез милициягә үзегез хәбәр иттегез бит.

—Минем бернинди милициягә беркайчан һәм беркем турында да хәбәр иткәнем юк. Һәм шушы ачу китергеч хәлдән соң мин кичә шунда булдым.

—Һәм шуннан?—дип Гайнан абый тагын борынын сеңгереп алды.

—Шуннан шул, анда миңа беркем дә аңлаешлы җавап бирә алмады. Әле берсе юк, әле икенчесе, начальникка үтә торган түгел. Башта көтәргә куштылар, аннары ничек булса да башка көнне килүемне сорадылар... Мин, обкомга шикаять белән барам, дидем.

—Шуннан нәрсә?—дип Гайнан абый кульяулыгын кесәсенә салды.

—Бүген бардым да. Туп-туры беренче секретарь янына кереп, шәһәребездә нинди хәлләр булып торганын сөйләп бирергә уйлаган идем дә, ләкин кертмәделәр...

—Беренчегәме?

—Гомумән... Обкомга кертмәделәр. Анда аларның кораллы милиция тора. Һәм п-партия б-билетын күрсәтергә кирәк икән. Ә ул минем юк, мин п-партиясез. Ризасызлык белдерергә тырышкан идем дә, тик тынларга да теләмәделәр, хәтта каядыр җибәрәбез дип янадылар да әле. Берни дә аңламыйм. Менә докладымны тәмамлыйм да обсерватория директоры белән сөйләшеп карыйм, ул йогынтылы кеше. Ләкин доклад, һичшиксез, әзер булырга тиеш, шунсыз обсерваториягә барып булмый.

—Борчылмагыз, Николай Сергеевич, борчылудан кандагы гемоглобин җимерелә. Мөһиме—тынычлык. Менә мин тыныч бит.

—Кызыксынырга рөхсәт итегез: ә сез нигә тыныч? Нишләп сез барып барысын да ачыклап кайтмыйсыз? Сез әти кеше ич, сезгә анда барын да аңлатырга тиешләр.

—Әтисе түгел, ә үги әтисе,—диде Гайнан абый, кәнәфидән күтәрелә төшеп. Бу әңгәмә аның күңеленә ятмаган юнәлеш ала башлады һәм аны икенчегә борырга кирәк иде.—Әнисе кайтсын— ачыклар. Хәер, нәрсәсен ачыклыйсың инде аның, анда...—ул баш бармагы белән тәрәзәгә таба төртеп алды,—анда кемне һәм ни өчен икәнен беләләр... Гаепләме—а-ля-мафо!—ал үзенә тиешлене! Димәк, үзен шулай итеп күрсәтергә теләгәнчә үк фәрештә түгел ул безнең хөрмәтле Шәехкәй.

—Сез ни сөйлисез?!—дип Николай Сергеевич ачу белән урыныннан торып басты һәм оппонентына өстән аска таба, маңгай астыннан, ияген күкрәгеннән алмыйча текәлеп карады. Гәрчә бөкшәйсә дә, ул буе белән аннан барыбер озын иде.—Шәех намуслы үсмер. Ул аны гаепләгән нәрсәне эшли торган кеше түгел. Монда коточкыч ялгыш килеп чыккан. Ләкин хакыйкать бүгенме, иртәгәме, барыбер өстен чыгачак. Хакыйкать ахыр чиктә барыбер өскә чыга бит ул.

Гайнан абый йөзен җыерып куйды.

«Түзәр хәл юк, нинди кеше соң бу?! Хакыйкать, гаделлек, имеш!.. Икеөч пуля белән миен чәчрәтеп чыгарасы нәрсә».

Тагын теше сызлый башлады.

—М-м-м!— дип ул янагын тотты.—Нәрсәдер эшләргә кирәк бу теш белән. Киттем мин... Оревуар!

Гайнан Субаев үзен көчле шәхес дип саный иде. Шуңа күрә, беренчедән, сызлаган тешләрен ул үзе суыра. Менә шул сишәмбе көнне дә—алтмыш икенче ел мартының соңгы сишәмбесендә ул, авызын ачып, көзге янына килеп утырды да, Шәех өстәленнән алган каргаборын белән казык тешен суырып та чыгарды. Әлбәттә, бу эш алдыннан, авыртуны сиздермәс дару сыйфатында, йөз илле грамм аракы эчеп җибәргән иде.

Әмма кәефең китүне, күңеленнән әлегә билгесез нинди дер начарлыкны сизенүен үзеңнән тешең шикелле генә суырып алып булмый шул. Аның кәефе Уйсулыкта соңгы пот ит белән аны Магаданның кунакчыл курортларына лаеклы ялга җибәрү өчен артыгы белән җиткән әйберләтә дәлилләрне юкка чыгарып кайтканнан соң бераз яктырып киткән шикелле иде. Ләкин Йолдызчы белән булган сөйләшүдән соң ул үзенең кабыргалары астында эче поша башлавын сизде. «Хәтта бу аңгыра да тавыш бирә башлады,—дип уйлап алды үзен күңелсезлек һәм билгесезлекләр эзәрлекләгән Гайнан абый.— Миннән үз минлегем хәтта шулай коралланмаган күз белән дә күренеп-сизелеп тора микәнни соң?! Уф, арыдым мин! Якташларының һәр икенчесе синең кислородыңны ябып куярга әзер икән, ник дөмекми шунда бу борынгы әби-бабаларым җире! Трамвайлар йөреп торганда таярга кирәк моннан, кыякларга».

Качып китү уе Гайнан абыйның Сократныкы кебек маңгаенда кичә

генә тумады. Беренче хәвефле сигнал үги малаеның дусты, инвалид, элеккеге фокусчы яна танышы Мөхәммәтшинның унайлы-жайлы гына, алма ботакларының көзге җилдә тәрәзәгә бәргәләп алуларын тынлый-тынлый Йолдызчыда төрле фәлсәфи темаларга сөйләшеп утырганда тыныч, чылтырап чыккан сүзләре булды. Яңа танышы ул чакта, сүзләренә басым ясап: «Ә-ә мин сезне кайдадыр күрдем»,—дигән иде бит. Гәрчә Гайнан абый аның үзен кайда күрүе мөмкин икәнлеген исенә төшерә алмаса да, тәшвиш орлыгы күңеленә төшеп калды. Аннары—тагын бер күңелсезлек: житмәсә, аңа үги малае да каныкты. Башка берәр малай-шалай булса, шундый әтиле булуына шатланыр, гаиләләренең сөенече һәм чәчәк атуы хакына һәр нәрсәдә, һәр эштә булышыр, ярдәм күрсәтергә тырышыр иде. Юк бит, юк! Рәхмәт әйтәсе урында, сатам, дип тора бит әле, ерткыч баласы. Житмәсә тагын, бу Марийка килеп чыкты! Сау-сәламәт икән һәм кайдадыр базар янындарак яши бугай. Бәлки, инде сырахана янындагы спектакль өчен кая булса да житкерергә дә өлгергәндер? Өстәвенә Пичуга тагын менә... тимер сыман нык итеп килешкән урынга килмәде... Дөньяда бер генә ышанычлы җан калды—«вальтер».

Гайнан абый каминдагы яшерен урыннан төенчекне алды да, төргән чүпрәген сүтеп, тонык кына ялтыраган пистолетны сөеп, сыпырып куйды. Ләкин җанына ул теләгән тынычлык иңмәде. Шунда ул шешәсендә калган йөз грамм аракысын эчеп бетерде. Тик чынбарлыкны аракы да үзгәртә алмады. Һәм Гайнан абый гадәттән тыш сәләткә ия булган акылы белән соңгы мәртәбә катгый итеп: «Китәргә кирәк, кичекмичә, хәзер үк!—дигән нәтиҗә чыгарып куйды.— Хәзергә билгеле түгел, ул үги малайның милициядә утыруы ни белән бетәр. Аның гаебен раслый торган дәлиле итеп көмеш акчаларны аңа ташлый алмадым, ә инде ул анда белгәненең барысын да чыгарып салгандыр. Монда, халык әйтмешли, әллә була, әллә юк, әллә болай, әллә тегеләй дип шикләнерлек урын калмады инде, монда барысы да ачык...»

Гайнан абый пистолетының магазинын шартлатып урынына кертеп куйды да, аны үзенең озын итәкле драп пальтосының зур кесәсенә салды. «Юкса тәмам назланып беттең син монда! Әлбәттә, жылы, якты һәм чебеннәр дә ашамый. Йокы баскан чебеннәр күк буш кул белән менә шундыйларны алалар да инде. Аллага шөкер, дары исен иснәгән бар. Беләбез!..»

### Мә сиңа-а!..

Хәниф абый өйдә юк иде. Шәех аның гаражына үтте, ә ул анда да юк. Әле кайтмаган. Нишләргә? Милициягә барып үги әтисе турында хәбәр итәргәме? Янадан шунда, үзен дә җинаятьче хәлендә тоткан жиргәме?! Әллә ноль-ике буенча шалтыратыргамы икән? Ләкин шул кадәр үк ашыгыч та түгел бит, Гайнан абый хәзерге вакытта беркемне дә үтермәгән, чәнчемәгән. Аннары боларның барысын да телефоннан ничек аңлатып бирәсең ди? Аптыраш: койрыгыңны кысып менә шушылай, тәмам җиңүгә ирешкәнче Хәниф абыйны көтеп утырырга каламы?

Кемгәдер уйланып торырга да мөмкин булыр иде, тик Шәехкә түгел. Әгәр болар балык тотуга яисә күгәрченнәр кетәгенә кагылышлы булмаса, ул бик еш кына үз адымнарын инде эш эшләнгәннән соң гына аңлый төшә иде. Үги әтисенең инде эштән кайткан булуы турында уйлаган булганмы ул? Бик мөмкин. Тик үги әтисе: «Базага киттем»—дигән язу калдырып, бик еш кына эшеннән вакыты житмичә дә ычкына, кайчакларда эшенә бөтенләй барып та тормый иде бит. Ләкин мин ышанам, Гайнан абый өйдә булмаса, Шәех туп-туры аның эшенә, базага, ит комбинатына, тагын әллә

кайларга киткән булыр иде.

Үги малае бүлмәләренең бусагасын атлап кергәч, инде «очып китәргә» карар кылган, моңа әзер булган Гайнан абый, авыртудан йөзен җыера-җыера арпа боткасы ашап утыра иде. Боткасы куе булып чыккан, ә чәйни алмый. Үги малаен чәйнәлеп бетмәгән боткасын йоту кебек җаваплы мизгелдә күреп алгач, ул чак кына тыгылмый калды.

—Син кайдан?!—дип гаҗәпләнде ул.

Әле әйтеп тә бетермәде, үз соравының әдәпсез икәнен аңлап, шундук елмаеп куйган булды.

—Җибәрделәрмени?

Шәех җавап бирмәде. Өстеннән курткасын да салып тормыйча, ул, өстәлгә арты белән торган урындыкны иярләп, кулларын аның артында кушырды да, алдында ул түгел, ә кинәт кенә Алмалыда яңадан терелгән Гитлер торган шикелле кыяфәт белән, үги әтисенең йөзенә текәлде.

Гайнан абый кулындагы арыш ипиенең йомшагын әвәләргә кереште...

—Нигә күзеңне терәдең? Җибәрделәрмени, дип сорыйм түгелме? Ачыкладылармы?—Һәм тагын йомшак итеп елмаеп алды.—Ә менә мин тешемне суырдым.—Ул, бармагы белән иренен каерып, авызын ачып күрсәтте.—Менә хәзер ашый алмыйм. Йөгереп кенә шешәгә барып кайт әле, һич тә түзеп булырлык түгел. Уртны актарып бетердем, хәзер менә тешне алганнан да көчлерәк авырта.

—Саквояжны бир!—дип әйтеп салды Шәех, үги әтисе белән беренче мәртәбә «син»гә күчеп.

—Нинди саквояж?—дип ихлас күңелдән гаҗәпләнгән булды Гайнан абый.

—Николай Сергеевичныкын, открыткалар белән.

—Түбән кыйшайдымы әллә синең?

—Әлегә юк. Кайтар яхшы чакта, аннары соң булыр.

Гайнан абыйның йөзеннән ясалма гамьсезлек шундук юкка чыкты. Битендәге күп санлы кан тамырчыклары кинәт тулышты һәм ул яңагыннан алып бугаз төененә тикле куе кызыл чөгендер төсенә керде.

—Ми-ин... ниндидер иске саквояжны... урлаганмы?

—Саквояжны гына түгел, көмешләрне дә.

—Мин?

—Син.

— Аһ, син, кисеп тә киселеп бетмәгән татар баласы!—Гайнан абый әкрен һәм рәхимсез кыяфәт белән өстәл янындагы утырган җиреннән торып басты.

Шәех тә урыныннан торды һәм кинәт үги әтисеннән биек булып калды.

—Әйе, татар мин! Моның белән горурланам! Кайберәүләр шикелле, кардәш-ыругларын хәтерләмәүче сарык түгел мин. Кайберәүләр шикелле, милләтемне дә, ватанымны да сатмадым.—Шәех, гәрчә бу җиңел булмаса да, дезертирның артык ярсудан бер-берсеннән тагын да ераккарак йөгерешкән күзләренә туп-туры карады.—Ә син—дезертир һәм сатлыкҗан. Башыңнан алып табан астына тикле сатлыкҗан син! Һәм безнең җирдә сиңа урын юк монда...

—Димәк, минем урыным җир астында?

—Ә монысын инде синең өчен башкалар билгеләр, борчылма.

—Бетерергә кирәк сине,—дип көрсенде Гайнан абый фаҗигале рәвештә, әле куркытуы гынамы, әллә чынын әйтүеме икәнен үзе дә аңлап бетермичә. Тагын нәрсәдер өстәмәкче иде дә, шунда аны:

—Сине кирәк ул күптән бетерергә,—дип Шәех бүлдерде.— Каһарман табылган, хәрби майор! Кырык дүртенче елда часовойны шапылдаткан да дисбаттан качкан...

—Кайдан?

—Хәрби комиссариаттан. Төнлә туган телендә юкә чөе кагып, якташыңның башына таш белән органсың да... Һәм безнең хөрмәтле дезертирыбыз бүгенге көндә рәхәт тормышта яши бирә, көче җиткәнчә үз әйләнәсендәге һәр нәрсәне умыра, сатып эчә... А-ля-мафо! Җинеп кара аны! Кая анда?! Сугыш вакытында да йөгәнли алмаганнар, ә хәзер, инде сугыш ветераны булып алгач...

—Ә-ә, әнә син нәрсә турында!—дип Гайнан абый өстәл яныннан аңа таба атлады.—Менәтерә син кем турында... Ә мин бит синең фокусчыңның миңа кайда очраганын искә төшерә алмадым. Димәк, аның башына тондырган мин ул чакта!.. Кызганыч, бик кызганыч, берочтан бөтенләй юк итәсе калган аны! Ә мин, нишләп соң әле бу бәндә миңе һәрчак гашыйкларча күзли, дип баш ватам. Ачыкланды, ачыкланды...—Ул өстәл яныннан аңа таба тагын бер адым ясады, кизәнде...

Ләкин колак төбенә кундыруларга ияләнгән Шәех аның йодрыгы астына инен куйды һәм аннары, аны өстәл янына кайтарырлык итеп, әкрен генә этеп җибәрде.

—Ә-ә, каршы торырга да өйрәнденмени әле син?!—диде Гайнан абый, аннары кулына өстәлдән чәнечкене эләктереп алды. Һәм үзенең чиркәүләрдә җырларга яраклы бас тавышына һич тә охшамаган гаҗәеп нечкә тавыш белән: —Ике сугуда сигез тишек ясыйм мин сиңа хәзер!—дип үкереп җибәрде. Һәм көтмәгәндә буш сул кулы белән Шәехнең иягенә китереп сукты. Сугуы шулкадәр каты иде, хәтта Шәех кулларын канат шикелле җилпеп, арты белән ишекләренә килеп бәрелде дә, ачылып киткән шул ишектән кухняга очып чыкты. Анда банкалар, тас, чиләкләр куелган киштәгә килеп сыланды, ә аларның тавышлары бөтен өйгә янгырады.

—Туйдырдыгыз, туй-дыр-ды-гыз...—дип ысылдады Гайнан абый, драп пальтосын кия-кия һәм тиз генә рюкзагын эләктереп.—Һәр түземлелекнең дә чиге була. Харэ-э! Бу фокусчылар, Йолдызчылар, шәехләрнең барысыннан да гарык мин...—Ул кухняда кулларын як-якка ташлаган килеш юлга аркылы яткан Шәех аша атлап чыкты да, шунда багана шикелле катып калды. Аңа таба, авыр, чәчләре тузгыган башын түбән иеп, бизон шикелле—озын гомерле булыр!—Йолдызчы килә иде. Тормыш сыман кыска гына мизгел эчендә Гайнан абый кинәт галим күршесендә, акылга сайрак әкиятче-хыялыйда монарчы туры карап та сизмәгән-күрмәгән нәрсәләр—озын буен да, зур, көчле кулларын да, һәм кыргый тәвәккәллек белән тулган күзләрен дә күреп алды. Ул бу юлы анда мескен кыяфәтле интеллигент кисәген түгел, ә ир-атны, нык, имән тамырлы, юкә таяк атта катыргыдан ясалган кылыч белән җинеп тә, читләтеп үтеп тә, коры кул белән алып та булмаслык ир-атны күрде. Гайнан куркуга төште, чөнки капкын инде ничә тапкырлар ябыла, ә көче элеккечә дә, элеккеге дә түгел, һәм вакыты да ул чактагы түгел, һәм инде аның бу капкыннан котыла алмавы да бик мөмкин бит. «Әгәр хәзер ычкына алмыйм икән,—дип уйланды ул,—ул чагында бетте, барысы да җәһәннәмгә очты дигән сүз». Һәм ул кесәсеннән «вальтер»ын чыгарды.

Күнекмәгән кулы калтырадымы, ләкин беренче пуля читтән, бары тик Николай Сергеевичның чәчләре чүмәләсен генә сызып үтте һәм инде аның артында, тик бераз өстәрәк, аннан агач тузаны чыгарып, ишек башына кереп юк булды.

Бу вакытта Шәех Гайнан абыйның бер инендә асылынып торган

рюкзагына ябышты, качкынны үзенә таба борды һәм теге, нокаутка җибәрелгән үсмергә шулай тиз җан керүенә таң калып, ике мәртәбә туптуры атып, аны мәңгелеккә егып салды.

Укчы берсеннән котылып өлгермәде, инде аның драп пальтосы кайтармасыннан икенчесе тарта башлады, ул, ниндидер аңлаешсыз сүзләр мыгырдый-мыгырдый тартты, авыр хәрәкәтләр белән һәм мәгънәсез рәвештә йолкыды да йолкыды. Андый очракларда галим интеллигенциясенең аек акылы кая китә икән?

—Мә сиңа-а!..

Гайнан абый аңа биле турысыннан атты. Эләктермичә калу мөмкин түгел иде.

Ул урамга килеп чыкканда, без өчәү—Хәниф абый, Юлия, мин каршы яктагы Хәниф абыйлар ишегалдыннан йөгереп чыгып килә идек.

Шәехнең үги атасының кем булуы турында Юлиягә, ул аларның Шәех белән нинди астыртын һәм шикле серләре турында төпченә башлагач, бабасы сөйләп биргән. «Бу нинди пышылдашу икән? Шуннан соң кунак нигә саубуллашмыйча һәм акайган күзләре белән качып китә?»—дип баш ваткан кыз ул чакта. Гәрчә Кыям абый, моннан берничә минут кына элек Шәехнең дезертир турында башка беркемгә бер сүз дә әйтмәскә кирәк, дигән сүзе белән килешкән булса да, серне кыскача гына оныкасына да сөйләп биргән иде.

Тынычсызланган Юлия миңа мәктәп янында очраклы рәвештә генә килеп бәрелде. Шәехне милициядән каршы алганнан соң мин нигәдер шунда кагылган идем. Без шул ук юл белән, Шәех шикелле үк, башта Хәниф абыйга чабып киттек. Ләкин, Шәехтән аермалы буларак, бу юлы язмыш безгә елмайды: безнең киң күңелле гений, безнең әкияти коткаручы могҗизаи таягыбыз өйдә булып чыкты. Хезмәтеннән әле менә хәзер генә, анда да бер генә минутка—капкалып алырга гына кайтып кергән булган. Ул хәтта үзенең бер генә төймәсен дә чишмәгән, бер генә каешын да ычкындырмаган халәтендә баскан килеш кенә, литрлы банкадагы сөт белән француз күмәчен зур-зур итеп тешләп ашап утыра иде.

—Хәниф абый, тизрәк!—дип ташландык без аңа.

Һәм менә без инде урамда.

Әгәр дә Хәниф абый янына Юлия берүзе генә кереп, ә мин туп-туры үзебезнең өйгә, дусларымны коткарырга дип ташланган булсам, моннан ни килеп чыгар иде икән? Коткарган булыр идемме икән мин аларны? Өлгергән булыр идемме? Әллә үзем дә алар белән бергә шунда ятып калыр идемме? Кем белә! Ул чакта бәла алай шомлы-дәһшәтле, чын һәм шундый якында гына шикелле тоелмаган иде. Ул чакта башымда берникди вариантлар да юк иде. Без Юлия белән бердәнбер салынган сукмактан һәм, безгә күренгәнчә, һичшиксез, иң дөрес юлдан—беркайчан да кире какмый һәм «BMW» двигателе шикелле туктаусыз эшли торган Хәниф абый Хәкимов янына йөгерә идек.

Һәм менә без өчәүләп язгы гөрләвекләр аккан, кояш нурлары белән тулган урамда. Көннең көндезге дүртенче сәгате бара, ә чылтыраулы һәм ялтыраулы көн карангылыкка һәм бозларга бирешергә җыенмый да иде әле.

Гайнан абыйны без беренче булып күреп алдык. Ишегалды түреннән. Ул да безне күрде. Башын иңнәренә батырган, ул башта бер якка ташланды, аннары икенче якка һәм ахырда Алмалы буенча, күмер өеме аркылы, мәктәпкә таба ыргылды. Килешеп тә тормыйча, Хәниф абый белән мин аның артыннан йөгердек, ә Юлия әле генә дезертир чабып чыккан җиргә ашыкты.

Яшенә карамастан, элеккеге «хәрби майор» бик житез атылды. Менә дигән спринтер дип белерсең. Драп пальтосы астыннан су тамчылары гына чәчрәп кала. Бер мәртәбә дә аягы таймыйча, мәктәпкә барып житте, елт

итеп хуҗалык капкасы артына кереп югалды, ишегалдын, гаражларны, сарайларны үтте, аннары артында кинлек, ирек, үзенә бертөрле шәһәр эчендәге шәһәр чите булган Уйсулык башланган койма аша сикереп чыкты. Ходай аякларына түземлек бирсен! Ләкин нәкъ менә шунда, әледән-әле тар сукмактан тирән юеш, көпшәк карга таеп төшә-төшә чаба торгач, «ветеран» көчен югалта, егыла башлады. Үзе егыла, үзе ата. Безгә таба дүрт тапкыр атты. Ә Хәниф абый аңа—ике мәртәбә. Берсен һавага. Ә Гайнан «вальтер»ыннан чыккан дүртенче фашист пулясы баш өстебездән бик якын ук сызгырып узгач (ул анын сонгысы икәнен без белмәдек, әлбәттә), Хәниф абый, туктап, һәм бу юлы, таяну өчен үзенең «макаров»ы астына терсәген куеп, туп-туры атып җибәрде. Кара драп ерганакның ап-ак кары фонында бик яхшы күренеп тора иде. Гайнан тагын тайган шикелле булды да, кар өеменә утырды һәм инде башка аннан кутәрелмәде.

Пуля анын аягына, тез бөгелә торган җирдән бераз өскәрәк, кыскасы, ботына эләккән иде. Ялтырап торган хром итектән, җилбәзәй драп пальтодан булган склад мөдире кымшанмыйча утыра һәм үзенең җылы каны белән салкын, берни дә сизмәгән, үзендә файдасызга туңып яткан итләр күмелгән кар көртен һәм тагын кайбер нәрсәне ашлый иде.

## Алар дуслары исән чакта яшиләр яисә Эпилог урынына

Тагын яз килде. Тагын май. Әйтерсең кояш астында юкәләрдә ябышкак яфраклар беренче мәртәбә генә ярыла, әйтерсең мин аларнын тешне камаштыргыч, авызны бөрештергеч, дулкынландыргыч исләрен беренче тапкыр гына исним.

Элеккеге урамда басып торам. Күпме еллар үтте, күпме язлар килде, күпме язлар узып китте! Безнең йорт урынында беренче катында зур, тоташ тәрәзәдән торган азык-төлек кибете булган тугыз катлы йорт басып тора. Анын бертуктаусыз ачылган-ябылган пыяла ишеге кояш нурларында ялт-йолт итеп куя. Халык керә, чыга, көлә, сөйләшә, чыраен сыта, дәшми, йөткерә... Икенче тормыш, икенче кешеләр, икенче вакыт. Аннан инде безнең еракта, зәнгәр офыклар артында калган ул елларны хәтерләтерлек хәтта бер коры үлән сабагы да таба алмыйсын. Йортны да, күгәрченнәр кетәген дә, алма бакчасын да тимербетон һәм пыяладан торган шушы мәгърур тау басып киткән. Гомумән алганда, болай матур корылма һәм, әлбәттә, кемнәрнеңдер туган оясы да.

Кешеләр үзләренең үлемнәреннән соң да яши бирәләр. Алар дуслары исән чакта яшиләр. Хәер, нишләп бары тик дуслары гына? Чөнки сүз, билгеле инде, балалары булмаган Шәех Шакиров белән Николай Сергеевич хакында. Берсе әле гаилә учагын корырга өлгермәде, икенчесе сонга калды...

Шәех дезертир белән булган бәрелештән соң бер көн үткәч, анына килә алмыйча, хастаханәдә үлде. Аны безнең татар зиратында әтисе белән янәшә җирләделәр. Аны сонгы юлга, берәүдән, иң яраткан кешесе Юлиядән башка, бөтен Алмалы озатты. Юлия хастаханәдә, Шәех белән Николай Сергеевич яткан шул ук хастаханәдә ята иде. Аларнын барысын да анда Алмалыдан аңнарын җуйган хәлдә ике «ашыгыч ярдәм» машинасында бер рейс белән алып килделәр. Юлия канга баткан Шәех белән Николай Сергеевичны беренче булып күргән иде. Башта Николай Сергеевичны, ә аннары мич артындагы киштәләр астында, ватылган, чәчелгән савыт-сабалар арасында яткан Шәехне. Һәм шунда анын йөрәге түзә алмый, андагы ниндидер клапан рәхимсез (әллә, киресенчә, рәхимле) рәвештә ябыла һәм ул, Юлия,

үзенең дуслары янәшәсенә егыла. Клиникада табиблар аның әтисенә, өмет бөтенләй юк, диләр. Ләкин кеше күкрәгендәге мотор искиткеч җайланма. Табигатьнең сукыр көчләре тарафыннан барлыкка килгән ул җайланма, кайчак кинәт, бернинди абруйлы фикерләр белән дә исәпләшмичә, аларга каршы баш күтәрә һәм үз-үзен дәвалый башлый. Шуннан соң бер дә бер матур көндә бетүгә дучар булган кеше кинәт күтәрелә дә үз аягы белән өенә кайтып китә. Юлия белән дә шундый хәл килеп чыкты, тик ул өенә кайтып китмәде, гади генә әйткәндә, хастаханәдән... качып китте.

Ә Николай Сергеевич тагын ярты ел яшәде әле. Пуля аның эченә эләккән иде. Биш сәгатькә якын сузылган катлаулы операция, табиблар әйтүенчә, уңышлы үтә үтүен. Һәм, чыннан да, инде бер атнадан ул шактый җиңел сөйләшә, бераз авырлык белән булса да укый, блокнотында ниндидер тамга-билгеләр ясый һәм янына килүче кешеләрне кабул итә ала иде. Шәехнең үлеме турында аңа әйтмәдек. Бары тик: «Шәех тә яралы, ләкин ул башка хастаханәдә ята һәм аның да эшләре терелү ягына таба бара»,— дидек. Җиңел ышанучан Николай Сергеевич моңа, һичшиксез, ышанды, әлбәттә. Ул бөтен яктылыкка һәм яхшылыкка һәрвакыт һәм бик теләп, җаны-тәне белән ышана иде. Әйтергә кирәк, без дә оста алдадык шул аны.

Николай Сергеевич янына килүчеләрне санап бетерерлек тә түгел иде. Һәм башкалар арасында теге, ничәмә-ничә еллар буе мин күз алдымда йөрткән, мине тынычсызлап килгән, мин аның турында үзем күп мәртәбәләр, ләкин һәрвакыт ничектер әйтеп бетермичә, һәрвакыт ничектер ярым-ярты сүзләрдән өзек-өзек кенә ишетеп килгән серле Татьяна Георгиевна Родимцева да бар иде. Ул хастаханәдә мин кизү торганда пәйда булды. Кечкенә, ябык, суырылган йөзле өлкән яшьтәге хатын-кыз иде ул. Мин аны коридорда каршы алып, палатага озатып куйдым.

Чал сакаллы картта Николай Сергеевичны танып алгач, ул, әле генә суыктан килеп кергән шикелле, ниндидер яшьлек алсулыгы белән кабынып китте һәм кинәт мин аның башта миңа төссез, бернинди хас билгеләре булмаган кебек тоелган йөзендә зәңгәр күзләренең үткен карашын сизеп алдым.

Мин аларны палатада ялгызларын гына калдырдым, яннарына сирәк-мирәк кенә, авыру янында утыручы буларак кайбер вазифаларымны үтәр өчен генә кереп чыккаладым.

Алар озак сөйләште. Бөтен көрешүләре барышында ул Николай Сергеевичның әллә нинди карасу-көрән даруга буялган зур кулын үзенең кечкенә генә, ак кулында тотып утырды. Әйтерсең ул ниндидер күптәнге ялгышлары өчен гафу үтенә, әйтерсең озак еллардан соң шул рәвешле аны да, үзенең ялгызлыгын да җылыта һәм әйтерсең ул бу кулны инде беркайчан-беркайчан да җибәрмәс сыман тоела иде. Ул минем алда аны Николай Сергеевич дип атарга тырышып сөйләште, ләкин юк-юк та, аның авызыннан миңа таныш булмаган һәм аның үзенә бик якын булган «Николай» сүзе ычкынгалый торды.

—Бүген, Николай, ике бәйрәм,—диде ул сүз арасында.

—Нindiләр?

—Изге хәбәр атнасы һәм бәрмәнчек якшәмбесе.

—Бүгенме? Юк ла, бу иске стиль белән генә бүген ул,—дип елмайды Николай Сергеевич, операциядән соң беренче генә тапкыр бугай.

—Аh,—диде хатын-кыз күңелсез генә,—мин бу иске-яңа вакытларда буталудан кайчан туктармын икән соң!?

Шул ук көнне Татьяна Георгиевна үзен авыр хәлдәге сырхау янында кизү торучылар исемлегенә язып куйды һәм үзенең «Николай»ы янында һәм хастаханәдә дә, өендә дә һәм аннары тагын кабат хастаханәдә дә ахыргача булды.

Николай Сергеевич сентябрьдә үлде. Операциядән соң бер ай үткәч, өзлегә башлады. Күрше галимебез якынлашып килгән үлеме белән тигез булмаган көрәштә әкрен һәм газапланып сүнә барды. Тормыш юлына кинәт кенә Татьяна Георгиевнаның кабат килеп чыгуыннан соң, үзенең шәхесенә һәм үзенең гомеренә, галәм һәм галактикалар җыелмасындагы бу гадәттән тыш мизгел һәм гадәттән тыш микроскопик рәвештә генә булган ялкынлы дәрт һәм теләкләр очкынына яшьтән үк ваемсыз һәм аек акыл белән караган Николай Сергеевичның һич тә үләсе килми иде. Үләренә бер атна кала ул беркатлылык белән мина үзенең телен чыгарып күрсәтте һәм: «Телем кызыл, анда бернинди куныгк та юк, аппетитым да яхшы»,— диде... Әйе, әйе, дидем мин аңа, сезнең организм бирешергә теләми дә. Соңгы көннәрдә дә аппетиты яхшы иде аның.

Николай Сергеевич Шәех исән, аның дусты «Васильево» шифаханәсендә дәваланып ята дигән уй белән үлеп китте. Бу шәһәрдән кырык минутлык кына юл, дип, без аңа аннан—янәсе, Шәехтән, көн саен диярлек күп сүзле «сәламнәр» алып кайта идек. Николай Сергеевич аларга ышана иде. Әллә безгә шулай булып күренде генәме икән?

Аны гасыр яшендәге имән күләгәсе астына, обсерватория янында җирләделәр. Моны искә төшерергә кирәкме икән?.. Кирәктер, шәт, минем үзем өчен генә булса да кирәктер. Ләкин бу чыннан да шулай булды, һәм бу, бераз хорафат рухындарак яңгыраса да, соңгы көннәрдә аның бик тә яшисе килүен тагын бер кат раслый торган, актыгында азга гына булса да тормышка дәртле рәвештә тотынып калырга, әле бу гөнаһлы дөньяда яшәргә теләвен раслый торган нәрсә булды. Һәм мин, озак икеләнүләрдән соң, бу эпизодны да үземнең шәхси хатирәләр почмагыннан чыгарырга уйладым. Оятыбызга, ә бәлки бу язмышның үзедер, без Николай Сергеевичның гәүдәсе салынган, җирләргә әзерләнгән табутын кабер өстендә тотып тора алмадык һәм ул... баш очы белән аска барып төште. Һәм Николай Сергеевич шунда, тере шикелле, хәтта бу гаделсез тоткынлыктан котылырга теләгәндәй, кулларын селтәп җибәрде, кинәт кенә ачылып киткән капкыннан бил тиңентен килеп чыкты һәм катып калды. Без аны яңадан табутына ничек керткәнбез—акылдан язарга мөмкин.

Гомер—вакытлы күренеш. Ләкин бу вакытлылык вакыт буенча озаккарак сузылсын иде. Нәрсә инде кешегә нииндидер илле—туксан яшь гомер! Әмма безнең әйләнәдәгесе дә һәм эчке дөньябыз да чагыштырмача гына. Кичә китеп барган таулар ягы озак гомерлесенә дә һәм Идел буенда яшәүче бер көнлек күбәләккә дә аларның үткәне дә, хәзергесе дә, киләчәге дә—барыбер һәм әһәмиятсез. Ләкин бит безгә, безгә, исәннәргә—юк, барыбер түгел. Исәннәр өчен үлем—иң зур мәгънәсезлек. Ә уналты яшьтәге үлем... Моңа хәтта исем дә табып булмый.

Ике пуля Шәехне үзенең яшь, сау-таза көчләре белән үлемгә каршы тора алырлык кечкенә генә мөмкинлегеннән дә мәхрүм итте. Николай Сергеевич көрәште, ләкин инде аның яшь һәм сау булмаган организмы берничә грамм кургашның бер ноктага тупланган көченнән күпкә зәгыйфьрәк булып чыкты. Аның каравы үзенең тиздән үләчәге турында алдан ук әйтеп куйган һәм аны тыныч кына көтеп яткан Кыям абый ничектер акрын гына, үзеннән-үзе аякка басты.

Үземнең туган шәһәремдә булган чакларда, мин аңа кермичә калмыйм. Минем аның хәленең ничеклеге турында биргән беренче соравыма ул һәрвакыт бер төрле җавап бирә, ул Николай Сергеевичның «Яшьлек эликсиры»н искә ала һәм, аның әдәби герое шикелле, вакытында үлмәү хакында куркуын белдерә.

Кыям абый бик картайды, ләкин башын югары тота һәм анда бер генә

ак чәч тә күрсәтми торган актерлык гадәтен һич тә ташламады.

Анын бүлмәсендә һаман шул ук бердәнбер картина—Юлиянен «Казансу» пейзажы. Һәм тагын (стенада түгел, ә бүлмә почмагында)—«Тынычлыкнын ак күгәрченнәре» чеканкасы, анын күптәнге, Шәех тә, Николай Сергеевич та төрле әзерлек чорында күргән, безнен барыбызга да бик ошаган һәм бик өметләнеп көткән художество конкурсында беренче турга да үтмәгән, ягъни беренчел сайлап алудан ук узмаган эше.

Безнен очрашулар ул кулында Дөнья Читеннән (бар андый мыс Сахалинда) Юлиянен ана адреслап җибәргән хатларын тотып утырганда бигрәк тә җанлы үтә. Юлия менә ничә еллар инде анда үзен геофизикага корбан итеп яши бирә.

Күнелгә рәхәтлек индерә торган андый күркәм көннәрдә Кыям абый чәй пешергеч чәйнек өстендә бигрәк тә зур тырышлык белән «сихерчелек» итә, ә мин кычкырып оныкасы ана зур, басма хәрефләр белән диярлек язган хатларын укыйм. Юлия бабасынын күзләре начар күрүен, газеталарны лупа ярдәмендә укуын белә, аннан сон бабасы русчаны һәрвакыт начар анлады, ә татарчага Юлия үзе шулай да өйрәнә алмады.

Анын Мәскәүдә яшәүче һәм анда зур фәнни вазифа биләүче оныгы Александр сирәк яза һәм хатларын берьюлы өйдәгеләрнен барысына да бергә адреслый.

Семён Васильевич пенсиядә. Күптән түгел генә Пушкин турында яна китап чыгарды. Ул анда, бу өлкә һөнәриләренен газета рецензияләрендә әйтелүенчә, шагыйрьнен декабристлар җәмгыятенен үтә дә яшерен әгъзасы булуы турындагы гипотезаны бик кыю тәкъдим итә һәм аны бик мавыктыргыч итеп раслый. Дуслары үлеменнән һәм шушы тарихи-әдәби басмадан сон Кыям абый белән кияве арасындагы мөнәсәбәтләр нульгә тикле төште диярлек. Хәер, алар беркайчан да аннан югары күтәрелмәде дә бугай.

Тагын кем? Хәниф абый... Ул милициядә озак тормады, чөнки башлыклары белән килешә алмады, Камага яна төзелешкә китеп барды. Анда ана, класслы автослесарьга, фатир вәгъдә иттеләр. Ә капитан Дубов элеккечә капитан һәм элеккечә тәртип сагы постында тора.

Кыям абый хуш ис килеп торган чәйне касәләргә сала һәм искәрмәгәндә генә: «Алай да бик иртә китте алар...»—дип көрсенеп куя. Мин аннан: «Кемнәр?»— дип сорамыйм. Башта, ана безнен салмак һәм һәрвакыттагы әнгәмәбезне һәм безнен дусларыбыз, анын алар хакында ялгызлыкта туган яна фикерләре турындагы сүзебезне дәвам итәргә мөмкинлек биреп, гомумән берни дә дәшмим. Әнә шулай сүзсез басып торганда еш кына күккә күтәрелеп карыйбыз. Ә анда, һаваларда—ак күгәрчен... Ни өчендер безгә алар Шәех күгәрченнәре кебек тоела...

Кешеләр үлгәннән сон да яшиләр. Алар дуслары һәм сөекләләре яшәгәндә яши бирә. Шәех белән Николай Сергеевичнын исә тегеләре дә, болары да бар иде.

**Әхәт САФИУЛЛИН** *тәрҗемәсе*



Фәрит
Суфияров

# ЮЛАУЧЫГА ЮЛДАШ БУЛАМ

***

Тауга менсәм тау буласым килә...
Яки моңы—аккан чишмәнең.
Күккә карыйм тәрәзәмне ачып,
Йолдыз булып балкыйм кичләрен.

Мин камышы булсам зәңгәр күлнең,
Дулкыннарын ярда кочармын.
Мин шоңкары булсам кыяларның,
Офыклардан биек очармын.

Яз чәчәге умырзая булсам,
Җиргә якты бизәк өстәрмен...
Кышы, язы, җәе, көзе булам,—
Күз камашкан төрле төстәмен.

Кешеләрнең мин шатлыгы булам,
Мирас итеп барын өләшәм.
Кардәшләрем сыман якын күрәм,
Сәлам биреп сезгә эндәшәм.

Юлаучыга юлдаш булып барам,
Маяк булам карлы юлларга...
Көмеш кыңгыраулар кебек чыңлап,
Җырым барсын ерак елларга!

## Яшен

Күк гөмбәзләрен тетрәтә
Яшеннәр—чатнап, уйнап.
Офыклардан аваз килә
Ерак галәмнәр буйлап.

Биек таулар тетрәнделәр,
Аккан сулар чайкалды.

---

Фәрит СУФИЯРОВ (1939)—*шагыйрь; унга якын («Яшьлегем авазы», «Яңавыл бизәкләре», «Күңел кошларым» һ.б.) китап авторы. Башкортстанда (Яңавылда) яши.*

Шомлы күкрәү авазына
Бар табигать тын калды.

Гайрәтен, көчен күрсәтеп,
Яшен яшьнәп уйнады.
Котын очырып җанымның,
Камчылый бар дөньяны...

Галәм битараф калмады
Күкрәүләр тавышына.
Хөкемен чыгара тагын—
Кемнең, соң язмышына?!

***

Яшен сүнә, ташу-сулар тына,
Үз сагында тота вакытлар:
Төн карасы кебек эреп бетсен
Күңелдәге бөтен ваклыклар.

Юлларыма каршы йөгереп чыга,
Читләп үтми нигә борчулар?
Атылырга торган вулкан сыман,
Бәгырьләрне телгән ачу бар.

Тынгысызлык җанны биләп ала,
Күкрәү сала—уйлар яңартып,
Газапларга сала йөрәгемне,—
Яраландым... тормыш яратып.

Юк-бар өчен акланулар бетми,
Җилгә оча ятлар вәгъдәсе.
Тормыш юлларымны били алмас
Бу дөньяның чуар пәрдәсе.

## Күңелемдә—җир бизәге

Күңелемдә мең төрле нур балкып уйный,
Кеше белми—бәлки, әллә ниләр уйлый...

Якты көнне караңгы төн алмаштыра:
Бу—табигать үзе белән таныштыра...

Табигатьнең мин сөекле улы булдым,
Юмартлыгын тоеп яшим, аннан үңдым.

Сахра-кырлар сыеп бетә: күңелем киң,
Зәңгәр дулкыннар уйнаткан диңгезгә тиң.

Чишмәләрнең дәртле моңын отып алдым,
Җырга булган мәхәббәткә тугры калдым.

Болын, тугайлардан кайттым күпме йөреп,
Күз камашты бетмәс матурлыгын күреп;

Таулар, чакырып биеклеккә кул изәде,—
Күңелемә күчте бөтен җир бизәге.

Нурислам Хәсәнов

# ЗОЛЫМ

РОМАН

## Калҗа бүлеш

Нәфиснең җен ачулары чыкты. Абага типографиясендә ут булмаганлыктан, «Байтирәк хәбәрләре» газетасы басылмый калды. Ана буш кул белән әйләнеп кайтырга туры килде. Кәефсезләнеп, редакциягә керсә, ана үрдәк янына бәбкәләре җыелгандай, газета укыган корректор Фираяны корреспондент кызлар сырып алган иде. Эш онытылган, рәхәтләнеп ләчтит саталар. Иреннән аерылган Фираяга, мәкалә яза белмәсә дә, юаныч табып, гәп сату мөһимрәк. Нәфис аны, «Эшләмәсәң эшләмәссең, тик башкаларны эшеннән бүлеп йөрмә, өеңдә утыр, үз кирәгеңне кара, ичмасам» дип кисәткән дә иде. Ул моны аңларга теләмәде, үзен нәчәлник хатыныдай хис итеп, һаман да түшен киереп, үз дигәнчә йөрүен белде. Нәфис аны эшкә алуына, башлык, Алия Тутаевна сүзләрен тыңлавына үкенде.

—Тагын «китапханә»гә җыелдыгызмы?—диде Нәфис, кызлар яныннан узышлый.—Миңа алдагы санга әзерләнгән материалларны китерегез әле!

Мөхәррирнең ризасызлык белән әйтелгән тонын ишетүгә, кызлар урыннарына таралышты. Әмма, шактый вакыт узуга карамастан, Нәфис өстәленә язылган материалларны китерүче булмады һәм ул аларны әрләп тә алды. «Эшләмәгән өчен премия язылмаячак...»—дип тә карады.

Нәфис өстәлендә телефон шалтырады.

—Ал-ло! Редакция тыңлый. Әйе, мин...—Чыбыкның аргы башыннан район аппараты җитәкчесе Тәкәевнең теш арасыннан ысылдап чыккан тавышы ишетелде:—Срочно монда администрациягә менегез.

—Нәрсәгә?

—Менгәч аңлашырбыз...

Нәфис янә аның дорфа сөйләшүенә аптырады. «Тагын нәрсәләр казып чыгарыр икән инде бу кылчык бәндә?»—дип, кашларын җыерды һәм, кәефе булмавын сиздермәскә тырышып, дәшми-нитми китеп барды...

Ул Тәкәев бүлмәсе ишеге төбенә килеп баскач, бер мәлгә туктап калды. Нигәдер аның гомер ачылмас сытык, ризасыз чыраена карыйсы килмәде. Тикшерү органнарында эшләгән шул адәмнең җирәнгеч, төксе карашлары күңеленә тиде. Кешеләргә ышаныч белән карамавы йөз-килбәтенә чыккан, җыерылган каш асларыннан кара рухы бөркелә. Каян тапканнар шундый кырыс, нурсыз бәндәне? Бирегә кем тарткан аны?! Ничек холыкфигылен Тукбаев белеп житкерә алмаган? Мөгаен, аны бу эшкә Ишкәев кодалагандыр... Нәфис, фикерен туплап, Тәкәев бүлмәсен ачып керде һәм бүлмәдәге авыр тынлыкны бозасы килми көтте.

---

*Ахыры. Башы Знче санда*

—Газетаң чыктымы?—диде Тәкәев күтәреп, очлы карандашын кәгазь өстендә уйнатты.

—Юк.

—Ник?

—Бастыру машинасы тукталып калган, утны өзгәннәр...

Тәкәев башын күтәрде. Ризасызлыгыннан җыерылган кашлары кысык күзләрен томалады.

—Алданрак карыйсы иде...

—Абагалылар башта үз газеталарын бастыра, аннары гына безнекенә тотыналар.

Тәкәев кулындагы очлы карандашны янә җир бораулагандай бөтерде.

—Менә нәрсә, иптәш редактор,—диде ул.—Моннан соң без газетабызны Абага типографиясендә бастырмаячакбыз.

—Кайда чыгарабыз?

—Казанда. Үзәкләштерелгән типографиядә.

—Үз типографиябезне кормыйбызмыни?

—Юк,—диде Тәкәев, кырыс кына.—Район администрациясенең карары шундый. Так что, әзерлән. Калада типография белән килешенгән, бездән тиешле хатлар китте, куллар куелган. Шунда барып, эшләренне җайлап кайт, газетаны чыгару графикларын төзе. Аңлашылдымы?

Нәфис гаҗәпкә калды.

Тәкәев өстәде:

—Сорауларың булмаса, минем шуның белән бетте.

—Ярар...—диде Нәфис һәм чыгып китте.

«Нигә бик тиз шулай эшләделәр?—диде ул, уйланып.—Яңа типография төзергә акча бүлеп бирәселәр иде бит...»

Ул бу хәлгә ике көн вакыт узгач кына төшенде. Администрация бинасына хуҗалык җитәкчеләрен һәм бухгалтерларын җыеп алдылар. Ни гаҗәп, һәммәсе бәйрәмгә килгәндәй елмаеп исәнләшергә тырыша, кулларында акча күчерергә дигән килешү кәгазьләре. Шундый ук кәгазьләрне, Тукбаев кул куйган карар белән, Нәфис кулына да китереп тоттырдылар. Анда типографиягә дип бирелгән биш миллион акчаны, алты айдан кайтарып бирү шарты белән, район хуҗалыкларына бүлеп бирергә диелгән. Сумнары да төгәл күрсәтелгән, куллар куеп, мөһер генә сугасы калган. Нәфисне бу хәл уйга калдырды. Ничек итеп ул редакциянең исәп-хисап счетына кермәгән акчаларны район хуҗалыкларына бирергә дип кул куярга тиеш? Ул акчалар кайда? Район финанс бүлегенә кайткнмы? Кайтса, үзләре күчерсен. Бу афера аңа нигә кирәк? Ул нинди максаттан чыгып эшләнелә? Аның шикле уйлары «стоп кран!»га басты: «Ялган килешүләргә кул куеп, мөһер сукканчы, киңәшергә кирәк,—диде ул.—Кеше күнелен күрәм дип, үзенне төп башына утыртмасыннар!» Нәфис бухгалтерына әйтте.

—Фәнзия! Кулыңны бер кәгазьгә дә куясы булма, печать сукма!—диде.

Фәнзия тотлыккандай ык-мык килде, боргаланып як-ягына каранды.

—Бүтәннәр куеп, бер без генә калгач ару булырмы соң?—Аның сораулы карашы «миңа монда яшисе, эшлисе бар бит әле» дигән мәгънәне анлата иде.

—Минем бүтәннәрдә эшем юк,—диде Нәфис, өзеп.—Иртәгә кем белән нәрсә буласын берәү дә белми, «типография корырга дигән биш миллион кая китте?» дисәләр ни әйтерсең?

—Нәчәлникләр үзләре шулай хәл иткәч...

—Алар синең өчен җавап бирер дисеңме? Мин ялган документка кул куя алмыйм. Бир кәгазьләрен, әйдә киттек...

Мөхәррирнең шулай каршы килүе минуты-сәгате белән Ишкәев белән

Тукбаевка барып иреште. Хужа бүлмәсендә өермә уйнап алды.

Яраклашырга тырышкан Ишкәев:

—Вот кабахәт...—дип, Тукбаев каршына килеп басты.

Аның зарын тынлаган Тукбаев сүзен кыска тотты:

—Нам не попути с ним...—диде урысчалап.

Бу вакыт Нәфис хакимият белән ике арада башланачак бәрелеш-каршылыкның ни дәрәҗәдә булачагын күз алдына китереп җиткерми иде әле. Ул, машинасына чыгып утыргач, бухгалтерына күз салмыйча гына рульне уңга да, сулга да боргалады. Борчулы сорауларына җавап эзләгән Нәфискә әчке мине ярдәмгә килде: «Мин синең бу карарга килүеңне хуплыйм. «Китсән китәрсең, аның каравы алар сине, пычракка салып, ялтыравыклы ботинкалары белән таптый алмый... Син эт типкәсе түгел! Булганы җитәр, илдә чыпчык үлми. Саулыгыңны, тынычлыгыңны сакла!..»

Әчке мине белән әңгәмә корып барган Нәфисне уйларыннан Фәнзия бүлдерде.

—Нәфис абый! Мин монда гына төшеп калыйм әле,—диде ул, машина почта бүлеге чатына килеп җиткәч,—райфинга кереп, хезмәт хакларын алырга заявка калдырасым бар...

Нәфис машина тизлеген акрынайтты. Аны да өч ай буена хезмәт хакы ала алмау борчыды:

—Заявка калдырып кына эш барып чыкмас, иртән эшкә килгәнче начальнигына кер, аңлат... Бер ашаган белән өч-дүрт көн ач йөреп булмый бит. Саварга сыерым да юк...

Фәнзия, көлемсерәп:

—Ярар, ярар,—дип китеп барды.

## Түрәнеке—түрдә

Нәфис өенә кайткач та тынычлык таба алмады, уйлары, сентябрьнең бәйләнчек чебенедәй, бимазалады. Бүгенге каршы килүе, шартнамәгә кул куймавы төрле сылтаулар табып үчләшү тудырачагын яхшы аңлады ул. Тырнак астыннан кер эзләгәндә, власть куштаннары да әзер торачагын яхшы белде. Гафу итүләрен көтмәде. Хәер, алар моңа сәләтле дә түгел. Тик шик тудыртып, ысылдап торырга аларга куш. Тукбаев әйтмешли, этлеккә тәһарәт кирәкми!.. Вакыт-вакыт аларның мәгънәсез, тук чырайларын күрергә теләмичә башын кая да булса алып китәсе килде, кулыннан каләме төште. Яраклашып, табан ялаучыларның тормыш кәсебен чит күрде. Яшәсеннәр, тик упкын читенә килеп җиткәндә дә ялган дан белән: «Без алга барабыз, без тырыш, булдырабыз!»—дип әллә кайчан, кемнендер әйткән сүзләрен кабатларга ашыкмасыннар иде. Кем өчендер кычкыртып талау да, «булдыруга» керәдер, бәлки... Кодрәтеннән килсә, яңгыр яудырыр син...

Нәфис, бәйләнчек уйларыннан арынырга теләп, яшелчә бакчасына чыкты. Ниндидер әче әйбер теләгәндәй, суган кыягы өзеп капты, аннан яшел укроптан авыз итте. Аннары үстергән чәчәкләренә карап сокланды. Көләч чәчәкләре аңа, рәхмәт әйтергә теләгәндәй, башларын иеп елмаештылар. Кичке тынлыкта алсу шәфәкъ нурларына манылган таҗлары, япь-яшь кыз-кыркындай хозурланып, татлы мизгелләр—гүя гүзәллеккә соклану кичерде. Тирә-юньгә аллы-гөлле балкышларын сибеп, Нәфиснең төшенке рухын сизгәндәй, әрнүле җанына шифа бирергә теләгәндәй талпынып-талпынып алдылар. Чәчәкләр Нәфиснең юанычы да, шатлыгы да. Ул, хет чәчәкләрем күңелне иркәләп торсын, дип, аларның берничәсен өзеп өенә алып керде һәм сулы вазага утыртты.

Ул чәйләп алгач, инде нишләргә дигәндәй, йөренде-йөренде дә диванга

сузылып ятты. Күзенә йокы кермәде, берничә көн элек булган эшмәкәрләр җыелышын исенә төшереп, диктофонын кабызды. Нигәдер аның тәбәнәгрәк буйлы, маңгай чәче арткарак шуышкан, илле биш яшьләр тирәсендәге «Шәрык» акционерлык җәмгыяте президенты Сәйфуллинның язмасын тынлыйсы килде. Менә микрофонда аның тавышы яңгырады:

—Шәхсән мин үзем дә дәүләт эшлеклесе дәрәҗәсенә чыгарга— депутатлыкка омтылып карадым,—дип башлады ул сүзен.—Нәрсә килеп чыкты? Фирмадагы тикшерүләрне икеләтә арттырдылар. Налог инспекциясе төнге уникегә кадәр утыра. Ник? Фәкать минем кандидатураны кандидатлыктан төшереп калдыру өчен, депутатлыкка уздырмас өчен... Килгән инспекторның берсе әйтә: «Безне монда махсус җибәрделәр, ни булса да казып табарга»,—ди. Менә сезгә дәүләтчә караш һәм мөнәсәбәт!.. Чын демократия булмаганда, гадел конкуренция дә була алмый ул. Мин сезнең районнан кандидат булырга теләгән идем. Миңа: «Син монда башыңны тыкма, без Сарбаевага наряд алдык...»—диделәр. Нәрсә, ул хатын бирегә килеп район экономикасын күтәрәме? Әллә башкасынмы?.. Чиновникларның тимер бөҗрасы безне дә кыса. Меңәр трактор кайтартып та, мине бер генә тапкыр да телевизордан күрсәтмәделәр, газетага язмадылар. Рәхмәт тә ишетмәдем. Әлегә уен кагыйдәсе барыбыз өчен дә тигез булмагач, ышаныч калмый... Юкса без бирегә эшләргә дип җыелдык, районга булышырга, налог түләргә телибез. Колхозын да кул астына алырга, тракторларын да, башка техникасын да бирергә. Гомумән, хезмәт хакларын да арттырырга исәп. Ләкин кая соң мин әйткән уен кагыйдәсе?.. Мин беләм, киләчәгебез җир белән бәйле. Бөтен дөнья тәҗрибәсе шуны раслый. Мин Калифорния университетында да, Австралия университетында да укыдым. Һәм моның ничек итеп эшләнгәнен беләм. Җирне бит закладкага салырга, кредитка алырга мөмкин. Кем аны безгә рөхсәт итә? Кем шәхси милекчелекне, колхозны алган очракта да, рәсмиләштерергә рөхсәт итә? Бүген без булган Ындыр совхозының унбиш миллион бурычы бар. Нигә мин аны бурычлары белән алырга тиеш? Мин ул унбиш миллионны хуҗалык үсешенә кулланыр идем: сыерлар фермасы төзергә, бозаулар сатып алырга, һич югы, рентабельле предприятие төзергә. «Син аны бурычлары белән ал»,—диләр. Ул хуҗалыкны кем соң карап торып хәерчелеккә төшергән?.. Синең тәкъдимнәреңне тыңларга теләү, аңлау юк. Син теләгән тиешле законнар да эшләми. Алда чыгыш ясаган Галимасов әйтмешли, берни бирмәгән законнарны ике куллап кабул итәбез. Депутатлыкка халык өчен уйлый белүчеләрне сайларга тырышмыйлар...

Бирегә әйтелгән фикерләр турында, ихтимал, газета битләренә язып чыгарга, телевидение тапшыруларында да сөйләргә кирәктер. Тик туры сүзне, дөреслекне әйткән өчен эзәрлекләмәсеннәр генә иде. Иң куркынычы шунда: бездә ул нәрсә бар...

Бездә бит промышленность, сәүдә палаталары бар. Аларга күп кенә чит ил вәкилләре килә, шунда күпме акча сарыф итәләр. Һәрберсе инвестор эзли, юкса үз инвесторларыбыз да әзер түләргә, юк, үзебезнекеләрне читкә кагалар, чит баланы ярата төшәләр. Без, әйтерсең, чит планетадан очып килгән!

Без бүген сезнең район администрациясе башлыгы Рәсим Юлаевич белән сөйләштек. Сезгә очсызракка тракторлар бирү турында да сүз булды. Тагын сорау туа. Ул тракторларны бераздан, налог хисабына бурычыңны түлә дип, тартып алмаслармы? Гарантия бармы? Юк. Җан сыкравы белән әйтәм, без һәрвакыт булышырга әзер, тик һәркем өчен уен кагыйдәсе бер булсын иде. Без бераз гына алга китәргә теләсәк, чәчәк аткан монополияне читкәрәк этеп, туктатып торырга тиеш... Гомумән, «Шәрык» фирмасы хезмәткәрләре

булышырга һәрвакыт әзер, әмма тигез шартларда. Рәхмәт...

Нәфисне Сәйфуллин чыгышы шундый нәтиҗәгә китерде: «Димәк, тиздән колхоз-совхозларны сата да башлаячаклар... «Акъяр»ның элекке рәисе Һашим абый әйтмешли, «хуҗалыкларның үзен тәпи йөрергә өйрәтү фирмер-чиновниклары кулына кайтып кала». Бу ни белән бетәр, нинди низаглар тудырыр? Хуҗалыкларның желегән корытмасалар ярый ла. Аннары чишмә суын да эчә алмассың, сулаган һаваң өчен дә авызына счетчик куйсалар— бетте, харап эш... Эшмәкәрләр чыгышында да хаклык бар. Алар зарын, дөреслекне газетаңа язып чыксаң янә Тукбаев: «Безнең житәкчеләргә құлагә төшергәнсең...»—дип, тукмак йодрыгын уйнатачак...»

Бүлмәгә карангылык иңә төште. Нәфис, сәер халәт кичергәндәй, үз-үзен анларга тырышты: «Нигә мин шулай? Кайбер нәрсәләргә битараф кала алмыйм? Йә, нәрсә оттым инде мин инженер һөнәрен ташлап журналист булудан? Мин дөресен язганга карап, Тукбаев, Ишкәев ишеләрнең намусы уянамы? Юк, үчләре генә арта. Акчага, дан-дәрәжәгә табынулары теләсә нинди этлеккә этәрә, алар сине таптап, изеп китәргә әзер... Бүгенге бүлеш заманында шайтан нәфесе белән котырган түрәләргә жил-янгыр тими, «гаделлек бизмәне» алар ягына авышкан... Байлык-муллыкта яшәү өстенлек итә, куллары, кар көрәүче машина калаклары сыман, һаман үзенә таба ишә. Намус почмакка поскан, кыйбла югалган... Жир шарын да минеке дип колачлар иде алар. Ишкәев, кодрәтеннән килсә, кеше өстенә кояшны да чыгарттырмас иде. Әллә шунамы, табигать чыгымлый, авыру җәмгыятькә фетнә күтәргәндәй, дингезләрне шаулата, аждаһадай авызын ачкан дулкыннар ярсып ярларга кага? Ялкын телләре урманнарны яндыра, күмергә әйләндерә...

Ул, шундый күңелсез уйлардан соң, балачагына әйләнеп кайтты.

Әйе, ул кайчандыр Акъяр урамнарыннан ач килеш, ямаулы чалбарлардан яланаяк йөгерде. Кышкы салкын көннәрдә тишек чабатасыннан күренеп торган бармак башын авызына кабып жылытырдай була иде. Шундый ачы салкын кышларның берсендә анын әтисен, налогын түләнмәгән, эшкә чыкмый калгансың дип, кәнсәләргә чакырттылар. Ул көнне Нәфис тә әтисеннән калмады. Авыл советының актив кешеләренең берсе—Әмин дигәне—кызарган колак кикриген сикертеп, кибәндәй очлы кашларын уйнатып, әтисенә аты-юлы белән сүгенде:

—Тегү тегәсеңме? Тегәсең. Налогын нигә түләнмәгән?..

—Акчам юк бит, Әмин. Кешеләрнең иске-москы чүпрәгеннән теккән киемнәре өчен күпме сорый алам соң мин? Алар да хәерче бит...

—Нигә ат жигеп тавык тизәге жыярга чыкмадын?—Ул тырпайган бармагын кылыч кебек уйнатып янады һәм, хәнжәр кадагандай, әтисе күкрәгенә килеп төртте.—Совет блачты кушканны үтәргә теләмәсәң, без сиңа права табарбыз, әнә колхозга керергә теләмәгән Садыйкка таптык бит, таптык. Себер киттеме? Китте...

Куркып калган юаш әтисе калтырана ук башлады. Ни дип тә әйтергә белми интекте, аннан көчкә телгә килде:

—Хатыным авырып китте... Ни бит, Әмин, минем ат жиккәнем юк...

Явыз Әмин аны тыңларга да теләмәде, зәһәрлегеннән төкерекләрен чәчте, сынаулы карашы белән әтисен баш-аяк күзәтеп әйләнеп чыкты һәм күзләре анын аягындагы итекләргә текәлеп калды.

—Ат жиккәнем юк дисен инде алайса?—диде ул, мыскыллап.—Әнә аксак Бәдри атны бик яхшы жигә, тик анын аягына кияргә менә мондый жылы итекләре юк.—Үзендә власть көчен сизгән Әмин күтәрелеп бәрелде:—Салып бир Бәдригә итекләренне!.. Нәрсә терәлеп каттын? Сал! Сал диләр сиңа...

Куркып-каушап калган әтисе бөтенләй телдән язды. Явыз Әмин котырынып җикеренде.

—Нәрсә, анлашылмыймы сиңа?—Ул әтисен урындыкка төртеп аударды.—Утыр, утыр!..—Ул аның итекләрен аягыннан салдырып алды.—Бар, хәзер кайтып кит!..

Әти, мескен, салкын кар өстеннән оекбаштан гына атлый. Аяклары туңганын улына сиздерәсе килми, үзе аларны кая яшерергә белми, тизрәк кар өстеннән шыгыр-шыгыр атлап тыркылдый. Гарьләнүләренә түзә алмыйча, ашыгыпмы-ашыга. Дулкынланулары калтыранган тәненә чыккан. Улына күрсәтергә оялган көмеш күз яшьләре, энже кар өсләренә төшеп житә алмыйча, бозга әйләнә. Иреннәре дер-дер калтырый, авыз эченнән кемнәрнедер сүгә, өзек-өзек сүзләреннән Әмин, Шиһап, Мәхмүт исемнәре яңгырап китә. Алар аны колхозга ирекле кермәгәне өчен дә кычкыртып талаганнар. Атын, кош-кортларын тартып алганнар, каралты-кураларын сүтеп, Мирәт авылына ферма төзергә дип озатканнар. Алай гынамы, йөкле әнием бала тапканда җәйгән мендәренә кадәр тартып алганнар...

Кеше талап баеган явыз Әминнәр, жирафтай озын, нәзек муенлы, ач яңаклы, комсыз Мәхмүтләр Нәфиснең күз алдыннан китми йөдәтте. Алар акча кирәксә дә, аракы, бал эчәсе килсә дә, төрле сылтаулар табып, безнең бәрәңге бакчасын үлчәргә төшәләр иде. Су буенда үскән таллык жирләрен дә кертеп, бакчабызны биш-ун сутыйга арттырып үлчиләр дә, «Кисәбез!» дип, жанга тия иделәр. Тегүче Ярулланың, бер тиенгә төннәр буе җәфа чигеп, кешенең иске-москы чүпрәкләрен сүтеп теккән кием акчаларына типтерел эчтеләр, ана, ул акча эшли дип, заемнарны да күбрәк салдылар. Безгә тагын бәрәңгедән пешкән әче ипи ашарга, кычыткан шулпасы эчәргә калды. Кеше каһәрләп, күңелне шомландырган бәндәләрнең өрәк-шәүләләре бүген дә янда гына йөри сыман...

Гарьләнү кичергән Нәфиснең күкрәк читлегендә парә-парә килгән нәни йөрәге чарасызлыгыннан нишләргә белми интекте. Үсә төшкән «хулиган малай» урта мәктәпне әйбәт кенә тәмамлады. Институтка кереп, инженерлык белгечлеге алды, шактый вакыт заводта эшләп чыныкты. Яшьли күңеленә кереп калган язу-сызу «чире» үзен онытгырмады, гаделлекне эзләүдән туган йөрәк бунт күтәреп калкып чыкты, каләм тибрәтергә кушты...

Түшәмгә карап яткан Нәфис, тамак төбе кытыклануын сизеп, йөткергәләп куйды. «Әллә түшәм ярыгыннан коелган пыяла тузаны тамакка кадала инде?» дип уйлады. Һәм ул үзен пыяла мамыгы белән төрелгән стеналар эчендә яшәүдән офтану кичерде. Нигә дип ризалашты соң ул бу йортка керергә? Агач йомычка чүбеннән прессланып эшләнгән ДСП стеналарыннан чыккан сумала, фенол исен иснәргәме? Юньле булса, мондый йортка Тукбаевлар, Ишкәевләр керер иде... Нигә бу дөнья шулай гаделсез? Кемнендер аягындагы соңгы итеген салдырып ала, тир түгеп тапкан малын талый, корган йорт-жирен жимерә, нахакка себер сөрә, зинданнарда җәберли, көчли, үтерә... Ә кемнендер, тасма телләренә ышанып, юлларына чәчәкләр сибә, алтынга төрә?!

Нәфис урыныннан сикереп торды да, ни дә булса эшләргә кирәк дип, иртәгә калага бару хәстәренә кереште.

## «Күренмәс кеше»

Кала үз тормышы белән яши бирде. Кырмыскадай үрчегән машиналар, урамнарга хуҗа булып, ары да бире дә чабыша, юл биреп өлгерерлек түгел. Һәркем каядыр ашыга, кабалана, мәшәкать артыннан йөгерә. Вакытнын чиген белмәгәннәр, тормыш гамен югалтканнар битарафлык кичерә.

Кемнәрдер, мина дингез тубыктан дигәндәй, сәрхушлыгыннан айнымаган, кемдер каргадай чүплектә казына... Нәфис: «Йа Хода, шушы көннәргә калдырма...»—диярга мәҗбүр булды.

Ул иң элек типографиягә керде, газетаны чыгаруга бәйле рәсми кәгазьләрне җайга салды һәм башка кирәк-яракны белеште. Компьютерларда җыелырга тиешле материалларны тапшыруны, газетаның басылу көнен ачыклады. «Байтирәк хәбәрләре» пәнҗешәмбе көнне чыгарга тиеш булды. Кала типографиясенең тәҗрибәле корректорлары да бар икән. Махсус югары белемлеләр. Бу кадәресе аны сөендерде. Биредә басылган газетаның сыйфаты да бермә-бер артачак. Язган мәкаләләрең кеше укырлык булып чыга. Мәшәкате бер үк: Абага районы типографиясенә бардың ни дә, калага килдең ни? Акчанны гына вакытында күчерт. Аннары шәһәрдә аралашу мөмкинлеге күбрәк. Гаиләң белән дә ешрак очрашасың. Шәп бит бу!..

Ул, типографиядән чыккач, мәдәният министрлыгына килде. Йомышы бухгалтериядә иде. Аны бүлмәдә илле биш яшьләр чамасындагы ябык, аксыл чырайлы, баш бухгалтер Зинаида Васильевна каршы алды. Сизгер карашлы тәҗрибәле ханым Нәфисне баш-аяк күзәтеп чыкты да аңа урын тәкъдим итте.

—Йә, Байтирәктә эшләрегез ничек бара?—диде ул, җай гына.

—Болай ярыйсы, тиражыбыз гына азрак...—диде Нәфис.

—Тиражлар кими шул хәзер, күп кенә район газеталары белән эш шулай тора...

—Зинаида Васильевна!—диде Нәфис, үз йомышына күчеп.—Без хәзер газетаны Казанда чыгарырга булдык.

—Мин беләм...

—Газетаны шәһәр типографиясендә бастыру уңаеннан сезгә бер соравым бар иде.

—Нинди ул?

—Мондагы типографиянең үз корректорлары бар икән. Минем корректор калага йөри алмый бит инде. Аның белән нишләргә? Корректорга бушка акча түләп тору кирәкме?

—Юк, билгеле...—диде Зинаида Васильевна, кистереп.—Корректорың корреспондентлык эшен башкара алса, аны шунда күчерә аласың, урын булса, әлбәттә. Башка яраклы эш юк икән, кыскартасың...

—Бу очракта мин хаклы буламмы?

—Әлбәттә. Бу сезнең карамакта...—Һәм ул өстәп тагын шунысын әйтте:—Редакцияләрдә тиздән болай да штатлар кыскартылачак, чөнки хезмәт хакларын күтәрү көтелә...

—Аңлашылды, Зинаида Васильевна,—диде Нәфис, үзенә кирәкне ачыклап,—киңәшләрегез өчен рәхмәт.

—Һәрвакыт рәхим итегез...

Коридорга чыккач, Нәфискә озын, төз гәүдәле, ыспай гына киенгән, кызыл галстук таккан яшь министр үзе очрады. Нәфис аның белән, ачыла төшеп, дустанә күреште.

—Исәнмесез, Сәет Әскәрович!

—Исәнмесез! Ничек эшләрең?—диде ул, ашыгуын сиздереп.

—Ярыйсы...

—Акчаларны алдыгызмы? Байтирәктә яна типография төзергә дигән.

—Ә-ә...—дип сузды Нәфис, уйлана калып.—Безнең исәп-хисап счетына кергән акчалар күренми әле.

—Мин шуны беләм,—диде министр.—Акчалар районыгызга китте. Так что, миннән калмады.—Кузгалып, берничә адым китеп сүзсез атлагач өстәде:—Ул акчаларга, җанкисәгем, берничә типография төзеп була. Йокламагыз...

Сәет Әскәрович шулай диде дә, Нәфисне коридор башында калдырып, кремланган очлы башлы ботинкаларын ялтыратып китеп барды. Нәфис аптырап уйга калды: «Ничек болай була инде? Ул акчалар тү-тү бит. Аларны, вакытлыча дигән булып, районның колхоз-совхозларына бүлеп бирделәр. Чынлыкта кайда соң алар? Бу турыда министр үзе беләме, белмәмешкә салышамы? Алар Тукбаев белән үзара килешеп эшләмәгәннәрме? Монда кем күз буа? Алла белсен! Янәсе, йокламагыз...

Сорау кыяфәтендә башын иеп озатып калган Нәфис турая төшеп кузгалып китте. Ул урамга чыккач та офтанды: «Нишлисен, эт өрә, бүре йөри, соңгы сарыкны тотып ашаганга кадәр...»

Ул бүген Байтирәккә кайтырга ашыкмады, гаиләсе янында кунарга булды. Эшләрен бетергәч, машинасын урам чатындагы стоянкада калдырып, өенә җәяүләп атлады. Инде көн кичкә авышкан иде. Почмактагы зур кибет артына житәрәк, милиция оперативникларының бер яшь егетне тентүләрен күреп, адымнарын акрынайта төште. Милиционерлар каршында аптырашта калган кара чәчле, түгәрәк йөзле бер егет тегеләр боерганны теләр-теләмәс үтәргә мәҗбүр. Аның күлмәк җиңнәрен сызгандырталар, янәсе, наркоман түгелме? Кесәләрен капшыйлар, әйләндерәләр. Эзләнә торгач, бер кесәсеннән күпмедер акча да килеп чыкты.

—Бу акчаларны каян алдың?—диде озын буйлысы, күзләрен ялтыратып.

—Үз акчаларым. Кибеткә әйберләр алырга чыккан идем...

—Бу акчалар урланган булса?..—диде тәбәнәк буйлы, киң гәүдәлесе.—Тикшереп карарга кирәк, милиция бүлегенә бармый булмас...

Егет ризалашмады, карышты.

—Сез нәрсә, мине карак дип белдегезме әллә?

—Ә кем белә, бәлки, син кесә карагыдыр, телефоннар урлап йөрүчедер. Документың юк, ачыклар өчен отделга бармый булмас.

—Беркая да бармыйм мин...

—Барырга теләмәсәң, акчаңны калдырасың. Икенең берсе...

Шушы күренешне күзәткән Нәфис күрмәмешкә салышып туктап ук калды. Оперативникларның озын, ач яңаклысы егеткә күзләрен калайландырып карады.

—Башкача булмый,—диде ул, чәнечкеле карашын егеткә текәп.—Отделга кайтып, акт төзергә туры киләчәк, кибет чатында сиеп тора иде, дип.

Киңчә жилкәлесе, авыз эченнән көлеп, иптәше сүзен хуплады:

—Безгә аты-юлы белән сүгенде, каршылык күрсәтте дип тә өстәргә туры килер. Бер тәүлек утырып чыккач, биш йөз сум штраф та чәпәрбез.

Нәфис шушы урында түзмәде, ни чарадан бичара хәлендә калган егеткә ярдәмгә килде.

—Сез нәрсә, куркыныч җинаятьчене эләктердегезме әллә?—диде, якын килеп.—Җибәрегез егетне!

Тегеләр гаҗәпләнде.

—Син кем безнең эшкә тыкшынырга?—диде озын сыйрак, мин-минлеген күрсәтеп.

—Гади бер гражданин. Нигә егеттән акча теләнәсез, шул көнгә калдыгызмы?

Калайланган караш Нәфискә текәлде.

—Абзый, сүзләреңне үлчәп сөйләш, юкса үзеңне дә алып китәбез. Будешь там свои права качать.

Нәфис куркып калмады.

—Әгәр егетне җибәрмәсәгез, мин милициягә үзем барам. Телисезме, хәзер үк нәчәлнигегез Федоровка шалтыратам.—Ул кесә телефонын чыгарды.

Тегеләрне Федоров фамилиясе сагайтты. Шикләнә калган аксыл чырай як-ягына каранып алды.

—Сез кем буласыз?

—Журналист.—Нәфис билетын чыгарып күрсәтте.—Телисез икән, бергә барабыз...

Нәфиснең үҗәтлеге оперативникларның кәефен кырды. Аксыл чырайлы акчаны егетнең уч төбенә салды да китәргә ым какты һәм, аклангандай итеп:

—Без аны наркоман дип торабыз,—диде.

Аерылышып бераз ара киткәч, Нәфис артыннан теге яшь егет куып житте дә:

—Абый! Сезгә бик зур рәхмәт инде,—диде.

—Бүтән эләгә күрмә...—диде Нәфис, артына борыла төшеп.

Бүтән эләкмим дисәң дә, кем гарантия бирә ала? Талауны кәсепкә корган милиционерлар ач бүредәй ауга чыксыннар да, ничек беркемне дә эләктермәсеннәр ди.

Нәфиснең игътибарын урам чатындагы уен автоматлары янына җыелган яшьләрнең көр тавышы җәлеп итте.

—Булат, акчаңны бу якка сал, моннан бер абый кичә биш йөз сум отты.

—Тыңлама, Гәрәй, бу як отышлырак,—диде икенчесе.—Мин моннан йөз сум оттым инде.

Егетләр автоматларның дүрт ягыннан да «бәхет»ләрен сыный. Отышка өметләнгән күзләре жем-жем иткән кызыл цифрлардан аерыла алмый. Биш тәңкәлек көмеш акчалар тар ярыктан «ояга» тәгәрәп төшә, егетләр көткән акча «янчыгы»ның авызы гына ачылмый.

Булат дигәненең көмешләре бетте, ул Гәрәйгә мөрәҗәгать итте:

—Миңа ун көмеш бир әле, откач кайтарырмын...

Комсыз автомат Гәрәйдән алган көмешләрне дә йотты. Ахырдан ачулары чыккан егетләр, автоматларга суккалап, көлә-көлә китеп бардылар.

Чат саен корыч сакчыдай үрә торып баскан автоматлар Нәфискә акча сорап торган оперативникларны хәтерләтте. Ата каракларны баетучы, кешеләрне психик яктан чиргә сабыштыручы, төрле җинаятькә этәрүче сихерче автоматлар, уен, кафе салоннары кемгә кирәк? Нинди тәрбия бирәбез? Гаделсезлек бунтын арттырабыз гына...

Нәфисне кызы язмышы, аның киләчәге уйландырды. Көләче шушы кыргый тормышны ничек кабул итәр, чит-ятларны таный белерме? Туры юл сайлый алырмы? Бәхетле булырмы? Авызыннан тәмәкесе, сыра шешәсе төшмәгән, автоматларга тибенеп китүчеләргә юлыкмасын иде ул! Акыл бир син аңа Ходай, көч бир, карагруһлардан йолып кал!..

Ул, вак-төяк күчтәнәчләрен күтәреп өенә керүгә, бусагада тукталып калды. Ишек ачылып ябылган тавышка түр бүлмәдән чыккан Сәриясе каршына килеп басты.

—Мин кайттым!..—диде Нәфис, яхшы кәефен сакларга тырышып.

—Күрәм,—диде Сәрия аңа, сынаулы караш ташлап.

—Нигә шатланмыйсың?

—Янымда шатланып кешем булмагач, нишлим соң? Син—читтә...

—Менә яныңа кайттым бит.

—Ничә сәгатькә?

—Төн буена, таң атканчы...

—Кунасыңмыни?

—Кунам. Кертәсеңдер бит?..

—Уйлап карарга кирәк.—Сәрия елмайды.

—Уйлый торганчы, бу сумканы алып куй әле!
—Монда нәрсә соң?—диде Сәрия, Нәфис кулыннан сумканы алып.
—Сиңа кучтәнәчләр: яраткан алмаларың һәм ит...
Нәфис аяк киемнәрен сала-сала сорады:
—Кыз өйдә юкмы әллә?
—Юк. Әле укуыннан кайтып җитмәде.
—Алай икән...
—Чәй эчәсеңме?
—Эчәм. Чәй эчәм дә мунчага кереп чыгам. Байтирәк тузаннарын юарга кирәк.
—Үз мунчаңны өлгерт инде...—диде Сәрия, Байтирәк өен күздә тотып.
—Әй, һаман да җитешеп булмый әле... Әллә авыл мунчасына керәсең киләме?
—Килә шул. Син дә һаман кешегә ялынып йөрмәссең бит.
Нәфис хатынының төртмә сүзен яхшы аңлады.
—Булды, болай булгач, быелдан калдырмам, Аллаһы боерса. Авыл мунчасы җанга да сихәт ул.—Ул уйлана калып өстәде:—Исән-сау гына эшләп торсак...
Сәрия аның нидер әйтеп бетермәгәнен сизде.
—Нәрсә, районнан куарга җыенмыйлардыр бит?..
Нәфис карашын читкә алды.
—Юк әлегә... Ярар, бу турыда соңрак сөйләшербез...—диде һәм чәй эчте дә мунчага җыенды...
Мунчада чират юк иде. Ул керүгә, чабыну бүлмәсенә үтте. Тирләп-пешеп чабынгач, сулыш алырга дип, чишенү залына чыгып утырды. Монда кемнәрдер шахмат уйный, сыра, чәй эчә, ә кемнәрдер үзара гәп сата. Нәфис як-ягына каранды, таныш-белешләр күренмәде. Анардан ерак кына түгел берничә ир кызып-кызып гәп сатты.
—Әгәр мин күренми торган кеше булсам,—дип, күркә кебек кабарынды табак битле ир, күзләрен акайтып.—Иң элек безне талап баеган лидер... теге Бикбаевны чукындырыр идем...—Ул, бармагын пистолеттай төзәп, тек дип куйды.—Ни өчен дигәндә, кара инде ул колхозларны? Нинди көнгә төшерделәр. Башта талап оештырдылар, хәзер талап тараталар. Бар җирне бүлеп, кешеләрне эшсез калдырып, инвесторлар басып алды... Хезмәт хакына кәгазь колбаса алып кайтып бирәләр. Мин ашамыйм ул колбасаны.—Ул җирәнеп чыраен сытты һәм прожектордай акайган күзләрен йомып-йомып алды.—Мәче дә ашамый аны.
Сәер кеше тукталуга, тәне рәсем дәфтәренә әйләнгән ябык чырайлы ир сүзгә кушылды, ул ярык тамгалы кашын сикертеп алды.
—Без төрмәдә баланда чөмердек, итне этләргә ыргыттылар... Мин шунда җәзве заработал...—Ул хатын-кыз сурәте ясалган иңбашын калкытып алды.—Бутадылар дөньяны...
—Контроль булмагач...—диде «күренмәс кеше», күзләрен акайтып.
—Контроль?!—дип көлде тоткында булганы, җәрәхәте ачылудан саклангандай, эчен тотып.—Тикшерүчеләрнең авызын момент томалыйлар. Ревизор килсә, гомерлеккә баеп китә...
—Кул кулны юа...—диде «күренмәс кеше», янә күзләрен сәер акайтып.—Нефть чутсыз...
Арык санлы кешенең киртекле кашы, син дә аңлый беләсең икән дигәндәй, сикергәләп алды.
—То-то, базара нет...
—Менә мин калада яшәсәм дә,—диде «күренмәс» фикерен авырдан

туплап,—барыбер авыл мужигы булып калган бит инде. Кайткалыйм авылга, Байтирәк районына...

«Байтирәк» сүзе чыккач, Нәфис: «Бу кайсы авылныкы икән?»—дип, аның ниләр әйтерен көтте.

—Авылда хәзер эшсезлек, иген иккән колхозчы хәерче,—дип дәвам итте ул.—Безнең игенне чит ил алмый. Агулы ул. Сыра эшләргә дә ярамый. Кырларга агу сиптертеп, кошларны үтереп бетерделәр, хәзер сайрар кош та калмады авылда. Быел җәй ишетмәдем сайраганнарын. Ул теге елларда сайрап җибәрәләр иде сыздырып... Мин үзем дә аларга кушылып җырлый идем. Шәп җырлыйм мин. Орып бирәм мин хәзерге артистларны. Аларның бер моңнары юк. Сүзләренең ата-анасы. Чыш-пыш шунда. Такмак җырлап, чикерткә кебек сайрашкан булалар, арт якларын иләп...—Ул, кемнедер күргәндәй, бер читкә сәерсенеп карады.—Цехта мин җиффәрә идем сайратып, авызларын ачып тыңлыйлар иде. Бер дә карап тормый идем. Салгач, абыйны да җырлата идем.

—Үзең гармунчы дамыни?—диде әңгәмәгә кушылмый сүз җыеп утырган өченче ир. Һәм ул, мыек астыннан елмаеп, керпе чәчен сыпырып куйды.

—Гармунчы! Җиффәрә идем сыздыртып авылым урамнарында...

—Кайсы авылдан син?

—Ындырдан. Исемем Шәриф була минем.—Ул керпе чәчле кешегә төбәлде.—Әллә син безнең авылны беләсеңме?

—Ул якларда булганым бар,—диде керпе чәчле.—Машинада икмәк ташыган елларда баргалый идем... Син хәзер пенсиядәме?

—Әйе. Әле эшләп йөрим, цехта вентиляция буенча слесарь булып. Эшләмәсәң, пенсиягә генә яшәп буламыни?..

Рәсемле кеше эчтән кытыкланып көлде, ул тамгалы кашын уйнатып сорады.

—Шәриф агай! Син, чыннан да, күренмәс кеше булсаң нишләр идең?

—Һе,—диде Шәриф, гаҗәпләнеп.—Берәрсен шыпырт кына килеп чүкер идем, кабинетына кереп.

—Кемне?

—Кемне, кемне? Эшли белмәгән башлары белән өстә утыралар бит байлык җыеп... Тегендә-монда кунак булып йөриләр, әле шуларны телевизордан мактап күрсәткән булалар... Ялганны халык белми дип уйлыйлардыр...

—Ну, монысы аңлашыла. Менә син министр булсаң байлык туплар идеңме?

—Нигә тупламаска?! Әллә мин кешедән кимме...

—Ким түгел, син молодец кеше. Йә, ничек итеп баер идең?

Шәрифнең акайган сәер күзләре гаҗәпсенде.

—Һе, гөмбәләр кебек үрчегән банклар беткәнме? Минем дә кеше шикелле яшисем килә.

—Дөрес, Шәриф агай. Байлар азынды хәзер. Талауны гына беләләр.

—Блачь юк, мин аларга Сталинны кайтарыр идем...

—Хәзерге мафиозниклар белән Сталин да көрәшә алмас...

—Алмас, мин аларны...—Ул янә бармагын пистолеттай төзәде.—Тек кенә итәр идем.

Тамгалы кашның авызы ерылды.

—Дөрес әйтәсең, Шәриф ага... Кара әле, бу илне тәртипкә китереп булырмы икән?

—Президентның,—диде Шәриф, кемнедер күзаллап һәм куш йодрыгын күрсәтте,—аның менә шушының кадәрле генә башында күпме ми бардыр дип беләсең син? Ул ничек зур илне тәртипкә китерә алсын?.. Ул илнең

тәртибе, культурасы алга китми торып. Телевизордан да әйтеп торалар ич, министрлар арасындагы урлашуны да туктата алмагач ничек була инде ул? Урлыйлар да кайсы чит илгә кача. Качтырыр идем мин аларны...

Тоткынның көләргә дип ачылган авызы ябылмыйча калды.

—Нишләр идең?

—Чүким, теге дөньяга озатам, нәрсә каракларга карап торырга? Җуләр түгел лә мин...

—Юк, син акыллы кеше, анысы. Әйтик, безнең шәһәргә сине мэр итеп куйсалар нишләр идең?

—Бер яхшы бәдрәф салдыртыр идем...

—Дөрес, баер өчен яхшы бизнес.

—Соң, йомышыңны гел койма буенда башкарып булмый бит инде.

—Тагын?

—Артезиан коесы казытыр идем. Торбадагы суны эчә торган түгел, чирлибез бит. Ул чишмәләр тәккә агып ята. Аларны шәһәргә китереп була бит инде. Су дахудлы хәзер... Киләчәктә су дефицит булачак ул!

Шәрифнең беркатлылыгын шәйләгән арык санлы шымчы, колаклардан шикләнә төшкәндәй, як-ягына каранып алды.

—Сиңа, Шәриф ага, иң яхшысы, күренмәс кеше генә булып калырга кирәк. Акчаң море булачак. Түлке, безнең эше вак каракларны гына чүкемә.

—Мин тиле түгел ич...

—Дөрес... Әйдә, тагын бер шәпләп чабынып чыгыйк әле...

Кузгалып киткән ирләр артыннан Нәфис тә юыну бүлмәсенә узды...

Ул мунчадан кайтканда, Сәриянең чәе әзер иде.

—Чәйне нәрсә белән эчәсең, карлыган вареньесы беләнме, әллә облепиха беләнме?—диде ул, Нәфисе өстәл артына килеп утыргач.

—Облепиха белән...

Сәрия, өстәл әзерли-әзерли, Нәфиснең күнел кылын тартты.

—Йә, ничек анда Байтирәктә эшләрең?

—Ярыйсы,—диде Нәфис, теләр-теләмәс кенә.—Тиздән газетаны Казанда бастыра башлыйбыз.

—Ник?

—Шулай карар кылдылар...—Нәфис, гадәтенчә, шаярткандай итте.— Моннан соң янына ешрак кайтып йөри башлаячакмын...

—Белмим инде нишләрсең, каядыр югалмасаң...—Сәрия көнләшүен сиздертеп алды.

—Монарчы югалмадым бит,—диде Нәфис, хатынының борчылуын аңлап.

Сәрия, кемне ышандырмакчы буласың дигәндәй, көлде... Әңгәмәне өзеп, шул вакыт кызлары Көләч кайтып керде.

—Исәнме, әти!—диде ул, ачык елмаеп.

—Әйбәт, кызым! Йә, студентның хәлләре ничек соң?

—Тоже әйбәт. Әллә мунча кердеңме?

—Әйе.

—Җиңел пар белән!

—Рәхмәт.

—Миңа нәрсә алып кайттың?

—Син яраткан алмаларны.

—Отлично...

—Байтирәктә ни хәл анда? Какмыйлармы?

Нәфис икеләнеп җавап бирде.

—Хәзергә юк, кызым...

—Ә аннары?—Көләч өстәлдән бер алманы алып тешләде.—Нигә әйтеп

бетермисең?

Сүзгә Сәрия кушылды.

—Байтирәктән куарга җыенмыйлардыр ич?

Нәфис уйга калды.

—Ул көн дә килергә мөмкин...

—Нәрсә булды соң?

Нәфис эчкән чаен кире өстәлгә куйды. Ул бер кызына, бер хатынына карады, ни дип әйтергә белми торды.

—Бер низаг килеп чыкты.

—Нинди?

—Безнең министрлыктан районга, типография төзергә дип, күп кенә акча күчерелгән. Счетка түгел, райфинга. Ул акчаларны, формаль рәвештә, колхоз-совхозларга бүлеп бирергә карар чыгардылар. Үзара ялган килешү кәгазьләре төзелгәч, мин аларга кул куймадым.

—Дөрес эшләгәнсең, әти!—диде кызы, белдеклелеген сиздерергә тырышып.

—Бүлдермә кешене!—диде Сәрия, кызын тыеп.—Шуннан?

—Шуннан шул, ачулары чыкты. Миңа карашлары үзгәрде, дошман күрә башладылар.

—Әй, юкны сөйләмә әле,—диде Сәрия.—Нәрсә эшләтерләр соң? Ул акчаларны син урламаган ич.

—Әйтмә дә!—диде Көләч, әнисе сүзен хуплап.—Исен киткән икән, кит, дисәләр, китәрсең, монда эш таба алмыйсыңмы? Нәрсә дип белдең син ул район газетасы редакторлыгын.

—Шулай да... Сүзе бар, эшли алмады диярләр.

—Сүзе?! Син нәрсә, әти, хәзер ул турыда уйлап тормыйлар, җаның ни куша, шуны эшлә! Син югалмыйсың...—Кызы бер мәлгә уйланып калды.—Мине редакция эшеннән чыгар. Үзеңә бәйләнергә сәбәп булмасын. Язган мәкаләләремне бастыр да...

Ике яклап өйрәтү Нәфис күңеленә тия башлагач, ул сүзен кыскартты:

—Ярар, җитте! Мин үз эшемне үзем хәл итәрмен...—диде.

Аннан соң бергә ашап-эчү кәефне күтәреп җибәрде.

## Берәү китә, берәү кала

Каладан киләчәк аппарат җитәкчесе, депутат Нишановны Тукбаев белән Ишкәев икесе, җыелыш башланырга бер сәгать кала урман почмагына—район чигенә барып каршы алырга булдылар. Нишанов карап торган иң олуг кунакларның берсе, Дәүләтхан Бариевич вәкаләтен үтәүче. Ул барган җиргә янәшә-тирәдәге башка район җитәкчеләре дә килми калмый. Сынатырга ярамый, аны тыңлау, хөрмәт итү мөһим!

Алдан сөйләшкәнчә, Нишановны чибәр кызлар кулына ипи-тоз тоттырып каршы алдылар. Мөхтәрәм кунакка, бар шартына китереп, игътибар күрсәтелде... Аннан, артык тоткарланмыйча, кәттә машиналарга утырып, выж гына Байтирәккә юл алдылар. Югары тизлектә барган машиналарны юл читендә үскән каеннар, хуш киләсез дигәндәй, башларын иеп сәламләде. Калкулыкка җиткәч, Байтирәкнең өр-яңа, икешәр катлы итеп салынган йортлары баш калкытты. Аларның иң зурысы Тукбаевныкы, икенчесе—Ишкәевнеке иде. Алардан кайтышлары район үзәгендә төзегән хуҗалык рәисләренеке...

—Байтирәк шактый үскән,—диде Нишанов, исе киткәндәй киерелә төшеп.—Тырышасыз, молодцы! Әле кайчан гына юкка чыгып барган авыл иде югыйсә...

—Сезгә зур рәхмәт инде, Фәрзи Морзаевич,—диде Тукбаев, кунакка теләктәшлек белдереп.—Ярдәмегездән ташламадыгыз... Бүген яңа почта бүлеген һәм прокуратура бинасын файдалануга тапшырабыз...

Нишанов моңа разый калып килеште:

—Кирәк, кирәк. Районны бар яктан да ныгыту, аякка бастыру мөһим эш.

—Тик менә яңа клубны гына төзеп бетерә алмадык,—диде Тукбаев, бераз офтангандай.

—Клубны Динар Хамаевич өлгертер инде,—диде Нишанов, сүзне булачак яңа башлык исеменә күчереп.—Администрация бинасын да корып бетерер...

Сүз җае чыгуга, Ишкәев:

—Яңа клубны да, администрация бинасын да киләсе елдан калдырмаска исәп, Фәрзи Морзаевич,—дип өметләндерде.

Нишанов канәгать елмайды:

—Сезнең ише егетләргә ышанырга була...

Бер-бер артлы килгән машиналар, клубка җиткәнче, ашханә ишегалдына кереп туктады. Юлдан килгән кунакларга табын әзер иде инде.

Сәгатьләргә күз салгач, вакыт җиткәнлеге, клубка җыелган халык искә төште. Һич көттермичә, биш минут дигәндә, ялт та йолт килгән кәттә машиналар клуб янына килеп тукталды. Биредә дә түрәләрне махсус каршы алучылар табылды. Клубка кергәч, аларга беренче рәттәге урыннар тәкъдим ителде. Фәрзи Морзаевич өчен урынны Ишкәев үзе сайлады.

Ниһаять, залдагы халыкны тынычландыргач, микрофонга җан керде.

—Исәнмесез, хөрмәтле районлашлар, хезмәт алдынгылары һәм кадерле кунаклар!—дип бәйрәм тантанасын ачты китапханәче Рәсимә, артистларча сөйләргә тырышып.—Без бүген бирегә ни сәбәпле җыелганыбызны барыбыз да беләбез. Сүземне районыбыз җитәкчесе Рәсим Юлаевичтан башлыйсым килә. Әйе, район башлыгы йокы күрми, ул көн-төн уйлана, нинди дә булса яңалык кертергә омтыла. Сәясәттә нинди генә хәлләр булмасын, барыбер, камчы район җитәкчесе сыртына төшә.

Бу тупас җөмләдән Ишкәевнең кашлары биеп алды.

—Шуңа күрә дә ул ялны да, бәйрәмне дә белми, ул гел эштә, эзләнүдә... Аның шатлыгы да, кайгысы да, яшәеше дә шушы хезмәт белән бәйләнгән. Шуңа күрә дә аның күңеле сафтыр, нечкәдер, шуңа күрә дә җилкә тамыры ныктыр!

Менә хәзер сүзне районыбызның хакимият башлыгы Рәсим Юлаевичка бирәбез.

Тукбаев урыныннан кабаланып торды да, томырылып, сәхнәгә юнәлде, ашыгып атлаган җиреннән күтәртмә баскычка сөртенде, чүт егылып китмәде һәм ул, каушамаска тырышып, мөнбәр артына килеп басты, тамак кырды:

—Хөрмәтле районлашлар, алдынгылар! Хөрмәтле Фәрзи Морзаевич һәм безне хөрмәт итеп килгән кунаклар!

Без бүген бирегә очраклы рәвештә җыелмадык. Сез моны яхшы беләсез. Барыгызга да мәгълүм, быелгы урып-җыю эшләрен матур гына тәгәлләдек, монда шулай ук зур уңышларга ирешкән хезмәт алдынгыларын бүләкләргә дә чакырдык. Алар безнең районда бик күп, монда алдынгыларның да алдынгылары җыйналды. Күрсәткечләргә тукталып тормыйм, аларны тантана барышында алып баручылар җиткерер, һәммәсен бездән әйтелгән сүзләр дип кабул итәрсез... Күргәнегезчә, без, икмәк үстерү белән бергә, төзелеш эшләрен дә алып барырга тырыштык. Бүген генә ике яңа бинаны—

почта бүлекчәсен һәм прокуратура бинасын ачтык...

Тукбаев, бераз каушый да төшеп, башкарган эшләрне санап чыккач, сүзен алдынгыларга яңа уңышлар теләп тәмамлады. Аннары сүз рәсми кунак Фәрзи Морзаевичка бирелде.

—Хөрмәтле байтирәклеләр! Алдынгыларның да алдынгылары!—диде ул һәм туралеген сиздереп җәелә төште.—Мондый бәйрәмнәрдә мина еш булырга туры килә. Бәйрәмнәрдә без дә сезнең кебек дулкынланабыз, сезнең алда үзебезне бурычлы итеп сизәбез...—Сез,—диде Фәрзи Морзаевич, дәвам итеп,—бөтен республиканы ашатырлык продукция җитештерүдә үзегездән зур көч куясыз. Әйтер идем, алдынгы урыннарда барасыз. Бу—сезнең казанышларыгыз!.. Хакимият башлыгы Рәсим Юлаевичның, төнне көнгә ялгап, тырышып эшләве күз алдыгызда. Ул Казан урамнарында һәркөн йөреп, кайда нинди әйбер ятканын күреп кайтса, бу әйбер икенче көнне Байтирәктә була. Ул көннәр буе чиновникларның кабул итү бүлмәләрендә йөреп, теләнеп-сорап үз теләгенә ирешә. Менә шундый кеше районны үстерә белде...

Без, республика кадрларын барлаганнан соң, хакимият башлыклары арасыннан тәҗрибәле Рәсим Юлаевичны сайлап алдык һәм аны зуррак районны күтәрергә, Камышлыга билгеләдек. Бу очраклы хәл түгел. Аңа, күрсәткән хезмәтләрен искә алып, Республиканың атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре дигән мактаулы исем дә бирелде. Хәзер шуны тапшырырга рөхсәт итегез.

Тукбаевны, көчле кул чабулар астында котлап Фәрзи Морзаевич аның кулын кысты.

—Дөрестән дә,—диде Тукбаев, җавап нотыгы тотып,—бу минем өчен зур исем. Монда бөтен районның да өлеше кергән дип әйтәсе килә. Моны мина авансом бирелгән дип әйтсәң дә ярыйдыр. Мин республика җитәкчеләренә рәхмәтемне белдерәм...

Фәрзи Морзаевич бераз тын торып сулышын алгач, янә болай дип игълан итте:

—Дәүләтхан Бариевичның Рәсим Юлаевич урынына беренче кандидатурасы Динар Хамаевич сез булдыгыз!.. Мин ышанам, байтирәклеләргә вәгъдә иткәнегезчә, районыгыз тирә-як районнары арасында алдынгылар рәтендә барыр. Уңышлар сезгә!..

Ишкәев, тизрәк үзен күрсәтергә теләгәндәй, ялт торып басты, залдагы халыкка карады һәм, Фәрзи Морзаевичның мөнбәрдән төшкәнен дә көтмичә, сәхнәгә юнәлде. Сәхнәдәге ут яктысында аның пеләш башы яктырып-яктырып алды.

—Мин, иптәшләр,—диде ул, «мин»гә аеруча басым ясап,—үземә күрсәтелгән ышанычны аклар өчен, бөтен көчемне куярга тырышачакмын... Һәм ул алдан ук әзерләгән сүзләрен кәгазьдән укып китте:—Иптәшләр! Бүген Рәсим Юлаевичны озатканда шуны әйтәсем килә. Бөтен кешегә дә андый бәхет тәтеми. Монда Рәсим Юлаевич хакимият башлыгы булганнан соң аны иң артта калган, иң авыр районга җибәрү—бу инде аңа зур җаваплылыкны ышанып тапшыру дигән сүз...

—Бер Байтирәк авылыннан район ясаган кешегә тагын да зуррак бурыч йөкләнелә,—диде Ишкәев, дәвам итеп. Сез, Рәсим Юлаевич, бай тәҗрибәгә, киң эрудициягә ия! Заманыбыз җитәкчесенең матур үрнәген гәүдәләндерәсез. Яңа эшегездә яңа җиңүләргә ирешүегезне телибез...

Чыгышлардан соң, алдынгыларга бүләкләр тараткач, концерт башланды... Клубтан чыкканда, Нәфиснең кәефе кырылган иде. Ул Ишкәев белән эшләү тагын да авыр булачагын белә иде. Түрәләр чит ил машиналарына төялеп күл буендагы «Чишмәлек»кә китеп барганнарын ризасыз гына күзәтеп калды.

## «Мәзәкләр яз!»

Нәфиснең йөрәгенә тагын ут капты. Бу юлысы анын ялкыны Чутый Бараев сызган шырпыдан кабынып китте бугай һәм бар җанын айкап алды, бөтен тынычлыгын качырды. Корректор Фираяны эштән кыскарту мондый шау-шу куптарыр дип һич тә уйламаган иде ул.

Чутыйныкыларга шул җитә калды. Район прокуроры бүген адвокат ролен башкара, милиция нәчәлниге хатыны Фирая мәнфәгатьләрен яклый, туганы Тәкәев кушканнарны үти. Ул инде мондый үчле эшләрдә шомарган, кемне ничек батырырга, кемнең бәгыренә төшеп интектерергә икәнен яхшы белә. Инде башына уй төшкән Нәфискә, хаклымы ул, хаксызмы, өчәр тиен өчен дә аклану кыенлашты, гәрчә янәшәсендә миллионнарны үзләштерүчеләр йөрсә дә. Аларга берни юк, алар һаман да почетта, мактауга күмелгән. Чутый да шулар мәнфәгатен якларга ике куллап әзер тора. Нәфискә килгәндә, киресенчә, мөхәррир өметсез, анын алырдай бете дә юк, ул алар өчен авырткан теш, аны бүтән комачауламасын өчен алып ташларга кирәк...

Нәфис власть тәгәрмәченең үзенә каршы әйләнә башлавын тиз сизде. Прокуратура хезмәткәрләре редакция эшен тикшерергә килеп тә житте. Хатанлатмалар алынды. Бухгалтериядагы акчага, килешү кәгазьләрләренә бәйле документлар энәсеннән җебенә кадәр тикшерелде. Ишкәев тарафыннан гаеп табарга дип күрсәтмә бирелгән.

Клубта икътисади конференция башлануын көтеп утырган Нәфиснең төрле-төрле уйлардан башы каткан иде.

Менә Ишкәев залдагы халыкны күзәтеп алды да җыелышны башлап җибәрде.

—Иптәшләр!—диде ул, партия мәктәбендә туплаган тәҗрибәсен эшкә җигеп.—Мин бүген сүзне экономика турында алып барачакмын, аннан башка тәртип юк. Фермаларына барсаң, керә торган түгел. Керсәң, үгез белән сыерны таный торган түгел, ашарларына юк... Мондый хәл район оешмаларына керсәң дә күзәтелә: беркемне табып булмый. Житәкченең өстәлендә ике стакан калган, үзе юк. Булмә тынчыган...

Ишкәев хокук саклаучылар адресына тәнкыйть яудырды, аннан «Акъяр» хуҗалыгы житәкчелеген «сәнәккә» алды.

—Егылып китәрлек әйберләр бар,—диде ул, тавышын көчәйтә төшеп.—Мин беркөнне Акъярга барып төштем. Карыйм, дуңгыз фермасына машиналар агыла. Жиде жинел машина кереп китте. Мин барганны берәү күрде дә, атлы арбасыннан сикереп төшеп, фермадагыларга хәбәр салды, шуннан машиналарның бер-икесе чыгып качты. Фермага керсәм, шунда ит төяп яталар, бернинди язусыз. Завферма аклана, колхоз рәисе бернәрсә белми. Бухгалтер кулы юк, бернинди акт төзелмәгән. Кесәдән телефонны чыгарып, милиция чакыртырга туры килде... Бу нинди хәл?

Ун житәкчене алыштырсак алыштырабыз, барыбер дә табачакбыз тиешле җитәкчене... Әгәр дә кешенең йөрәге, менә эшлим дип тормаса, баш мие белән ике арада, ягъни йөрәк белән связь булмаса, ул бәндә беркайчан да эшләми. Хуҗалык житәкчеләре, сынykka сылтау итеп, эт—эткә, эт—койрыкка, дип яшәргә өйрәнгәннәр. Белегез, Байтирәкнең бюджетына акча керер урын юк дип, беркем дә китереп бирми. Ярый ла Рәсим Юлаевич безгә, үзенең бөкресен чыгарып, һаман да көне-төне чабып, акча юнәтү артыннан йөри иде. Ул тапса табыла, ул тапмаса—юк. Миннән аны көтмәгез... «Үзән» совхозы директорын алыштырдык бит. Эш аннан башка да бара. Хәзер ул, эш бирмиләр, дип үпкәләп йөргән була. Мин аек кешене арт ягына тибеп чыгарып, исерек кешене агробанк управляющие урынына ала алмыйм бит...

Ишкәев шактый җитәкчеләрне сүгеп, «эшкәртеп» чыккач, бер мәлгә тынып калды, ялт-йолт каранып, арткы рәттәгеләрне күзәтте, карашы Нәфисне капшап узды һәм ул, дипломатия сакларга тырышкандай, сүзен дәвам итте:

—Менә мин бүгенге көнне җитәкчеләр арасында булган үзара мөнәсәбәтләрдән, шау-шулардан канәгать түгел. Шул ук вакытта «Байтирәк хәбәрләре» редакторының эше, тәртибе дә мине һич канәгатьләндерми. Мин аны аңлый алмыйм, ул үзе дә анларга теләми. Бәлки, сезгә дә шулайдыр... Редактор тәнкыйть язудан, кешеләрне мыскыл итүдән туктарга тиеш,—дип дәвам итте Ишкәев, нәфрәтен залга чәчеп.—Ул бу эшкә нокта куярга тиеш. Тагын музей турында язган булып, ул мәкаләне шәхси бер кешедән көлү өчен эшләргә тиеш түгел. Мин моны район җитәкчесе буларак әйтергә тиеш. Районда унбиш меңгә якын халык бар, алар безгә карап торалар, газетада чыккан мәкаләләргә карап бәя бирәләр...

Газетада халыкның күңеленә хуш килә торган, аның хезмәтен яктырта торган, хезмәт белән горурлана торган алдынгылар турында мәкаләләр язарга кирәк. Бу кеше,—дип дәвам итте Ишкәев, икенче ияген кабарта төшеп,—журналист та булырга тиеш түгел, ул үзе кул күтәреп китәргә тиеш...

Бу сүзләр Нәфиснең яңагына суккандай яңгырады. Ярсына төшкән Ишкәев моның белән генә чикләнмәде.

—Мин хәтерлим әле,—диде ул дәвам итеп,—партия вакытларындагы редакторларның авторитетын. Беренче урында—райком секретареныкы, аннан прокурорныкы, милиция начальнигыныкы, дүртенчесе—редакторныкы санала иде. Шулай бит, Маннур Мансурович?

Элекке райком секретаре, хәзер «Алпар» колхозы рәисе үзенә булган мөрәҗәгатьне тиз кабул итте.

—Так точно!—диде.

—Иң ихтирам ителә торган кешеләрнең берсе иде ул редактор,—дип дәвам итте Ишкәев.—Абага районында бүген дә шулай ул. Мин бүльнистә ятканда «Абага таңнары» газетасы редакторының мәзәкләрен укыдым. Әле аның яртысы гына чыккан. Мәзәкләр язгыз сез, Нәфис абый, әгәр дә хәлегездән килә торган булса...—Һәм ул соңгы сүзенә басым ясады.—Бүген кайткач, нәтиҗә ясап, уйланырга тиешсез...

Ишкәев тиешле кешеләрен иләктән иләп торгач, икътисади конференциягә җыелганлыкны, анализлар ясарга кирәклекне онытып, сүзен болай дип тәмамлады:

—Әгәр кемнең дә булса сораулары, сөйләр сүзе юк икән, таралырга мөмкин. Хуҗалык җитәкчеләре монда кала.

***

Нәфис аквариумга карап утыра. Анда кызыл саңаклы, тукмак башлы балык аксыл канатлы кечерәк балыкның әле бер, әле икенче ягыннан килеп чукый да йөз сиксән градуска борылып койрыгын болгый. Аның бу һөҗүмен күзәткәнваграк балыклар да, куанып, кызыл саңак артыннан ияр. Аларга ни җитми?! Юкса һәммәсенә бер үк мохит—яшел үләннәр үсеп утырган комлы, чуерташлы су асты «дөньясы». Ашарларына җим сибелгән, суларына кислород өрдергән, яктылык төшкән. Һәммәсе табигый төсләрендә балкый, рәхәтләнеп яшә, бар булган дөньяң белән хозурлан!.. Ә юк, үз өстенлеген сизгән балыкның моның белән генә килешәсе килми. Һаман да корбанын эзли, уктай атылып йөзә-йөзә дә чукып ала. Аннан, койрыгы белән буран уйнатып, читкә тайпыла, тукмак башын горур калкытып өскә чыга. Янәсе, күрегез, бу—мин! Көчленеке замана!..

## Чарасызлык

Ишкәевнең карары катгый иде: «Кит! Китмәсәң, куып җибәрәбез...»

Нәфис монын белән һич тә килешә алмады. Редакция эшен нольдән башла да, ни гомерләр азапланып эшлә һәм сине яраксызга чыгарсыннар... Үзең атказанган мәдәният хезмәткәре исемен күтәреп йөр һәм син, башыңны иеп, эшеңнән китеп бар. Тыңлаучан бул, Ишкәевкә каршы килмә...

Вакыт дигәнең Нәфис файдасына эшләми. Район сессиясе карары һәм аның дәрәҗәсен пычраткан төрле ташланулар матбугат министрына барып ирешкәнче аңа ничек тә чираттагы ялга китеп барырга дигән гаризага Сәет Әскәровичтан кул куйдырырга кирәк.

Шушы уе аны министрлыкка алып килде. Бәхеткә, шефның кәефе шәп чак туры килде. Сәет Әскәрович, аны-моны сорашып тормыйча, гаризага «рөхсәт» дигән имзасын салды. Нәфис министр бүлмәсеннән куанып чыкты...

Ул өенә кайтып кергәндә йөзенә кәеф күтәренкелеген чыгарырга тырышты.

—Менә мин кайттым,—диде ул, гадәтенчә, Сәриягә елмаерга тырышып.

—Күрәм,—диде Сәрия иренең йөзендә юкка чыкмаган борчуларны сизеп, аннан бүтән сүз әйтмәде.

Нәфис дипломатын читкәрәк куеп чишенде, аннан кухняга узды һәм хатыныннан сорады.

—Ашарга бармы?

—Аш бар,—диде Сәрия.—Җылытып бирimme?

—Бир.

Сәрия суыткычтан кәстрүлне алгач сорап куйды.

—Авыл ите алып кайтмагансыңдыр?

Нәфис сорауга теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

—Юк...—Ул тынып калды, аннан өстәде.—Итне базардан гына сатып алырбыз инде...

Сәрия иренең нәрсәнедер әйтеп бетермәвен аңлады.

—Эшеңдә берәр хәл булмагандыр бит?—диде ул, газ кабызып.

—Булды,—диде Нәфис авырыксынып. —Мине эштән куарга җыеналар...

—Әйбәт булган...—диде Сәрия, бер дә исе китмичә генә һәм кәстрүлне шап иттереп янган газ өстенә куйды. Хатын, җавабны өнәмичә тыныч кына сүзен дәвам итте.

—Кусалар, кайгырма, гаиләң янына кайтырсың. Байтирәктә интегеп йөрмәскә вакыт җиткәндер. Китмә шунда дип күпме әйттек, тыңламадың. Ишетәсең дә килмәде...—диде.

Уйларыннан башы каткан Нәфис тора торып сорады.

—Дәшми-нитми генә китеп барыргамы?

Сәрия аңа гаҗәпләнеп карады.

—Әле син алар белән көрәшмәкче дә буласыңмыни?

—Синеңчә, «үз теләгем» белән гариза язып китеп барыргамы? Көрәшмәгән үзе егыла...

—Көрәшеп җиңәрмен дип уйлыйсыңмы? Алар власть кешесе...

—Матбугат та властька керә...

Сәрия, әллә син җүләр инде дигәндәй, чак көлеп җибәрмәде.

—Син шуңа ышанасыңмы? Кайчан булганы бар?! Партия заманыннан калган икейөзлелек битлеге генә ул. Кемнең газетага язып гаделлек тапканы бар? Хәзер барысын акча хәл итә. Күрмисеңме, журналистларны атлаган

саен үтереп торалар, үтерүчене жүнләп эзләмиләр дә һәм ул властька да кирәкми.

Сәрия тәлинкәгә аш салды да, ачулы итеп:

—Мә, аша!—диде.

—Кашык та бир инде!

—Алдыңда бит, күрмисеңмени?

—Ә-ә, алай икән,—диде Нәфис, өстәлдәге кашыкка үрелеп.—Әллә күзләр дә күрми башлады инде?

—Кирәкмәгәнне күрәсең, шуңа үзеңне яратмыйлар...—диде Сәрия, төрттереп.

—Мина нишләргә соң?—диде Нәфис, аштан авыз итеп.—Дәм сукыр, чукрак һәм телсез булыргамы?

—Сукыр булма, тик алгарак карый бел. Алгарак карый белгән булсаң, урының өстәрәк тә булыр иде. Әнә шул депутатлар шикелле президент тирәсендәрәк... Гаиләңә дә күпме файдалы эш эшли алган булыр идең. Ә хәзер...—Сәрия, үзен бәхетсез сизгәндәй, рәнжеп алды.— Күпме энергия түктең, саулыгыңны югалттың. Өстәвенә минекен дә бетердең... Син мине теге вакытта аңламадың. Заводта, компьютерда эшләмәгән өчен, баш механик Закиров миңа күпме үчләнеп йөрде, премияләрдән коры калдырды. Шуннан үрнәк алып, барысы да кырын карап йөри башлады. Тере килеш тотып ашарга әзерләр иде... Заводтан китә алмадым. Син эш табып бирмәдең. Сиңа барыбыр иде. Хәзер шундый ук хәл үз башыңа төште...—Зыяннан башка бернәрсәгә дә ирешә алмадың. Зыяннарың безгә дә төште сүз тыңламагач. Үҗәтлегең, кирелегең менә нәрсәгә китереп житкерде.

Нәфис акылына килгәндәй дәшмәде, хатынын кызгана төште.

—И-и, жүләр дә инде син,—диде Сәрия, бераз тынычлангач.—Әйтәм бит, алар власть кешесе, аларны сайлап куйганнар, яклаучылары бар. Син кая язсаң да файдасыз. Стенага борчак сибеп утырудан ни файда? Аңа карап, барыбер, штукатур коелмый...

Нәфис килешмәгәндәй әйтеп куйды.

—Тамчы тама-тама ташны да тишә, ди халык.

Сәрия янә, тинтәк икәнсең дигәндәй, гажәпсенде.

—Син башта тамчы булып кара! Син—тузан бөртеге генә әле, өрсәң, очып китә торган.

—Кимсетмә инде.

—Кимсетмим, дөресен әйтәм. Хыялый булма дим. Нәрсә исбатларга телисең? Син—берүзең, шуның өстенә акчасыз. Хәерче. Хәерче кеше кемгә кирәк? Аңардан йөз чөерәләр. Ә алар акчалы. Акчалы чиновниклар төрмәгә дә утырмый, теләсә кемне сатып ала. Бу дөньяда акчага сатылмаган кеше бармы? Булса, табып күрсәт берәрсең?

—Табам.

—Йә, кем бар?

—Академик Сахаров.

—Ул илләр масштабында танылган галим. Аны да ничек интектерделәр.

—Беләм...

—Белгәч?! Алар синең белән сөйләшмиләр дә. Чөнки синнән берни алырлык түгел, бернәрсәң дә юк. Гонорарың да сукыр бер тиен...—Ул, ире белән берәр нәрсә эшләмәгәйләре дип, эчтән курку кичерде.—Алар кеше үтереп тә чиста кала. Әнә төзелештә кран авып ике кеше үлде, берсе түбәдән егылып төште. Йә, кемне гаепләделәр? Кран төзек булмаган, диделәр дә шуның белән эш бетте. Чөнки төзелешне чиновник кора. Гаепләргә

«дәлилләр» юк. Шуннан соң эзләп кара гаделлекне?! Бездә кирәк кешене башлык итеп сайлар өчен булган законнарны да үзгәртеп язалар. Ә син алар өчен бер кирәкмәс бөҗәк кенә, сине сытып, изеп китү берни тормый... Үз тормышың турында уйла.

Нәфис, кәефе кырылып, кулындагы кашыгын читкә куйды.

—Алар да әллә кем түгел, ялган сәясәттә уйнаучы бер төркем караклар гына.

—Урласыннар,—диде Сәрия, каршы килеп.—Ул сиңа кирәкми. Күрмә. Урлаганнар, урлыйлар, урлаячаклар. Миллионнарны урласалар да, аларныкы күренми, синең бер тиенең дә күренә...

—Нәрсә, миңа аларның кем икәнен күрә торып, яраклашырга кирәк идеме?

—Ә нигә? Бәлки, кирәк тә булгандыр...

—Моны һәркем дә булдыра алмый, холкыңны үзгәртү кыен...

—Кешеләр ничек үзгәртә? Кирәк булгач, кырык төрлегә керәләр. Аның дөньясы шундый...

Нәфис Сәриясенә гаҗәпсенеп карады. Аңардан моңарчы ишетмәгәнне ишетте. Сүзләрендә бүгенге тормыш реальлеге ятканын сизеп, бәхәскә кермәде, күңелендә тулганнарын бераз бушатсын дип уйлады. Аның үзенә дә борчуларын таратыр, киңәшер кеше кирәк иде. Нәфис, ашау үтмәгәндәй, кире кашыгына үрелмәде. Аптырап калды.

—Эштән җинелеп китү гарьлек бит,—диде.—Аннары прицип дигән нәрсә дә бар...

—Принцип?!—Сәрия, аңламасаң анламассың икән дигәндәй, аны элеп алды.—Син принципларыңны читкә куеп тор, алар сине теге дөньяга алып китмәсен... Машинада бәрдереп китүләре дә бар, гомер буе авыру булып, кеше өстендә калсаң нишләрсең? Нинди заманда яшәгәнеңне бел!..

—Беләм...

—Белгәч... Син безне дә уйла. Йөрмә үзеңне яхшылап өйрәткәннәрен көтеп, кайт монда. Әйтәсең бит, берәүне машина белән бәрдереп киттеләр дә больницага илткәндә авызына аракы койганнар һәм, машина астына үзе килеп керде дип, «дога» кылганнар дисең... Азмы шундыйлар? Шәһәр белән район арасында, тилебәрән орлыгы ашагандай, әйләнчек сарык булып йөрмә. Кайт та кирәген эшлә...

Сәрия өстәлгә чәй куйды. Нәфис чәенә җиләк вареньесы салып болгата башлады.

Чәй эчеп утырганда, кызлары Көләч кайтып керде.

—О-о, әти кайткан!..—диде кызы, куанып.—Ни хәлләрдә син?

—Әйбәт.—Нәфиснең йөзе электәгечә ачылып китә алмады.

Көләч әтисенең күңел төшенкелеген тиз сизеп алды.

—Әти, сиңа нәрсә булды?

Җавапны Сәрия бирде.

—Әтиеңне эштән куалар.

—Чынлапмы?

—Әйе...

Көләч шулай диюгә, дәшми генә түргә узды һәм, озак та тормый, әйләнеп чыкты.

—Менә минем гариза,—диде ул, кәгазь битен өстәлгә куеп.—Иртәгедән мине эштән азат ит... Йөрмә алар белән вакланып.

Нәфис дәшмәде. Гаризаны читкәрәк алып куйды.

—Укуың барамы соң?

—Бара. Минем өчен борчылма син әти...

Көләч шулай дигәч тагын бүлмәсенә узды. Сәрия бу турыдагы сөйләшүне

түгәрәкләргә ашыкты.

—Әйдә, чәенне эчеп бетер дә аннары базарга барып килерсен,—диде һәм иренә сатып аласы ашамлыкларны санады да Нәфисне ишектән озатып калганда өстәде.—Миңа алма да, җимеш тә ал...

—Ярар,—диде Нәфис, йөрәк чиреннән интеккән хатыны белән килешеп.

Сәрия аның артыннан ишекне бикләп калды.

## «Какма кеше капкасын...»

Чираттагы ялына чыккан Нәфисне телефоннан эзләтеп, көндезге унбердә редакция коллективы белән бергә эш урынында булырга куштылар. Димәк, Ишкәев мөхәррирне ничек эштән азат итү чарасын планлаштырган. Бу миссияне үтәүне министр үз өстенә алгандыр дип фаразлады ул.

Сәгать унбергә редакциягә килергә тиешле министр Ишкәев кабинетында тоткарланды. Бергә киңәшләшеп чәйләр эчкәч, сәгать икедә генә, кадрлар бүлеге начальнигын һәм юристын ияртеп, Байтирәк районы аппараты җитәкчесе Тәкәев белән берлектә, редакциягә килеп керделәр.

Тулы бер делегация редакция бинасын карап чыккач, кызыл галстуклы, ыспай гына киенгән министр Сәет Әскәрович ялтыравыклы очлы ботинкалары белән түргә узды һәм бер урында таптанып сөйләп китте.

—Да,—диде ул, коллективка мөрәҗәгать итеп,—суверенитет игълан ителгәч, Республиканың картасына кайбер үзгәрешләр кертелде. Яңа административ бүленешләр барлыкка килде, шул исәптән Байтирәк районында да. Әлбәттә инде, район булгач аның үз атрибутлары да булырга тиеш. Ул атрибутларның берсе—район газетасы. Һәм менә Байтирәктә редакция оешып китте. Бүгенге көндә газета начармы, яхшымы, дөнья күреп килә.

Без монда иң әүвәл бисмилла рәвешендә редакция хезмәткәрләре сүзен игътибар белән тынларга теләр идек. Аннан соң үзебезнең фикерләрне җиткерергә ниятлибез. Ничегрәк яшисез?. Иҗат атмосферасы хакында нindирәк фикер йөртеп була? Язалармы? Язмыйлармы? Менә шушы бинада без эчкерсез сөйләшү алып барырга тиешбез. Әйдәгез, кайсыгыздан сүзне башлыйбыз? Финанс ягыннанмы?!

Бухгалтер Фәнзия нәрсә дип әйтергә белми торып басты.

—Быел сезгә күпме финанс каралган иде?—диде министр.

—Өч йөз дә биш мең,—диде Фәнзия.

—Бүгенгесе көндә күпме финансланган?

—Ике йөз дә бер мең.

—Сез ничек, сопряжениедә барасызмы?

—Әйе,—диде Фәнзия «сопряжение» дигән сүзнең мәгънәсен аңлар-аңламас.—Безнең типография чыгымнары күп, шуңа кыен. Газетаны шәһәр типографиясендә бастыру кыйммәткә төшә.

—Бу хәлдән чыгу мөмкинлеге бармы?

—Компьютерлар, җиһазлар алсак булыр иде...

—Ә нигә алмыйсыз? Сезгә бездән зур акчалар бирелде.

Фәнзия, ул акчаларны безнең күргән юк дигәндәй, башын аска таба иде.

—Юк, монда карашны читкә алырга кирәкми. Узган ел гына без сезгә ике миллион тугыз йөз мең сум акча бирдек, аңарчы да биргән идек. Моның кадәр акчаны министрлыкның бер генә районга да биргәне юк. Һәм моны бер генә министрлык та бирә алмый. Ә нигә ул акчаларны редакторыгыз белән бергәләп юлламыйсыз.

Шушы урында Нәфиснең сабырлыгы төкәнде. Ул акчаларның күптән җилгә очуын, бурыч капларга дигән сылтау белән икенче көнне үк каядыр күчерелгәнен чамалап болай дип аңлатты.

—Ул акчаларны безгә бирмәделәр...

—Анысын белмим,—диде Сәет Әскәрович, гәрчә акчалар язмышын яхшы белсә дә.—Ә ни өчен бирмиләр? Сезгә диелгән бит ул...

—Безгә бирелсә, акчалар редакция счетына күчерелер иде. Дөрес, ул акчалар райфинга кайткан, аннан кая киткәндер... Формально, ул акчаларны колхоз-совхозларга «биреп» торырга дип, алты айдан кайтарып бирү шарты белән үзара килешүләр төзелде.

—Аларын мин белмим,—диде министр, Нәфиснең тешләкләнүен ошатмыйча.—Сез ни өчен редактор?..—Ул җитдиләнә төште.—Сез, теге, кем әйтмешли, сессия тарафыннан куелган, расланган кеше. Әгәр дә редактор икән, редактор должен добиваться... Редактор моны сессиягә куярга тиеш, редактор моны чакырып алырга тиеш, редактор моны әйтергә тиеш, әйеме?!

—Тиешен тиеш тә...—диде Нәфис, министрның юкны исбатларга тырышуын күреп, тик тегесе аның сүзен ишетмәмешкә салышып дәвам итте:

—Шуның хәтле акча керсен дә...—диде ул, кызып.—Әгәр дә сез бөтенесен «Аллаһы әкбәр!» дип көн узсынга кул кушырып утырсагыз, йә булмаса, амин кылырга килешсәгез, әлбәттә, беркем дә бирмәячәк...

Нәфис шуны аңлады: Сәет Әскәрович инде кичәге кеше түгел, ул үзгәргән иде.

—Финансны җайлауның нинди юллары бар?—диде министр бухгалтерга.

—Подписка күбрәк булса гына инде...—диде Фәнзия.

—Тираж күпме?

—Ике мең.

—Ике мең тираж белән ерак китеп булмый,—диде министр һәм башка район газеталары тиражын мисалга китерде. Аннан журналист Факилгә мөрәҗәгать итте.—Сезнең исемегез ничек?

—Факил.

—Сездә җыелышлар буламы? Летучкалар. Дөресен әйтегез!

—Була...

—Сез редакция эше турында нинди фикердә? Сезгә мондагы атмосфера ошыймы?

—Аның объектив сәбәпләре бар инде... Компьютерлар булмау, сиксән чакрымга калага барып газета чыгару мәшәкатьләре. Анда ике көн вакыт әрәм була. Аннары атнага бер тапкыр гына газета чыгару оперативлыкны югалта...

—Ну, компьютер үзе язмый бит. Әллә пассивлык та борчыймы? Яки башкалар?.. Айга күпме хат килә?

—Утыз-кырыклап...

—Күпер юк халык белән,—диде министр, аның сүзен элеп алып.—Халыкка сез ниндидер, теге, кармак салмыйсыз, үткенрәк, кызыклы мәкаләләр язып. Ул чагында иртәгә үк, кимендә, алтмышлап хат килер иде. Кузгатырга кирәк халык күңелләрен, битараф булмаслык итеп, менә теге кырмыска оясына таяк тыгып бутыйлар бит әле, шулай...

Чират Нәфискә җитте.

—Йә, сөйлә үзең,—диде Сәет Әскәрович, төз буй-сынына ятып торган костюм-чалбарын каккалап, шул ук вакытта ялтыравыклы очлы башлы ботинкалар да биеп алды.

—Мин нәрсә әйтим?!—диде Нәфис, урыныннан торып.—Дөрес, газета калада атнага бер чыга. Бүгенгесе көндә фәкать унөч мең генә халкы булган кечкенә районга газетаның атнага бер тапкыр чыгуы да житә дип уйлыйм. Әле бер тапкыр чыгарып та акчасын күчерергә теләмиләр. Аннары без компьютер, тиешле җиһазлары булмагач, башка районнар кебек газетаны үзебездә макетлап, типографиягә электрон юл белән тапшыра алмыйбыз. Болар сыйфатка да суга, вакытны да ала. Газета вакытында чыкмый дигән сүз ул дөрес түгел...

Нәфискә ачу белән текәлгән Тәкәев түзмәде.

—Безнең газетаны финанслау мәсьәләсендә тоткарлык булганы юк,—диде ул, акланып.—Нәфис Хаков үзе кала юлыннан кайтып керә алмый...

—Алдашмагыз инде,—диде Нәфис, Тәкәевкә таба борылып һәм басылган газеталарны складтан ник бирмәүләрен әйтте, типографиягә күпме бурыч барлыгын раслаган кәгазен чыгарып күрсәтте.—Менә документ, монда күпме акча тиешлеге язылган, пичәт куелган...

Тәкәев кара көеп авызын йомды.

—Менә сез, Сәет Әскәрович,—диде Нәфис, сүзен дәвам итеп.—Акчаларны типография өчен ике тапкыр бирдек дидегез. Беренчесе миллиард ярым сум иде, анысы иске акча белән исәпләп, икенчесе ике миллион тугыз йөз мең сум. Хәзер акчалар да юк, типография дә, компьютерлар да алынмаган. Мин, ул акчаларны сорап, район башлыгына хат та яздым. Аңардан мәгънә чыкмады. Акчаларның җилгә очуын белә торып, мин хәзер глава белән сугышырга тиешме? Болай да тырнак астыннан кер эзләү китте, Байтирәктән ничек куарга белмиләр. Уйлавымча, сезнең бирегә сәяхәтегез дә тикмәгә түгел, мине эштән азат итеп, аларга булышу өчен...

Министр шунда ук Нәфисне бүлдерде:

—Алай түгел! Гафу ит, мин монда әрепләшергә килмәдем. Мин үз фикеремне генә әйтәм. Минем өчен газета—көзге, мин ул көзгедә беркемне дә таный алмыйм. Нәфис түгел, хет Шолохов дисәләр дә мин әйтәчәкмен: «Нинди газета соң бу?»—дип. Алама чыгамы? Чыга! Дилбегәне нык тотмыйсың... Башканы әйтмим.

—Газетаның кай җире алама?—диде Нәфис, ризалашмыйча.

Нәфискә министрның иярченнәре текәлде, янәсе, шеф белән сүз көрәштермә!

—Болай булмый,—дип дәвам итте Сәет Әскәрович.—Ул акчаларны ике мәртәбә биргәнбез икән, сезне коллегиягә куябыз...

—Куегыз, мин ул акчаларны кесәмә салмаган...

—Әгәр компьютер дисез икән, әйтәм бит, компьютер үзе язмый ул, компьютерсыз да эшләп була. Димәк ки, монда хакимият белән ике арадагы гайкалар бушаган дип әйтимме, или ике арадагы гайкалар артык кысылганнар... Чөнки сездә газетаны гамәлгә куйган учредитель белән редакция арасында мөнәсәбәтләр кискенләшкән. Монда үзеңә тәнкыйть күзлегеннән карарга кирәктер. Гафу ит, соңгы вакытта жалобалар да күбәеп китте.

—Коллективта барысы да ишетелә. Редакция машинасын үзеңә оформить иткәнсең.

—Дөрес түгел,—диде Нәфис, инкяр итеп.—Мин ул машинаны, глава үзе тәкъдим иткәч, сатып алдым.

—Газетаны сайлау алдыннан атнага бер генә чыгарып хур булабыз. Немедленно атнага ике чыгарырга кирәк. Аның өчен...—Ул тагын пауза ясады.—Кайнап тора торган бүтән җитәкче кирәк...

Министр бу сүзләре белән Нәфиснең яңагына чалтыраткандай итте һәм ул редакция хезмәткәрләренә бүлмәдән чыгып торырга кушты. Бүлмәдә

иярченнәре белән калгач, ул, уртак фикергә килергә теләп, Нәфискә текәлде.

—Нишлибез?—диде.

—Эшлибез...—диде Нәфис, тыныч кына.

—Юк, булмый. Гариза яз!..

—Нәрсә дип?

—Эштән китәргә... Редактор замы булып күчәрсең, редакциядә әдәби түгәрәк оештырып җибәрерсең. Монда яңа канлы кеше кирәк...

—Минем кан бозыкмыни?! Ул диагнозны кем куйды?

—Эш анда түгел.

—Нәрсәдә соң?

Сәет Әскәровичнын ачуы кабарды.

—Аңлаштык бит. Короче, нишлисең?

—Уйларга кирәк...

—Безнең уйлап торырга вакыт юк...

—Мин отпускада бит әле...

—Сезне ялга җибәрү минем ялгышлык булды... Анысы ярар, кайчан эшкә чыгасың?

—Унсигез көннән.

—Эшкә чыгасы көненнән гариза яз!..

Нәфис айнып киткәндәй булды. «Тукта әле, мин нишләгән? Урлап тотылганмы? Берәр яманлык кылганмы? Ничә ел эшләп, хәзер Ишкәевкә ошамыйм дип, кул күтәреп китимме? Үз мөхәррирен яклый белмәгән министр Ишкәев каршында яхшатлы булып калсын өченме? Юк инде, ничек теләсәгез, шулай азат итегез...»

—Юк, алай булмый, мин үлмәс борын үз-үземә ясин чыга алмыйм,—диде Нәфис.

Министр янә кабарынды, бүртенде.

—Яхшы! Язмыйсың икән, мин сиңа бүген бер ялгышың—өтерең өчен бер выговор биреп китәм, киләсе атнага икенчесен, өченчесендә увольняю. Мин профессиональ журналист, миңа синең газетадагы хатаны табар өчен унбиш минут җитә... Монда КЗОТ дигән нәрсә дә бар. Син бөтен кануннардан читләшәсең...

—Гаепле икән, судка бирсеннәр.

—Мин сиңа бала-чага түгел. Мин хөкүмәт кешесе, кем белән эш итүегезне онытмагыз,—диде ул «Сез!»гә күчеп һәм иярченнәренә ишарәләде.—Чакырыгыз әле монда бухгалтерны?

Йөзе агарынган Фәнзия шунда ук кереп житте.

—Миңа,—диде Сәет Әскарович,—бүген үк бухгалтерия документларын җибәрегез...—Һәм ул Нәфискә ишарәләде.—Документларда биш сум гына чагышмаса да күрерсең аннары.

—Мин күрәсен кеше күрмәс...

## Дәвам

Нәфис Байтирәкнең юл чатында тукталып калды. Нигәдер аңа бүген игътибар итүче, элеккеге шикелле якын итеп исәнләшүче дә күренмәде кебек. Ул үзен урталыкта калгандай сизде. Хаклык көткән уйлары һаман да җанын тынгысызлый. Ул аларны читкә куарга, бөтенләйгә арынырга теләде һәм кая китеп барырга белмичә аптырап торды. Судта анын дәлилләрен ишетергә теләмәделәр. Суд системасында нинди «хаклык» хөкем сөргәнлегенә ныклап инанды... Хәер, юкса шушы юл чатыннан Тукбаев та, сатып алган Байтирәгем түгел дия-дия, Камышлыга китеп барган иде. Ишкәев исә Сәет

Әскәровичны яхшылап сыйлап, шушыннан, кабат очрашырга вәгъдәләр биреп, озатып калган. Әмма Нәфискә бер өтерең өчен дә мин сина шелтә бирәчәкмен, дип китеп барган министрга бирегә кайтырга насыйп булмады. Ул да эшеннән алынды, бер киткән жиреннән бөтенләй килмәслек итеп китеп барды. Ишкаев кенә, Байтирәктә мөхәррирдән куркып яшәү бетте, дип, канат яра... кайчанга кадәрдер? Ул моннан кылган гөнаһлары өчен ирекле атлап үтәрме? Бәлки, ана да бу юл чатын читләп узарга туры килмәс. Аллагысын, акчалыга кемнең кулы житәрен кем белгән?..

Кинәт, һич уйламаганда, юл тузаннарын туздырып өермә чыкты. Бәйләнчек жил янәшәдәге агачларны бөгеп салды һәм бер яфракны өзеп аны айкый-чайкый һавада тибрәтте. Әйтерсен жил ниндидер бер явыз «жинаятьче»не колагыннан эләктереп алган да аны селки-селки бөтен дөньяга фаш итәргә тели. Шулай үз «корбанын» ташларга бәрә-суга суд бинасы ягына таба очырта. Нәфис вакытсыз өзелгән яфрактан күзләрен алмый торды. Әйтерсең анын үзен суд бинасына житәкләп алып баралар...

Жилдә—көч! Гүя ул власть тәгәрмәчен әйләндереп жибәргән диярсен—юлында очраганнарны аямый, таптап-сытып узарга әзер... Бу дөньяда мөмкин булмаган эшләр юктыр да ул. Ә бит тормыш дигәнең тегеләй дә, болай да көрәшеп дәвам итә. Кемдер гадел көрәшә, кемдер юк. Кемдер жинә, кемдер жинелә. Ничек кенә булмасын, Нәфис үзен жинелүче итеп санамады, түзде, жил басылуын көтеп торды һәм күнеле тарткан Акъярга таба китеп барды...

***

...Саумы, Акъярым! Син минем барлыгым да, бөтен яшәешем дә. Кайларга гына барсам да, нинди генә хәлләргә юлыксам да, мин һаман синеке булып калам. Мине шушы тауларын артыннан калыккан кояш нурлары иркәли, иртәгесе көнемә яшәү өметләре уята. Таулар горур, гүя алар авылымнын мәңгелек һәйкәле! Жир күчәре әнә шул тауларын аша үтәдер, ул әйләнә-әйләнә гомер сәгатьләрен саный, авылым сәхифәләрен язып барадыр кебек.

Акъярым! Мин синең тарту көченә буйсынам, серле тауларына карап сокланам. Тау өсләрендә ата-бабамнарның рухлары искән жилдәй очып йөри сыман. Кояшка ачылган күкрәгендә катлам-катлам ак ташлар ялтырый. Алар янгырлардан юылып шомарган. Кырлы ташларына кагылган жилләр бакый киткән жаннарның моңлы көйләрен искә төшергәндәй, бәгырьгә тиеп сагышлана. Ташлар сырлы-сырлы, буыннар шәжәрәсен сызып барганнар диярсен...

Жир сөреп, эштән арып кайткан бабамнар шушы тау иннәренә утырып чабатасын каккан, еллар тузанын койган. Салам түбәле кысан йортларына карап якты киләчәк турында хыялланган... Аннары алар тау астыннан аккан чишмәгә килеп сусауларын баскан, ярылган сөялле кулларын, битләрен юган. Көмештәй йөгерек суларга кушылып, уй-хисләре аккан, күңелдәге хатирәләре сүтелгән. Миңа ул чишмә сулары бабамнарның йөрәк тибешеннән бәреп чыккан күк. Аккан сулар кире кайтмый икән шул... Ә исәннәр, Акъярым, сиңа бер кайтмаса бер кайта. Мин дә бүген яланаяк чапкан сукмакларымнан йөгерәм, тауларына менәм. Менгән саен офыкларым киңәя, исән калган жаным канат кага. Мин үземне синең янәшәңдә генә бәхетле сизәм...



*Татар халкының бөек композиторы Нәҗип Җиһанов. 1981 ел.*



*Байрак күтәрү. Шанлы 90нчы еллар истәлеге.*




*Озак еллар «Казан утлары»нда эшләгән шагыйрь, мөхәррир Наис Гамбәрнең 50 еллык юбилеенда төшерелгән фоторәсем. 1997 ел.*



*Рәшит Гәрәй һәм Фәнзаман Баттал.*
*Минзәлә районы. 1964 ел.*



*Рәссам*
*Илдар Әхмәдиев.*



*Замандашлар. Сулдан уңга: Әхәт Гаффар, Данил Салихов,*
*Рафис Гыйззәтуллин. 1992 ел.*



Илдус
Диндаров

# Ә ГАСАБИ УЙЛАР БӨТЕРЕП АЛА...

## Тәсбих тартам

Төрек дустым дисбе бүләк итте
Шәһри Болгарында Иделнең.
«Безнең ара шуның сыман тыгыз,
Таралмаслык булсын», дидеме?

Таза җепкә ишен-ишкә тезгән,
Төймәләре—хөрмә төшеннән.
Кулга алган саен ирексездән
Үткәннәрне искә төшерәм.

Тәсбих тартам...
Ә гасаби уйлар
Бөтереп ала, һич тә җибәрми;
Күзаллыйм да кардәш халыкларны,
Барлап чыгам илләр... җирләрне.

Бер, ике... ун... Үзбәк... бусы казакъ...
Төймә саен—үзбаш дәүләт, ил...
Без генә юк шушы гаиләдә,
Һәркайсына юкса без дә тиң.

Читкә чәчелгәнбез гарасатта,
Өзелгән дә тарих чылбыры.
Югалмаган татар гасырларда,
Булгач иман, теле, моң-җыры...

Төрек дустым! Безнең арадашлык
Җитәр дә бит озак елларга,
Өзелеп төшкән бөҗраны менә
Шул чылбырга ничек ялгарга!?

Илдус ДИНДАРОВ—*шагыйрь, журналист; «Гомер фасылы» исемле китап авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Нурлатта яши.*

## Ярлыкау

*(2010 елның җәй челләсе)*

**Бар җиһанны эссе табасында**
**Кыздыра күк тәмуг утлары;**
**Гаҗизлектән аңгырайган авыл**
**Яңгыр көтүдән дә туктады.**
**Тузан өсләп тамчы-чык төшмәгән,**
**Кузлы көлдәй кайнар туфракка**
**Чак-чак басып, ындыр артлап кына**
**Бер ир кайтты.**
**Узды зиратка...**
**Ул икән ич яшьли нигез ташлап**
**Сукбайлыкка киткән Мөбарәк;**
**Ялгыз үлгән ана каберендә**
**Үксегән ди, ятып, тәгәрәп.**
**Мәрхүмәнең юлдан язган улын**
**Ярлыкавы әллә идеме:**
**Саран гына сибәләгән яңгыр**
**Изге җанның керсез, сабыр**
**Күз яшьләре булып түгелде...**

## Карлыгачлар бала очыра

**Тын кичләрдә ак түшләре белән**
**Агачларның орынып очына,**
**Яшь алмашның көчен сыный-сыный,**
**Карлыгачлар бала очыра.**

**Капка буйлап картлар утырганнар:**
**«Кара, болар ничек очына!»**
**Канат читен күл суына манчып**
**Карлыгачлар бала очыра.**

**Җәй бит әле, ник соң олы-кара**
**Уйчанлана, нидән борчыла?**
**Эшләре юк әмма кешеләрдә,**
**Карлыгачлар бала очыра.**

**Кошлар кузәткәндә уфтаналар:**
**Җиттек менә гомер очына...**
**Ерак юлга җыенырга вакыт,**
**Карлыгачлар бала очыра.**

**Ымсындыргыч бу җиһанда тагы**
**Их, яшәргә иде... очарга...**
**Әмма инде күңел юашланган—**
**Карлыгачлар бала очыра.**

## Җәйге манзара

**Бытбылдыклы арыш арасыннан**
**Боргаланган басу юллары...**
**Аккаеннар белән каймаланган,**
**Ал болытлы офык буйлары...**

Илаһи шул манзараны мәңге
Күңелемдә йөртсәм гаҗәпме?!
Төшләремдә, имеш, аералмыйм:
Туган җиремме бу? Җәннәтме?

## Сабантуй

Сабан туен күрдем бер шәһәрнең,
Парк уртасында—мәйданы.
...Мәҗлес кызгач, агач башларыннан
Бер шом узды сыман. Аннары
Кабат-кабат чаң кактылар—набат!—
Ярылырлык итеп күк йөзе!
Тилгән күргән тавык-чебимени,
Өскә карап куйды күбесе.
Аңлаттылар: күрше аланлыкта
Чиркәү тора икән ләбаса;
Гыйфриттәй ярсып тимер кагып,
Бәйрәм ямен кайчак шул баса.
Яшь-җилкенчәк моңа күнеп беткән,
Картлар гына моңсу, уйчаннар...
Алар белә: күпме гасыр инде
Матәм көенә суга ул чаңнар.
Ә бүгенгә күрше төбәктәге
Сабан туе үтте гөр килеп;
Тик күңелдә калды ул нигәдер
Кемдер бозган моңлы җыр кебек...

## Ялгызлык

Көзге авыл. Шомлы караңгылык;
Тормыш күчкән инде шаулы шәһәрләргә.
Ялгыз йортта юанычка тик бер шөгыль:
Онытылганны кабат-кабат хәтерләргә.

Тәрәз аша төшә караш буш бакчага;
Табигатьнең кышны көтеп оеган мәле.
Ак яулыклы шәүлә тора кебек анда—
Ә бу фәкать чалмабашның тирбәлүе.

Нидер тоеп кинәт чәнчи, сызлый йөрәк—
Кемдер үксеп йөри мәллә өй тирәли?
...Чагыла да пыялада чит-ят күзләр,
Карыйдыр күк сиңа рәнҗеп, әрни-әрни.

***

*( Этюд)*

Кояш нурында якты күл
Күзләрне камаштыра.
Тынычлыгын яр тирәли
Камышлар саклап тора.

Йокымсыраган гүзәл күк,
Күл өсте уйчан, җитди;
Алкын суларын айкарга
Җилләр дә җөрьәт итми.

Чү, бер кошчык очкан көйгә
Канат очын тидерде дә,
Ярга дулкын йөгерде—
Кытыгы килде ак күлнең,
Елмайды гүя, күлдә.

## Печән Базары

*Сатирик әсәрләр конкурсы*

Чулпан

# ХӨКЕМ

Хөкем башланды.

Түрдә тәхеттә утыручы Баш Хөкемдар, уң кулын өскә күтәреп, баш какты.

—Бүген 3253нче кала башлыгы эше каралачак. Аты—Сәмигулла оныгы, Идрис улы Мостафа булыр. Алда без аны СИМ дип йөртербез. СИМ җирдә илле тугыз ел, ун ай һәм унҗиде көн яшәде. Хезмәт юлы: җир белгече, баш агроном, авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе, шәһәр башлыгы. Шәхси тормышы: ике хатынның никахлы, бер хатынның никахсыз ире, биш хатынның сөяркәсе, ике баланың законлы, алты баланың законсыз атасы. Аның тәүге хисап көне якынлаша. Тагын ике айдан бу бәндәнең җәмгыять каршында җаваплылыгы тәгәлләнәчәк һәм ул гади кешеләр сафына басачак. Шуңа күрә без аның изге һәм яман гамәлләрен барлап, үз карарыбызны чыгарырга тиеш. Барыгызны да искәртәм: хөкем иң югары дәрәҗәдә һәм гадел булырга тиеш. Без мәңгелек каршында җаваплы.

Беренче сүз Яклаучыга бирелде:

—СИМ бала чактан ук хайваннарны яратты. Ул бер хайванны да рәнҗетмәде. Үз гомерендә аның барлыгы сигез эте булды. Этләр тарафыннан СИМга карата бернинди рәнҗү-үпкә юк. Тамаклары тук, куышлары җылы иде. СИМ асраган барча этләр исеменнән Акбай шаһит булып килде. Әфәнделәр, әгәр каршы булмасагыз, мин беренче шаһитымны чакырам.

—Мин каршы!—диде Гаепләүче.—Һәр хуҗа да үз этләрен тәрбияли. Мин монда бернинди изгелек күрмим. Эт хуҗаны, хуҗа этен саклый. Әгәр СИМ урамда әлсерәп йөргән берәр мескен хайванга калҗа ташлап, бичара хайванны ач үлемнән йолып калган икән, ул чагында СИМның бу гамәлен изге эшләр рәтенә кертә алабыз.

Яклаучы кабаланып каршындагы китапны актарды:

—Бар-бар, андый гамәл дә бар! 1976 елның 28 октябрендә, көндезге ике сәгать унҗиде минутта СИМ ачлыктан үләр дәрәҗәгә житкән ташландык мәче баласына 52 грамм колбаса кисәге ташлый.

—Шаһит биредәме, чакырыгыз,—диде Баш Хөкемдар.

Хөкем залына вәкарь генә басып, өстенә аклы-каралы күлмәк кигән нечкә билле мәче килеп керде. Ул боргаланып мөнбәр артына килеп басты да, мыегын сыпырып, хәйләкәр генә елмаеп куйды.

—Хөрмәтле Песи Раджа кызы, 1976 елның 28 октябрендә сез кайда идегез?
Мәче, күзен уйнатып, бөдрә чәчле башын боргалап алды:
—О-о, ул чаклар! Мин әле шундый яшь, чибәр идем! Әле сабый бала гына идем... Ә мине...
Мәченең күзенә яшь тыгылды. Ул кесәсеннән ефәк кульяулык чыгарып күзен сөртеп алды.
—Сорауга төгәл һәм кыска җавап бирү кирәк!—дип ризасызлык белдерде Хөкемдар.
—Шаһит бик дулкынлана. Рөхсәт итегез, мин үзем ул вакыйгага ачыклык кертим,—дип торып басты Яклаучы.—РУТ гаиләсендә тәрбияләнүче Раджа атлы затлы нәселле мәче урам мәчесе белән элемтәгә кереп, өч сабый таба. Хуҗа аларның өчесен дә урамга чыгарып ташлый. Мәче балаларының икесе туңып үлә. Ә өченчесен—каршыгыздагы Песине СИМ коткара.
—Әйе, шулай булды. Бүгенгедәй хәтерлим, карлы яңгыр ява иде. Суык минем җелегемә үтте,—дип мескенләнеп сулкылдый-сулкылдый сүзгә кушылды шаһит.—Ашыйсы килүдән буш ашказанымда тычканнар чиелдый башлады. Мин... аһ, ничек газапландым мин... Салкыннан, юештән бөрешеп, ярдәм сорап, кешеләрнең аякларына сыландым. Шул чакта Ул очрады. Минем мәрхәмәтле, хөрмәтле Хуҗам! Мин аны яратып Музик дия идем. Ул мине үз бүлмәсенә алып кайтты, ашарга бирде, җылы юрганга төреп йокларга яткырды. Минем иң бәхетле елларым Музик белән үтте. О, бу—изге кеше! Аңа оҗмах ишекләре ачык булырга тиеш.
—Шаһитка сораулар бармы?
—Бар, Судья әфәнде,—диде Гаепләүче.—Әйтегез әле, Песи ханым, СИМ сезне соңгы көнгә кадәр тәрбияләдеме?
Мәче еламсырап башын иде:
—Юк шул... Ул бүлмәдәге джентельменнар, укуларын бетергәч, каядыр киттеләр. Тулай торакка башкалар килде. Алар минем белән яшәргә теләмәде, бүлмәдән кудылар. Соңгы елларымны мин кача-поса коридорда яшәдем. Ләкин зарланмыйм. Ачка интекмәдем, өшеп йөрмәдем. Ни генә булмасын, Музик мине ач үлемнән коткарды. Мин аңа гомерем буе рәхмәтлемен, әфәнделәр!
Шаһиттан сорау алу тәмамланды.
Гаепләүче торып басып, кырыс карашын Яклаучыга төбәде:
—СИМның хайваннарга карата мәрхәмәтле булуына ышандык. Әгәр СИМ зоопаркта, тыюлыкта яки фермада эшләп, аңа бары тик хайваннар өчен генә җаваплылык тапшырылган булса, сез китергән дәлилләр, әлбәттә, бик саллы булыр иде. Ләкин СИМ һәрвакыт кешеләр өчен җаваплы булды. Аның кешеләргә карата кылган игелекләре турында ни әйтә аласыз?
Яклаучы төртелеп калды. Кабат китабын актарырга кереште:
—1992 елның 27 мартында, иртәнге сәгать сигездә СИМ урам аша чыгып баручы бер карчыкка хәер бирде. Карчык аңа ихлас күңелдән рәхмәт әйтте.
—Бу факт миндә дә теркәлгән,—диде Гаепләүче.—Бу көнне СИМ башкалага, Президент янына ашыга иде. Коммунизм һәм Театр урамнары чатында алар юл кагыйдәсен бозып, җәяүлеләр өстенә менделәр. Бәхеткә каршы, беркем дә зыян күрмәде. Шул чакта СИМ, юлы унмаудан куркып, бер ятим карчыкка хәер сузды. Рәхмәт ихлас күңелдән әйтелсә дә, хәер риясыз түгел иде. СИМ карчыкны кызганып түгел, үзен кайгыртып хәер бирде. Чөнки аның машинасы әлеге карчыкны таптый язды. Мин рия белән бирелгән хәерне изге гамәлләр исемлегенә кертә алмыйм!
—Мин Гаепләүче белән килешәм,—диде Баш Хөкемдар.—Яклаучы

әфәнде, тагы нинди дәлилләрегез бар?

Яклаучы бармак калынлыгы дәфтәрен кабат кулына алды һәм аңа тиз генә күз йөгертеп чыккач, илһамланып сөйли башлады:

—Шәһәр башлыгы итеп сайлангач, СИМ сукбай этләрнең язмышын кайгырта башлады. Аларның һәркайсы исәпкә алынды. Сукбай этләрне ату, рәнҗетү тыелды. СИМ карары нигезендә шәһәр читендә сукбай этләр һәм хуҗасыз калган мәчеләр өчен пансионат төзелде.

Гаепләүче урыныннан сикереп торды:

—Сез моны изге эшләр рәтенә кертмәкче буласызмы?

Яклаучы, сүзенең хаклыгына бернинди шик калдырмыйча, горур елмайды:

—Әлбәттә! Ярдәмсез калган җан ияләренә булышу изге гамәлләрнең берседер.

—Шаһитлар бармы?—дип сорады Баш Хөкемдар.

—Пансионатта яшәгән һәр эт, һәр мәче минем сүземне җөпләп кул куйды. Аларның күрсәтмәләре теркәлгән. Чакырып сүз бирүнең зарурлыгын күрмим,—диде Яклаучы.

—Судья әфәнде, рөхсәт итегез! Бу гамәл буенча минем дә шаһитым бар,—диде Гаепләүче.

Шаһитны чакырырга рөхсәт бирелде. Суд залына, авыр гына атлап, орчык буе бөкре карчык килеп керде. Аның арык гәүдәсе мөнбәр артына кереп югалды. Карчык аяк очларына басып калкырга күпме азапланса да, булдыра алмады. Ахырда аңа мөнбәр артыннан чыгып, утырып сөйләргә рөхсәт ителде.

—Мин,—диде карчык,—инде унике ел этләр арасында яшим. Чөнки үз урынымнан китәргә теләмәдем. Пансионат төзер өчен без яшәгән иске йортларны җир белән тигезләделәр. Кешеләр зур калага күчте. Мин калдым. Мин дә этләр арасында яшим. Ләкин миңа эт ризыгы да бирүче юк. Мине шул оямнан да куалар.

—Сез ялганлыйсыз!—дип каршы төште Яклаучы.—Тузган йортларда яшәүчеләргә каладан фатир бирелде. Беркем дә урамда калмады.

—Мин калдым,—диде карчык.—Йортым янгач, мин халык өстендә яши идем. Кешеләр киткәч, урамда калдым. Ләкин мине этләр яныннан да куалар. Анда бер генә мәрхәмәтле, изге кеше бар. Шуның аркасында гына җан асрыйм. Аллаһының рәхмәте яусын ул бәндәгә, урыны оҗмахта булсын. Колыгызның аты Нәбиулла булыр, онытмагыз.

Баш Хөкемдар алдындагы дәфтәренә нидер теркәп куйды.

—Шаһитка сораулар бармы?

—Бар,—диде гаепләүче.—Сез шәһәр башлыгы каршына ярдәм сорап килдегезме?

—Бардым ул имансыз бәндә каршына...—дип уфтанды карчык.—Каберлектән җылы фатир бирербез, күп яшисең калмагандыр, дип мыскыллап куып чыгарды.

Яклаучы утлы табага төшкән чебеш кебек куырылып, мескенләнеп калды. Калтыранган бармаклары белән юка дәфтәрен актарды, йөзендә бинигаякә өметсезлек иде.

Сүз Гаепләүчегә күчте. Ул өстәлгә кирпеч-кирпеч китапларын тезә башлагач, барысы да «ах» итте. СИМның аклануына тамчы да өмет юк иде.

Гаепләүче сөйли торды, суд залына бер-бер артлы шаһитлар керә торды. Зал зурайганнан-зурая, киңәйгәннән-киңәя барды. Ул халык белән шыгрым тулды. Бу хөкемнең ахыры-чиге булмас төсле иде...

СИМ өстенә гаеп өстенә гаеп яуды, нәтиҗәләр Хөкемдар дәфтәренә

теркәлә барды: «Ялганчы—138 факт; карак—274 факт; алдакчы—222 факт; гаделсез—402 факт; азгын—667...»

Фикер алышулар тәмамланып, Баш Хөкемдар карар чыгарырга әзерләнгән чакта залга ашыга-кабалана ак яулыклы бер хатын-кыз килеп керде. Керү белән тезләнеп, Хөкемдар алдына егылды:

—Кичерегез! Зинһар, кичерегез газиземне! Минем улым начар кеше түгел. Ул ялгышты. Аны ялгыштырдылар. Минем улымны кешеләр бозды. Ана дөрес юл күрсәтүче булмады. Туганда ул бер гөнаһсыз сабый иде. Кичерегез аны! Зинһар, мәрхәмәтле булыгыз!

Баш Хөкемдар хатын янына төшеп, аны күтәреп торгызды:

—Сабыр бул, Ана! Син бит гомерең буе сабыр булдың. Улың синең хакта оныткач та, авырып егылгач, хәлеңне белүче булмаганда да, язмыштан зарланмадың. Хәләл ирең мәңгелеккә киткәч, улың аны озатырга кайтмаганда да син сабыр булдың. Беркемгә рәнҗемәдең, беркемне каргамадың, улыңның бар гаепләрен кичердең. Һәр намазыңда аңа исәнлек, җитеш тормыш теләдең. Синең теләкләрең кабул булды, улың сау-сәламәт булып, рәхәт яшәде. Тик нигә соң синең күзең яшьле, Ана?

Ак яулыклы хатын Баш Хөкемдарның кулларына үрелеп, аларны үбә башлады:

—Улымны аклагыз! Аклагыз минем газиземне!

—Мин аклармын да бит, гаепләүчеләр риза булырмы икән?—диде Баш Хөкемдар.

Зал гөрләшеп алды. «Юк!» дигән кырыс сүзләргә анда-санда «Ана хакына...», «Ана хакына...» дигән сыек кына өннәр дә кушылды.

Хәсрәтеннән сыгылып төшкән Ананы йомшак кәнәфигә утыртып, су бирделәр.

Хөкемдар кабат үз урынына менеп басты. Горур карашын залга төбәп:

—Әй, кешеләр! СИМга хата-гаепләрен күрсәтүчеләр булдымы? Аны ялгыш юлдан чыгарырга омтылучылар булдымы? Күңел күзен ачарга булыштыгызмы? Арагызда Хак сүз әйтүчеләр, Дөреслек өчен көрәшүчеләр бармы?

Залда авыр тынлык урнашты.

Шулчак Гаепләүченең тавышы ишетелде:

—Андый кеше бар, тик ул авырый. Ул үз акылында түгел.

—Алып килегез!—дип боерды Баш Хөкемдар.

Күп тә үтмәде, тоташ актан киенгән берәүне җитәкләп керделәр. Соңгы шаһит итеп китерелгән зат хатын-кыз җенесеннән булып, аңа 35-40 яшьләр чамасы иде. Хатын мөнбәр артына басты, гаҗәпсенеп ачылган зур күзләре белән бүлмәне айкап чыкты, аннары күргәннәреннән бик канәгать калган сыман балаларча елмаеп куйды. Аның соклану тулы тугры карашы Хөкемдарга төбәлде.

—Мин сезне беләм. Сез минем төшләремә керәсез,—диде ул.

—Без дә сезне беләбез. Борчылмагыз, сезгә бернинди хөкем булмаячак.

—Барысы да булды инде,—диде хатын.

—Әйе, барысы да булды,—дип килеште Хөкемдар.

—Шулай булырга тиеш идеме соң? Мин ялгышмадыммы?

—Күңел күзе ачык затларга җинел түгел.

—Мин арыдым,—диде хатын.

Хөкемдар аңа яратып һәм юатып бакты:

—Алла сине мәңгелек тынычлык, озын ял көтә.

Хатын Гаепләүчегә һәм Яклаучыга күз салды. Тегеләр икесе дә торып басып аңа баш иделәр.

—Явызлык тиешле җәзасын алырга тиеш!—диде Гаепләүче.

—Явызлык юлын кешеләр үзләре бүлергә тиеш!—диде Яклаучы.

—Мин явызлык юлын бүлергә тырыштым. Көрәшем җүләрләр йортында тәмамланды. Мин хәзер төшләремдә генә яшим,—диде хатын.

—Син ялгыз идеңме?

—Мин ялгыз түгел идем. Юлдашларым мине сатып тәхет, дәрәҗә, мал алдылар.

—Барысы да ишетсен: сез кем?

—Мин—Журналист. Журналист мин! Журналист!!!—Хатын кинәт ярсып бәргәләнә башлады. Аны җитәкләп алып чыгып киттеләр.

Аның артыннан ишек ябылгач, кабат Гаепләүче торып басты:

—Судья әфәнде, соңгы шаһитыбыз чынлап та журналист иде. Аның хак сүзләре ташка басылган. Тик ул хак сүзләрне СИМ ишетмәде, Журналисттан үч алып, аны авыру хәлгә җиткерде. Бу гамәле СИМнын гаебен генә арттыра.

—Минем улымнын гаебе юк!—дип кычкырды Ана.

—Ана хакына гаепләнүчегә соңгы мөмкинлекне бирәбез. СИМны дөньяга тудырган Ана хакына!—диде Хөкемдар.—Бер тәүлек! Бер көндә бары бер генә изгелек эшләсә, бары бер генә бәндәгә риясыз ярдәм күрсәтсә дә, ул Этләр Утравына сөрелмәячәк.

***

Ул төнне Идрис углы Мостафаның йокысы тыныч булмады. Төне буе күршеләренең эте өрде. «Ни булды икән бу бичарага?»—дип борчылды Сәмигуллин. Ахырда түзмәде, киенеп урамга чыкты. Капка аша үрелә-үрелә: «Барсик! Алтыным! Ни булды сиңа?»—дип өзгәләнде.

Барсик, әлбәттә, җавап бирмәде. Аңа Мостафа түгел, ана көчек кирәк иде. Ул аның исен сизә, бик якында икәнен тоя, тик чылбырыннан ычкына алмый. Шуңа да үрле-кырлы сикереп разбуй сала иде.

Ләкин Мостафа аны аңлады. Ау этенекедәй үткен, елтыр күзләре тирә-якны капшап чыкты, карашы юл кырында койрык болгап, кәнтәйләнеп басып торган ана эткә килеп төртелде.

—Кил монда, кил, наный. Сине бик кирәксенәләр, чакыралар анда. Әйдә, наный, мин сине үзем кертәм.

Ана эт, йомшак сүзгә алданып, шыншый-шыншый аңа якынайды. Тәмле ризык өметләнеп, куштанланып, аякларына елышты.

Сәмигуллин кесәсеннән казылык кисәге чыгарып эткә сузды да, тегесе шуның белән əвәрә килгәндә, моны җәһәт кенә эләктереп алып, койма аша ишегалдына атты.

—У-у-у!—дип сөенде Барсик.

Барысы да риза-канәгать иде. Тик Мостафаның йокысы ачылды. Өенә кереп йомшак, җылы түшәктә күпме генә әйләнгәләп ятса да, кабат йокыга китә алмады.

Шуңа күрә иртән кәефе дә булмады. Ә аны капка төбендә көтәләр иде инде. Берсе—шоферы, икенчесе—сабакташы Ярулла. Анысы хуҗаны күрүгә авызын ерып, төчеләнеп күрешә:

—Исәнмесез, Мостафа Идрисович! Хәлләрегез ничек, Мостафа Идрисович? Хәерле иртәләр сезгә, Мостафа Идрисович!

Тик Мостафа ачылып китәргә ашыкмады. Сабакташын танымаганга сабышты. Шулай кулайрак иде. Ярулланың аны сагынып килмәгәне көн кебек ачык. Моңа нидер кирәк, таң тишегеннән нидер теләнеп килгән.

—Эшеңә барган идем, Мостафа Идрисович, кертмәделәр. Сезнең анда төрмә кебек. Айгыр хәтле егетләр эләктереп алмасынмы. Сөйләшмиләр

дә, урамга чыгарып аттылар, хи-хи...—дип тезеп китте аны-моны сизмәгән беркатлы Ярулла.—Яшьти, ярдәмең кирәк бит. Башка барыр җир юк. Бөтен өмет синдә, Мостафа Идрисович.

—Тыңлыйм,—диде Сәмигуллин коры гына.—Кыскарак тот, ашыгам.

—Кызны эшсез калдырмакчылар. Кыскарту, имеш. Моның өстендә ике бала. Берсе түләүледә укый. Аларны кеше иткәнче әле... Кызның ире үлде бит. Чернобыль зәхмәте әләкте мескенгә. Кияү шунда эшләп кайткан иде. Зинһар, ярдәм ит, яшьти. Зарплаты яхшы иде монда. Каян таба тагын...

—Аңлашылды. Данныйларын язып бир.

—И, рәхмәт яугыры, игелекле кеше инде үзең. Мәңге онытмам, буш итмәм, яшьти... Бәхилләтермен, Мостафа Идрисович...—Ярулла сөенә-сөенә кәгазь кисәгенә нидер сырлап, Мостафага сузды.

Сәмигуллин беркайчан беркемгә «юк» дими. Чөнки бик яхшы белә, «юк» дисә, зар-моңнары белән аның бусагасын таптаучылар өстәгеләр янына китә. Ярар, карарбыз, ди ул. Көтегез, ди. Сезнең эш уңай якка хәл ителергә тиеш, ди. Вәгъдә биргәч, адәм баласы ышана, көтә, өметләнә. Бер ай өметләнә, ике ай, бер ел, ике ел... Көннәрдән бер көнне ул үзен алдап-йолдап йөртүләрен аңлый. Тик инде соң була. Зар-моңның хәл ителер, тимерне сугар кызу-кайнар вакыты үткән була. Йөреп-көтеп гаҗизләнгән кеше арып, барсына кул селти...

Мостафа сабакташының гозерен кесәсенә салып кую белән аның турында онытты. Чөнки хакимият бинасы төбендә аны башка зар-моң көтә иде. Бу хатын инде өч ай аның бусагасын таптый. Һәр иртәдә Сәмигуллинны шунда сагалый. Ике баласы белән каршына килеп баса да: «Безгә фатир кирәк! Безгә фатир кирәк!»—дип кычкыра-даулый башлый. Боларны оешма фатирыннан урамга куып чыгарганнар. Ул фатирга кемнеңдер кеме кереп утырган. Кем икәнен Сәмигуллинга әйттеләр, аңлаттылар. Әлбәттә, ул затка кагылырга ярамый иде. Ә боларга ярый. Боларның яклаучысы юк. Үҗәт хатын үзе, ярдәм итмәсәгез, Президентка барам, дип яный. Тәки хат язган. Ул хатны почтада тотып алып, Сәмигуллин кулына тапшырдылар. Ләкин икенчесе ниндидер юллар белән Кремльгә барып җиткән булып чыкты. Шуннан соң, бәласеннән баш-аяк дип, тулай торактан бер бүлмә бирделәр. Ләкин ул һаман фатир даулый. Ике бала белән тулай торакта җайсыз икән. Җайсыз булгач, ничү ирсез килеш хәерче үрчетергә. Президентка, мәсьәлә хәл ителде дип, матур гына хат юлланды. Хәзер инде бу аяклы бәла чуртымны да кыра алмый. Баш өстендә түбә бармы, бар. Артыңны кысып тик утыр шунда.

Хатын акыра-яный калды, Сәмигуллин эре-эре басып ак бинага кереп китте. Ләкин анда да тынычлык юк. Анда инде икенче «мамаша Кураж» күкрәк киереп басып тора. Анысы да таныш Сәмигуллинга. Ул да бу тирәгә күптән ияләште. Шикәр чирле улын армиягә җибәрмәс өчен җан талаша. Чирләсә ни, укол кадарлар. Анда һәркемгә урын табыла, учак ягып торырга булса да ярар. Аның кебек чирлеләр китә тора, кайта тора. Сау-сәламәтен кайдан алырга соң? Военкомат планы үтәлсен өчен, олы башын кече итеп, үз малаен җибәрсенмени? Күз өстендә каш буласы шул асыл зат өтекләр арасында ике елын әрәм итеп йөрсенме?!

Сәмигуллин хатын каршында туктап, һәр көн әйтә торган сүзләрен кабатлады:

—Борчылмагыз, сезнең мәсьәләне тикшерәбез.

—Тикшерәсез?! Инде ничә атна тикшерәсез!—Хатын кулындагы кәгазьне болгый-болгый үкереп елый башлады:—Менә! Повестка килде! Иртәгә алып китәләр чирле баламны! Нишлисез сез, оятсызлар?! Ник үзегезнең үгез кебек таза малайларны җибәрмисез?!

—Армиядә госпитальләр яхшы. Дәвалап кайтарырлар,—дип тынычландырды Мостафа аны, һәм, исән чакта таярга кирәк дип, кабинетына элдертте.

Елаган бер кешене юатырга нәнкеме әллә ул?!

Җылы, йомшак кәнәфиенә утырып, музыка да кабызып җибәргәч, зар-моңлы дөнья онытылды. Музыка нервыларны яхшы дәвалый икән. Ә нервыны сакларга кирәк. Сәмигуллин күзен йомып, илһамланып Мәдинә җырларын тыңлап утырды. Мәдинә дә аныкы бит... Шул татлы уй күңелен иркәләп куйды. Яшәү рәхәт, яшәү кызык бу дөньяда!

Иртәнге унга утырышлар залына оешма, предприятие житәкчеләре җыелырга тиеш иде. Килделәр. Америка ачып киттеләр. Башлык үз телләре белән әйтте: бер атнадан Май бәйрәмнәре икән! Шул өч көн ялда милиционерлар тәртип сакларга, янгынчылар янгын-фәлән чыкса, аны сүндерергә тиеш булды. Юл инспекторларына исерекләрне рульгә утыртмаска боерылды. Табибларның авыруларга да, эчеп егылучыларга да ярдәм күрсәтергә тиешлеге дә нәкъ менә шул җыелышта ачыкланды. Бәйрәм көннәрендә йорт-фатирларда ут, су, газ булырга тиешлеген дә белделәр. Бик күп яналыклар ачылды ике сәгать буе барган бу мөһим җыелышта. Түрәләр җиргә өр-яңадан тугандай вәкарь, канәгать кыяфәт белән чыгып китте. Яшәү рәхәт, яшәү кызык бу дөньяда!

Сәгать өчтә шул ук залга эшмәкәрләр җыелды. Каш асларыннан карап бүселеп утырдылар. Боларның башлыкка «мәхәббәтләре» ифрат көчле. Юкка чакырмаганны беләләр. Алда—Май бәйрәмнәре. Шуны үткәрү өчен «ясак» җыячаклар. Әз бирсәң, боларга начар, күп бирсәң—үзеңә... Ләкин бирергә кирәк. Ул «ясак»ның кая киткәнен төгәл генә беркем белми. Әмма дә ләкин фаразлар бар... Ак йорттагыларның тормышы харап яхшы бара, рәхәт яшиләр. Хезмәт хаклары да әлләни түгел югыйсә. «Моны кайдан, нинди акчага алдың?»—дип селки башласалар, койрыклары бозга тиз ябышыр иде дә, әмма дә ләкин әүвәл тикшерүчеләрнең үзләрен тикшерәсе бар... Әнә бер бичара журналист хатын бик күп белмәкче иде дә, психбулниска тыгып куйдылар үзен. Оҗмахка озатылганнары да житәрлек. Күп белсәң, мәңге картаймассың, теге дөньяларга матур булып яшьли китәрсең...

Эшмәкәрләрне «хәйрия ярдәме бирергә» күндергәч, Сәмигуллинның кәефе күтәрелде. Кәефе күтәрелсә, ул Зоечкасы янына ашыга иде. Зоечканың күңеле булсын өчен Мостафа барысын да эшли. Берүзенә шәһәр уртасында өч бүлмәле фатир алып бирде. Җаны ни тели—шуны кайтарып тора. Китереп кенә түгел, кертеп, урнаштырып бирәләр. Зоечкага яхшы булса, Мостафага да җәннәт капкалары ачыла. Бу өр-яңа фатирга тузган йорттан күп балалы гаилә күчәргә тиеш иде, ләкин ул Зоечка бәгырьгә бик ошады шул. Күп балалы гаилә бу хакта белми дә калды, Зоечканың ике бүлмәле иске фатирына сөенә-сөенә, мәрхәмәтле түрәләргә рәхмәтләр укый-укый кереп утырдылар. Газиз туган халкыңны ничек яратмыйсың ди?! Татар белән эшләү, аны идарә итү җан рәхәте! Ходайның рәхмәте, күндәм, сабыр инде үзләре, булганына гел риза, гел канәгать. Зарлана да белми, бахырлар.

...Иркен йомшак караватта, Зоечканың кайнар кочагында гырлый-гырлый йоклап ятканда, Сәмигуллинның баш очында ике фәрештә үз киңәшмәләрен башлап җибәрде.

—Мин моңардан гарык,—диде Беренчесе.—Бу бәндәгә бернинди өмет юк.

—Көтәргә кирәк, әле бер тәүлек үтмәде,—диде Икенчесе.

—Бу бүкәннән кемгә нинди файда? Гомере буе игелек кылмаганны бер көндә генә нишләр?

—Күтәргә кирәк, әле тәүлек үтмәде,—дип кабатлады Икенчесе.

—Минем түземлегем бетте. Бу имансыздан яхшылык көтәсе юк!

—Имансыз?! Андый хөкем чыгарырга синең ни хакың бар?

Беренче фәрештә артта басып торган ак яулыклы Анага күз салды:

—Син бүген гел безнең белән булдың, барысын үз күзең белән күрдең, ишеттең. Соңгы сүз синдә, Ана! Ни диярсең?

Ана дәшмәде, оялып, чал башын гына иде.

—Вакыт,—диде Беренче фәрештә.

—Өстән хәбәр юк,—дип икеләнде Икенчесе.

Шулчак баш очларында Хөкемдарның кырыс карары яңгырады:

—Этләр Утравына! Бу имансызны Этләр Утравына олактырырга!

Икенче көнне 3253нче шәһәрнең газетларында бит тутырып кайгылы хәбәрләр басылды: «Көтмәгәндә... арабыздан... авыр югалту.... уртаклашабыз...» Кемнәрдер, «өзелеп сөйгән» башлыкка «олы хөрмәт» йөзеннән, ул газетларны урам бәдрәфләренә ябыштырып чыкты...

Ә Этләр Утравында дәрәҗәле кунакны каршылап шайтан туе оештырдылар. Сәмигуллин кебекләр анда шактый җыелган иде.

---

# Солтан Морат

## Ил белән...

**1**

**...Тарихтан укып беләм:**
**Ленин бабай үлгәч, халык**
**Елап калган ил белән...**

**2**

**... Ни-нәрсә уйлаганнар?!—**
**Сталин бабай үлгәч тә,**
**Ил белән елаганнар...**

**3**

**...Уйланам хәйран калып:**
**Патшабыз әле үлмәгән—**
**Ил белән елый халык...**

**4**

**Гомеремнең кай чоры соң—дөрес?**
**Кай чоры соң—аның ялганы?!—**
**Өндәү (!) белән—50 яшем үтте,**
**Сорау (?) белән—уза калганы...**

Мөдәрис
Мөхтәсипов

## Юкны бушка аудару

мәсәл

Куян урман буйлап озак чабып йөргәч,
Һәм агач башындагы карганы күргәч,
—Нишлисең?—дигән сорауны бирде кошка.
—Мин аударам,—диде карга,—юкны бушка.

Куян карап озак кына торгач уйлап,
«Нигә,—диде,—мин чабамын урман буйлап,
Бу дөньясына төкереп бер карыймчы,
Карга кебек юкны бушка аударыймчы...»

Агач төбендә ятканда ул тынычлап,
Тәпиләре белән колакларын учлап;
Мәҗбүр булды кинәт торырга сикереп.
Төлкенең ул сораулы карашын күреп:

—Карап торам сиңа һәм син бигрәк көлке!
Нишләп ятасың монда?—дип сорый төлке.
—Күрмисеңмени?—ди куян,—юкны бушка
Аударабыз карга белән, синнән башка.

Хәйләкәр төлке дә күп тормый уйлап,
Юкны бушка аударышырга чамалап;
Ятты куян янына ук ул сузылып,
Һәм талды тыныч йокыга онытылып...

Аучыга шул гына кирәк! Озак йөргәч,
Эзләгәнен аяк астында ук күргәч,
Куш көпшәдән икесен тиң атып алды.
Атып алды һәм дә капчыгына салды...

Моны күреп агач башындагы карга,
Әйтте шунда: «Юкны бушка аударырга,
И, тинтәкләр, бу дөньяда була бары
Тик утырган урының булса югары!

# РӘСЕМ—БЕЗДӘН, ҖАВАП—СЕЗДӘН



## Дәүләт кайгыртуы

**Указ чыккан—ире әдип булган хатын-кызларга:**
**«Хезмәт хакы аз булса да әдипләрне сакларга.**
**Гаффар сыман вагракларын кисмәкләрдә тозларга!**
**Гали кебек эреләрен бауга асып какларга!»**

**СӘЙЛӘН**

***

**Яхуд яңа Читлекбаш.**

**Ниләр күрми ир-егеткәй белән ат башы.**

**Бәрәңгедән бушаган челтәр даһи башына бик таман.**

**—Динә! Авоськага салып Марсель башын, кая барасың?**
**—Ломбардка! Исәп—кире алмаска!**

**БАТУЛЛА**

***

**Әйле-шәйле башың бәйле,**
**Кулларда—богау.**
**Шул хәлләргә риза булып**
**Торучы—бозау!**

**Миңа кара да аңлачы,**
**Милләт, үзеңне!**
**«Кул» төенне төйнәгәнче,**
**Әйт син сүзеңне!**

**«Ням-нәм» кабиләсе экспонатын бөтендөнья күргәзмәсенә алып баралар.**

**Нәҗибә САФИНА**

***

**Базар тулы каз, тавыклар,**
**Хәтта бар чучка башы.**
**Хатын да шунда җыена:**
**Шушы булды микән инде**
**Башкаемның язмышы?!**

**Ринат МӘННАН**

***

**Йә, гонорар сорап бак хәзер?!**

**Бүгенге татар ирегенә ишарә.**

**Бизмәнгә салсаң, ничә батман килер икән?**

**Әллә Кабан күленә кире ыргытабызмы?**

**Госман ГОМӘР**

***

**Хатын иреннән сорау ала.**

**Нурислам АЙБУЛАТОВ,**
*Чиләбе өлкәсе, Чибәркүл каласы.*

***

**Кавын дисәң—мыеклы,**
**Бекон дисәң—күзе ачык.**

**Күп йөрдең күбәләк күк**
**Чәчкәдән чәчкәгә кунып!**

**Хәлимә ГАЛИЕВА**
*Укытучы, Казан.*

***

**Ошбу мәхәббәт әсире—**
**Чатыртауның Марселе.**

**Хәлең ничек, Бөегем?**

**Һәркемнең күңелендә үз Атлантидасы бар.**

**Суфия ЮНЫСОВА**
*Балтач районы, Алан авылы.*

***

**Ычкындыр, хатын, авырта—**
**Ул бит—баш, түгел—кабак!**
**Ну, булды инде—сүз бирәм:**
**Бу кадәр эчмәм кабат!**

**Хатын:—Гел рәхәт кенә булмасын—**
**Бераз интек ичмасам!**
**Тагын «сул» якка каерсаң,**
**Теге башыннан асам!**

**Мөдәрис МӨХТӘСИПОВ.**
*Башкортстан, Туймазы районы.*

Габделхәй
Сабитов

## ХӘВЕФЛЕ ҖӘЙ

Мәче баласы идәндә хөрмә төшеннән тезелгән дисбе белән уйнап йөри иде. Кыяметдин бабайның урыныннан кузгалганын күргәч, эшне сизенде, ап-ак тәпиләре белән дисбене этәли-суккалый, мич астына кереп китте. Бабай, шактый изаланып, дисбесен кисәү агачы белән тартып чыгарды. Аннары озаклап кулын юды, өс-башын алыштырды, култык астына намазлыгын кыстырды.

Улы Зариф аның бу кыйланышларына сәерсенеп карап тора иде.

Сирәк-мирәк, айда бер, кайда бер дигәндәй, намазлык өстенә менеп төшкәләсә дә, Кыяметдин бабай моңарчы артык диндар карт түгел иде... Әмма быел җәй үзгәрде дә китте кеше. Ничектер борчыла, тынгысызлана. Баскычка чыгып, озак-озак күккә карап тора, көненә дүртәр-бишәр кат ындыр артларын, инеш буйларын әйләнеп кайта. Кайта да намазлык өстенә менеп утыра.

Монысына Зарифның әлләни исе китми дә әле китүен. Картка быел йөз яшь тула. Йөз яшь!.. Анысы да әле үз исәбе белән генә. Үлү-тууларны теркәп барган кәгазьләр кайчандыр иске мәчет янганда көл булып күккә очкан. Бабайның үз хәтеренә ышанып кына соңрак метрика язып биргәннәр. Кем белгән, чын дөресе әллә йөз яшь, әллә йөз ун, әллә тагын аннан да артык...

Теге кем әйтмешли, дөнья белән алыш-биреше беткән чукрак картның намаз укуы кем өчен гаҗәп булсын!

Әмма менә болай мәчеткә җыенган кебек олы кубып каядыр әзерләнә башлагач, Зарифның күңеленә шом төште. «Әллә хәтере чуала башладымы юкса» дигән уй килде аның башына.

Картны ул ишек төбендә туктатып, колагына иелеп кычкырды:

—Кая җыендың болай, әти?.. Кая җыенуың, дим? Чәй әзер бит, утыр, ашап алыйк.

Әллә ишетте Кыяметдин бабай улының сүзләрен, әллә ишетмәде... Кулын колагына куеп, тыңлагандай итенде дә һичбер җавап кайтармыйча чыгып китте.

Икенче көнне тагын шул ук хәл кабатлангач, Зариф, тәмам пошынып, әтисе артыннан күзәтә китте.

Капкадан чыгуга, Кыяметдин бабай тыкрыкка борылды. Ындыр артында үскән яшь каен күләгәсенә барып, намазлыгын җәйде.

Бу юлы Зариф әтисенә сүз әйтмәде. Хәтерен калдырудан куркып, аңа күренмичә, алдан ук кайтып китте. Әмма бер-ике көннән, картның тагын чыгып китәргә җыенганын күргәч, түзмәде:

—Нишләп йөрисең син, әти?—диде ул, картның колагына ук иелеп.—Кеше көләр бит! Намаз укыйм дисәң, әллә сиңа урын тармы?! Әнә бит, мәчет чаклы өең бар, берүзенә бер як, рәхәтләнеп укы. Көлкегә калдырасың бит болай мине. Бер әтисен сыйдырмый башлаган икән, диярләр.

Кыяметдин бабай улын сабыр гына тыңлап торды, ләкин бу юлы да ләм-мим сүз кайтармыйча үз юлына китте.

«Ишетмәде, ахры. Колагы бөтенләй томаланып җиткән!»—дип уйлады Зариф.

Әмма Кыяметдин карт аның сүзләрен ишеткән дә, аңлаган да иде. «Нинди

ваемсыз балалар соң болар!—дип борчылып уйлады ул, тыкрыктан төшеп барышлый.—Ил өстенә афәт килгәнен күрмиләрме әллә юкса?! Бала-чага шул, ни әйтмәк кирәк...»

Зариф—Кыяметдин бабайның бердәнбер улы. Аңа да инде тиздән алтмыш тула. Ләкин карт алдында ул барыбер бала хөкемендә. Кадерле бала, соңгы бала. Башкалары инде күптән үлеп бетте. Ике өлкән кызын, ике сөлектәй улын ваба кырып салды. Бер кызы, буйга җиткәч, ачлык елны вафат булды. Шул ук елда өч яшьлек сабыйлары, күзгә карап, ачка тилмереп үлде. Аналары мәрхүмә акылыннан язды. Чүпрәккә төргән бәләкне бала итеп, бишек җыры җырлый-җырлый, шуны кулында тирбәтеп йөрде.

Нинди генә кайгы-хәсрәтләр күрмәде Кыяметдин карт үз гомерендә! Әмма ачлык афәтеннән зуррак афәт күргәне булмады. Шунлыктан гомере буе иң курыккан, иң нык тетрәнгән нәрсәсе—ач бала кайгысы, ач бала фаҗигасе иде.

«Йа Алла! Ничек аңламый соң бу Зариф?—дип баш ватты Кыяметдин бабай.—Балалары бар лабаса, ажгырып ачлык килә! Ачлык! Инде менә ничә ел булганы юк иде бит мондый хәвефле җәйнен».

Картның бу шомланулары бөтенләй нигезсез түгел иде. Җәе генә түгел, узган көзе үк шыксыз килде. Кыш урталарына кадәр әле яңгыр, әле юеш кар явып, гел җепшетеп, җылытып торды. Бер кат яфрак ярган агачлар, яз килде дип алданып, өр-яңадан бөре ачтылар. Шулчак кинәт кенә каты суыклар башланды. Хәтта очар кошлар егылып төште. Көзге яңгыр суларын эчеп туенган, бүртенгән агачлар зәһәр суыктан шартлап-шартлап ярыла башладылар.

Мондый зәмһәрир суыклары артык озакка бармады баруын. Гыйнвар урталарында кыш бабай, кинәт дуамалланып, ак сакалын җилпеп җибәрде. Төннәр буе котырынды, биеде, дулады. Ихата буйларында, абзар-кура тирәләренә сыртлап-сыртлап кар көртләре өйде.

Кары мул төшкәч, Кыяметдин бабайның күңеле бераз күтәрелгән иде. Тик... теге суыклар вакытында арыш уҗымы тоташтан өшегән булып чыкты.

Анысына халык бик аптырап калмады калуын. Ул җиргә бер атна дигәндә бодай чәчеп чыктылар. Рәхәт, йомшак язгы күкрәүләре белән яшь уҗымнар өстенә ләйсән яңгыр да явып узгач, тагын тынычланган иде карт. Әмма юкка гына куанган икән. Беренчесе—соңгысы шул яңгыр булган, ахры. Менә инде ай ярым буе ник бер тамчы тамсын! Иртәдән кичкә кадәр кояш кыздырып, мич авызыннан өргәндәй, кайнар җил исеп тора... Басулар тәмам сусады, җирләр яргаланып бетте. Игеннәр серкә очыра алмыйча ук саргаеп, көеп калдылар. Хәтта урам буенда үсеп утырган агачлар да әлсерәп төште. Июль башында ук бакчаларга, урманнарга көз төсе керде.

Бу хәл авыл халкының күңелен борчый иде, әлбәттә. Тик берәү дә Кыяметдин бабай кебек ач үлем көтми, берәү дә аның кебек кырга чыгып, яңгыр теләп намаз укымый. Картның шуңа эче поша.

Өстәл янына ашарга утырган саен һаман бер үк нәрсәне уйлый. «Менә бит ничек муллан кыланалар! Өстәл тактасы сыгылырлык итеп турыйлар ипекәйне,—дип, эченнән сыкрана ул.—Кара көнгә сакларга иде бераз. Нәрсәгә шулай ышаналар соң болар?! Сәер шул, бик сәер хәзерге яшьләр!»

Башына шундый уйлар килгәч, тамагыннан аш узмый, төннәрен күзенә йокы керми.

Шулай җәфалана торгач, көзгә таба шактый бетәште бабай. Ул инде быелгы хәвефле елдан исән калу турында уена да китерә алмый. Хәзер аның күңелен бөтенләй башка уйлар борчый... Ничек булыр? Җеназасын укып чыгучы табылырмы? Рәтләп җирли алырлармы?.. Әнә бит теге ачлык елларда... Мәетләр атналар буе күмелми аунап ятты. Ач кешенең кабер казырлык егәре дә булмый... Кышы салкын килеп, туңы да тирәнгә китсә...Һәм Кыяметдин бабай хәстәрен алдан күрергә булды. Шулай беркөнне, Зариф ат җигеп эштән кайткач, аңа

каршы чыгып, арба янына килде:

—Тугармый тор атынны. Илтми тор. Тиз генә барып кайтасы җирем бар,—диде ул.—Сал әле арбага бер-ике кочак салам... Әйе, әйе, салам сал, дим. Бәрәнге чокыры өстенә каплый торган карама кабыкларын да китер...

Зариф күпме төпченсә дә, карт башка сүз әйтмәде. Кушкан нәрсәләре төялеп беткәч, арбага менеп утырды.

Зариф үзенең жиденче класста укый торган улы Зөфәрне чакырып алды:

—Бабаң каядыр бармакчы була, Жәмил картларгадыр, мөгаен,—диде ул ана.—Бар, күз-колак бул. Калдырып китмә. Үзең алып бар, үзең алып кайт, ишетсен колагың!

Ләкин Җәмил картлар урамына борыла башлагач, Кыяметдин бабай дилбегәне тартты:

—Кая барасың?.. Типтәр очына алып бар, зират ягына.

Малай аптырабрак торгач, дилбегәне бөтенләй үз кулына алды. Авыл башына чыккач, атны зират капкасы алдына илтеп туктатты. Аннары үзе зиратка кереп, карчыгы кабере янында бер урын сайлады.

—Әйдә, улым, төшер кабыкларны. Саламны да шунда илт.

Бабай, бик тәфсилләп, карчыгы кабере янындагы буш урынга салам түшәде. Эшен төгәлләгәч, тагын Зөфәргә дәште:

—Капла кабыкларны салам өстенә. Иплэп капла! Кар керерлек, тун үтәрлек булмасын. Миңа кабер казыганда халык рәнжемәсен!..

Шул көннән соң карт, бу фани дөнья белән алыш-биреш бетте дигән кебек, бар нәрсәгә битараф булып калды. Сиңа да башка әйтер сүзем юк дигәндәй, Ходайга да ялвармый. Йә көннәр буе урын өстендә ята, йә баскычка чыгып утыра да үзенең бетмәс-төкәнмәс уйларына чума.

Авылдашлары аның турында:

—Бу карт чынлап торып теге дөньяга җыенды, дигән фикергә килделәр. Ләкин...

Ләкин һич көтмәгәндә бабайга җан керде.

Әбиләр чуагының соңгы көннәре. Карт, көзге кояшның сүрән нурларына йөзен куеп, баскычта йокымсырап утыра. Шулчак капка ачылып китте дә ишегалдына йөк машинасы килеп керде. Бер яшь кыз белән бер егет көлешә-көлешә машинадан капчык бушата башладылар.

Кыяметдин бабай башта, гаҗәпсенеп, утырган урыныннан гына карап торды. Аннары, кузгалып, якынрак килде. Капчыкларга таягы белән төртеп-төртеп карады, куллары белән капшады.

—Нәмәрсә бу, кызым? Кемгә?

—Бодай, бабай, бодай. Сезнең двурга кергәч, кемгә булсын инде!

Картның йөнтәс кашлары өскәрәк күтәрелде. Ул, ниндидер авыр мәсьәлә чишкәндәй, озак уйлап торды.

—Бодай дисеңме? Безгә дисеңме? Шушы бөтенесеме?..

Ул калтыранган куллары белән капчык авызын чишәргә кереште, ләкин булдыра алмады. Әлеге егет чишеп бирде.

Карт үзенең корыган ботак-тармактай ябык кулларына бодай учлап алды, күзләренә ышанмагандай, озак карап торды, аннары әкрен генә капчыкка агыза башлады.

—Ипекә-әй! Сөбханалла! Сөбханалла!.. Балалар ачка үлми икән болай булгач, Ходайга шөкер! Ходайга мең шөкер!

—Ни сөйлисең, Кыяметдин бабай!—дип көлде егет.—Хәзерге заманда ачка үләмени кеше!

—Җәе бик хәвефле ие бит! Ничек кенә җаен чыгардыгыз соң, хикмәти Хода? Бу сүзләр егеткә тагын көлке тоелды.

—Гел Ходайга гына ышанып тормыйбыз бит, бабай! Үзебез дә бераз

кыймылдыйбыз. Жире ничек эшкәртелә, ашламасы күпме кирә!

—Алай икән, алай икән... Мал-туар гына кырылмаса инде...

—Кырылмас, бабай, курыкма. Элекке замандагы корылык түгел бит... Курмы да бар, икмәк тә... Себер дә, көньяк районнар да ярдәм итә.

Кыяметдин бабай тагын озак кына уйланып торды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

«Менә Ходайның хикмәте! Аңламассың хәзерге халыкны,—дип уйлый иде ул.—Көньяктан да җибәрәләр, диме? Бурычка микән соң?.. Үзбәк ягында җир тетрәү булгач, студин малай, ялын ташлап, җәй буе шунда барып эшләгән иде. Шуның өчен җибәрделәр микән әллә?.. Шөкер Ходайга! Меннән мең шөкер!»

Бу көнне карт тамагына умыртып ашады. Аның йөзе нурланып китте. Колагы да ничектер яхшырак ишетә башлаган кебек булды. Өстәл янында сүзгә кушылып, хәтта балаларны шаярткан булып утырды. Ашап туйгач, Актәпине дисбесе белән уйнатты.

Икенче көнне иртә таңнан Зариф ат җигеп кайтканда, бабай инде ишегалдында иде.

—Кайттыңмы? Ашап чык әйдә!—дип каршы алды ул аны.—Килен бик тәмле каз шулпасы пешергән. Ашык-пошык ашама, йөрәгеңә ятмас... Атыңны үзем карап торырмын...

Ләкин... Зариф ашап чыкканда, Кыяметдин бабай каядыр китеп югалган иде. Капка баганасына бәйләп куйган аты да урынында юк...

Зариф аптырап урамга чыкты, тыкрык башларыннан карап килде...

Кешеләрдән сораштырыйм дип кибет янына таба барганда, Типтәр урамы чатыннан атка утырган Кыяметдин бабай үзе килеп чыкты. Арбасына салам төягән, карама кабыклары салган. Кәефле генә юырттырып кайта.

—Кар астында череп ятмасыннар әле... кабыкларны әйтәм,—диде ул, арбасындагы йөгенә ымлап.—Бәрәңге чокырына капларга кирәк булыр. Кышы салкын килеп, туңы да тирәнгә китсә, дим... Әйдә, бахбай, теркелдә! Кайткач бирем бер көлтә!..

**РЕДАКЦИЯДӘН:**

Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә, ягъни 80 ел элек, Татарстанның Минзәлә районы Югары Тәкермән авылында колхозчы гаиләсендә туа. 1949 елда шул ук райондагы Күзкәй авылы урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Иске Мәлкән җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшли башлый, ике елдан Түбән Тәкермән авылы мәктәбенә күчә, анда укытучы, соңыннан уку-укыту эшләре мөдире була.

1960-1965 елларда Г.Сабитов Казан телевидение студиясендә әдәби-драматик тапшырулар буенча өлкән мөхәррир, аннан «Ялкын» журналында әдәби бүлек мөдире булып эшли. 1965 елда «Чаян» журналы редакциясенә күчә, анда башта—фельетончы, соңыннан, 1968-70 еллар арасында, журналның җаваплы секретаре вазифасын башкара. 1970 елдан ул әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә. Әдипнең «Туган җир туфрагы» («Айбаш»), «Агач аяклы кеше», «Өч күңел», «Корбан ашы», «Сәйлүн чәе», «Урман кызы», «Хәвефле җәй», «Кәккүк ялгыша икән» кебек халыкчан матур тел белән, кызыклы, табигый сюжетларга корып язылган хикәяләрен татар укучысы яратып кабул итте. Аның әсәрләре сәнгатьчә эшләнеше һәм милли эстетик хасиятләре җәһәтеннән югары сыйфатлы булулары белән аерылып тора.

Габделхәй Сабитов көндәлек матбугатта, шулай ук аерым җыентыкларда басылган үзенчәлекле очерклары һәм әдәби тәрҗемәләре белән дә укучыларга таныш. Э.Распеның мәшһүр «Барон фон Мюнхаузен маҗаралары»н, П.Трэверсның «Мэри Попинс», Ф.Златенның «Бемби» («Урман әкияте») повестьларын татар укучылары Г.Сабитов тәрҗемәсендә укыйлар.

Ул 1995 елда Казан шәһәрендә вафат була, туган авылы зиратында җирләнә.

«Хәвефле җәй» хикәясе 1966 елда язылган, 2010 елда ТКНда дөнья күргән «Ай сукмагы» китабыннан алынды.

# ШИГЪРИ ҖАН БӘЯНЫ

Хәзерге кешене нәрсә белән дә булса гаҗәпләндерүе бик тә кыен, билгеле. Ләкин... Ләкин шулай булса да, бүгенге тормышыбызның үтә житди мөнәсәбәтләрен чагылдырган менә бу күренешкә игътибар итегез әле. Соңгы елларда актив иҗат итә башлаган Халисә Ширмәннең «Асылъяр» исемле бәянында тасвирлана ул. Әлеге әсәрнең төп героинясы Асылъяр кияүгә чыгарга җыена:




«...—Мин көлмим, Әлфис. Әгәр дә син мине яратсаң һәм кияүгә алырга риза булсаң, мин сиңа барыр идем. Тик өч шартым бар.

Кыз егетне үзеннән читкәрәк этәрде. Әлфис бераз вакыт тынын җыеп торгач, Гөлкәйнең кулларын ирененә китереп үпте.

—Нинди генә шартлар булса да, мин аларны үтәргә әзер. Миңа кияүгә чыгарга риза бул, Гөлкәй!

—Ашыкма, Әлфис.

Кыз да бераз тынып, әйтергә теләгән сүзләрен тәртипкә китерде.

—Иң авыр шартым: миннән мәхәббәт таләп итмә, Әлфис. Яраткан кешем барлыгын күптән беләсең. Мин аны беркайчан да оныта алмамын кебек. Гаилә булып торганда сиңа хыянәт итмәм. Иң тугры хатын булырмын, балалар үстербез. Тик мәхәббәтем чакырса, мин синнән китәчәкмен, Әлфис. Иң авыр шартым шул.

Әлфис дәшмәде. Шактый озак тын торды. Аннан көрсенеп куйды, яңадан учларына Гөлкәйнең кулларын кысты.

—Хәтерлисеңме, мин сиңа бер тапкыр әйткән идем: мәхәббәт бер генә була, тик ул ике йөрәктә яши. Минем мәхәббәтемнең яртысы синеке булыр, Гөлкәй. Мин синең беренче шартыңа риза.

—Икенче шартым: мин аспирантурага укырга керергә телим.

—Монысына мин һәрвакыт риза! Ирләр укыган хатыннарны бик яратмыйлар инде, шулай да мин сиңа кулдан килгәнчә ярдәм итәрмен. Бу шартыңны да үтәргә мин әзер.

—Алайса, өченчесе бөтенләй җиңел инде: Әлфис, мин чәчләремне кистерәчәкмен.

Әлфис аһ! итте. Шунда ук Гөлкәйнең кара толымнарын учларына чылбыр ясап менгезде, сыйпады, үпте.

—Гөлкәй! Ни сөйлисең син! Синең чәчләрең бит дөнья бәясе тора, нишләргә уйлыйсың?!

—Әлфис, мин сиңа кияүгә чыксам да, чыкмасам да, чәчләремне кистерәчәкмен. Бәлки хәзер үк түгел, бераздан соң булса да, мин чәчләремне кистерәчәкмен.

Бер үк сүзләрне үҗәтләнеп кабатлаган кызга Әлфис аптырап карады. Бу аның өчен иң авыр шарт иде. Нәрсә булган Гөлкәйгә?!

—Бу шартымны кабул итмәсәң, гафу ит, Әлфис. Димәк, мин сиңа лаеклы түгел.

—Гөлкәй... Мин риза. Нишләтәсең син мине, аһ, гөлем-гөлкәем...

Гөлкәй сискәнеп китте. Бу сүзләр тик аныкы, Мансур Ибраһимовичныкы гына иде. Әлфис кагылырга ярамаган урынга кагылды. Үзе сизмәстән кагылды.

—Дүртенче шартым калган: мине беркайчан да алай дип атама! Оныт ул сүзләрне! Оныт!»

Халисә Ширмән әсәреннән алынган менә шушы бер өзек (озынрак тоелса,

укучы гафу итсен, чөнки бу күренеш тоташ кабул ителә) бик күп яктан уйландыра. Тормыш һәм кеше язмышлары ягыннан алсак—никадәр фаҗига бу күренештә. Кыз бала үзе яратмаган кешегә кияүгә чыкканда нинди үтергеч шартлар куя бит! Ир-атны үтерә торган шартлар! Аның «миннән мәхәббәт таләп итмә!» диюенең үзендә генә дә күпме җан өшеткеч хөкем, мөнәсәбәт, боз салкынлыгы! Гүяки кыз бала үзенең булачак иренең йөрәксез (димәк ки бернинди хис-кичерешсез) генә яшәргә риза булуын тели.

Ә иҗади осталык ягыннан алып карасак, Халисә Ширмән биредә үз геройларын нинди көчле психологик киеренкелек халәте аша үткәрә! Алар гүяки бер табиб бүлмәсендәге УЗИ аппаратына килеп кергәннәр диярсең! Шушы урында хатын-кыз иҗатчылар хакында әледән-әле кузгалып ала торган бәхәс тә искә төшә. Кайберәүләр «әдәби иҗатта женесләргә бүлү юк»—дигәндәйрәк фикерне кабатларга ярата бит.

Андый карашта торучыларга мин Халисә Ширмән әсәрендәге әле генә без күреп киткән өзекне укытып карар идем. Әнә шундый тирән психологик халәтне—кыз баланың гаять нечкә һәм үтә каршылыклы хисләре бәрелешеннән хасил булган үтә киеренке халәтне—безнең ир-ат язучыларыбыз белә, күрә, аңлый һәм тасвирлый аламы? Юк бит!

Әйе, әлеге өзектә бер Халисә Ширмән иҗатының гына түгел, ә тулаем татар прозасының иң уңай сыйфатлары калку чагыла. Алар: укучылар өчен үтә якын һәм кадерле булган мәхәббәт темасының әдәби әсәрләрдә әйдәп баруы һәм герой-героиняларның нигездә әнә шул мохиттә сыналуы, хис-кичерешләргә аерым һәм зур игътибар бирелү, реаль вакыйгаларны бик тә тормышчан рәвештә ачып, дәлилләп, ныгытып бара торган психологизм, геройларның рухи кичерешләрен тулыландыручы матур табигать күренешләрен тасвирлау; авторның шигъри, сәнгать чараларына бай һәм сыгылмалы теле...

Әдәби иҗатта әнә шундый дөрес һәм киләчәктә бик тә зур казанышлар китерергә мөмкинлек бирә торган юлны тапкан Халисә Ширмән үз әсәрләре белән чын мәгънәсендә укучылар мәхәббәтен яулады. Шуңа күрә биредә аның басылып чыккан китапларын бераз гына барлап, күрсәтеп үтү дә сорала кебек.

Югарыда без укып киткән өзек күптән түгел Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Язмышлардан юк ла узмышым...» исемле җыентыктан алынды. Анда язучының «Яшәү моңы» һәм «Асылъяр» исемле ике бәяны урнаштырылган. Моңа кадәр язучының тагын ике китабы төрле нәшриятларда басылган иде. Ә хикәяләре белән Халисә Ширмән «Казан утлары», «Идел» журналларында һәм «Мәдәни җомга» атналыгында еш күренә. Аның бер хикәясе «Казан утлары» журналы оештырган конкурста (2007 ел) җиңеп тә чыкты. Халисә Ширмәннең әдәби тел мәсьәләләренә багышланган мәкаләләре һәм каләмдәшләре алдында ясаган чыгышлары да истә кала торган була.

Аны иҗатчы буларак халык күңеленә бигрәк тә якынайткан юл—телевизион фильмнар булды. «Кайтаваз», «Язмышлардан узмышлар юк», «Еракта гы йолдызым»—соңгы елларда «Татарстан—Яңа гасыр» каналында барган һәм тамашачылар яратып кабул иткән, көтеп алып караган телефильмнар алар. Аларның һәммәсенең сценарий авторы—Халисә Ширмән.

Янадан «Асылъяр» бәянына әйләнеп кайтыйк әле. Ул төрле төбәкләрдән Казанга укырга килгән беренче курс кызларының бәхетле көннәрен тасвирлаудан башланып китә. Биредә автор сурәтләгән күренешләр барысы да җанлы булып һәм үзенчәлекле кешеләр, аларның кабатланмас сөйләшүләре белән күз алдына килә.

Әмма үзәктә ерак Себердән килгән Гөлкәй тора—«озын толымнары билдән түбән төшкән зур кара күзле кыз...» Аның үзләрендә фәлсәфә фәнен укытучы яшь иргә гашыйк булуы бәяндагы вакыйгаларны куертып, «әсәрнең» психологик киеренкелеген арттырып җибәрә.

Ә көннәрдән бер көнне бу укытучы авырып киткәч, Гөлкәй үзенең иптәш кызын ияртеп аның хәлен белергә өенә дә бара, шунда укытучының гаилә хәле дә ачыклана—аны хатыны ташлап киткән икән...

Бу укытучы кайчандыр Себердә эшләп йөргән, ул Гөлкәйнең әти-әнисен дә яхшы гына белә икән... Шуңа күрә җәйге яллар җиткәч Гөлкәй аны үз

авылларына кунакка чакыра... Биредә табигать кочагында калгач ике йөрәкнең мәхәббәт иркенә бирелүе дә әсәрдә бик шагыйранә тасвирлана. Бәянның бу өлеше—кыз баланың мәхәббәт ялкынында януы—язучының үзенең дә иҗади көчен, аның каләменең зур мөмкинлекләрен раслый.

Әмма янадан калага кайткач укытучы үзгәреп китә—ул Гөлкәйдән читләшә башлый. Моны үзенең балалары хакына дип, җаваплы эшенә зыян килер дип борчылуы белән аклый. Кыскасы, ул курка! Әсәрдән әнә шул аңлашыла.

Язмабызны башлаганда без укыган бик драматик өзек Гөлкәйнең әнә шул хәлләрдән соң үзе сөймәгән кешегә кияүгә чыгарга җыенуын күрсәтә иде.

Әйе, бу автор үз геройларының күңел төпкелләренә бик тә тирән үтеп керә, алда барган гарасатларны зур психологик осталык, нечкәлек белән ачып бирә. «Иптәш кызының бертуктаусыз нәрсәдер такылдавыннан Гөлкәй гарык булды, китапханәдә утырырга кирәклеген сылтау итеп, тизрәк кыздан котылырга ашыкты. Аның үзенең генә каласы, укытучысы әйткән һәр сүзне күңелендә торгызып, янадан рәхәт мизгелләрне кайтарасы килә иде. Йа Ходa, нинди бәхет бирде аңа ул бүген! Кыз укытучы алдында калтырап басып торганын гел онытты. Булсын, укытучысы өйләнгән булсын, балалары да булсын—Гөлкәй бит аның тормышына бәреп керергә җыенмый; бары шундый гүзәл, мөкатдәс укытучы белән икәүдән-икәү калып, сөйләшүсерләшүен янадан күңеленнән кичерергә генә тели... Кыз, үз уйларының татлы ләззәтенә чумып, әкрен генә шәһәрнең икенче читендә диярлек урнашкан тулай торакка таба җәяү атлады...»

Менә шушы һәм алдарак кичерелгән башка өзекләрдән күрүебезчә, Халисә Ширмән мәхәббәт кебек нечкә хис турында бик тә сак, аның бөтен нечкәлекләрен тоеп һәм шул тойгыны укучыда да тудырып, анда да яшәтеп яза. Мисал өчен, Себер урманында Гөлкәйнең сөйгәне белән ялгызы гына калуы һәм андагы мәхәббәт мизгелләре үзе бер гүзәл поэма кебек укыла.

«Асылъяр» дип бик тә мәгънәле исем белән аталган бу бәян үзе тулаем алганда да яшьлек хисләренә, аларның кеше йөрәге өчен алыштыргысыз бәһасенә мәдхия дип кабул ителә. Әсәр укучының җанын, күңелен әлеге бөек кичереш биеклегенә, бөеклегенә күтәрә. Ана әнә шул бөек бәхетне бүләк итә!

Халисә Ширмәннең бу китабында тагын «Яшәү моңы» дип исемләнгән бәян да бар. Анысының үзәгендә яшь Алинә язмышы тора.

Бу әсәр бигрәк тә киеренке психологик халәттә башланып китә: Алинә бөтен көченә йөгерә, кемнәндер, нәрсәдәндер качып бара ул.

Бәянның беренче битендә үк әдибә каләме белән хасил ителгән әлеге психологик табышмак укучы күңелендә кызыклы бер эчке пружина тудыра һәм әнә шул халәт укучыны әсәр беткәнче киеренкелектә тота. Укучы «Нәрсә булган?» дигән сорауга җавап эзләргә мәҗбүр ителә. Мондый алым үзе үк иҗатчының шактый ук осталыкка ирешкәнлеген раслап тора.

Әсәрдә тагын шунысы бик мөһим төс һәм мәгънә ала: Алинә урманга карап, урманга таба йөгерә. Бу хәл гадәти яшәеш ягыннан караганда шактый сәер күренә, чөнки без моңа кадәр куркыныч ерткычлар урманда яши дип күнеккән, шулай тәрбияләнгән бит инде. Ә биредә исә яшь кыз, киресенчә, урманга таба йөгерә. Димәк, серлелек тагын да арта, табышмак сере тагын да ерагая төшә.

Бераз алгарак китеп булса да әйтик: Алинәнең урманга таба йөгерүе торабара символик мәгънәдә аңлашыла башлый...

Әйе, Алинә авыл кызы икән. Ул шәһәрдә яши башлагач машинада барганда ире һәм баласы белән юл фаҗигасенә эләккән. Аның иң кадерле кешеләре һәлак булган! Ә бу фаҗигага кадәр аз гына алдарак алар өчесе бергәләп урманда шундый бәхетле сәгатьләр кичергән булганнар... Алинә хәзер менә психологик шок хәлендә шул урманга таба йөгерә. Кеше гомерләрен өзә торган, кеше бәхетләрен таптый һәм юкка чыгара торган шәһәр һәм зур-зур трассалар фаҗигасеннән качарга тели ул!

Язучы үз әсәренең сюжетын әнә шулай бик оста кора. Бу бәян мавыктыргыч детектив кебек укыла. Алинәнең фаҗигадан соң алган психологик шок нәтиҗәсендә хәтерен югалтуы, хәтта үзенең кем икәнен дә белмәве, үз исемен онытуы—шулай ук безнең өчен башта

олы сер тудыра, ул серне беләсе килү теләге әсәр дәвамында сүрелмичә бара.

«Яшәү моңы»на яңа геройлар күп кертелми. Алар—Гамир, Рөстәм, Шурик. Алинәнең менә шушы егетләр белән төрле-төрле мөнәсәбәте аша автор эчкерсез ярдәмчеллекне, кешелеклелекне, намуслы булуны өскә күтәрә, югары гуманизм сыйфатларын мактый.

Тулаем алганда бу бәянга да мәгънәви тирәнлек һәм психологик нечкәлек, теманың үтә актуальлеге, мөһимлеге хас. Халисә Ширмәнгә хас булганча биредә дә җөмләләр бик тә төзек, хис-кичерешкә бай, хәтта шигъри аһәңгә ия. Ә болар, әлбәттә, үз чиратында әсәрнең укучыга тәэсир көчен арттыра.

Күп кенә яшь авторларның әсәрләрен укыганда сюжетта вакыйгаларның күплеген, хәтта ки артык күплеген күрәсең. Аларның байтагы мәгънәви һәм логик яктан акланмый да—бары тик тышкы эффектка корылган шау-шу булып кына кала. Ә менә биредә вакыйга һәм күренешләр фикри һәм хисси яктан бер-берсенә бик гармоник һәм табигый рәвештә үрелеп бара. Вакыйгалар агышында укучының маңгай күзе генә түгел, ә күңел күзе дә бик актив яши.

«Яшәү моңы» Халисә Ширмәннең менә мондый шигъри юллары белән тәгәлләнә:

*Үләм, дисең.*
*Ә менә син*
*Үлмичә кара яшәп.*
*Мамык мендәр урынына*
*Булса да салам түшәк,*
*Кемдер каймак ашаганда,*
*Син каты кимерсәң дә,*
*Берәү шәраб чөмергәндә,*
*Син суга тилмерсәң дә...*

.......................

*Үртәлүнең соң чигендә*
*Тамса да күз яшьләрең,*
*«Булганына—рәхмәт!»—диеп,*
*Ходайга әйтеп кара.*

.......................

*Мең газаптан мең терелеп,*
*Бер гади булып, яшьнәп,*
*Сызланып кара яшәп...*

Мона кадәр безнең прозаиклар үзләре сирәк-мирәк кенә шигырь язсалар да аны әдәби әсәргә бирәр геройларыныкы диеп кертәләр иде. Г.Бәшировның «Җидегән чишмә»се, Г.Әпсәләмовның «Гөлшаһидә» жыры һ.б. лар әнә шулай туды. Ә менә Халисә Ширмән куркыпшикләнеп тормыйча үз шигыре белән проза әсәрен тәмамлап куя.

«Бу автор иҗатында бер житешсезлек тә күренмимени соң?»—дип сорарлар бәлки.

Әйе, кайчагында, бигрәк тә. «Яшәү моңы» бәянын укыганда, Американың Голливуд фильмнары искә төшеп ала. Сүз унаенда искәртеп үтик: хәзерге яшь прозаиклар иҗатында, чыннан да, икенчеллек (вторичность) еш кына күзәтелә. Алар үзләренең байтак әсәрләрен телевизордан караган кинолар тәэсирендә, шул сюжетларны кертеп яза. Ә Халисә Ширмән бу яшьлек авыруыннан тиз арынды. Аның әлеге китаптагы «Асыльяр» бәяны һәм матбугатта күренгән хикәяләре («Казан утлары»нда басылган «Кыргыйлык» хикәясе бигрәк тә уңышлы мисал) безнең алда өлгергән прозаик иҗаты икәнлеген ышандырып раслый. Аның яңа әсәрләрен укып сөенергә насыйп булсын!

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**

**Редакциядән:**

*2011 елның 29 апрелендә Милли китапханәдә «Ел китабы—2009» конкурсына йомгак ясау тантанасы узды. Х. Ширмәннең «Язмышлардан юк ла узмышым» китабы чәчмә әсәрләр арасында өченче урынны алды.*

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Байлангар

Байлангар авылы Кукмара районында, район үзәге Кукмара эшчеләр бистәсеннән 12 чакрымда, Вятка Аланы пристаненнән 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы шактый тарихи чыганакларда теркәлгән. А.Артемьев тарихи белешмәсеннән авылны түбәндәгечә күз алдына китерәбез. Нурма суы ярына утырган авылның 150 хуҗалыгында 532 ир-ат һәм 563 хатын-кыз яшәгән, мәчет эшләгән. Нажия Борһанова мәгълүматларына караганда, Байлангар авылы халкы Өлге, Татар Кукмарасы, Манзарас, Кәчимир, Киндеркүл, Ташлы елга, Пычак, Арпаяз, Камышлы, Каенсар, Иске Пенәгәр авыллары белән Өлге җыены үткәргәннәр. Ул июньнең соңгы декадасында үткәрелгән.

Олылар авыллары оешуын болай сөйлиләр.

Авылны Чурай тавы итәгенә нигезләгәннәр. Бу тирәләрдә авыл оешканчы кара урман үскән. Иске Йорт дигән авылдан 3 бай малае бирегә төшеп урманнарны кискәннәр, йортлар төзегәннәр һәм яшәп калганнар. Авылга алар хөрмәтенә Байсланнар исеме бирелгән. Тора-бара атама Байлангар булып үзгәреп киткән. Авыл XV гасыр ахырларында оешкан.

Авылны урталай ярып Нурма елгасы ага. Елганың бер ягында Аю күле ялтырап ята. Бик еракларда кайткан кешеләр суын алып китә торган изге чишмә—Салкын чишмә белән дан тота Байлангар. Бу чишмә бура белән буралган, түбәсенә манара белән ай куелган. Аның янында бер кабер дә бар. Бу каберне карап, чистартып торалар.

Авыл тирәсендә вак урманнар бар. Халык аларны Рәхилә, Рәхимә һәм Кашаф урманнары дип атый. Элекке заманнардан ук авыл халкының кушаматы «усаллар» булган. Халык моны чукындыру сәясәте чоры белән бәйләп аңлата. Чукындыручылар килүне алдан күргән авыл халкы Чурай тау башына менгән һәм аларны таш атып каршы алган, чукындыруга каршы торган.

Олылар сөйләве буенча, элек авылда зур гына «ат тегермәне» булган. Тегермән ташларын махсус җайланма ярдәмендә атлар әйләндергән.

Элек авыл уртасында зур гына мәчет эшләгән. Янында мәдрәсә дә булган. Анда Нурый мулла белән Зариф мулла дин сабагы укытканнар. Яманаты чыккан елларда мәчетнең манарасы киселә. Бүгенге көндә элекке урынында мәчет балкып утыра.

Байлангар авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә язучы Мәгъсүм Нәҗип улы Насыйбуллин туып-үскән.

---

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6нчы санында.*

## Бакча-Сарай

Бакча-Сарай бистәсе Югары Ослан районында, район үзәге Югары Ослан авылыннан 23 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Вахитов исемендәге авылдан—1, Казаннан—26, Ключищи пристаненнән 1 чакрым ераклыкта урнашкан.

Бистә Идел суы буена, тау башына утырган.

Казан елга портында тиз йөрешле «Метеор»га утырсаң, 15 минут дигәндә Бакча-Сарай авылына килеп житәсең. Яр буйлап тезелеп киткән таллар, чияләр, алмагачлар сине сәламләп каршы алалар.

Бу авылны 1927-30 елларда тирә-юньдәге татар авылларыннан күчеп килеп утырган кешеләр төзегән.

Авылның бер башыннан катнаш урман сузылып китә. Анда имән, каен, өрәңге, усак, нарат агачлары, чикләвек куаклары үсә. Халык урманнан жиләк, гөмбә, чикләвек жыя.

Бистә янында суларын Иделгә илтүче чишмә-чыганаклар күп. Зур чокыр, Коры чокыр дип йөртелгән инешләр дә ага.

Жәй көне авылда бакчачылар ял итә. Ял итүчеләр Мәскәүдән үк кайталар.

Авылны чыккач та зират урнашкан. Ул чиста, аны бистә халкы игътибар үзәгендә тота.

Элек халык арасында Мөбарәкша исемле аксакал карт бик дәрәжәле булган. Ул бик матур бакча булдырган, күп төрле агачлар, жиләк-жимеш һәм чәчәкләр үстергән. Хәзер авылда помидор үстерү белән шөгыльләнәләр. Бер гаилә икешәр мең төп помидор үстерә.

Балалар укырга күрше авылга йөри. Бистәгә газ кертелмәгән, мәдәният йорты юк.

## Бакшанды

Бакшанды авылы Саба районында, район үзәге Байлар Сабасы авылыннан 18 чакрымда, жирле үзидарә советы үзәге Иске Михтаннән—4, Шәмәрдән станциясеннән 17 чакрымда урнашкан.

Авыл атамасы аны беренче нигезләгән кеше исеменнән алынган. Тау ягыннан чыккан йомышлы татар кенәзе 1620 елда Саба районындагы Бакшанды авылын нигезләгән. Бакшанды кенәзгә жирләр башка урыннардан да бирелгән. Тарихи документлар шул хакта сөйли.

И.А.Износков хезмәтендә дә (XIX йөз) Бакшанды авылы телгә алына. Мичән суы ярына утырган бу авылда 75 ир-ат һәм 76 хатын-кыз көн күргән. Алар ислам дине тотканнар.

Н.Б.Борһанова мәгълүматларына караганда, Бакшанды авылы халкы май ахырында күршедәге Югары Утар, Түбән Утар, Керәнне, Өчиле авыллары белән бергәләшеп Күпербаш жыены үткәргән.

Олы буын авыл тарихын болай сөйли. Авыл борынгы, нигездә, анда 3 нәсел яшәгән. Бер нәсел Бакшанды бабай белән бәйләнешле, икенчесе Чистайдан килгән, өченчесен әйтә алмыйлар. Элек тә һәм хәзер дә авыл бары мөселманнардан торган. Авыл янында борынгы зират бар, халык аны иске зират дип йөртә.

## Бик-Үти

Бик-Үти авылы Буа районында, район үзәге Буа шәһәреннән 26 чакрымда, Кильдураз тимер юл станциясеннән —15, Тәтештән 68 чакрым ераклыкта урнашкан. Бик-Үти—жирле үзидарә советы үзәге.

Бик-Үти авылы тарихи белешмәләрдә искә алына. Д.А.Корсаков белешмәсендә (XVIII йөз) Үти һәм Бик авыллары икесе ике авыл буларак теркәлгән. Үти авылында 52 ясаклы, 23 керәшен татары, ә Бик авылында 177 ясаклы, 9 керәшен татары көн иткән. 1898 елгы чыганакта авыл Биково-Утеево дип атала һәм анда татарлар яшәве күрсәтелә. К.П.Берстель белешмәсендә авыл Биково Утеево дип күрсәтелгән һәм анда 967 татар кешесе яшәгәнлеге әйтелгән.

Олылар сөйләвенә караганда, Бик бабай һәм Үти бабай шушы якларга килеп чыгып йорт нигезләгәннәр. Аларның берсе авылның югары очына, ә икенчесе түбән очка утырган. Аннары бу җирләргә тагын кешеләр килеп төпләнгәннәр. Шулай итеп, ике авыл барлыкка килгән: Бик авылы һәм Үти авылы. Вакыты белән ике авыл арасында сугышлар да чыккан. Ике авыл халкы бер-берсенә кыз бирешергә теләмәгән. Ике яшь кеше бик яратышсалар, ул вакытта егеткә кызны урлап китүдән башка чара булмаган.

Еллар үткән. Бик бабай, аннан соң Үти бабай вафат булганнар. Аларны һәр авыл үз зиратына күмгән.

Күпмедер вакыт үткәч бу авыллар кушылганнар һәм Бик-Үти авылы барлыкка килгән. Әле хәзер дә авылның бер башын Бикләр, ә икенчесен Үтиләр дип йөртәләр.

Үтиләр унган халык булганнар, ә Бикләр күбесенчә сату-алу белән шөгыльләнгән.

Авыл Кырыеннан Олы Бола елгасы ага. Аңа Кушлар чокыры, Каен-үзәк, Тирән чокыр, Яукорылган елгалары коя. Бола бассейнында, авыл янында Тимерче күле һәм Баллы куак күле бар. Авыл уртасында Сиртмәле кое бар. Халык аны «чәй суы» дип йөртә, аның суы тәмле.

Авылдан ерак та түгел Кукау җире җәелгән. Халык сүзенә караганда, элек анда урыс авылы булган. Халкы таралгач, бу авыл җире Бик-Үти авылы кергән күмәк хуҗалык җирләренә кушылган. Кукаудан ерак түгел Алмагач җире дигән урында бик матур алмагач бакчасы булган. Аларны кисеп урынын сукалаганнар. Хәзер анда тагын агачлар утырткannар. Моннан киткәч, авылдан шактый еракта Баллы куак күле бар. Халыкта бу тирәне Женле урын дип әйтәләр. Чөнки бу турыда гел төрле фаҗигалар булып тора икән.

Бик-Үти һәм Ташкичү авыллары «Марс» колхозына берләшкәннәр. Бу ике авыл уртасында катнаш урман үсә. Аны халык Ташкичү урманы дип атый. Ташкичү урманында халык бәйрәмнәр үткәрә, укучылар экскурсияләргә баралар.

Авылда йортлар 4 урамга утырган. Югары оч (Бикләр), Түбән оч (Үтиләр), Урта урам (Бикләрнең калганы) һәм Аслап урамы (Үтиләрнең калганы). Авылда барлыгы 112 йорт исәпләнә, аларда 121 ир-ат, 212 хатын-кыз яши.

Авылда өч зират. Берсе—Бик бабай зираты, икенчесе—Үти бабайныкы. Бу зиратларга мәетләр күмелми. Ә өченчесе—хәзерге вакытта мәетләр күмелә торган зират.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# М

**МӘҖМУГА** (гарәп. җыентык), төрки әдәбиятларында җыентык, альманах, сайланма әсәрләр җыелмасы. Күп очракларда М. дип «хрестоматия» атамасына якын булган чәчмә һәм тезмә әсәрләрне үз эченә алган китаплар яки фәнни хезмәтләр җыентыгын атаганнар (мәс., «Мәрҗани мәҗмугасе»). Аерым очракларда «М» атамасы «журнал» мәгънәсендә кулланган.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миннегулов.*

**«МӘҖМУГЫЛЬ-ХИКАЙЯТ»**, татар әдәбияты ядкәре. Ул елларда Көнбатыш Себердә яшәгән, чыгышы б-н Казан арты кешесе Мөхәммәтрәхим ибне Рәфыйкъ әл-Казаный тарафыннан төзелгән. Романтик, фантастик, мәхәббәт-романтик һәм нәсихәт характердагы әкият һәм хикайятләр җыентыгын тәшкил итә. Алар сюжет (фарсы язма чыганакларга барып тоташа) катлаулыгы һәм төрлелеге, композициянең төзеклеге, күпсанлы персонажлары, теленең байлыгы һәм нәфислеге б-н аерылып торалар. Беренче тапкыр Казанда 1994 тә басыла.

Әд.: Исмагилов Н.Ф. Сборник «Маджмугал-хикаят» как проявление литературных связей с Востоком // Средневековая татарская литература (VIII-XVIII вв.). К., 1999.

*Н.Ф.Исмәгыйлев.*

**МӘКАМӘ** (гарәп.—сеанс, әңгәмә), урта гасыр гарәп, фарсы һәм төрек әдәбиятларындагы хәйләле (плутовская) новелла. 10 гасырда Гарәп хәлифәтендә барлыкка килә. Бу төр жанр әсәрләрендә гадәттә сәүдәгәрләрне яки түрәләрне алдаучы, алардан көлүче оста хәйләкәр хәрәкәт итә, хикәяләүче исә бу галәмәтләрне үз күзе б-н күрүче. М. ритмлы проза, рифмалар, катлаулы тел б-н язылганнар, сүз уйнату еш кулланылган. Циклларга (мәкамәт) берләштерелгәннәр. Аеруча гарәп-фарсы шагыйре Әхмәд әл-Хәмәдәни (чама б-н 52 новелла, 990) М.лары танылган. Бу циклның герое—үзенең талантын шантаж һәм караклык эшенә җиккән—шагыйрь, галим Әбү-л-Фәтх Искәндәри. Гарәп шагыйре Ибн әл-Хәрири (чама б-н 50 новелла, 12 йөз башы) циклы герое Әбү Зәйд ш.у. алдау өчен үзенең сүзгә осталыгын һәм шигъри сәләтен файдалана. Геройның сәнгатьчә һәм тапкыр сөйләү рәвеше, шигъри рифмасы М.дә камиллек дәрәҗәсенә җиткерелә.

Әд.: Крымский А. Арабская поэзия в очерках и образцах. М., 1906; Бади аз-Заман Абу-л-Фадл Ахмад ибн ал-Хусейн ал-Хамадани; Макамы. СПб., 1999.

*А.М.Ахунов.*

**МӘМСӘВИ** Ихсан Гомәр углы (1821, Казан губерниясе Казан өязе Мәмсә а. дип фаразлана—1871), дин эшлеклесе, шагыйрь. Гарәп һәм татар телләрендә язган. 1845 тән Нократ губерниясе Борбаш а. мәчет имам-хатибы һәм мәдрәсә мөдәррисе булып тора. Ш.Мәрҗани дини-фәлсәфи карашлары яклы. 1868 дә «Мөстә-фадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»ның 1 нче том кушымтасында аның әсәрләренә карата шигъри комментарийлар бастыра. Танылган замандашларына мәдхия һәм мәрсияләр багышлый.

Әд.: Татар әдәбияты тарихы. К., 1985. Т.2; Фәхретдин Р. Асар: Кыскача конспект-аннотация. К., 2003.

*А.М.Ахунов.*

**МӘНДИ КОТЫШ** (тулы исеме Мәнди бине Котыш бине Туеш бине Таганаш) (1976, хәзерге Башк. Респ. Көйоргәзе р-ны Кинзабыз а. дип фаразлана—9.4.1849, шунда ук), шагыйрь, хаттат. Гарәп һәм татар телләрендә язган. Берничә мәдрәсәдә белем ала, ш.и. Казанда да. Мал асрый, кымыз язый. Суфи нәкъшбәндиләр тәрикате тарафдары. Суфи эчтәлекле тезмә һәм чәчмә формада язылган кульязма рәвешендә дини-дидактик трактатлар авторы. Танылган әсәре—«Вакты сәхәр...».

*Х.Й.Миннегулов.*

**МӘНЗУМӘ** (гарәп.—назым—тәртипкә китерелгән сөйләм; тезмә), гарәп, фарсы һәм төрки-татар поэзиясендә—поэтик әсәр, поэма, эпик яки лироэпик әсәр. «Мәнзумә» дигән күпчелек формасы б-н шигъри җыентыкларны да атыйлар. Хәзерге фарсы әдәбиятында балладаны М. диләр. Татар әдәбиятында бу атама беренче тапкыр «Китабе Гөлстан бит-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санында басылып килә.*

төрки»дә искә алына. Әсәрдәге 5 хикаятне автор «хикаяте мәнзумә» дип атый.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘРСИЯ** (гарәп. елау-сыктау, некролог), шәрекъ поэзиясе жанры, гүр иясе булган танылган галимнәр, әдипләр, җәмәгать һәм дин эшлеклеләре, остазларга һ.б. багышланган элегик әсәр. М.дә аларның әхлакый сыйфатлары, кылган эшләре, гамәлләре санала. Бу жанр әсәрләренә элегик, кайгылы аһәң хас. М. мәдхия жанрына якын тора: икесенең дә катгый структурасы, төгәл сыйфатлары юк, икесенә дә макталган персонажларның яхшылыкларын күпертеп күрсәтү (гиперболаштыру) хас. Аерым үрнәкләре борынгы төрки әдәбиятта (кабер ташлары язмаларында), фольклорда очрый. Татар әдәбиятында М. жанрында Г.Утыз Имәни, Акмулла, Г.Тукай, Н.Думави, Ш.Бабич һ.б. язганнар.

Әд.: Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘСӘЛ** (гарәп. әдәп, әхлак өйрәтү өчен читләтеп сөйләнгән хикәя), әдәби жанр: 1) персонажлары хайван, җанвар, кошлар яки терек булмаган әйберләр булган кыска чәчмә, тезмә яки кушма формадагы читләтеп әйтүгә, кинаягә корылган хикәя; 2) мәкаль, әйтем. М.нең азагында, гадәттә, өстенлек итүче нәсыйхәт, мораль (әхлакый нәтиҗә) бирелә. Жанрның барлыкка килүе санскрит әдәбияты ядкәре «Панчатантра»ның «Кәлилә вә Димнә» исеме б-н гарәп теленә тәрҗемә ителүе б-н бәйле. Урта гасыр татар әдәбиятында аеруча киң тарала. К.Насыйри, Т.Яхин, Г.Тукай, М.Гафури, С.Рәмиев, Ә.Исхак, А.Шамуков иҗатларында урын алган.

Әд.: Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘСНӘВИ** (гарәп. икеләтелгән, янәшә куелган, кушылган), шәрекъ поэтик атамасы: 1) шигырь юллары бердәй үлчәмле, үзара рифмалашкан, интонацион һәм мәгънәви яктан чагыштырмача бөтен һәм мөстәкыйль бәет; 2) аа, бб, вв рәвешендә рифмалашучы бәетләрдән төзелгән фәлсәфи-дидактик, романтик, героик әсәр. М. формасы эпик поэзиягә хас; лирик шигырьләрдә монорим (бөтен шигырьгә бер рифма) кулланыла. Бу форма урта гасыр фарсы әдәбиятында барлыкка килеп, төрки халыклар әдәбиятларында киң тарала. Урта һәм зур күләмле эпик һәм лироэпик әсәрләрдә (Фирдәүсинең «Шаһнамә»се, Нәваинең «Хәмсә»се) еш очрый. М. формасында Баласагунинең «Котадгу белег» поэмасы, Котб, Хисам Кятиб, Мөхәммәдъяр поэмалары, Г.Утыз Имәни, Ә.Каргалый, Г.Чокрый, Г.Тукай, Н.Думави шигырьләре язылган.

Әд.: Квятковский А. Поэтический словарь. М., 1966; Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Әдәбият белеме сүзлеге. К., 1990.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛА КАЗЫЙ МӨХСИН** (14 йөз), Алтын Урда чоры төрки-татар шагыйре. «Китабе Гөлестан бит-төрки» кульязма җыентыгында урын алган газәл жанрында бер шигыре б-н мәгълүм. Анда лирик геройның сөйгәне, аның «адәмиләр жаны» булуы җырлана. Кызның чибәрлеге «ай б-н кояшны» таң калдыра, аның алдында зифа буйлы кипарислар баш ия.

Әд.: Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

**МӘҮЛАНА ГЫЙМАД МӘҮЛӘВИ** (14 йөз), төрки-татар шагыйре. «Мәүлана» тәхәллүсе б-н билгеле (гарәп. ия-без, хуҗабыз)—мөхтәрәм затларга, дин эшлеклеләренә мөрәҗәгать формасы. «Китабе Гөлстан бит-төрки» кульязма җыентыгына кергән үзенең бер шигыре (6 бәйт) б-н билгеле. Шигырьдә лирик геройның мәхәббәт газаплары кичерүе тасвирлана. Бу шигырьгә Сәйф Сараи назыйрә язган.

Әд.: Миңнегулов Х.Й. Сәйф Сараи: Тормышы һәм иҗаты. К., 1976; Сәйф Сараи. Гөлестан. Лирика. Дастан. К., 1999.

*Х.Й.Миңнегулов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# Радик Фәизов

## «Күңелле поезд»

Бернича еллар элек мин әнә шундый баш астында кечкенә генә хикәя язган идем. Арча—Казан поездында баручыларга бер дә күңелсезләнеп утырырга туры килмәвен, вагоннарга бертуктаусыз сыра, сагыз, тундырма, төрле ашамлыклар, көнбагыш, хәтта инә ише әйберләрне сатучыларның килеп керүен, аларның шәрран ярып үз тауарларын тәкъдим итүләрен, вагоннарның үзенә күрә бер сәүдә үзәгенә әйләнеп китүен күрсәтеп. Хәл әле дә әлләни үзгәрмәде, сәүдә элеккечә җанлы дәвам итә. Тик көнбагыш сату гына бетерелде бугай. Аллага шөкер дип әйтик, чөнки көнбагышны күп итеп сатып алалар да, вагон идәннәре тиз арада чүплек башына әйләнеп кала иде. Югарыдагы түрәләрнең үткер карашы, ниһаять, вагон идәненә дә төшеп җитте, күрәсең.

Аның каравы поездыбызда яңа гамәлләр барлыкка килде. Хәзер вагоннар, совет чорындагыча итеп әйтсәк, культура-агарту һәм агитация-пропаганда бүлекчәләренә әйләнеп киттеләр. Әйтик, ачылып китә вагон ишеге, килеп керә бер үсмер малай белән кыз. Егетнең кулында гармоника, ә кызныкында ... кечкенә капчык. Басалар ишек катына терәлеп, җибәрәләр дуэт белән җырлап. Беләсезме, хәйран матур җырлыйлар. Кайбер өлкән юлчыларның хәтта күзләренә яшь килә. Тегеләр исә ары таба эшне әлләни озакка да сузмыйлар. Китәләр вагон буйлап, кыз кулындагы капчыкны ачып куя һәм ошбу янчыкка байтак кына акча коела.

Һәм, беләсезме, мин моны, ихлас менә, һич тә саилче балалар өстенә гаеп ташлау йөзеннән әйтмим. Замана авыр, үксез калган балалар да җитәрлек, ә тамак дигәнең ашарга сорый. Үземнең дә мондый саилче балалар янчыгына сәдака салмыйча калганым юк.

Әле беркөн Казан каласыннан кайтып килә идем, яна күренешкә тап булдым. Килеп керде вагонга ике егет белән дүрт кыз. Болар инде балалар түгел, җиткән егетләр белән кызлар. Барысы да чисталар, күркәмнәр, егетләре кулында баян һәм гитара. Җибәрделәр егетләре уйнап һәм кызлары җырлап, артистларың бер якта торсын! Һәм, шунда ук искәрдем ки, болар ... христиан диненә мәдхия укый торган җырларны башкаралар. Искәрегез, сакалы биленә җиткән поплар түгел, яшь егетләр һәм кызлар. Агитация юнәлешендәге ошбу концерт тәмам булгач, халык алдында башларын иделәр, тынлаган өчен рәхмәт әйттеләр, Яна ел теләкләре җиткерделәр. Мин дә, бүтәннәр дә сәдака акчаларыбызны чыгару өчен кесәләребезгә тыгылдык. Ләкин тегеләр үзләренә сузылган кулларны итагатьле итеп кенә кире бордылар һәм ... вагонда утырган барча кешенең алдына үзләренең «Доброе слово» дигән христиан дине газетасын китереп салдылар. Яхшы кәгазьгә, эре шрифтлар белән басылган, төсле итеп, рәсемнәр белән бизәлгән, төрле вәгазьләр белән тулган, егерме битле менә дигән газета!

*Ахыры. Башы 4нче санда.*

Бушлай, бер тиенсезгә. Әле ишектән чыгып киткәндә дә вагондагыларга изге теләкләрен әйтергә онытмадылар.

Һәм мин моны да кем өстенә булса да гаеп ташлау яисә киная белдерү йөзеннән әйтмим. Вөҗдан иреге заманасы бу, һәркем үз кыйбласын тотарга, үз динен хупларга иреклe.

Тик шунысын әйтми кала алмыйм, шушы хәлдән соң күңелгә бер төер килеп утырды. Ә безнең үз динебезне халык алдында шушылай итеп хуплаучылар, аңа мәдхия укучылар кайда? Вәгазь җырлаучылар, аның турындагы әдәбиятны халыкка бушлай таратучылар?

## Чумара

Хәзер сагынып сөйләргә калган социализм чорында без барыбыз да тигезлектә яшәдек. Ул заман хәтта зур гына түрәләрнең дә тормыш рәвеше гади халыкныкыннан әлләни аерылып тормады. Әйтик, менә безнең Арчада КПСС райкомының беренче секретаре Х. З. Зәйнуллин һәм район Советы башкарма комитеты рәисе Т. Б. Борһанов яшәгән йортлар башка кешеләрнекеннән берни белән дә аерылмый торган гадәти йортлар иде. Үзләре әйбәт, тырыш кешеләр иде, ачы таңнан караңгы кичкә кадәр хезмәттә булдылар.

Әйе, ул чорда барыбыз да азмы-күпме тигезлектә һәм ... хәерчелек чигендә көн иттек. Иң начары һәм үзәккә үткәне—хезмәт хакы бик аз булды. Дөрес, кайбер авыр һөнәр ияләре, әйтик, тирән җир асларында күмер чапкан шахтерлар, ут бөркеп торган мартен мичләре янында тир түккән корыч коючылар, эссе-салкыннарда гидай дала-кырларда нефть чыгаручылар яхшы гына алып эшләделәр. Тик алар ил халкының бик аз өлешен генә тәшкил итәләр, ә күпчелек халыкның тормышы һич кенә дә мактарлык түгел иде. Ул чорларда гомер иткәннәр моны бик белә.

Беләсезме, үзгәртеп корулар башлангач, матбугатта шундый хәбәрләр күренде: безнең ил халкы үзе эшләп чыгарганга нисбәтле хезмәт хакының бик аз өлешен генә алган. Аның күп өлешен Совет хөкүмәте кораллануга, үсеп килгән һәм социалистик бердәмлек илләренә ярдәм итүгә тоткан. Үзебезнең ил халкын михнәттә яшәтү хисабына. Моның кайбер мисалларын мин үз күзем белән күрдем. Магнитогорск комбинаты эшләп чыгарган металл әйберләрнең зур күпчелеге бөтен Ауропага, хәтта Һиндстанга озатыла иде. Иң яхшы сыйфатлылары гына. Аннан килеп, СССР дигән иләмсез дәү илнең төрле халыклары да тигезсезлеккә куелды. Әйтик, Кавказдагы Союздаш Республикаларда халык үзәктәге өлкәләргә караганда шактый иркенлектә, муллыкта яшәде. Үткән гасырның сиксәненче елларында без карчыгым белән Кавказга, язучыларның Пицунда шәһәрендәге Иҗат йортына бардык. Шунда мондагы халыкның муллыкта, рәхәтлектә, урыс әйтмешли, иркен адымнар белән яшәвенә исебез китте. Иҗат йортындагы грузиннар ашханәдә бирелгән искитмәле ризыклар белән генә дә чикләнмәделәр, алар торган бүлмәләрдәге өстәлләр җиләк-җимешләр, затлы шәраб, казылыклардан сыгылып торды. Мин бер грузин әдибе белән танышып киттем. Ул үзара сөйләшкәндә үзләренең хөкүмәт тарафыннан аерым тәэмин ителүләре белән ачыктан-ачык мактанды, безне, үзәктә яшәгән төрле халыкларны, мескенгә чыгарып куйды. «Сез бичараларны җәллим!»—диде.

Безнең бөек шагыйребез Тукай «Халык зур ул, көчле ул ...» дип тикмәгә генә әйтмәгән. Өстәвенә, халык бик зирәк тә бит ул. Совет хөкүмәтенең төрле чикләүләре, кысулары астында яшәгән халык, бәлки, ачык аңлап бетермәстән, эшләгәненә тиешленең бик азы гына тамганын чамалап алды. Менә шул нисбәттә үткән гасырның 50нче елларында бөтен илдә яңа бер хәрәкәт—чумара хәрәкәте барлыкка килде. Кешеләр эш урыннарында,кайда

туры килсә шунда матди байлыкларны, хәтта дәүләт янчыгына керергә тиешле акчаны үзләштерә башладылар. Чумара ул, гәрчә бер үк төрдән булса да, урлау ук түгел. Чөнки ул күпчелек очракларда ачыктан-ачык эшләнә. Аңлаешлы булсын өчен берничә мисал китерәм.

Минем бер танышым, колхоз тракторчысы, шул үзе чумаралап җыйган бүрәнәләрдән менә дигән, алты почмаклы йорт салып куйды. Ничек эшли алды ул моны? Шактый ансат кына! Кыш көне алар Мари урманнарыннан колхоз фермасы салырга бүрәнә ташыдылар. Тагып кайта бу чылбырлы тракторына биш бүрәнә. Аны авыл башындагы колхоз утарына меңгереп куйганчы өенә чәй эчәргә кереп чыга. Һәм шунда теге биш бүрәнәнең берсе, иң матуры ишегалдындагы кар астына шуып кереп китә. Утарга дүрт бүрәнә менә. Моны барысы да, күршеләр дә белә, хәтта колхоз рәисе үзе дә чамалый. Тик беркем бер сүз әйтми, тиешле органнарга барып чакмый. Бар халык хөкүмәткә каршы пассив оппозициядә торды ул чагында. Шундый ук гади генә ысул белән шәхси хуҗалыкларга саламы, печәне, төзелеш материаллары кайта торды. Ферма хатыннарының, төзелешләрдә эшләүчеләрнең дә кичләрен эштән кайтканда куллары бар бит әле!.. Мин моның өчен кемне дә булса җавапка тартканнарын, төрмәгә утыртканнарын хәтерләмим. Урысча әйтсәк, круговая порука иде ул елларда.

Ул заманда автотранспорт предприятиеләре һәм колхоз шоферлары да чумараны күрәп алдылар. Авыл халкы сөтен-маен, бәйләгән шәлен сатарга Казан каласына йөреп тора, әмма автобуслар юк. Станцияләргә ашлык ташыган шоферлар капчыклар өстенә кешеләрне дистәләп утырталар. Әлбәттә, бушлай түгел, моның ныклы таксасы бар. Ул елларда чумара акчасына йортлар салынды, җиңел машиналар сатып алынды, бәйрәмнәр үткәрелде, хәтта туйлар да ясалды.

Авыл җирендә, шәһәрләрдә, бөтен илдә киң таралган гамәл иде бу. Хәтерлим ки, бервакыт «Чаян» журналында рәсем чыкты. Бер сыер, аның янында өч адәм басып тора. Сыер авызын зур ачып җырлый:

Директор, мастер, лаборант
Шахыр-махыр ясыйлар.
Хәләл сөтемне хәрәмләп,
Чумаралап ашыйлар.

Ул заман колхоздагы вак-төяк түрәләр арасында мондый җыр йөрде:

Колхоз диңгез, без корабль—
Рәхәтләнеп йөзәбез...

Нәкъ шул елларда, яшьлегемдә мин Уралның Магнитогорск шәһәрендә, тимер юлда эшләдем. Көз көне безне Оренбург өлкәсе совхозларына, урып-җыюда ярдәм итәргә җибәрәләр иде. Мондагы гарәбәдәй бодай басуларының иге-чиге юк! Без исә совхозның ындыр табагында эшлибез, ашлык чистартабыз. Без төн куна торган йортның хуҗабикәсе кулларга кичкенә капчыклар тоттыра. Өйгә кайтканда буш кул кайтмас, шул капчыкларга бодай тутырып кайту өчен. Бер атна вакыт үтми, хуҗабикәнең келәтләре, барча савытлары ашлык белән тула. Аннары инде без аны лапаска, җиргә сала башлыйбыз. Без ташыган пүчтәк ул әле, әнә шоферлар! Алар инде ашлыкны машина әрҗәсенә салып кайталар, сораган кешегә йөге-йөге белән арзанга гына сатып җибәрәләр. Чөнки мондагы ашлыкның исәбе-чуты юк. Мондый хәлгә, дәүләтнекен чумаралауга шундагы җаваплы кешеләр, бригадирлар, амбар мөдирләре дә әллә ни игътибар бирми.

Боларын әйтәбез әле, мин чумара дигән бәрәкәтле гамәлнең хәтта авиациягә үтеп керүенә дә шаһит булдым. Кайттым шулай Уралдан үзебезнең Казанга, очкычка утырып кына. Ул заман билет бәясе бер башка 15 сум иде. Казанда йомышымны йомышлап аэропортка йөгердем. Ә анда Магнитогорскига кайта торган рейска билетлар беткән. Ни хәл итим, кассада бераз тавышланып алдым да, бастым бер читкә барып. Шунда очучы киемендәге бер адәм бармагы белән генә мине үз янына дәште.

—Билетлык акчаң бардыр?—дип пышылдый.

—Әлбәттә инде!—мин әйтәм.

—Алайса, син шушында торып тор. Бераздан мин очу мәйданына үтәрмен. Шунда сак кына миңа иярерсең,—ди бу.

Шулай иттек тә. Мин ул адәмгә ияреп очу мәйданына чыктым, без очкыч янына килдек, буш салонга кердек, ул мине очучылар кабинасына кертеп, бер урынга утыртты.

—Кара аны, мондагы бер әйбергә дә кагыласы түгел. Юкса бездән башка гына һавага күтәрелеп китүең, аннары җиргә төшә алмыйча, шунда торып калуың да бар!—диде ул һәм мине ялгызымны калдырып чыгып та китте.

Утырам шулай. Кабинадагы хисапсыз күп приборларга, пружиналар өстендә биеп торган әллә ниткән әйберләргә карап. Менә бер заман очкыч калтырана башлады. Чамалап алдым, салонга пассажирлар тула... Күп тә үтмәде, кабинага өч очучы килеп керде. Тегесен-монысын боргаладылар да, һавага менеп тә киттек. Шунда теге танышым әйтте:

—Син монда безгә комачаулап кына утырасың, чык салонга!

Анда чыксам, ниткән урын булмаган ди! Бик җайлысы, түгәрәк тәрәзә янындагысына утырдым! Магнитогорскига кайтып җиткәч, әйттем тегеләргә.

—Йа Аллам, чумара дигән нәрсә сездә, һавада да бар икән!—дидем.

—Нишләп булмасын ди, без рыжыйлар мәллә? Менә хәзер син биргән акчага ресторанга кереп утырабыз. Ярый бит ул!—диделәр.

Әйтәм бит, чумара дигән хикмәтле гамәл ул заман бөтен илгә таралган, халык хуҗалыгының барлык тармакларына үтеп кергән иде. Менә бернинди ят кеше утырмаган, чит йөк төялмәгән паровозда чумара ясап буламы? Була икән шул. Безнең егетләр тапты моның җаен. Әйтик, кераләр буш вагоннар тагып шәһәрдәге бөтен дөньясына атаклы металлургия комбинатына. Шунда тендердагы күмер астына төргәге белән калай шудыралар. Ә ул калайны инде Агаповка дигән станциядә сатып алучылар көтеп тора!

Сорау туа: шактый кырын гамәлне ил җитәкчелеге белдеме икән? Бер дә белми калмагандыр, әмма ләкин моңа каршы бернинди чикләүләр, тәгаен һәм кырыс чаралар күрелмәде. Бәлкем, картаеп беткән, күпне күргән түрәләр шундый юл белән генә булса да халык үзенә тиешлесенең бер өлешен алсын дип хәл иткәннәрдер? Ахыргы чиктә алар да кеше, шул халыкның вәкилләре бит. Моңа шактый саллы ишарә дә булды. Менә тарихи факт. Ул заман ил белән идарә иткән Леонид Ильич Брежнев үзенең бер чыгышында мондый сүзләр әйтте:

—Хәзерге яшьләр тормыштан зарланалар. Яши белмиләр алар. Менә без студент чагында мондый хәлдән чыгунын юлын таба идек. Төшәбез пристаньга баржа бушатырга. Ун капчыкны складка салабыз, унберенчесен үзебез генә белгән җиргә... Азрак яши дә белергә кирәк аны!

Мин чыгышның сүзгә-сүз шулай булуына дәгъва кылмыйм. Әмма ил җитәкчесе шушы фикерне әйтте! Ни дигән сүз була инде бу? Ил җитәкчесенең чумарага фатиха бирүе түгелме?!

Хәзерге заманда чумара дигән гамәл юк инде ул. Аңа ихтыяҗ да, мөмкинлек тә бетте. Илдә капитализм, бар мал-мөлкәт шәхси кулларда. Ә шәхси милекне чумаралап кара син!

Әмма изге урын буш булмый дигәндәй, чумарага алмаш бар ул. Ришвәт! Ул шул ук чумараның бер төре, урлап алу түгел бит. Ришвәтнең дә башлангычы иҗтимагый күренеш, асылда хезмәт хакы түбән булу, адәм баласының эшләгәненә нисбәттә тиешлесен ала алмавы. Ә тиешлесен тулысынча алу беркайчан да булмаячак. Чөнки дәүләтне, хөкүмәтне, чиновниклар армиясен яшәтәсе бар.

Киләчәк нинди гамәлләр күрсәтер тагын. Алланың үзенә тапшырдык.

## Ачлык терсәге

Инде сиксәнемә житсәм дә, мин Бөек Ватан сугышы беткән көнне ачык хәтерлим. 1945 елның 9 мае ялт иткән кояшлы, йомшак кына жилле, шулкадәр ямьле иртә иде. Авылның колхоз эшенә ярамаган бар халкы, әби-бабайлар, малай-кызлар бәрәңге бакчаларын китмәнләргә чыккан. Шунда авыл өстендә хат ташучы Гайсәнең дулкынланган тавышы янгырады:

—Авылдашлар, шатланыгыз! Сугыш беткән! Сугыш туктаган!

Ул заманда авылда телефон юк, илдәге барча яңалыкларны авыл халкына хат ташучы житкерә. Бу хәбәрне ишетүгә кешеләр көрәкләрен жиргә атып бәрделәр, китте шатлыктан ни эшләргә белмичә сикерүләр, кычкырулар, биюләр, кочаклашулар. Бу якты көн алып килгән олы куанычтан бөтен авыл гөрләп торды.

Әйе, сугыш бетте һәм, беләсезме, авыл халкы тормышына бер тамчы да жиңеллек килмәде. Юкса бу көнне халык зарыгып көтә, ул көн нинди дер жиңеллекләр алып килер дип өметләнә, кешеләр «Менә сугыш бетсен, аннары тормышлар да гел бүтәнчә булыр дип сөйләшәләр иде. Рәтләнмәде тормыш. Хөкүмәт китереп салган һәм рәхимсез түләткән кырык төрле салымнар кимемәде, заем акчаларын да элеккечә үк халыкны елатып, тартып алдылар. Шул ук ачлык, хезмәт көненә ашлыкны граммлап бирү, бер телем ипигә зар булып яшәү, жәй буе алабута, ат кузгалагы белән туенып торулар дәвам итте. Законнар шул ук имансыз калды, басудан җыеп алган берничә башак өчен, әвеннән кесәгә салып төшкән бер уч ашлык өчен элеккечә өтерменгә яптылар.

Ни гажәп, сугыштан соңгы елларда ул ачлык дигән афәт аеруча көчәеп китте. Ашыйсы килү—дөньядагы иң көчле теләкләрнең берсе. Ачлык дигән аяусыз хөкемдар болай алганда инсафлы, әдәпле кешеләрне дә авылда моңарчы күрелмәгән бик ямьсез гамәлләр ясарга этәрде. Китте чит кешеләрнең бакчасындагы әле өлгереп кенә килгән бәрәңгеләрне йолкып алулар, базга төшеп сөт-каймакларны эчеп бетерүләр, тавык-казларны урлап чалулар һәм тагын шундый хәерсезлекләр. Алай да, мин хәзер уйлыйм ки, ул чорда безнең Дусым авылы халкы үзенең намусын җуеп бетермәгән әле. Мондый кырын хәлләр бездә булмады диярлек. Ә менә күрше авыллардан байтак ишетелгәләде.

Менә шуларның берсе.

Жәйнең бер көнендә әти мине, ул чагында инде унике-унөч яшьлек үсмерне, күршедәге бер авылга жибәрде. Кулыма бер тәпән бал тоттырып. Мин бу балны шул авылда торган безгә туган тиешле апайларда атлан майга алмаштырып кайтырга тиеш идем. Ярый, бардым, алмаштырдым, кайтырга чыктым. Авылны чыгып үргә түбән төшеп барганда күрәм, каршыма таякка таянган бер аксак адәм килә. Әллә нинди бик таушалган, гел кара киемле, йөзен-битен сакал-мыек баскан бер бәндә. Шунда һич көтмәгән, уйламаган хәл булды. Гамьсез генә үтеп барганда ошбу адәм кинәт мина ыргылды, кулымдагы тастымалга төрелгән майга ябышты. Мин ике куллап тотындым, тастымалны бирмәскә черәштем. Шунда ул куеныннан озын пычагын тартып чыгарды.

—Үтерәм! Суям!—дип янады.

Мин, ачлы-туклы үсмер, бу талаучыга каршы нишли алам? Ычкынып

китте кулымнан тастымал. Теге шунда ук майны комсызланып ашый-ашый юл читендәге арышлар арасына кереп китте. Әле авыл ерак түгел иде, мин сөрән салдым:

—Таладылар! Маемны тартып алдылар.

Бу хәлне болындагы көтүчеләр күреп торган икән. Алар:

—Артыннан бар. Артыннан калма!—дип кычкырдылар. Мин исә пычаклы кеше артыннан арыш арасына керергә курыктым. Кычкыра-елый теге авылга киттем. Минем тавышка кешеләр чыктылар, кулларына сәнәк-көрәкләр тотып. Арышлар арасыннан бераз баралар да, сәнәкләрен алга ыргыталар. Теге талаучы курыксын, килеп чыксын дип.

Ахырда аны тотып алдылар. Ул шул ук авылның сугышта яраланып, аксаклап кайткан, бик авыр тормыштагы бер кеше булып чыкты. Исемен әйтеп тормыйм. Без тотып алганда инде эш узган, ул минем майны ялмап куйган иде. Шунда теге апай да, бүтән кешеләр дә әйттеләр:

—Энем, сез моны милициягә җәвит итеп тормагыз инде. Болай начар кеше дә түгел ул үзе. Күрәсең, үзе яралы сугышчы, тормышлары авыр...—диделәр.

Өйгә кайткач, әти бу хәлгә ышанмый торды. Аннары уйга калды һәм бу җинаять турында ул да беркая да хәбәр итмәде. Юкса аның сүзе үтә, ул атаклы укытучы иде.

Мин бу кешене тагын бер очраттым әле. Кеше дип әйтәм, чөнки мин инде дөньяны азмы-күпме күргән егет, ачлыкның ни икәнен үз җилкәмдә татыган, аның адәм баласын нәрсәләргә этәрә алганын бик белә идем. Әтнә саклык кассасында инспектор булып эшләгән чагым иде. Казанга барырга кирәк булды. Ул заман автобуслар юк, туры килгән атлы чанага утырып Коркачык стансасына йөри идек.

Чыгып киттем Әтнәдән бер атлы чанага утырып. Йөкче үзе алдарак утыра, без шундагы бер кеше белән сөйләшеп барабыз.

—Ә безнең авылда булганың бармы синең?—дип сорады бу сүз арасында һәм теге мин таланып кайткан авылның исемен атады.

—Бар, ниткән булмаган!—дидем мин һәм, үзем дә сизмәстән, теге вакыйганы сөйләп ташладым. Бу кеше көлә башлады, ә түрдә утырган олаучы өстендәге кожанына төренеп, бөтенләй бөрешеп калгандай булды. Бактың исә, ул нәкъ мине рәнжеткән кеше икән.

Күнелемнән теге вакыттан калган рәнҗүләрем, ачуларым ташып чыкты. Тегене чана түреннән тартып алып унлап-суллап яңаклыйсым килде. Мин хәзер яшь, ярыйсы гына егет, моны рәхәтләнеп эшли ала идем. Ләкин тиз арада суындым, киресен уйладым. Уйлап баксаң без бит икебез дә шул чорның, илдәге имансызлыкларның очлаеп чыккан бер терсәге—ачлык корбаннары. Житмәсә, ул агай бик-бик оялды, кат-кат гафу үтенде.

Коркачык стансасына килеп төшкәч, мин аңа юл хакы өчен тиешле акчасын да түләдем. Табигатем йомшак, кешеләргә ачу саклый торган гадәтем юк.

## Хәсән! Сабан туе кайчан?

Безнең Дусым авылында түбәч очта Кыска Сабир абзыйлар яшәде. Чыннан да тәбәнәк буйлы Сабир абзый һәм аның күгәрчен тиклем генә карчыгы Кәшифә апай икесе дә бик эшчән, хасиятле кешеләр, җыйнак кына йортлары янында бик куе итеп чия куаклары үстерделәр. Ә менә олы уллары Хәсән абый, үзләреннән аермалы буларак, озын буйлы, таза, көчле-куәтле егет иде. Ул югары очта колхозга такта яра, кайбер көннәрдә сонга калып төшә, яхшы гына салып та алган була. Югары очтан як-якка чайкалып, лап-лоп атлап төшә, без малай-шалайлар аңа ияребез,үчеклибез.

Хәсән! Сабан туе кайчан?
Бүген түгел, иртәгә,
Хәсән менгән киртәгә.
Киртә бавы чишелгән,
Хәсән башы тишелгән!

Моңа каршы Хәсән абый женләнә, тиргәнә, безне эләктереп алмак була. Тик кая инде аңа безне тоту? Ул заман авылда аракы эчүчеләр бик сирәк әле. Сабир абзый улының ошбу гадәтен бер дә яратмый, аны капкалары төбендә кулына чыбыркы тотып каршылый. Капкадан кергәндә сырт буена берне төшереп тә ала.

Ә үзләре болай ару гына яшәделәр. Хәсән абый өйләнде, балалары да булды, хатыны белән икәүләп колхозда тырышып кына эшләделәр, югары очта йорт торгызып башка чыгарга җыеналар икән дигән хәбәрләр дә йөрде. Гаиләсе булгач, Хәсән абый салып йөрүләрне дә чикләде. Тормышлар жай гына гел алга бара иде. Шулай матур гына яшәп торганда сәт сукты, сугыш башланып китте.

Хәсән абыйны авылдан иң беренчеләрдән итеп озаттык. Без, кайчандыр аны үртәп йөргән малайлар, аның белән елый-елый саубуллаштык. Хәер, ул вакытта әле беркем дә сугыш шулкадәр озак барыр, авылдагы ир-атларның күбесе һәлак булыр дип уйламады. Китүчеләр үзләре дә:

—Без ул фашистларны хәзер бөгәрләп үз тишекләренә тыгабыз! Безне урак өстенә көтегез!—дип киттеләр.

Шул китүдән Хәсән абый эзсез югалды. Сугыш кырыннан аның бер хаты да килмәде бугай, тик берничә айдан «хәбәрсез югалды» дигән язу гына килде.

Еллар үтте, инде сугыш та күптән бетте. Хәсән абыйның хатыны белән (инде мәрхүмә, исемен оныткандмын) улы Гайсә үзләренә яңа йорт салып чыктылар. Гайсә башта колхозда эшләде, тырыш егет, оста шахматчы да иде, клубта үткәрелгән ярышларда күп тапкырлар җиңеп чыкты. Аннары Казанга китеп барды. Инде сугыш яралары да төзәлеп, хәбәрсез югалганнарның табыласына да өметләр өзелеп килә иде.

Шунда, үткән гасырның сиксәненче еллары башында, безнең Дусым авыл Советына бер сәер хат килеп төшә. Әллә кайдагы ерак Бельгиядән! Латин хәрефләре белән язылган бу хатны миңа укыттылар. Хат язучы үзенең Дусым авылы кешесе Сабиров Хәсән икәнен, сугышта немецларга әсир төшүен, сугыш беткәч Бельгиядә яшәп калуын бәян итә. Ул анда әйбәт кенә яшәп ята икән. Авылда үзенең гаиләсе калуын әйтә, әгәренки исән булсалар, үзенә хат язуларын үтенә. Туган илне, гаиләсен, авылны бик сагынуын, бик тә күрәсе килүен дә әйтә.

Хат алышу башланды. Хәсән абый Бельгиядән гаиләсенә посылкалар да җибәрде, һәм шунда бик ямьсез күренеш, безнең илдә посылкаларны ачып караулары, шунда крохоборлар утырганы ачыкланды. Бер хатында Хәсән абый элекке посылкасында нәрсәләр салганын әйтеп исемлеген җибәрә. Монда тикшереп карасалар, салынган әйберләрнең ... яртысы гына калган икән!

Аннары Хәсән абыйның туган илгә кайтасы, авылны, сабан туйларын бик тә күрәсе килде. Ул гаиләсенең югары органнарга мөрәҗәгать итүен үтенде. Инде туган илдә торып калырга рөхсәт итмәсәләр, бер күреп кенә китәр идем, дип ялварды. Гаиләсе аны кайтарту артыннан бик йөреп карады. Юк, булмады. Хакимияттә утырган имансызлар тәки рөхсәт итмәделәр. Хәзерге заман булсамы! Уйлыйм ки, Хәсән абый үзе дә авылга кайтыр, гаиләсе дә гомерендә бер генә тапкыр булса да чит илгә бара алыр иде. Юк шул инде. Хәсән абый анда туган илне бер күрергә тилмереп вафат булды. Хатыны белән улы Гайсә дә мәрхүмнәр инде. Урыннары оҗмахта булсын.

## Киләчәккә бер караш

Менә, китерәләр дә әйтәләр, тарих үлчәмнәре белән алып караганда бер кеше озынлыгындагы дәвер берни түгел ул, диләр. Без исә бу фикергә каршы чыгабыз. Алып карасаң, тарих өчен чыннан да күз ачып йомарлык кына шушы вакыт эчендә кешелек җәмгыятендә гаять зур үзгәрешләр булып өлгерә. Хәтта ки глобаль үзгәрешләр, һәм фәнни-техник тәрәккыят өлкәсендә, һәм иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр ягыннан.

Менә хәзер мин, шәхсән, сиксән яшемә атлап киләм. Шуннан чыгып вакыт берәмлеген сиксән ел дип алыйк, һәм шушы берәмлектә булган үзгәрешләргә күз салыйк.

Кереп китик фәнни-техник юнәлешкә. Минем гомер башында, ягъни үз-үземне белә башлаганда көндәлек тормыштагы хәзерге техник казанышларның берсе дә юк иде. Берсе генә дә! Күз алдына китерегез: өйдә электр уты да, радио, телефон, суыткыч—берсе дә юк. Өй утын яисә салам ягып җылытыла, керосин лампалары белән яктыртыла. Автомобиль авылга күп булса елына бер тапкыр, анда да райком кешеләре утырып кына килә. Авылның яше-карты урам буйлап шул машина артыннан йөгерә.

Минем, ягъни бер кеше гомере дәвамында тормыш-көнкүрештәге үзгәрешләр зур гына түгел, глобаль булды. Үзегез күреп торасыз ич: электр энергиясе, радио, телефон, урам тулы машиналар, өйдә суыткычлар, телевизор, газ, компьютер, интернет, төрле сайтлар, кесәдәге телефон... Ошбу могҗизаларны санап бетерерлекме!? Шул дәвердә кешелек атомны таркатты, аны үзенә эшкә җикте, Айга менеп аягын салындырып утырды, нанотехнологияләргә, тереклекне клонлаштыруга барып җитте. Нинди кодрәтле машиналар, очкычлар ясалды, һәм болар барысы да шул бер вакыт берәмлегендә!

Хәзер инде алыйк сәяси якны. Минем гомер дәвамында берничә сугыш-бәрелешләр, бөтен дөньяны тетрәткән Бөек Ватан сугышы булды. Күкрәп алга барган социализм тирән кризиска килеп керде һәм... шул кризистан чыга алмыйча тиз арада җан тәслим кылды. Мин ихлас күңелемнән ышанган, сырхаулап китүен уема да китермәгән, дөньяда иң кодрәтле һәм йогынтылы саналган Коммунистлар партиясе гаҗәеп җиңеллек белән, берничә көн эчендә таралып китте! Шул партия түрәсенең әмере белән! Бу хәл дөньяда иң зур һәм кодрәтле СССР дигән дәүләтнең таркалуына китерде. Һич башка сыймаслык, глобаль үзгәрешләр ләбаса бу.

Хәзер инде посып кына булса да киләчәккә күз салып карыйк. Кешелек дөньясы ул шундый, ирешкәннәре белән һич кенә дә разый торып калмый. Галимнәр киләчәктә тәрәккыятнең тагын да гигант адымнар белән буласын вәгъдә итәләр. Алыйк фәнни-техник үсеш фаразларын. Монда инде без, билгеле ки, үзебездән берни дә әйтә алмыйбыз, рәсми фаразлауларга таянабыз.Аларның да иң зурларына гына тукталыйк. Әйтик, әлләни ерак та булмаган киләчәктә авыл хуҗалыгының да, сәнәгатьнең дә кирәге калмаячак. Әйе! Чөнки теләсә нинди предмет яисә материалның молекуляр дубликаты торгызылачак. Гади итеп әйткәндә, урамдагы пычрактан азык-төлек, кием-салым, асылташлар, машиналар ясап булачак. Ул заман кеше сәнгать, мәгариф, спорт һәм күңел ачу белән мәшгуль булыр дип көтелә. ДНК структурасы буенча динозаврлар клонлаштырылачак, кечкенә динозаврлар каравыл этләрен алыштырачак. БМО атом-төш коралын юкка чыгару турында карар кабул итәчәк. Кешеләр кызыл йөзле күршебез Марс планетасы өстенә төшәчәк. Ясалма интеллект кешене куып тотачак. Тагын нинди хикмәтләр булыр, анысын чамалавы да кыен.

Сәяси үзгәрешләрнең исә нинди буласын әйтергә дә кыенсыналар. Мона алынган гакыл ияләре күренми әле.

# БЕРЛӘШИК!

*Җитмәде безгә һич бердәмлек.*
*Баш булды безгә гел таркаулык.*
*Мең җирдә мең учак пыскыды,*
*Мең дулкын булып без вакландык...*

Бу таркаулыкның «өҗерен» даими тоеп, татып торабыз. Ләкин милләтебез клиник үлемгә җитеп килгәндә дә, бик азларны санамаганда, без һаман тыныч, ваемсыз әле.

Бу мәкаләм, бәлки, өзек-төтек чыгар. Чөнки элеккеләренә[1] өстәп кенә язам. Язып та әлләни юк: чукракны колаклы, сукырны күзле, гамьсезне гамьле итә алмыйсың икән ул. Әмма дәшми дә кала алмыйм.

90нчы еллар башында халкыбызның бер өлеше уянган да иде. Ләкин 9-10 елдан, инде яуланган хөрлекне үзләре үк саткан (арзанга түгелдер) җитәкчеләребез ягына карап төкерендек тә, Мәскәүгә юрган астыннан йодрык күрсәттек тә, тагын гырлап йокыга киттек.

Төп хаталарыбыз да шул тирәдә булды: олуг түрәләребезгә мөкиббәнлек һәм дә Рәсәй хакимиятеннән азмы-күпме гаделлек өмет итү.

Яулап алынганнарны түгел, үз халкын да халыкка санамаган Мәскәү Кремленнән бүләк төсендә нидер тамар дип уйлау—ахмаклык. Демократик традицияләрнең әсәре дә булмаган илдә тиз арада яңа тип җитәкчеләр үсеп чыгар дип тә өметләнмик. Ярсымыйк һәм нәфрәтләнмик тә, нинди вәзгыятьтә ни котәсен белеп эш итик—бары шул гына.

Рәсәй тәрәзләрендә дөнья күрсенгә демократик пәрдәләр җилфердәгән 1990-94 елларда, зур авырлык белән, эзлекле рәвештә—ныклык, тәвәккәллек, кайчакта хәтта чын батырлык та күрсәтеп, ул чакта шактый көчле булган милли хәрәкәткә һәм аның лидерларына таянып, Татарстан җитәкчелеге, бу, әлбәттә, М.Шәймиев һәм шактый дәрәҗәдә М. Сабиров һәм Ф. Мөхәммәтшин, Дәүләт суверенитеты турында декларация игълан итүгә, шуны раслаган референдум үткәрүгә, аның нәтиҗәләрен закон төсендә теркәгән Конституция кабул итүгә һәм шуларда салынган мөстәкыйльлекнең төп өлеше кергән Шартнамә булдыруга, ягъни моны Мәскәүдән дә раслатуга ирештеләр. Димәк, алда бер киртә дә калмады диярлек. Ләкин нәкъ менә Шартнамәдән соң кинәт серле бер чигенү башланды. Ул берөзлексез әлегәчә дәвам итә.

Хикмәт нидә соң? Мин үзем моны болайрак аңладым. Рәсәй капитализм төзи башлагач, ашыгыч рәвештә капиталистлар кирәк булды. «Обогащайтесь!» дигән шигарь игълан ителде. Бусы күбрәк халык күрсенгә, имеш, телүгән һәркемнең мөмкинлеге бар, тырышлыгың һәм осталыгың гына булсын, янәсе. Ләкин зур байлыкның ишекләре махсус исемлекләр буенча гына ачылды шикелле. Менә шунда безнең хакимнәрнең дә капитализм төзү дәрте тулып ташты булса кирәк. Алар да адәм балалары бит! Югыйсә Татарстаныбыз бөтенләй башка юлдан бара ала иде. Завод-фабрикаларны, колхоз-совхозларны анда эшләүчеләрнең уртак милке итеп. Ягъни халык гамен гамьләп. Заманында Казанга сыймыйча Мәскәүгә китәргә мәҗбүр булган мөстәкыйль фикерле олуг галимебез Әгъдәс Борһанов нәкъ менә шундый тәкъдим белән безнең җитәкчеләр янына кергән дип беләм. Шул юлдан китсәк, гаделрәк кенә түгел, отышлырак та буласы иде кана. Халкыбыз башка өлкә-республикаларныкыннан шәбрәк яшәгәнгә, мөстәкыйльлегебезнең нигезе дә тимер-бетон булыр иде, аны бөреүнең дә җуясы килмәс иде...

330 сум—«Казанькомпрессормаш»ның элекке җитәкчесе Әхмәт Галиевнең

[1] Карабыбыз батып барганда. 2008. №12; Бу – төкәнмәс көрәш! 2010.№1; Татар батырмы? 2010, №5; Фәүзия Бәйрәмова татарга кем тия ул? 2010.№12.

(заводны үстерүгә һәм дөньякүләм танытуга гаять зур көч салган кеше!) айлык хезмәт хакы әнә шундый булган. Хәзерге директорларныкы күпме икән? Сорап карагыз, бәлкем, әйтерләр? Ә бит директорлар керем җәһәтеннән бала-чагалар гына әле. Кесә белән кесә арасындагы аерма, берәүләргә күктән төшкән милек исәбенә, дөньяда беркайда да булмаганча зурайды.

***

«Рус мәктәбендә белем алучы татар балаларының күпчелек өлеше ана телен һәм әдәбиятын өйрәнми һәм белми, шунлыктан татар телен начар беләләр яки бөтенләй белмиләр, татар халкы гасырлар буена тудырган мәдәнияттән читләшәләр.» «Мин шундый нәтиҗәгә килдем: эшләр чынлап та бик мөшкел. Без татар мәктәбенең асылда юкка чыгарылу куркынычы алдында торабыз.»—Моны кем әйткән дип уйлыйсыз? Берәр татар түрәсе авызыннан моныңише сүзнең чыкканы бармы? КПСС өлкә комитетының беренче секретаре әйткән, 1958 елны. Семен Игнатьев, урыс кешесе. Аның да ниндие әле—1951-53 елларда СССР Дәүләт иминлеге министры булган зат! Ул «Татар гомуми белем бирү мәктәпләрендә эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы мәсьәләне партия өлкә комитетының 1958 елның 21 маенда үткән пленумына чыгара. Татар телен чын-чынлап күтәрә торган карарлар кабул ителә. Ләкин... Моның белән кайбер татарлар килешми, мәсәлән, элекке беренче секретарь З.Моратов. Ул, Игнатьевны милләтчелектә гаепләп, КПСС Үзәк комитетына мөрәҗәгать итә. Икенче секретарь С. Батыев та хупламый моны. Нәтиҗәдә Игнатьев эшеннән алына. Сүз уңаеннан әйтик, хәзер күпләрнең күзен кыздыра торган Тукай премиясе дә С.Игнатьев фатихасы белән гамәлгә куела һәм аның урынына Ф.Табеев килгәчтен 5 ел буена бирелми тора.[2]

Рәсәйнең мәгариф министры Д.Толстой 1870 елны болай дип язган: «Илебездә яшәүче барча инородецларны укытуның ахыр максаты, һичшиксез, аларны урыслаштыру һәм урыс халкына кушудан гыйбарәт булырга тиеш.» СССР чорында да, соңрак Россия Федерациясе дип аталган мәмләкәттә дә бу эш әкертен һәм астыртын башкарылса, соңгы бер-ике елда ачыктан-ачык һәм җимертеп диярлек эшли башладылар. Курыкмыйча. Бераз шикләнү булса да, бездән түгел, Кавказ республикаларыннандыр. Аларны урыслаштыру мәшәкатьле һәм шау-шулы эшкә әйләнергә мөмкин.

Фәндәс Сафиуллин язып чыккан хәл бик тә гыйбрәтле. Без латин әлифбасын кертәбез дип йөргәндә Думада моны тыйган закон проекты тикшерүгә чыгарыла. Рәсәй хакимнәре шул беренче укудан ары китәргә уйламыйлар да, чөнки Татарстанда шуннан соң гарасат кубасына шикләнмиләр. Бу үзенә күрә бер йодрык изәп алу, сынап карау гына була. Татарстан хакимнәре коелып төшкәч һәм бөтен эшне шундук туктаткач, халык та дәшмәгәч, закон кабул ителә. Фәндәс абый моны белеп сөйли, чөнки ул чакта Дума депутаты иде. Менә шунда безнең никадәр гайрәтле халык икәнебез, безне теләсә нишләтеп булганлыгы ачыклана да инде.

Татар түрә булса, түргә урыс чабатасын элә. Каян килә бу? Иң әүвәл—гасырлар буена астыртын рәвештә кертелгән тәрбиядән. Безнең башларга салынган сайланма гыйлемнән.

Референдум үткәрәбез дип янып йөргән чакта М.Шәймиев Россия телевидениесенең «Без ретуши» дигән тапшыруында 7-8 иң гайәр журналистның үткеннән дә үткен сорауларына җавап бирде. Булдырды, сөенеп утырдык. Ләкин күңелне бер нәрсә тырнап куйды: сезнең өчен үрнәк сәясәтче кем дигәч, президентыбыз Петр Іне атады. Татарга иң зур зыян салган ике патшаның берсен. Татарга гынамы? Ключевский атлы тарихчы аның турында болай дип язган: «Чтобы защитить отечество от врагов, Петр опустил его больше всякого врага.»

Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, сәнгать институтында, кульязмалар бүлегендә татар язуының үсеше музееи булдыру идеясе туа. Иң борынгы чорларга ук ялганган мөһим язма документларның мәңге сакланышын тәэмин итәчәк, кульязмаларның күплеге җәһәтеннән әрмәннең мәшһүр «Матадаран»ыннан да ким дигәндә калышмаячак, татарга шөһрәт китерәчәк бу музейны бар итү акчага терәлеп кала. Мәсьәләне тикшерергә килгән чиновник, кульязма өемнәрен күрә дә, «Шушы

[2] Б.Солтанбәковның «Татарлар һәм Игнатьев» дигән мәкаләсе буенча бәян ителде. К.Утлары, 2008, №12.

мусор өчен шау-шу куптардыгызмени?!»—ди.

Татарстан дигән республикада татар язмышына тәэсир итә торган мөһим постларда утырган, шуның өчен зур гына эш хаклары алган, ул урыннарга татар булган өчен куелган күп кенә түрәләргә татар халкының иң кадерле ядкарьләре дә, аның гомумән яшәве-яшәмәве дә—чүп тә түгел! Кайберләре татарның киләчәген җимерүгә бәлкем әле аңлы рәвештә дә хезмәт итәдер. Татар анасын да сатар дигән сүз шундыйларга карыйдыр ул. Әнә шулар да бездә рәхәт яши, карьера ясый ала бит! Гомуми тырышлык белән дөньяның татар мәркәзендә шундый хәл-халәт хасил ителде ки, аны үз җиребездә үзебез булып яшик дип Кытайдан Казанга күчеп килгәчтән тәмам күңеле кайткан Зифа Табиева сүзләре белән генә аңлатып буладыр: «Әллә татар булып калыр өчен чит илдә яшәргә кирәк микән ул?» Мондый гайре табигый хәл дәүләт җитәкчеләребезнең күптән йокысын качырырга тиеш иде юкса. Ләкин—әйбәт күренәләр, йоклыйлардыр... Әллә республикабызга керү юлларына кызыл хәрефләр белән зур итеп «Татарлар! Сак булыгыз, Татарстан!» дип язып куярга кирәк микән?

Түрәләргә мөкиббәнлек, ләббәйкәлек безнең канга сеңгән. Башка илләрдә сабыйларга кадәр белгән гап-гади хакыйкать бит бу: халык дәүләткә түгел, дәүләт халыкка хезмәт итәргә тиеш. Исән калыйк дисәк, түрәләрнең һәр эш-гамәлен контрольдә тотарга, әйбәтләрен—хупларга, ялгышларына ризасызлыгыбызны белдерергә тиешбез. Кирәксә, мәйданга чыгып та.

Референдумнан соң, матбугат конференциясендә, «Хәзер Татарстан Россия составындамы? Юкмы?» дигән сорауга Шәймиев болай дип җавап бирде: «Халык референдумда куелган сорауга «әйе» диде. Киләчәктә үзебезнең хокуклардан *кирәк кадәр файдаланырбыз*». Ягъни халыкның яңа референдумнан тыш беркем дә үзгәртә алмый торган карары түрәләр кулында кала дигән сүз иде бу. Нәтиҗәсен татыйбыз менә.

Референдум дигәннән, аның үткәрелүенә (1992нең 21 марты) тиздән 20 ел тула бит. Ничек билгеләп үтәрбез икән? 10 еллыгы, 15 еллыгы кебек үктер инде. Ягъни берничек тә! Күрмәгәнгә-белмәгәнгә салышып!

***

Безгә хәзер нишләргә соң?

Иң әүвәл халыкны уятырга кирәк.

Шәймиев бер хәлиткеч мәлдә биек тәрәзәдән Ирек мәйданына бага да, «Халык аз бит!» ди. (Миңа моны әлеге сүзләрне үзе ишетеп торган кеше әйтте.) Мәйданнан да көчле нәрсә юк хәзер. Чигенүнең бер сәбәбе Шәймиевнең үз артында куәтле халыкны тоймавы да булгандыр. Мәйданга ничәдер йөз түгел, йөз мең кеше чыкса, митингларда, Балтыйк буе илләрендәгечә, иң популяр, иң абруйлы асыл затларыбыз нотык тотса, татар язмышы гел бүтәнчә булыр иде дип уйлыйм мин. (Әзһәр Шакировның чыгышлары да мәйданны тергезеп җибәрә иде әнә.)

Халыкны зыялыларыбыз, интеллигенция уятырга тиеш. Ләкин безнең интеллигент дигәннәребез, берничә дистә кешене исәпләмәгәндә, «Печән базары»нда берәү язганча, кыю сүзне бары бәдрәфкә бикләнеп, анда да тел яшереп кенә әйтә ала бугай шул.

Иң ашыгыч максат мәгарифебезне саклап калу булырга тиеш. Аны бездән тартып алырга Мәскәүнең әхлак буенча да, халыкара хокук буенча да, хәтта үз Конституциясе буенча да хакы юк. Шунысы да бар: татарча укытуны тәэмин итә алмагач, ни пычагыма безнең төзек мәгариф системабызны җимерергә иде? Карл Фукс (Казан университетын җитәклэгән кеше, немец) 1844 елда ук болай дип язган бит әнә: «Всякому заезжему, без сомнения, странно покажется найти в Казанских татарах, говоря вообще, народ более образованный, нежели некоторые даже Европейские».

Татарда көчле, алдынгы халык булу өчен кирәкле бөтен сыйфатлар да бар. Һәрхәлдә, булган. Фукс әйткән сәвәтлелектән тыш (шундый сүз булган аркылы тел ватып «грамотность» дибез!) бу—тырышлык та («Аттан артык эшлибез».). Гайрәт- батырлык та («Юлбарыстан көчлебез»). Соңгысын Тукайдан тыш шул ук Фукс та раслый. Көзен һәм язын урыслар һәм татарлар арасында була торган кумәк «спорт» давы—йодрык сугышы турында язганда ул болай ди: «Я заметил, что в этом боксировании татары имеют преимущество перед русскими бойцами». Булдыклылык та хас икән бит безгә. Революциягә кадәр Рәсәйдә алтын чыгаруның

төп өлешен кулга алып бетерә язганбыз. Хәйләкәрлек, ушлылык та булган. «Там, где есть татарин, еврею делать нечего», «Один татарин двух евреев стоит» дигән сүзләр тикмәгә генә телгә кермәгәндер ул.

Кызганычки, безне шушы хәлгә төшергән сыйфатлар да хас шул безгә. Яудагы батырлыкка тынычтагы куркаклык ялганган. Түрәләр алдында дер калтырап тору. Көчлеләргә, шул җөмләдән «хаким» халыкка ярарга тырышу. Күршеләргә хас начар сыйфатларны алардан да уздырып сеңдерә бару. Балаларны татар балалары итеп, милли иммунитет биреп, аларга татарга хас иң әйбәт сыйфатларны салып тәрбияли белмәү (әти-әниләр, әби-бабайлар вакытлы отышка алданып чит телле, ят рухлы балалар үстерүнең бала язмышына һәм, әлбәттә, үз язмышларына да бик тә каты китереп суга алачагын чамаламый булса кирәк! Телевизордан квартирларыннан куып чыгарылып бомж хәленә калган абзыйлар-апаларга кадәр күрсәткәләп торалар юкса... Туган халкыңнан йөз чөерү әниеңнән йөз чөерү кебек җирәнгеч бер эштер,рухи имгәклек билгеседер).

Һәм, әлбәттә, әлеге дә баягы таркаулык инде.

Сәяси-иҗтимагый берләшү барып чыкмауның бер сәбәбе, бәлкем, төп сәбәбедәдер, рухи бердәмлек булмау. Үз кавемең кешеләренә бераз гына булса да җылы мөнәсәбәт, аларны үз итү, якын күрү фарыздыр. Бармы соң бездә мондый җылылык?

Күптән түгел генә Шәүкәт Галиев дөнья куйды. Татарның чын халык шагыйре. Бәлкем, соңгы чорның иң популяр әдибедер бу. Нигәдер Камал театрында түгел, ишек алларында гына үткәрелгән матәм тантанасына килгән йөзләп кешегә шагыйрьнең мәкальгә әйләнгән менә бу ике юлы кат-кат җиткерелде:

*Исәннәрнең кадерен бел,*
*Үлгәннәрнең каберен бел.*

Халык шагыйренең каберен бик аз кеше генә беләдер. Чөнки теләүчеләрне Яңа бистә зиратына алып барырга дигән өч автобусның икесе артып калды. Зиратка килгән «Газель»дә дә буш урыннар бар иде. Берәүләр үз машиналарында да килде анысы. Ләкин барыбер дә бик аз идек. Әдәбият-сәнгать әһелләреннән алты-җиде кеше булдымы икән? Бераз гына элек Рафаэль Мостафинны күмгәндә дә шундыйрак иде хәлләр.

Исәннәрнең кадерен белү дигәне дә шул чамарак инде.

Безгә, йөзендә үлем шәүләсе чагыла башлаган бөек халыкның балаларына, хәзер бөтенләй башкача яшәргә кирәктер. Үзеңнең бөек шәхесеңне генә түгел (милли әйдәрләребезгә әйтүем!), башкаларны да күреп. Аларның йөзенә гайбәт җиме, гаеп түгел, әйбәт сыйфатлар табар өчен багыйк. Бер-береңә аз гына булса да ярдәм итешү, ким дигәндә җылы сүзеңне җәлләмәү—мөмкиндер бит бу? Беребез дә фәрештә түгел—иң асыл затларыбыз туктаусыз кырыла торганда, гасырларга сузылган коллык шартларында фәрештәләр каян килсен ди ул? Бер-беребезнең ялгыш фикерен иплән кенә кире кагып, һәр акыллы тәкъдимне гамәлгә ашырырга омтылыйк. Фантастик ук теләкләр түгел ләбаса бу, яһүдләр шулайрак яши бугай бит.

Татар гаиләсенә татулык иңгәч, милли бердәмлек дигәне дә ерак йөрмәс, Аллаһы боерса!

*Җилләр тик көч-куәт өстәрләр,*
*Бер учак булып без дәрләсәк.*
*Бер киртә дә безгә чыдамас,*
*Дулкынтау булып без бер бәрсәк.*

*Берләшик әле без, берләшик!*
*Бер халык булып бер,*
*Бер җан, бер тән булып*
*Бер яшик әле без, бер яшик!*

**Рәфикъ ЮНЫС**

# ЖУРНАЛГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2011 елның икенче яртысы өчен вакытлы матбугатка язылу тәгәлләнергә санаулы көннәр калды. «Казан утлары»ның индексы **73210** (физик затлар өчен), **16262** (юридик затлар өчен). Татарстанда ярты елга язылу бәясе физик затлар өчен **272 сум 94 тиен**, юридик затлар өчен **309 сум 30 тиен.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

«Казан утлары»на язылырга онытмагыз!

**Ф.СП-1**

Почта России

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ **журнал** | **73210** (индекс издания)

*«Казан утлары»*
(наименование издания) | количество комплектов:

на 20 11 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

---

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал | **73210** (индекс издания)

*«Казан утлары»*
(наименование издания)

| Стои-мость | подписки | ___руб.___коп. | количество комплектов: |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ___руб.___коп. | |

на 20 11 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда ______ (почтовый индекс) ______ (адрес)

Кому ______ (фамилия, имя, отчество)

**ИГЪТИБАР!**

Журналыбызның *kazanutlari@telebit.ru.* электрон адресы ябылу сәбәпле, хатларыгызны, документларыгызны фәкать **kazanutlari@yandex.ru** адресына гына юллагыз.

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу—безнең сәхифә!

*Ак җилкән*

*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ КАМИЛ

## Үзем түлим

***

VII сыйныфларга күчкәч зурлар киносына йөрисең килә башлый икән ул. Бала-чагалар арасында чуалган кызларның кызыгы бетә. Залдагы пырыш-пырыш борын тартыш, этеш-төртеш, рәт арасында йөгереп йөреш, кычкырып сөйләшеп утырулар—барысы да ачуны гына китерә, бу мескенлектән әкренләп котылу җаен карыйсың.

Кич җиткәч, киенеп-төзәнеп, ислемайлар сибенеп чыккан кызларның сере арта, адымнары салмаклана. Партадашың Зәкиягә дә ничектер сокланып, сагыну белән карыйсың. Аның яныннан үткәндә минем дә гәүдәм турая, муеным озыная, күз алларым яктырып китә.

Мина да «кино жене кагылды» дигән сүз инде бу! Клуб тәрәзәләрен каплап кына төшкән ясалма күләгәдә йөрми ул җен. Аңа залдагы чын карангылык, кызлар кулына үрелгән чакта да күршеләрең күрмәслек җете кара төн кирәк. Кино өзелеп, залда ут сүнгән арада сөенә-сөенә яшәп ала инде ул җен...

Монарчы кичке дүртләрдәге биш тиенлек сеанслар да ярап тора иде. Өйгә кайтканда урам буйлап бер-беренне бүлдерә-бүлдерә көләсең, үртәшәсең, бәхәсләшәсең. Зурлар каршы очрап, киносы кызыкмы, дип сорыйлар. Йә мактап туя алмыйсың киноны, йә бөтенләй бетереп ташлыйсың. Башка нәрсәләргә ис китми торган иде.

Безнең Шәледә зурлар киносына керәм дисәң паспорт сорамыйлар анысы, егерме тиен акчаң гына булсын! Элек ике сум иде ул. Гагарин галәмгә очкан елны бәяләрнең бер нуле югалды—акча алышынып, ун тапкырга кечерәеп калды. Аһ, ул яңа акчаларның матурлыгы! Затлы, тансык, көчле иде алар!

Авыл зур булгач, көн саен кино: бүген комедия, иртәгә «шпионаж», аннан индийский. Ул арада Казаннан концерт килеп төшә. Безгә акча күп китә...

Әйе, буш шешә белән бер йомырка китереп тапшырсаң, авылдагы өч кибетнең теләсә кайсысы ялык-йолык килеп торган егерме тиенлекне тоттыра инде кулына. Сельпога авыл хуҗалыгы продукциясе җыю планы куелган, буш шешәнне тавык йомыркасы белән түгел, сарык йонына төреп илтсәң дә акчага әйләндереп бирәләр.

Әти үлгәннән соң безнең өйдә аракы эчәрдәй кеше калмады, керосиннан бушаган шешәләрне дә эчен-тышын кычыткан белән юып тапшырдым инде.

Бушлай кинолар зур бәйрәмнәрдә генә: 8 Март, Җиңү көне, Октябрь бәйрәме...

Әнә, колхозның отчет-сайлау җыелышы бара. Ул да зур бәйрәм. Сельподан ярминкә төяләп килгән. Клубның фойе дип аталган ягына рәт-рәт лавкалар тезелгән, алар шәһәр нигъмәте, тәм-том, алма-хөрмә белән сыгылып тора. Әти-әниләр бу көнне юмарт, колхоз җитәкчелеге дә никтер шәфкатьле бу көнне.

Сыйланып тамак туйгач мажара кирәк бит инде, ә мажара клубның кино күрсәтә торган ягында. Анда жыелыш бара...

Без, жиденчеләр, инде мондый сайлауларга иярәнеп барабыз. Колхоз председателе алышынасы елны өч йөз урынлы залга биш йөз кеше кереп туласын да алдан ук белеп торабыз. Залдагы әрләш-кычкырышның туктаганын урам ягында көтеп йөрибез.

Соныннан бушлай кино була!

Безгә иске председатель калса шәбрәк, кешесе дә әзрәк була, алдан ук кереп утырып урын алып өлгерәбез, залдан куып чыгаручы да юк.

Председательнең кәгазьгә язылган докладында без анларлык юллар да бар... «Колхоз көче белән, 650 бала укырлык яңа мәктәп салыначак... Бүгенгесе көндә унөч йөк машинасы, жиде комбайн, сигез тракторыбыз бар... Авылда ике «Урал» мотоциклы, бер «Москвич», жиде телевизор исәптә...»

Бездә иң бай кеше—комбайнчы. Жиде телевизор да аларныкы. Ну кызыгабыз үзләренә—өеңнән чыкмыйча гына сөйгән кызың белән кино карап утыр әле син! Телевизордагы киноларны бер дә кыскартмыйлар ди. Ә безнең Ибрай, бу өлешен балаларга күрсәтергә ярамый, ә бу өлеше зурлар өчен күңелсез дип бер-ике кисәген төшерә дә калдыра. Моны белмәгән кеше юк инде...

***

Тагын бер бушлай кино караганыбыз истә калган.

Герой-пионер Марат Казей исемендәге безнең отряд (класс дип әйтик инде) тимер-томыр жыю буенча мәктәптә беренче урынга чыкты. Председатель бөтен укучыларны линейкага тезеп мактады. Безне район үзәгендәге «Вперёд» кинотеатрына бушлай сәяхәт белән бүләкләде. Ике серияле «Война и мир»ны карарга, беренче тапкыр киң форматлы, төсле һәм бушлай кинога барабыз!

Мәктәп машинасына урындыклар тезеп утырттылар, әрҗәнең борт кырыенда укытучылар, ә без—уртада. Егерме алтыбыз да! Беркем дә дәрес калдырмады бүген! Өйрәнгән жырларыбызны жырларга сигез чакрымлы урман юлы житмәде.

Өч сәгатьлек кино барышында мин «Война и мир» киносындагы Наташа Ростовага охшаган бер рус кызы белән танышып, адреслар алышып өлгердем. Ул күрше Анненково авылыннан Нина Леонтьева иде. Нина белән без өйгә кайту белән, бүгеннән башлап, хат алышырга сүз бирдек. Шәленекеләр кечкенәдән базар юлын таптаган халык, мин дә рус кызының адресын алырлык кына русча беләм инде.

Без «Сугыш белән солых» арасында пышылдашып утырган арада май кояшы әллә кайчан баеп, сигез чакрымлы нарат урманы дөм карурманга әверелгән иде инде. Ике чакрым үттек микән, машинабызның алгы көпчәге шартлады. Жиргә коелдык. Караңгыда кармаланып, арткы парлы көпчәкнең сынарын алга күчереп куйдылар. Янә ярты чакрым үттек микән, алгы көпчәкнең икенчесе—«шарт!». Тагын арткы көпчәкнең берсен күчереп куйдык. Инде машинабызның исән көпчәге дүртәү генә калды. Ярты юлга житәр-житмәс килеш тагын, бу юлысы инде арткы көпчәкнең сул яктагысы ярылды. Мәктәп машинасы өч көпчәк өстендә калды...

Шунда мин авыл шоферларының тапкырлыгына сокландым, яшерен-батырын түгел, үскәч үзем дә шофер булыр идем дигән уй туды хәтта... Шофер абыебыз дөм караңгы урман эченнән өч-дүрт метр чамасындагы юан сиртмә кисеп алып чыкты. (Авылныкылар балтасыз йөрми инде.) Һәм көпчәксез калган арткы күчәрне шул сиртмәгә бастырды.

—Ачуланмагыз, жәяү кайтырсыз инде,—диде шофер.—Мин сызган юлдан тайпылмагыз, адашырсыз,—дип шаяртты да әле үзенчә.

Чынлап та, өч көпчәкле машина кузгалып китте, ә дүртенче көпчәк урынына куелган сиртмә такыр юлны тырнап, буразна сызып бара...

Мәктәп машинасы сызган туры юлдан төнге берләрдә кайтып життек. Радиаторы кызмасын диптер инде, шофер туктап-туктап көтеп алды, аның ерак китмәве батырайта иде безне.

Төнге юлда мин Зәкия белән дә, Мөслимә, Әлфия белән дә сөйләшмәдем, Нинага язасы беренче хатның эчтәлеген иншалап бардым. Юл газапларын тәфсилләп язып булмас, русча түгел, татарчалап язсам да механизаторлардан башка кеше аңламас.

Без кино караган арада машинабызның өч көпчәгенә дә пәке белән кадаганнар икән. Мин Анненково малайларыннан шикләндем.

Нина белән без бер ел хат алыштык. Сигезенчене тәмамлагач килгән соңгы хаты хәтеремдә: «Коля (Мин инде бу.), извини, я уехала в Казань. И фамилия у меня теперь не Леонтьева, а Власова... Не обижайся!»—диелгән иде. Тагын унбиш елдан Анненково дигән авыл да бетте. Сигез классны тәмамлауга ук фамилия алыштыручылары күбәйгәндер, ахрысы... Хәер, болары инде минем бәләкәй чакларга бигүк кагылмый. Мин үзем дә дүртенче сыйныфта укыганда ук Хәйдәр абыемның хатынына—Фәризә жингигә өйләнәм дип елаган кеше...

Шулай итеп, без жиденчене тәмамлап киләбез. Май аен да жинсәк, жәйге каникуллар башлана.

***



Кино жене кагылгач, өйдә утырам димә. Көн саен клубка чыгар өчен акча житкерер хәл юк.

Урамыбызның дүрт малае, ничегрәк акча эшләргә микән дип баш ватып утырабыз. Елның да жайсыз-ашсыз чагы, кала базарына илтеп сатар иден—шомырт-жиләк чәчәк атмаган, суган кыягы чыкмаган... Бер кило ландыш чәчәге киптерсәң, аптекалар биш сумга ала икән алуын. Ләкин ул чаклы энже чәчәк үсми шул бездә. Авылдан алты көтү чыгып жәй буе урман таптый. Нарат күркәсенең дә килосы унике тиен, тик акчалата түгел, йә утын, йә деловой нарат белән түлиләр. Үтильчегә капчыклап иске чүпрәк, сөяк-санак жыеп тапшырсаң, алтышар тиеннән ярыйсы гына жыела. Тик хикмәт тә шунда—кино жене кагылганнан бирле капчык күтәреп тыкрык таптап йөрүләре хурландыра башлады.

Заготовка турында сүз чыккач, Рафаэль дигәнебез әйтеп куймасынмы: бурсык, әрлән, йомран тиреләренең дә бәясе ару гына икән...

Рафаэльгә ышанмый хәл юк, тире жыючы ана әнисе ягыннан туган тиешле кеше.

Бурсыкларның кайда яшәгәнен беребез дә белми булып чыкты. Аучы Нәгыйм абыйдан сорасаң да әйтмәячәк инде ул аны. Ә менә әрлән-йомранның кайдалыгын Рафаэль үзе әйтеп бирде—Коры Кәвәл буенда икән. Аның әтисе колхозның баш агрономы, узган жәйдә Коры Кәвәл басуына житмеш гектар борчак чәчкәниек, йомран ашап бетерде, быел өч йөз гектар чәчәбез, тыгынсыннар, дип әйтеп әйткән ди.

Иртән иртүк торып Коры Кәвәлгә акча эшләргә чыгып киттек, капчык асып. Көне буена дигәч, үзебезне генә жибәрмәделәр. «Трай» тибеп «шакал трест»лыкта йөрмәссез, кәжә-сарыкларны да жир иснәтеп алып кайтырсыз, диделәр. Әле авыл көтүе чыгарга иртәрәк, мал-туар өйдә жәйне сагынып үкереп ята.

Йомраннар безне сыбызгылар белән каршы алды: арт аякларына басып, малай-шалай шикелле, әллә ике бармагын авызына кабып әче итеп сызгыралар шунда... Анысы еракган аермачык күренми, якын килә башласаң, текә ояларына чумалар. «Сызгырма, акчаң булмас!»—дигән ырымны без беләбез, ә йомраннар аны каян белсен?!

Йомран төннегенә ерганактан су ташыйбыз, күнитекләр белән. Ике итек—бер чиләк... Алты чиләк су тутыргач, оядан йомран башы күренде. Чалбар каешыннан элмәк ясап, муеныннан сөйрәп алдык тегене. Кыш буе өнендә кипкән борчак кимереп кайралган тешләрен ыржайткан, камыт энәсе кебек очлы тырнакларын тырпайткан, элмәктән ычкынса, битеңә сикереп, тәүбә-тәүбә, кино женең чыгара инде аннары...

Тизрәк капчык эченә ыргытып, элмәкне бушаттык.

Шушы тирәдән генә сигез йомран чүпләдек. Калганнары тоттырмады, салган су буш ояларга сеңеп кенә барды.

Бер әрлән оясы да очраган иде, тик ул бер чиләкле самавыр моржасы юанлыгы, күнитек белән су ташып кына тутырырлык түгел... Төннегенә колак терәп тынлаган идем—Җир шарының теге ягыннан һинд кызларының җырлаганы ишетелә сыман.

Кеше башына икешәр йомран тия, боларын сатып акчасын туздырып карыйк әле, аннан соң тагын килербез дидек тә, кояшның баеганын көтмичә үзебез байлык артыннан ашыктык.

Капчыкны биштәрләү һич мөмкин түгел иде, утыз ике тәпиле тырнак тишеп чыккан. Озын таякка асып юл буе икәүләп күтәрергә туры килде.

Тире җыючы Гатаулла абый биштәрне ачып карады да, авызын бөрештереп кенә сызгырып куйды: тәк, ди бу, фәлән дә төгән, мин тирене тере килеш җыймыйм, боларны тунарга кирәк.

Әйтергә генә ансат, тунаганчы чалырга кирәк бит әле бу тешләкләрне! Хәер, авылда мал чалучылар бетмәгән. Өлешкә кирәрләр инде.



Шунда башыма бер шәп сорау килде, минәйтәм, ничә сум соң монын берсе?

—Алты тиен,—диде Гатаулла абый.

Без аны шаярта дип уйладык, чынлап та бер йомран тиресе алты тиен генә икән... Алты тиен—бер, ике һәм өч тиенлек бакыр-бокыр булып күз алдымда тора. Акча алышынгач, бу сары тимерләр иске-москы килеш әйләнештә калды. Яңа егерме тиенлекләр арасында бик ямьсез иде алар.

Йомран чалдырып йөреп бәеткә кирәсебез килмәде. Сигез йомранлы капчыкны күтәреп өйләргә кайтып барабыз... Песи ашамый инде боларны, Коры Кәвәлгә илтсәң, соңга калдык, клубка чыгар чак җитеп килә. Әниләр күрсә, каравыл кычкырачак!

Дүртебез дә, сүз куешкандай, күпер өстендә туктап калдык. Инешнен зур елгага охшарга тырышып масаеп аккан мәле. Як-якка каранып кеше юклыкка ышандык та капчыктагы борчак убырларын язгы ташкынга селкедек.

Без генә белмәгәнбез, шәп йөзәләр икән, «эһ» дигәнче сөзәк ярга чыгып, Гатаулла абыйларның бакча башындагы таллыкка кереп югалдылар.

Әни чишмәдән кайткан саен йомраннар хакында хәвефле яңалык көтәм. Шөкер, авылыбыз алардан кеше теленә керерлек зур зыян күрмәде бугай... Инде 46 ел көтәм... Ишетелер иде.

***

Ул җәйне мин каникулга чыккач прицепщик булып эшкә урнаштым. Коры Кәвәл басуыннан борчак саламы әвәләгәндә Каюм абыйның «Владимировец» тракторыннан өркеп качкан симез йомраннар күренгәләде. Тик сызгырмыйлар иде инде алар.

Сабантуй алдыннан механизаторларга хезмәт хакы бирделәр.

Кесәгә кәгазь акчалар керде. Аһ, ул акчаларның матурлыгы! Кичке киноларга йөрү үзе бәйрәм хәзер. Рәшидәне кунак кызы белән алдан үткәрәм дә, киномеханик Ибрайга горур гына ияк кагам:

—Үзем түлим!

**Камил КӘРИМОВ**

# ЗУР СӘРДЕКТӘН «АК ҖИЛКӘН»ГӘ ИҖАТ СӘЛАМЕ

*Мөхтәрәм «җилкәнчеләр!»*

*Кукмара районының Зур Сәрдек гимназиясендә «яшь иҗатчы» түгәрәге эшли икән. Шуларның каләменнән төшкән язмаларны укып торып җибәрегез әле!*

## Тәмен белеп эшләсәң!

Һәр авылның үз йөзе, үз архитектурасы була. Бизәкләп эшләнгән капка-тәрәзәләр,челтәрле рәшәткәләр йортның кабатланмас матурлыгын тәэмин итә. Минем әтиемнең алтын куллары шул матурлыкны тулыландыра кебек тоела миңа. Бу куллар чүкеч, кадакны биетеп кенә йөртә, ватык техниканы төзәтә, өстәл-урындык ясый,бизәкләп эшләгән капкадан башлап өй эчендәге җиһазларга кадәр бар итә.

Әтием—Васил Горохов, мәктәп елларында ук агач эше белән мавыга һәм хәзер дә әлеге һөнәрен ташларга җыенмый. «Бу сәләт сиңа кемнән килде?» дигәч, әтием болай дип сөйләде: «Хезмәт дәресеннән безгә Әхмәтшин Гаян абый керә иде. Без аны бик хөрмәт итәбез. Бервакыт мин олы малайлардан көнләшеп Гаян абыйдан станокта эшләп карарга рөхсәт сораган идем. Аның җавабы мондый булды: «Өйрәнәм дигән кеше станокка басмыйча да өйрәнә ул, балакаем». Мин аптырап калмадым,кайтуга кирәкле эш коралларын булдырып станок кордым. Бу хәл минем агач эшенә кереп китүемнең төп этәргече булды. Сәләт миңа бабам Шәрәфидән дә килгәндер. Ул да бик оста кеше иде. Ә мин улым Госманга күчәр дип өметләнәм. Ике яшьлек кенә булса да,пычкысын да, чүкечен дә кайдан тотасын белә ул.»

Күңел биреп эшләгән хезмәтең, яраткан һөнәрең булу ярты бәхет бит ул. Хезмәт җимешләрең чәчәктәй тирә-ягыңны ямьләндереп, кешеләр күзен сөендереп торса,бигрәк тә.

Хәзерге вакытта әтиемнең алтын кулларыннан өебез балкып тора. Безнең «оябызда» бер генә кибет җиһазы да юк. Ул дивандыр, төрле зурлыктагы өстәл-урындыктыр,кәнәфидер,караватшифоньердыр—санап бетерерлек түгел аларны.

Агач эшеннән башка әтием тегә,бәйли,чигә,оста итеп рәсем ясый белә һәм шулай ук зур, матур хыялларга күмелеп йөрергә ярата. Диван, кәнәфиләргә чехолны үзе текте,мине бәйләргә һәм чигәргә өйрәтте ул. Матур итеп рәсем ясауны да әтиемнән йоктырдым мин. Әтиемнең киләчәккә хыяллары иксез-чиксез. Менә күп кенә еллардан бирле аның палас бәйләп карыйсы килә, тик куллары гына каты яргаланган шул.

Бакчага беседка һәм аның янына аккошлы күл дә ясыйсы килә әле аның. Хәтта эскизларына кадәр бар,ләкин быел җәй буе капка ясау белән мавыгып,алары киләсе елга калды. Әтием нинди эшкә генә тотынмасын,«Һәр эшнең тәмен белеп эшләргә кирәк!»—дип әйтмичә калмый. Без дә моның белән килешәбез.

**Исламия ГОРОХОВА**

## Кар көрәүнең тәме

Явып та күрсәтте быел кар. Башка еллардагы кебек гыйнвар, февраль айларында гына түгел, кышның беренче көннәреннән үк ишеп яуды. Күбәләк-күбәләк булып та, буранлап та, тәңкә-тәңкә булып та... Ява да ява. Аннан бөтен җиргә ак бәс булып, табигатькә әкияти сихрилек өстәп тынып кала.

Авылны кышын яратам мин. Мондый көннәрдә урамыннан йөрүләре транспортка түгел, җәяүле өчен дә җәфа булса да. Карап хозурланырга матур! Бөтенләй элекке заманнар кебек. Өеп куелган кар сыртларының икенче ягыннан үткән кеше күренми дә. Тиздән кар ерып юл салуы күңелле дә соң! Йорт тирәсен кардан чистартуның үзенең бер рәте бар. Көрәгеңне тотырып бер аласың карны, ике аласың. Алай гына нәтиҗәсе күренми әле. Берничә селтәнүдән соң күзгә күренеп яңа сукмак салына башлый. Аннан дәртләнеп китеп тагын, тагын алып ташлыйсың. Кулга киеп чыккан бияләең кесә төбенә шуа, шарф бавыңны бушатасың, бишмәтеңнең өске төймәләре чишелә. Тирләп пешәсең. Көне дә эсселәнеп киткән кебек. Туктап хәл алганда, артка карап эшләгән эшеңә карап ләззәтләнүләре тагын!

Моржадан төтен өскә күтәрелә. Әһә, иртәгә суык булырга ошаган. Димәк, кар яумаячак. Әле син көрәгән бу урын бер-ике көн рәхәтләнеп чиста килеш тора дигән сүз. Ишегалды ачылды, капка төбе, гараж алларына юл салынды. Эшеңнең ахырына якынлашасың. Яңа гына кардан арчылган сукмактан ахыргы тапкыр көрәгеңне шудырып баруы тагын рәхәт. Чистартылган юлдан ул да җырлап бара.

Авыл җирендә капка төбенең ничек ачылуыннан йорт хуҗасы турында күпне белеп була. Ялгызы гына яшәүче карт-коры гадәттә капка төбен үзе йөрерлек кенә, кәҗә сукмагы калдырып ача. Өендә булышчылары булганнар юлларын әллә каян күренеп торырлык итеп, киң итеп ялтырата. Аеруча тырышлары себереп куярга да онытмый.

Салкын һавада кар көрәп кергәч, җылы өйдә кайнар чәй эчүләре үзе бер ләззәт. Җылыга кергәч, җебегән борын да, уттай кызган бит алмалары, куллар да бу хисне көчәйтә генә. Чәйне бер чынаяк эчәсең, икене, өчне...Маңгаеңа, борын очларыңа борчак-борчак тир бәреп чыкканчы. Шулай яратып эшләгән эшеңнең нәтиҗәсе һаман күз алдында күңелне үсендереп тора. Иртәгесен шул үзең ачкан юлдан чыгып китүләре дә күңелле. Ә кичен өеңә кайтканда кабат акрын гына кар ява торган була. Яусын!

*Энже* **ХӘБИБРАХМАНОВА**

## Мин ялкау түгел

**Мәктәптә дә, өйдә дә**
**Мине ялкау диләр.**
**Нишләп ялкау булыйм ди мин,**
**Алар белми сөйлиләр.**

**Ал-ял белми телевизор**
**Карый идем моңарчы.**
**Аптырагач, армый-талмый**
**Уйныйм инде туйганчы.**

**Ә кушамат миннән калмый,**
**«Ялкау!» диеп көләләр,**
**Еларга да күп сорамам,**
**Алар мине беләләр!**

*Нәзилә* **ФӘТХЕТДИНОВА**

## Менә шундый укытучы!

...2009 елның 2 сентябре, 5нче сыйныфта укыган вакыт. 3нче дәрестә безгә инглиз теле кирәргә тиеш. Без әле бу фәннән кем укытачагын да белмибез. Дәрескә кыңгырау чылтырагач, классыбызга яшь кенә, чибәр, мөлаем укытучы килеп керде. Ул иплəп кенә үзе белән таныштырды. Апабыз Нурфия исемле икән, ул безне инглиз теленнән укытачак. Шушы көннән бирле Нурфия Фәритовна безнең яраткан укытучыбызга әйләнде. Үзенең гадилеге, тырышлыгы һәм яшьлек дәрте белән үзенә генә түгел, укыткан фәненә карата да кызыксыну уята, мәхәббәт тәрбияли алды ул.

Нурфия Фәритовна—күрше Чишмәбаш авылы кызы. Гади авыл баласына кайдан килгән чит тел белән кызыксыну теләге? Ул үзе бу турыда менәниләр сөйли: «Кечкенә вакытта ук инглиз телен тирәнтен өйрәнәсем һәм мәктәптә укытучы булып эшлисем килде. Бу хисне 5нче сыйныфта укыганда остазым Рафилә Зөфәр кызы тагын да көчәйтте. Гадәттә укытучы булу теләге кечкенә сыйныфларда укыган чакта уяна да, соңыннан онытыла. Ә мин онытмадым. Мин бу хыялымны йөрәк түремдә сакладым». Ерак хыял иле—Америкага барып кайту да үз эшен эшли. Укытучыбызның белеме тагын да арта, теле шомара, тормышка карашы үзгәрә. «2008 елда 5 ай чит илдә яшәп, андагы тормышны өйрәндем. Анда тормыш бөтенләй башка. Америкада бик эссе, ашавы да, акчалары да, кешеләре дә башка. Тормыш күпкә алга киткән. Халкы бик мөлаем, ачык йөзле. Гел елмаеп кына сөйләшәләр, һәрчак ярдәм итәргә әзерләр. Моңа үзең күрмичә ышанып та булмый. Шуңа бер вакыйганы сөйлим әле сезгә. Бервакыт банкка акчаны долларга үзгәртергә дип кердек. Инде эш сәгате ахырына якынлашкан иде, хезмәткәрләр кайтырга әзерләнә. Шулчак бер ханым безнең нишләп йөрүебез белән, кайдан килүебез белән кызыксынды. Гозеребезне әйткәч, сүндерелгән бөтен аппаратын кабат кабызып, кайтырга дип кигән киемен салып эшкә керешә. Безнең җәяү килгәнне белгәч, утырырга урындыгын бирде, ә үзе безнең янибызга тезләнеп аңлата башлады. Үз машинасы белән өйгә кадәр кайтарып куйды. Соңыннан гына белдек, ул банк җитәкчесе булган икән. Башка илдән килгәнебезне, ярдәм кирәклеген белгәч менә ничек булышты ул безгә, шаклар каттык! Мондый игътибарлылык, гадилеккә иялəнгәнмени без?! Американнар аралашырга ярата һәм ... ашарга (көлә). Гел консервантлар белән генә туклана. Бәлки, шуңадыр, аларның күбесе артык таза».

Нурфия апабыз укытучы гына түгел, биюче дә әле. Ул бик актив, төрле конкурсларда катнаша. Үзе артыннан укучыларны да ияртә белә. Яңа ел, Сөмбелә кебек бәйрәмнәр өчен төрле биюләр өйрәтә. Укытучыбыз үзе: «Тәпи йөри башлаганнан бирле биим. Иң беренче бию алымнарын укытучым Фәридә Мөхлис кызы өйрәтте, аннан соң Арча педагогия көллиятендә оештырылган «Ләйсән» бию ансамблендә шөгыльләндем»,—ди.

Моннан тыш, Нурфия Фәритовна иҗтимагый-сәяси тормыш белән дә кызыксына. Узган ел ул авыл җирлегенә депутат булып сайланды. Гимназиядә профсоюз оешмасын җитәкли. Читтән торып Татар дәүләт педагогика университетының чит телләр факультетында белем ала. Машина да йөртә әле!

Менә шундый ул безнең яшь, тиктормас Нурфия апабыз. Барысына да ничек өлгерә дә, каян вакыт таба дип уйлыйбыз аңа карап. Күптән түгел гаиләле дә булды әле. Ире Салават белән тигез тормыш, гаилә бәхете телибез аңа!

**Динә ГАБДЕЛМАННАПОВА**

# *Дания Нәгыймуллина*



Мин—Балык Бистәсе районының Югары Тегермәнлек авылыннан. Шаян, уйчан, үҗәт, тыңлаучан, хыялый һәм максатчан кыз.

Хәзерге вакытта Казан сәүдә-икътисад техникумында белем алам. Шигырьләрем басылганда тәмамлаган булырмын инде, чөнки соңгы курста укыйм.

## Гөнаһлы җиһан

**Мин гаҗәпкә калмам кебек, әгәр**
**Җир әйләнеп беркөн туктаса,**
**Кылган гөнаһларны кичералмый**
**Язмыш таяклары тукмаса.**

**Гаҗәпләнмәм, кояш чыкмый гына**
**Оятыннан торса кызарып,**
**Җиһан тулы нәфрәтләрдән өркеп**
**Бәби туса әгәр соңарып.**

**Тәнен сатканнарга ачу итеп**
**Күкләр меңгә әгәр ярылса,**
**Сәерсенмәм. Адым саен сүгенү**
**Тузан булып җанга сарыла.**

**Кара туфрак кардәш-туганнарның**
**Сеңдергән күп садә каннарын.**
**«Кичер безне»,—диеп әби сала**
**Мәчетләргә сәдакаларын.**

## Тынгысызлык

**Үҗәтләнеп гөнаһлы җиһанга**
**Туа алсу таң.**
**Дөньясына зәһәр рәнҗеш төшкән**
**Үпкә, ярсудан.**

**Юып элгән керләр агармаган—**
**Күренә табы.**

**Аталмыйча сулды гөлчәчәгем...**
**Ни булды тагы?**

**Күзгә кыйпылчыгы үтеп кергән**
**Кан тамырына.**
**Акчарлаклар очкан җирдән аска**
**Хис томырыла.**

## Халкыма

**Таң туа... Салдыр тәрәздән**
**Караңгы пәрдәләрең.**
**Җиләк-җимеш белән тутыр**
**Милләтең әрҗәләрен.**

**Күгәректән азат иттер**
**Тутыккан татар җанын.**
**Милләттәшләрең кайтсыннар**
**Сагнып Татарстанын.**

**Куркып караш ташлап ятма**
**Камышлык арасыннан.**
**Тарихларга керә күрмә**
**«Титаник»-караб сыман.**

**Кабер ташы куймасыннар**
**Сиңа өметләр өзеп.**
**Җимерелгән диварларны**
**Җибәр яңадан төзеп!**

## Тормыш кануны

Тормыш юлын уч төбеннән карап,
Тигез җиргә басма салабыз.
Эшсез күкеләргә боерабыз:
«Гомерләрне мильләп санагыз!»

Карта ачып, шуңа ышанабыз,
Ерагаеп Бөек Алладан.
Кеше күзгә төтен җибәрсә дә,
Тәкъдирләрне кемнәр алдаган?

Тау кадәрле бәхет алыр иде
Күпләр, биреп булган акчасын.
Гамәл аша кеше үзе сайлый
Тәмуг яки җәннәт бакчасын.

Тормыш кануннары юк диябез
Атлаганда җәбер-золымнан.
Безнең тормыш үрнәге ул—Коръән!
Раббым, сакла гөнаһ юлыннан.

## Өйнең нуры

Ап-ак болытларга карап
Йөзә өч лачын.
Белдең микән безнең, әни,
Берчак очасын?

Изге эш-гамәлләреңнән
Сузылган күпер.
Шуның аша саф чишмәгә
Йөрүче күптер.

Күзләрең нуры, әнием,
Җылыта өйне.
Эретә назлы кулларың
Җандагы җөйне.

* * *

Синнән калган зәңгәр кулгә
Ком сибәм учлап-учлап.
Син сындырган канатымның
Каурыен ятам очлап.

## Хыялга тугры калам

Мин хыялга тугры калам!
Дуслар өмет өзгәндә дә
Мәрхәмәтле бул, Аллам.

Хыялларга тугры калам...
Очкын бәреп торсын өчен
Каләмнән кулым алмам.

Хыялыма тугры калам.
Сагыш эземә басса да,
Өмет канатын салмам.

Хыялыма калам тугры!
Мин очлаган кояш нуры
Хыялга очсын туры!

## Соңару

«Яратмадым» диеп ялганлама,
Күзләреңнән укыйм киресен.
Сагынуның тозлы тәмен тоеп,
Төшләремә килеп керерсең.

Кайтавазлар толымнары кебек
Сарылырсың минем тәрәзгә.
Соңгы өмет тамчың төшеп калыр
Карлы юлдан үткән тар эзгә.

***

Чагылганмы күзләр ал кояштан?
Тузан баса көмеш яшьләрем...
Йөрәгемне әрнү басканда да
«Мин бәхетле» диеп яшәрмен.

Чуар күктән җыям итәгемә
Йолдызларның иң-иң асылын.
Көзге яфрак сәйләннәрен кушып
Тәрәзәмә ясыйм яз сынын.

## Эт тормышы

**Аксаклап һәм иеп башыңны**
**Кайларга, и маэмай, юл тотыш?**
**Төш булса, уяныр идең дә,**
**Әмма ул—тәкъдирең, ул—тормыш!**
**Ул—тормыш!**

**Кемнәрдер, йомшакта чәңгелдәп,**
**Ризасыз булуын аңлата.**
**Урамның тузаны—туганың.**
**Кояшсыз тагын бер таң ата**
**Таң ата...**

**Язмышың кебек үк тигәнәк**
**Артыңнан калырга уйламый.**

**Күзеңнән тын гына яшь тама...**
**Әйтәсең: көчләләр уламый.**
**Уламый.**

**Бер кеше сиңа дип калдырган**
**Ризыкны таптады башкасы.**
**Изгелек буенча үлчәсәң,**
**Хәзерге замана—таш гасыр.**
**Таш гасыр.**

**Әкренләп чокырлы юллардан**
**Атлыйсың, мескен эт, каядыр...**
**Көлмәгез сез аннан. Тормышта**
**Һәркемнең аягы таядыр.**
**Таядыр...**

---

## «Ишәкләр белән очрашмыйм!»

Урта мәктәптә өйрәнелгән физиканы онытмаган шәхесләр хәтерлидер, мөгаен: СИ системасындагы температура шкаласының берәмлеге 1968 елга тиклем Кельвин градусы дип атала иде. Кем соң ул, Кельвин исемле галим? Баксаң, аның чын исеме Уильям Томсон булган икән. Фәнни тикшеренүләрендәге искиткеч казанышлары өчен Бөекбританиянең әби патшасы Виктория 1892 елда аңа лорд дәрәҗәсен бүләк иткән, ә ул, форсаттан файдаланып, үзенә яңа, Кельвин (Kelvin) исемен «приватлаштырган» (Глазго шәһәрендәге үзе эшләгән университет мәйданы аша агып үткән инешнең атамасы шундый булган). Шуннан соң инглиз телендә электр энергиясенең берәмлеге дә kelvin дип атала башлаган. Кызык бит: географлар яңа объектны аны ачкан кешенең исеме белән атыйлар. Ә мәшһүр физик, кайбер артистлар яисә әдипләр кебек, киресенчә, үзенең исемен үзгәрткән. Бәлки, ул үзен Томсон фамилияле башка галимнәр белән бутамасыннар дип шулай эшләгәндер. Англиядә аталы-уллы ике мәшһүр физик, Джозеф Джон һәм Джордж Паджет

Томсоннар да булган бит әле. Өстәвенә, Шотландиядә дөньякүләм танылган океанограф һәм биолог Джордж Уайвилл Томсон да яшәгән. Рәсәйдә атаклы тел белгече Александр Иванович һәм соңрак геолог Ильмар Николаевич Томсоннар да фән хәзинәләренә саллы өстәмәләрен кертkәннәр.

Хәер, лорд дәрәҗәсенә лаек булган кешенең үз исемен үзгәртү традициясе Англиядә хәзер дә саклана. Әмма, сүз башым бит шуңа дигәндәй, лорд Кельвинга кире кайтыйм әле. Аның гидродинамика өлкәләрендәге, сыгылмалык тәгълиматендәге, математикадагы, электр һәм магнит күренешләре һәм башка бихисап юнәлешләрдәге ачышлары һәм казанышларын кыскача гына тасвирлап китәр өчен генә дә шактый вакыт һәм журнал битләре кирәк булыр иде. Аның эшчәнлеге кабинет яисә лаборатория кысаларында гына чикләнеп калмаган. Ул трансатлантик кабель элемтәсен тормышка ашыруда ифрат актив катнаша, тибрәнеш контуры ешлыгының аның сыешлыгы һәм индуктивлыгына бәйлелеген ачыклый, бик күп электр үлчәү җиһазларын уйлап таба, диңгез навигациясе җиһазларын камилләштерә, аның исеме белән аталган берничә күренешне ачыклый. Кыскасы, физика, механика, математика, техника өлкәләрендәге фәнни һәм гамәли эшләре белән үз заманының иң күркәм галиме буларак таныла. Лондондагы король җәмгыятенең (Англиянең Фәннәр академиясе әле дә шулай дип атала) президенты булу белән бергә башка илләрдә, шул исәптән Россиядә дә, Фән академияләренең абруйлы әгъзасы итеп сайлана.

Шундый уникаль галимнең тәрҗемәи хәлен дә белү зарур. Уильям Томсон Ирландиянең Белфаст каласында, математика укытучы гаиләсендә дөнья күрә. Ана сигез яшь тулгач, гаилә Глазго каласына күчә. Шундук яшүсмер университетта әтисенең лекцияләренә йөри башлый, ике ел узуга ун яшьлек искиткеч сәләтле малай Глазго университетында студент сыйфатында укуын дәвам итә. Анда укуын тәмамлагач, Уильям Кембридж университетында белем туплый һәм, әтисенең киңәше белән, Парижда күренекле физик А. Реньоның лабораториясендә фәнни тикшеренүләрен дәвам итә. Тиз арада яшь студент җылылык үткәрү тәгълимате буенча беренче эшен матбугатта нәшер итә. Глазго университетында профессор булып эш башлаганда аңа егерме ике генә яшь була әле. Илле өч ел буена галим шул университетта кафедра мөдире сыйфатында эшли. Яши дисәк, дөресрәк тә булыр, мөгаен.

Бөек галим үзен оста укытучы сыйфатында да таныта, теориягә өйрәтүне гамәли эшләр белән берьюлы алып бара. Аның физика буенча лекцияләре һәрчак темага кагылышлы тәҗрибәләргә ифрат бай була. Тәҗрибәләрдә Томсон шәкертләрен дә катнаштыра, әлбәттә, андый алымнар укучыларда зур кызыксыну уята. Һәрдаим иҗат процессында яшәгән «физика короле» фән дөньясына зур мирас, 25 фәнни китап, 660 мәкалә һәм үзе уйлап тапкан җитмеш яңа җайланма калдыра.

Сүз ахырында «Пәрәвез»дә табылган бер риваятьне китерәм. Берчак лорд Кельвин, ниндидер сәбәбе чыгып, лекциясен икенче көнгә кичектерергә мәҗбүр була һәм аудиториядәге тактага болай дип язып калдыра: «Professor Tomson will not meet his classes today». Тәрҗемәсе: «Профессор Томсон бүген укучылары белән очрашмаячак». Студентлар, профессорны шаяртып, «classes» сүзендәге беренче хәрефне бозалар. Икенче көнне язманы күргән профессор аптырап калмый, шул сүздәге икенче хәрефне дә сөртә дә, дәшми генә аудиториядән чыгып китә. Сүзләрнең тәрҗемәсе: classes—класслар, lasses—сөяркәләр, asses—ишәкләр.

**Ким ШАКИРОВ**

# ЧАЙНВОРД




1. Г.Тукайның «...Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл...» дигән юллары булган шигыре;
2. «Тукай маршы» авторының исеме;
3. Шагыйрьнең псевдонимы;
4. Кушлавыч авылында нәни Тукайны тәрбияләгән ярлы карчык;
5. Г.Тукай шигырьләрен бастырган, мөхәррире К.Мотыйгый булган журнал;
6. Г.Тукайның мәдрәсәдәге шук малай мажарасы турында язган поэмасы;
7. Г.Тукай сүзләренә язылган татар халык җыры;
8. «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш» поэмасындагы персонаж;
9. Берничә кисәктән торган зур калын китап;
10. Әнисенең исеме;
11. Казандагы мәчет;
12. Әтисенең исеме;
13. Г.Тукай корректор булып эшләгән гәҗит исеме;
14. «Шагыйрь мәхәббәте» операсы либреттосының авторы исеме;
15. «Су анасы» югалта язган әйбер;
16. Г.Тукай дәваланган хастаханә;
17. Агачка чокып ясалган орнамент (бизәк);
18. Г.Тукай поэмасына язылган балет;
19. «Канатлы ат»ны уйлап тапкан язучы.

***Чайнвордның җаваплары киләсе санда.***

---

*«Ак җилкән»гә хат язу өчен адрес:*
*420066, Казан, Декабристлар ур., 2, «Казан утлары», «Ак җилкән».*
*E-mail: kazanutlari@yandex.ru.*



Казанның 1000 еллыгы уңаеннан Америкадан килгән милләттәшләребез «Идел-Пресс» хезмәткәрләре белән. 2005 ел.



Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Илфак Ибраһимов (Мөхәммәт Мирза)



«Казан утлары»нда хезмәт иткән шәхесләр. Сулдан уңга— Нури Арсланов, Кояш Тимбикова, Сибгат Хәким, Зәки Нури. 1980 еллар.



*Дөньякүләм мәшһүр композитор София Гобәйдуллина (уң яктан икенче) Казанда. 1993 ел.*



*Композитор Әнвәр Бакиров.*



*Рәсемдә: журналист Венера Ихсанова, җырчы һәм режиссер Нияз Даутов, шагыйрь Мөхәммәт Садри. 70нче еллар.*

Фәнис
Яруллин

# ХӘТЕР ТӨПЛӘРЕНДӘ УТЛЫ КҮМЕР

КӨНДӘЛЕКЛӘР

**31 март.** «Казан утлары»ның 3нче санын укып яттым. Журналда проза турында сөйләшү бара. 2нче сан А.Гыйлажев мәкаләсе белән башланган иде. Бу санда Р.Мостафин, Ф.Галимуллин мәкаләләре бирелгән. Татар прозасы союзкүләм югарылыкта түгел дип пошыналар авторлар.

Һәр тәнкыйтьче зур күләмле әсәрләр турында гына сүз алып бара. Ә бәлки хәзер әдәбиятыбыз йөзен билгеләүче булып хикәяләр торадыр. Әмма хикәягә әһәмият бирүче юк. Рус әдәбиятында да шулай бу. Безнең татар әдәбиятында прозаның артта калу сәбәпләрен ачыклый башласаң, иң әүвәл урынсыз мактауны алырга кирәктер. Берәүне актуаль темага язганга мактыйбыз, икенчесен—роман тикле романны «җинеп чыкканы» өчен, өченчесен—күптән язган кешене тәнкыйтьләү яхшы түгел дип, дүртенчесен әйбәт урында утырганы өчен. Шул мактау тынычлану тудыра. Тынычлану, үз-үзеңнән канәгать булу исә бер урында таптануга китерә.

Аннары кыргыз, казакъ яки Дагыстан әдәбиятлары безне узып китте дибез. Безнең мең еллык әдәбиятыбыз була торып, алардан калышабыз, дибез. Әдәбият үсешен җәмгыять үсешеннән аерып карарга ярамый, минемчә. Артта калган халыклар тарихның ниндидер бер баскычында «сикереш» ясыйлар. Бу сикереш әдәбиятта да чагылмый калмый. Хәзерге Африка илләрендә әдәбиятның нык алга китеше моңа мисал була. Ә безнең әдәбиятта андый сикерешкә урын юк. Ул—салмак аккан елга кебек.

Әдәбиятыбызның ил күләмендә яңгырый алмавына тагын бер сәбәп: кем әйберләре тәрҗемә ителә һәм кайчан? Союз тирәсендә йөрүчеләр роман яки повесть язса, татарчада басылып чыкканчы ук тәрҗемәсен эшләтә башлый. Әйбәт әсәр исә тәрҗемәчесен таба алмый ята. Ә ул көтеп яткан арада теге проблемаларны күтәргән әсәрләрне башка халыкның язучылары язып чыга. Һәм әлеге әсәр актуальлеген җуя. Бик оста язылса да икенчел әсәр итеп кабул ителә.

Тагын бер нәрсә: без кайчандыр авыл турында әйбәт-әйбәт әйберләр яза идек. Тик хәзер авыл турында гына язган кешеләр ничектер икенче категорияле язучылар кебегрәк санала. Производство темасына язарга чакырулар башланды. Ә безнең язучыларыбызның күбесе авылдан чыккан, канына авыллык сеңгән кешеләр. Алар заводка командировкага барып кына әйбәт роман яза алмыйлар. (Менә яшь буын, бәлки, бу бурычны үти алыр). Шушы сәбәп аркасында язучыларыбыз авылдан аерылдылар, шәһәргә кушылып җитмәделәр.

Тагын шул нәрсә әдәбиятыбызны артта калдыра: безнең бөтен күләмле әсәрләребез производство, зур төзелешләр, шәп колхозлар турында. Әдәбиятның төп фигурасы булырга тиешле Кеше образы бары тик эш процессында гына бераз ачыла. Без аның эчке кичерешләренә, психологик халәтенә бик аз игътибар итәбез. Эчке кичерешләрне зур итеп, фәлсәфи планда биреп, төп конфликтны психологик планда ачу урынына, бер бригаданың икенче бригада белән ярышуына кайтарып калдырабыз һәм шуның нәтиҗәсе буларак дөнья әдәбиятыннан артта

*Дәвамы. Башы 1нче санда*

барабыз. Хэмингуэйның «Диңгездәге кеше»сендә бернинди көрәш тә юк сыман. Анда төп геройның эчке кичерешләре, яшәү өчен көрәше эчтән ургып чыга. Менә шундыйлардан үрнәк алырга иде дә бит. Ләкин безнең идеология аңа корылмаган. Һәм шушы идеологиядән читкә чыга алмыйбыз.

**3 апрель.** Фәридә исемле 2 курс студенткасы шактый җырлар җырлап китте. Кичә шул ук курстан, бары тик башка группадан Венера Сәләхова һәм Нәкыя исемле кызлар килгәннәр иде. Аларга яңа шигырьләрне укыдым. Венера Сәләховасы—Чүпрәле кызы. Үзе дә шигырьләр яза икән. Берничә шигырен укыды, матур гына тоелды. Бәлки, чынлап язып китәр. Бүген килгән Фәридәнең дә энесе язгалый икән. Фәнис Мөхәммәтҗанов. 10 класс укучысы. «Ялкын»да чыккалаган. Шул малай кызлар эшен бик ярата ди. Сыер да сава. Кайвакыт апасы урынына фермага барып, 16 сыерны савып кайта икән. Әле саву гынамы, сыерларыңны юып йөртмисең дип апасын ачуланып, сыерларын юа ди.

Мартның өченче ун көнлегеннән башлап көннәр җылы тора. Көндезләрен 13-15 градус җылы була. Болай озак бармас әле, суытыр. Май айларының рәте булмас инде быел. Миңа тизрәк җылы кирәк.

**6 апрель.** 18нче кичке эшче яшьләр мәктәбеннән 8 кеше килде. Бу мәктәп укытучылары 1962-63 елларда, мин больницада ятканда минем янга килеп, урта мәктәп программасын укыттылар. Аттестат бирделәр. Юкса университетта укый алмаган булыр идем. Шул вакыттан бирле кайсы да булса укытучы, берничә укучыны ияртеп, туган көн белән котларга килә. Бигрәк тә Наилә Гарифулловна Гатауллина тырыша инде. Оештыручысы шул. «Иң гүзәл кеше икәнсез» җырын да шул мәктәп укытучыларына багышлап язган идем. Боларның һәрберсенә автограф яздым. «Һәркемнең үз сукмагы»на. Нурсөя аларның килүенә кыстыбый пешергән иде, чәй эчердек, бер шампанский куйдык. Күңелле утырдык.

**9 апрель.** Кайчагында гел уйламаган кешеләр килеп чыга. Кичә Түбән Камада яшәүче Инсаф дигән кеше үзенең дусты Рашат белән килде. Инсафның ике аягы да тездән өстә юк. Берсен 81нче елны, икенчесен моннан дүрт ай элек кисканнәр. Артерияләре кан үткәрми башлаган. Сызлауларга түзәр әмәл юк, ди. Диагнозы истә калмаган инде. Сызлап та аякны кисәләр икән. Заводта механик булып эшләгән. Хәзер менә «Бу хәлдә нәрсә эшләргә була?»—дигән сорауга үзенчә җавап эзли. Язучы булып булмасмы икән, ди. Исәбе зурдан тотынырга, повесть язарга. Белмим, белмим. Дәфтәренә бер ун битләп әйбер язган. Шул кадәресеннән чыгып эш йөрткәндә, бер дә кулыннан килердәй күренми. Өйдә генә башка берәр эш эшли алыр идең, кулларың таза бит синең, озаклап утырып тора аласың, дигән идем дә, андыйга риза түгел. Сапожник булырга яки сәгать төзәтеп утырырга минем түземлегем дә җитми, теләмим дә, ди. Язучылык эшен итеккә олтан салудан да җиңел дип күз алдына китерәләр. Башка эшләргә бик үгетләп карасам да, күндерә алмадым. Әйдә, язып карасын инде. Бәлки, соңыннан үзе дә аңлар әле. «Менә син яза башлагансың бит, башта синеке дә әйбәт булмагандыр»,—ди. Әйбәт булмаса да, кешедә сәләт дигән нәрсәнең бармы-юкмы икәнлеген күрерлек кенә була инде ул. Ни хәзерге әдәбиятны белми. Кайчандыр тәмамлаган 8 класс белем белән генә язучы булып китеп булса икән ул.

Көннәр матур тора. 10-15 градус җылы. Агачлар яфрак ярырга маташалар инде. Болай булса, быел май бәйрәменә яфраклар ярып кына калмаслар, эреләнерләр дә.

Бүген Рәйсәдән хат килде. Бигрәк хыялый кыз инде. Бәхете булыр микән? Егетен шулкадәр нык ярата. Егете нинди рәк кеше икән? Моның мәхәббәтен аңларлык кешеме? Нишләсәм дә бу мине ярата дип масаеп кына йөрми микән?

**10 апрель.** Нурсөя бүген бакчага китте. Әле быел беренче баруы. Өйне пыр туздырганнар дип елап кайтыр микән инде. Нервысын бозарга сәбәп табылып тора. Кичә Клара туалетка су агызды. Аны пыр туздырып төште. Гараж түбәсен ябарга плитә китергәннәр иде, 17нче өйнең көнчеләре, кем плитәләре бу, милициягә хәбәр итәргә кирәк дип чабышып йөри башлаган. Берсе өйгә дә керде. Бездә бит шулай, минеке юк икән, аныкы да булмасын. Янәшә йорт каршында әнә 5 гараж тора, берсе дә инвалидныкы түгел. Анда түрәләр тора.

Өйдә үзем генә калгач нинди дер Зәфәр Фәтхетдинов дигән кешенең «Тайна

стоит жизни» дигән повестен укыдым. Әлләни түгел.

18нче мәктәп укытучыларына багышлап бер шигырь яздым. Быел кичке яшьләр мәктәпләре ачылуга 40 ел тула икән. Наилә апалар бердр нәрсә яза алмассынмы дип киткәннәр иде. Менә бер нәрсә чыкты инде.

**14 апрель.** Көннәр суытып җибәрде. Бүген иртән торуга кар яуган иде, көндез боз яуды. 2 градус салкын булды. Агачларның бөреләре ачыла башлагач кына суытып куйды. Чаганнарның яфраклары күренә башлаган иде инде. Ярата башлагач кына яры ташлап киткән кеше хисләре кичердем.

11 апрель көнне Нурсөя агачларга дару сиптереп, редискалар чәчеп кайтты. Болай булса, кар астында редискалар «рәхәтләнеп» үсә инде.

Кичә пединституттан студентлар киләбез дип шалтыратканнар иде. Шушы гараж төбәсен ябучыларны көтеп, аларга килмәскә куштым. Шулай итеп, ни тегеләре, ни болары килмәде.

Бу көннәрдә бәетләр укып яттым. Кызык кына бәетләр бар икән. Юмористик бәетләр бар дип башыма да китерми идем. Юмористик бәетләрне бәет дип атау дөрес микән әле ул? Бәет бит ул ниндидер фаҗигагә нигезләнеп языла. Ул елау,сыктау белән бәйле. Ә монда «Чәй» бәетләре, «Самавыр» бәетләре һ.б. болар просто авторы билгеле булмаган шигырьләр инде.

**19 апрель.** Көннәрне янадан җылыта башлады. Хәзер колхозларда борчак чәчә башлаганнар. Нурсөя кичә һәм бүген бакчага барды. 18е көнне, ягъни кичә, кишер чәчеп кайтты. Редискалар шыта башлаган ди инде. Быел яз бик иртә килеп маташа. Теге кар эреде, «ташлап» киткән кызым кире кайтты. Бакчада җиләкләрне эшкәртеп бетерә инде Нурсөя. Башка елны бу эшләрне май кермичә эшләгән юк иде әле. Кичә мин бер шигырь язып куйдым. «Җир кешесе». Әкиятләр укып ятам әле. Бүген төшемдә дә җен-пәриләр белән сугышып йөрдем. Халык әкиятләре әйбәт, ләкин бертөслелек бар. Кайбер вакыйгалар бик күп әкиятләрдә кабатлана. Яңарак әкиятләр язасы килеп китте.

Язга таба бик арыта. Берни белән шөгыльләнәсе килми. Әле шушы көннәрдә З.Абдуллин дигән кешенең «Мин флотта хезмәт итәм» дигән повестен рецензиягә алган идем. Аны укып чыктым. Кайбер яклары белән минем «Җилкәннәр»гә ошап китә, ләкин артык кызыксыз язылган. Телдә бернинди образлылык юк. Журналист икәнлеге әллә каян күренеп тора. Персонажлар бар да бертөсле сөйләшә. Моны бик каты эшлисе бар әле.

18 апрельдә астра чәчтек, өйдәге ящикка. Кайчан шытып чыгарлар икән? Өч атнада гына шыта диләр.

**20 апрель**. Астралар ике көндә шытып чыктылар. Бүген беренче тапкыр урамда йөреп кердек. Көн җылы, 20 градуслар тирәсе иде.

**25 апрель.** 23е көнне бакчага бардык, Ирекләр машинасы белән. Көн җылы иде. Битләр кып-кызыл булып янып чыкты. Ике көн урамда яттым. 24е көнне кич кенә кайттык. Нурсөя суган утыртты, бераз бәрәңге. Агачлар ямь-яшел. Миләшләрнең яфраклары бармак башы хәтле инде. Каеннар, таллар, топольләр, чаганнар бар да яфрак ярып бетеп килә. Быелгы кебек иртә язны бер дә хәтерләмим. Бөтен дөнья коп-коры. Хәтта безнең бакча юлы да шылтырап тора. 24 апрельдә кыяр да чәчкәнбез икән әле. Шыттырмыйча гына орлыгын түтәлгә сибеп, өстен пленка белән каплап киттек.

Бүген Нурсөя кер юа. Мин «Казан утлары»н укып яттым. 4нче санын. Проза турында һаман сөйләшү бара.

**1-10 май.** Быел яз бик иртә килде. 23 апрель көнне Ирекләрнең машинасы белән бардык, бер кич кундык, мичкә якмый гына. 23-24 көне буе урамда яттым. Кызындым. Вакыт-вакыт күлмәкне дә салгаладым.

Икенче мәртәбә 1 майда үзебезнең машина белән килдек. 2 май көнне коеп яңгыр яуды. Салкын җил иде. Буксовать итә язып кына чыгып тайдык. Май бәйрәменә тюльпаннар чәчәк ата башлаган иде. Өчесен өйгә дә алып кайттык. Быел, гомумән, май бәйрәменә агачлар яфрак ярып бетерде диярлек. Имәннәр генә ачылып җитмәгән иде. Чияләрнең бөре борыннары агарып, чәчәкләре күренеп тора иде. 1 майда кыяр чәчкән идек, шытып чыкканнар да түтәлнең өстен җил

ачып, өшегәннәр.

8 май—өченче тапкыр килдек. Кыярларнын түтәлен казып ташлап, өр-янадан чәчтек. Редискалар ашарлык түгел әле.

1 майда суган утырткан идек, борыннары күренә башлаган. 9 майга бәләкәй слива һәм электр баганасы төбендәге чия чәчәк атты. Бүтән чияләр бик ныклап ачылып җитмиләр. 1 майлардан 10 майларга кадәр көннәр салкынча торды. 10 көн эчендә агачларда әлләни үзгәреш булмады. 9 май көнне иртәдән кичкә кадәр көчле яңгыр яуды. Бүген 10ысы. Көн чалт аяз. Иртәдән бирле тышта ятам. Төштән соң күлмәкне салып аттым. Тюльпаннар шау чәчәктә. Алмагач та чәчәк атарга маташа. Сиреньнең чәчәге ачылмый әле. Бакчаның бик матур чагы. Яз үзенең чәчәкләре, тәмле исләре белән күңелне күтәреп җибәрә. Һәр яңа көн үзенең матурлыгын, җылысын, яктылыгын салып китә. Кыш көне күңелләр боекканда, җаннар өшегәндә язның шушы көннәре, кояшның якты нурлары керфекләр арасыннан саркып чыгып, йөзләрне яктырта, тәндәге йоклаган күзәнәкләрне уята. Тиккә генә язларны көтеп алмыйбыз шул. Ел саен язлар килеп бушаган күңелләрне матурлык белән тутырып тормаса, безнең рухларыбыз фәкыйрьләнер иде.

Балтачка кунакка чакырганнар. Бармасак, агачларның чәчәк атканын күрермен инде, Алла бирсә. Аларга барырга уйласак, 12ләрендә китәрбез, пожалуй. Анда берәр атна торылыр әле. Хәзер бакчада чия, слива, тюльпан, незабудка, анютины глазки чәчәкләре бар. Бүген кайтып китәргә дип торабыз. Икене кундык, иртә-кич мичкә ягып кына.

Беренче чыкканда спидометрда 5770 км иде. Җәй буе күпме йөрелер икән. Үземнең 20 апрельдән бирле бер юл да язган юк. Бер повесть, бер «эпопея»га эчке рецензия яздым.

**17 май.** Берничә көн Балтачта йөреп кайттык. Вәгыйзьнең клубында очрашу ясадык. Мәктәптән дә килгәннәр иде. Очрашу бик кызыклы булмады. Беркем сорау бирмәде. Бер укытучы һәм Вәгыйзь минем турында сөйләде, аннары шигырьләр укыдылар. Соңыннан мин берничә шигырьне укыдым.

Балтачның юллары бик начар, эре-эре ташлар калкып ята, эре ташын читләп үтсәң, машинаң чокырга килеп төшә. Кайтканнан бирле мантып булмый әле.

**19 май.** Узган төн бик көчле яшенле яңгыр яуды. Яшене чытырдатып йомган күзләрне ачып керә. Майдагы өченче көчле яңгыр булды бу. Менә бүген тагын яшеннәр яшьнәп йөри. Яңгыр төшкәләп тора. Сәгать икеләр тирәсендә мине өйгә куалап кертте. Явар, пожалуй, йокы да килеп тора. Бу узган төндә Казанда да яңгыр көчле яуган. Кайбер урыннарда боз да яуган. Алмагачларның чәчәкләре коелып бетеп бара. Кичә генә әле бәрәңгеләр берән-сәрән генә тишелгәннәр иде, бүген барсы да чыгып, тезелешеп торалар. Төнлә яуган җылы көчле яңгыр колакларыннан тартып чыгарган диярсең. Тюльпаннар кызык кына икән: кояш чыкса ачылалар, көн болытласа йомылалар. Кызлар да бит күзләренә туры карасаң, оялып башларын читкә бора.

**25 май.** Бүген төш вакытларында бакчага килдек. Көн матур иде. Бераз кызынып алыйм әле дип күлмәкне салган идем, кояш сүнде, яңгыр төшкәли башлады. Сәгать 2 ләр тирәсендә котырып яңгыр явып алды. Ярты сәгатьләр чамасы дәвам иткәндер. Бәрәңгеләр колакларыннан су эчендә калдылар. Минут эчендә чакыр-чокыр күл булды. Май аенда дүртенче тапкыр инде көчле яңгыр бу. Болай барса, җәй заказ белән килгән кебек әле: ява да җылытып җибәрә.

Бакчада хәзер редискалар картая, тюльпаннар бетеп килә. Чәчәкләрне өзмәсәң дә шул бер ай икән инде сроклары. Кызлар да юкка гына яшь, матур чакларында кияүгә чыгарга ашкынмыйдыр.

**1 июнь.** Нурсөяләр авылына кайтып килдек. 28 майда авылларында сабантуй булды. Беткәнче карап утырдык. Өч кич кунып кайттык... Бүген Казанга кайтып китәбез. Әле Нурсөяләрдән кайтышлый да бакчага кергән идек.

Монда тирес сала торган чокыр кырыена, үләннәр арасына бер кош оялаган. Нурсөя тирес алырга дип чокырга төшеп бара иде, оясындагы күкәйләрен күреп алды. Алты күкәе бар. Яшькелт төстә. Чәнчә бармак башы хәтле генә. Утыра торган кош булып чыкты. Тиресне алмадык инде, куркыр дидек. Хәзер читтән генә карап

китәбез. Әлегә бик тырышып утыра. 30 майда күргән идек. Балаларын ничә көннән чыгарадыр. Кура җиләге чыпчыгы бугай ул. Без аны элек сандугач дип йөргән идек. Гел сандугач төсле сайрый ул. Утырган вакытта сайрамыйлар икән. Бигрәк кеше йөри торган җиргә оялаган инде. Юлдан ярты метр да юк.

**6 июнь.** Безнең теге кошчык тырышып-тырмашып утыра. Ана карата бер хикәя сюжеты туган иде. Кайчан язып куярга инде, бакчада һич язу эшләре бармый.

Агачлардан иң соңыннан балан чәчәк ата икән. Чәчәк ату белән язып куярга онытканмын. 1 июньнәр тирәсендә бугай. Баланның икенчесе нишләптер үсә алмый утыра.

Әлегә бакчада чәчәкләр юк диярлек. Тюльпаннар коелып бетте. Лилияләр ачылып җитмәде әле. Бер люпин гына чәчәк атып утыра. Ана иптәшкә гөлҗимеш аткан тагын.

Борчаклар да чәчәк ата башлаганнар. Быел ак сирень чәчәк атты. Ак сирень нишләптер табигый кебек түгел. Башка кешенең күлмәген киеп уенга чыккан кыз кебегрәк.

Бакчадагы чәчәкләрнең исемлеге:

1. Гладиолус. 2. Астра. 3. Флокс. 4. Ромашка—бакчаныкы. 5. Гвоздика. 6. Анютины глазки. 7. Незабудка. 8. Лилия. 9. ... 10. Тюльпан. 11. Сирень (ике төрле). 12. Гөлҗимеш. 13. Кынгырау. 14. Карлыган. 15. Люпин. 16. Золотой шарик. Һәм тагын берничә вак-төяк. Быел георгин булмады. Бәрәнгеләре нишләптер череде. Орлыгын базардан да алып утыртырга була иде дә, бик матур чәчәк, өзеп чыгып тенкәгә тияләр. Былтыр өзеп чыккан ачудан утыртмадык.

Кешегә тамак туйдыру гына җитми шул, матурлык та кирәк.

Бакчадагы агачлар:

1. Алмагач (4 төп). 2. Балан (2 төп). 3. Слива (2 төп). 4. Сирень (2 төп). 5. Чия (7-8 төп). 6. Карлыган (20 тирәсе). 7. Кура җиләге. 8. Миләш—кара һәм кызыл. 9. Усак. 10. Тал. 11. Крыжовник. 12. Гөлҗимеш.

Агачлар булмаса, кошлар кая куныйп сайрасын?!

**9 июнь.** Кошыбызның оясын нәрсәдер туздырган. Әллә кайда читтә бер күкәе төшеп калган. Калган күкәйләре юк. Саесканнар эшедер инде. Кичә җил вакытында үләннәре егылып, оясы күренеп тора башлаган иде. Үләннәрнең башларын бәйләп, оясын күренмәслек итеп куйыйм микән әллә дигән иде Нурсөя, тотынсан, оясына керергә куркыр дигән идем. Каплатасы калган икән. Балалары чыгарга да күп калмаган иде. Яңадан бу кош безнең бакчага ояламас инде.

**10 июнь.** Көннәр салкынча. Бүген иртән 4 градус җылы иде. Көн саен иртә дә, кич тә мичкә ягып ятабыз. Кичә дә бераз яңгыр явып китте. Мин көне буе Заһид Мәхмүтовның әйберләрен укып яттым. Бүген шуның кайберләрен төзәткәләп маташам. Газеталарга биргәләп карарга булыр. Бу егеттә, кем әйтмешли, нәрсәдер бар, тик ашыгамы шунда—язганнарының 95 проценты брак.

**13 июнь.** Безнең өй кыегында чәперчек дигән кош бала чыгарган, шифер астында. Мин ята торган почмакта гына.

Бу язманы язып ятканда котырып яңгыр ява башлады. Туктаусыз ике сәгатьләп койгандыр. Өй кырыендагы мичкәләрне тутырып куйды. Тагын бер-ике көн үтмичә машина белән чыгуны уйлыйсы да юк. Безнең советский асфальт шундый балчыктан түшәлә инде. Авылга кайтсаң да шул. Бер елны авылга керүгә машинаның ишеге ачылмаслык булып пычракка чумдык. Нурсөя босоножкидан иде. Утырабыз аптырап. Ярый инде озак утырырга туры килмәде. Бер трактор өйгә хәтле өстерәп кайтарып куйды.

**21 июнь.** Бу көндәлекнең күп өлеше бакчада языла. Шуңа күрә бакча турында күп сөйләнә. Гомумән, без болай гына табигатькә чыкмыйбыз. Аккош күле янында туктарга мөмкин түгел. Анда бер квадрат метрга өч кеше. Урман эчендә бөркү. Аннары үзең күз карасыдай кадерләп үстергән һәр чәчәк кадерле, һәр җиләк тәмле...

Һәр барганда батып ятмабызмы икән дип кайгырып барабыз. Кайтканда тагын шул кайгы. Безнең партиябез язучылар турында шундый «кайгырта»: мускуллары ныгысын дип кирпеч заводының карьерыннан өчәр сутый җир бирде. Аны җир дип атавы да кыен, дөресе—чокыр бу. Шул чокырга ком, торф, тирес китертәбез.

Якын-тирәдә асфальт салучылар булса, ком китертү жинел түгел. Шоферлар КамАЗ белән ташып кына тора. Акчанны гына түлә. Аларга бу икеләтә файда: ком асфальтка салынган дип хөкүмәттән акча ала. Менә шуна безнен асфальтлар бик тиз чокырланып бетә. Кемгә ташы, кемгә комы, ә кемгәдер әзер асфальты ук илтеп аударыла.

Узган атнада өч көн бик каты температурить иттем. 39 га житте, артып та китте бугай әле бер-ике сырга. Гараж янына чыгып алкашларның эшен карап утырган идем, шунда жил өргән, ахры. Көн кызу иде юкса. 27ләр булгандыр. Үләм бугай дип үземә бер бәет тә яза башлап куйдым.

Быел июнь аена бик төшенеп житеп булмый: кинәт суыта, кинәт жылыта.

**26 июнь.** Бүген Казаннан килдек. Көн суык. Төннәрен 2-7ләр. Көндез дә 10-12 ләрдән бик артмый. Янгырлар. Беркөн без кайтып киткәч боз яуган. Кайбер агач ботакларын, чәчәкләрне сындырган. Салкын булгач жиләкләр һаман өлгерә алмый. Туйганчы ашарлык жиләк юк әле. Берән-сәрән карлыганнар, кура жиләкләре, чияләр ашаштырабыз. Быел бөтен нәрсә берьюлы өлгерер, ахры.

Килү белән мичкә яктык. Өйдә 12 градус иде. Казанда Сабан туе. Бар халык шунда агыла, ә без ишәккә төягәндәй машинаның сыртына такта-токта төяп килдек. Ягарга. Жил бик көчле. Агачларны сындырып бетерә инде. Кинәт-кинәт исеп куя, тәгәрәп китәрсең.

**27 июнь.** Узган төндә бик көчле янгыр яуды. Иртән тору белән мичкә ягып жибәрдек. Июнь аен ягып кына жылытабыз. Бүген «Базарда» дигән бер шигырь яздым. Дөнья күрүен күрмәс, шулай да фикере күңелне борчып тормасын. Кичә телевизордан Ә.Гаффарның «Бер картлыкта, бер яшьлектә» дигән комедиясен карадык. Минзәлә театры куйды. Бигрәк пүчтәк нәрсә. Аннан элек шул ук театрның «Яратуың чынмы?»сын караган идек, Р.Кәрами әсәре. Тоже пүчтәк иде.

**28 июнь.** Төнлә көчле янгыр яуды. Янгыр яумый калган көн сирәк. Көндезләрен салкын. 16-17 градуслар тора. Бераз тышка чыгып ятам да, өшеп керәм. Йә булмаса янгыр куалап кертә.

Кичә телевизордан Минзәлә театрының «Соңгы төн»спектаклен карадык. И.Юзеев әсәре. Әсәре болай акыллы гына язылса да, ниндидер салкынлык. Дулкынландырмый. Шагыйрь образының жинеп чыгачагын алдан ук белеп торасың. Алда нәрсә булыр микән дигән кызыксыну юк. Артистлары да Г.Камал театры артистларыннан нык калышалар. Беркөн Ульяновск драма театры Гогольнең «Женитьба»сын куйган иде. Үзешчәннәр кебек кенә уйныйлар. Гогольнең бу әсәре шулай ук пүчтәктер дип уйламаган идем. «Ревизор»ы белән чагыштырсаң—жир белән күк арасы. Икесен ике кеше язган диярсең. «Үле жаннар»ны сәхнәләштерсән, анда нинди генә типлар юк. Сәхнә өчен һәр персонажның үз теле, үз холык-фигыле булырга тиеш. Прозада бу бик беленми.

«Иностранная литература» журналын укып ятам. Ирвин Шоуның «Нищий вор»ын ике санда укыдым. Ахыры киләсе санда. Бик күп нәрсәләрне кабат-кабат яза икән бу язучы. «Богач, бедняк» романының күп кенә вакыйгаларын монда да кабатлый. Геройлары шул ук.

**29 июнь.** Көне буе янгыр яуды. Иртән Нурсөя тирес чокырын күмәргә дип ике машина жир китерткән иде. Шуларны чокырга көрәп төшергәнне дә көтмәде. Ярый әле Зәет абый Мәжитов ярдәмгә килде. Нурсөянең берүзенә бик авырга килә иде. Зәет абый, гомумән, ярдәмчел кеше инде. Без керә алмый торганда мине дә еш кына күтәреп кертә, йә машинаны этешә иде. Бүтәннәр Нурсөянең күтәргәнен күреп: «Ай, мескен, авырдыр инде»,—дип калсалар калалар, күтәрешмиләр. Кешеләрнең кызганулары күп очракта тыштан, ягъни телдән генә була, үзенә кагыла башласа, кызгану дигәннәре онытыла.

Зәет абый мине университетта да укытты. Монда тагын мине укыткан укытучылар бар. Мөхәммәт Мәһдиев. Ул минем күрше дә. Каршы якта Вахит Хаковлар.

Язучылардан Мөсәгыйт Хәбибуллин, Әхәт Гаффар, Габделхәй Сабитов, Жәүдәт Дәрзаман, Рәшит Әхмәтжанов, Мидхәт Миншин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Мәдинә Маликова, Әхмәт Рәшитов, Разил Вәлиев. Разил безнен килеп туктаганны күрсә, мине машинадан күтәреп алып, раскладушкага яткырып китә

иде. Тагын Рөстәм Фәйзуллин, Әмир Мәхмүтовлар бар иде. Тора-бара рәтләрәк урын табучылар безнең урынны ташлап качтылар.

Быел төрле жирдә боз ява. Әзәрбайҗанда яуган бозның кайберләре 300 гр, Грузиядә яуганнары 250 гр булды дип, телевизор каз күкәе чаклы бозлар күрсәтте.

**30 июнь.** Менә июнь аен да тәмамлап куйдык. Иртән бераз янгыр явып узган иде, төшкә таба җылытты. Кулмәкчән ятарлык булды.

Кичә кич утырырга Кояш килгән иде. Зары күп мескеннең. Башта бирәү журналның җаваплы секретарьлыгыннан алдыруга ирешкән. Хәзер учет карточкасына язып строгий выговор биргәннәр. Ничәдер сум партия взносы түләнмәгән булган. Анда минем кебек взносы түләнмәгән кешеләр күп иде, башкаларга бер сүз юк, ди, миңа гына каныгалар, ди.

**2 июль.** Көндәлеккә табигать турында күп язылa сыман. Ләкин еллар буе урамга да чыгып карамаган кеше өчен янгыры, кояшы, суыгы—бар да әһәмиятле.

Бүген Әхмәт Рәшитов сөенечле хәбәр алып китте: «Ялкын»да чыккан бер хикәям беренче урынны алган. «Бүректәге бүре баласы». Девиз белән бирелгән булгач, аны журналда эшләүче егетләр минеке икәнлекне белми йөриләр. Хәйдәр Гайнетдинов: «Бездә бер әйбәт хикәя бар, Мөхәммәт Мәһдиевныкыдыр ул»,—дип йөри иде. Премиясе дә әйбәт кенә: «Волга» халыкара лагерена путевка һәм 100 сум акча.

Әхмәт чыгып китеп күп тә үтмәде, Эльмира Шәрифуллина килде. Ул да шул хикәя белән котлады, аннары бераздан Габделхәй Сабитов килеп шул турыда әйтте. Шатлыкның да тәпие озын икән, бакчага да бик тиз килеп житте.

**13 июль.** Тәрҗемә итәргә дип ике хикәя алып килгән идем, кайчан тотынырга булыр. Жәй көне бик эшләп булмый шул. Тышта ятасы бар. Кызу көнне мәлҗерәтә, суык көнне ирендерә, кулларны юрган астыннан чыгарасы килми. Кыскасы, эшлисе килмәсә, сәбәбен табып була.

**15 июль.** Кояшлы иртә. Жылы. Хәзер урамга чыгып ятам. Нурсөя соңгы карлыганнарны җыя башлады. Бакчаның бөтен жимешләрен сатсаң, 200 сумнар тирәсе акча эшләп була икән. Бигрәк пүчтәк. Ярый әле сатасы юк. 4 ай баш калкытмый эшләгән эшең 200 сум табыш бирсен инде. Хәер, ансы да табыш түгел әле аның. Күпме тирес сатып аласың, взносын түлисең, өен 40-50 сумга страховать итәсең, жәй буе ничә сумлык бензин яндырасың. Әгәр расходларын исәпләсәң, үзеннең хезмәтеннән башка да 500ләр чыгып китәдер.

Мин бәләкәй чакта әнигә ияреп Октябрьскийда катык сатып йөргән чакта: «Их, дөньяда бер нәрсә дә сатасы булмасын иде, бөтен нәрсәне сатып кына алсаң иде»,—дия идем. Теләгем кабул булды. Хәзер артык нәрсәне дә саттырмыйм. Бакчасы юк кешеләргә бушлай бирәбез. Ичмасам, рәхмәте була. Кешеләрнең күзенә карап: «Алса ярар иде»,—дип тилмереп торудан да кыен нәрсә юк иде минем өчен. Бәләкәй чакта ландыш чәчкәсе сатып бер чалбар алган идем. Бу минем фабрика теккән беренче чалбарым булгандыр. Безгә мәктәп тә шундый тәрбия биргән: әйбер сату хурлык, базарга чыгу—оят. Хәзер балаларны андый рухта тәрбияләмиләр. Үзеннән артканны сату бер дә оят нәрсә түгел диләр.

**16 июль.** Иртәгә, ягъни 17 июльдә, минем егылган көн. Үзенә күрә юбилей. 25 еллык. Адәм башы чыдаса да чыдый икән.

*Дәвамы киләсе саннарда*

# НКВД КҮЗЕ АСТЫНДАГЫ ГОМЕР



Наратлар һич тә аварга ашыкмады. Төптән киселгән алты агач, сүз берләшкән кебек, ауган чакта ботаклары белән жиденче—исән наратка эләгеп калды. Ә аста бер кеше тораташ булып катты. Ул озак кына уйга чумып басып торды, аннан кабаттан язмышын сынарга карар кылды. Жиденче наратны кискәч, ул колак тондыргыч шартлау тавышы ишетте. Кинәт бар дөнья тын калды һәм күзен ачты. Ул ауган агачлардан хасил булган ныгытманың үзәгендә басып тора иде. Бу—үлем белән шаярунын нәүбәттәгесе булса да, шушы вакыйга анын тормышын кискен үзгәртте. Шуннан соң инде ул язмышын башка сынамады: Ходай Тәгалә анын гомерен кемдер һәм нәрсә өчендер саклый иде. Гарәфи Хәсәновка бәйле әлеге вакыйга 1949 елда, ул Себердә сөргендә чакта булды.

***

—Абый, эшеннән килделәр,—диде ана сенлесе Суфия.

Ишегалдында смена житәкчесе һәм бригадир басып тора иде.

—Кадрлар бүлегенә чакыралар,—дип әйтеп куйды кайсыдыр.

—Мин хәзер кайтып житәм,—диде Гарәфи сенлесенә. (Их, шул чакта анын бары тик 12 елдан соң гына әйләнеп кайтасын кем белгән?)

Ул көнне Ленинградтан эвакуацияләнгән Калинин исемендәге завод цехында туп ядрәләре ясау өчен кирәкле әйберләр бетте, шуна да эш юк иде. Гарәфи өенә гадәттәгедән иртәрәк кайтып китте. Хәзер менә янадан эшкә барырга кирәк.

Кадрлар бүлегендә аны НКВДчылар көтә иде.

—Йә, военкоматка таба киттек!

Гарәфине армиягә күз күреме бик начарлыктан алмадылар. Шулай да ул, башка егетләр кебек үк, сугышка жибәрүләрен сорап, хәрби комиссариатка гариза арты гариза юллады. Сугышнын кызган мәле, димәк, аны фронтка жибәрүне кирәк тапканнар. Әмма алар бер дә хәрби комиссариат ягына атламадылар.

—Син кулга алындын,—диде ана урыс баһадиры Илья Муромецны хәтерләткән Черек күл тикшерүчесе Баскаков.

—Нәрсә өчен?

—Белерсен... Камерага озатыгыз үзен,—дип боерды ул төрмә сакчыларына.

Тегеләр шәрә калганчы чишенергә боердылар, киеменнән барча төймәләрен өзеп алдылар. Бик күп ишекләр белән чуарланган тар коридордан ян белән генә атлап, камерага якынлаштылар. Каршыга берәрсе очраса: «Тукта! Йөз белән стенага борыл»,—дигән фәрман янгырады.

Бер кешелек камера. Диварга жыеп куела торган карават. Аны кичке тугызда гына жәяргә ярый. Әмма нәкъ менә шул вакытта сорау алу башлана. Бүлмә жир астындагы өченче катта урнашканлыктан, анда түзеп булмаслык суык иде. Слесарьлар килде, торбага суккаладылар, тик файдасыз—жылы килмәде. Гел янып торган ялгыз лампочка. Баштарак Гарәфи дивардан тишек эзләде. Шунын аркылы аны атып үтерерләр кебек иде.

Беренче өч айны Баскаков сорау алды, аннары аны Рукавичников фамилияле

тикшерүче алыштырды. Бирелгән сораулар ахмакларча иде: «Төрек разведкасы белән кайчан хезмәттәшлек итә башладың?», «Террорчылык оешмасына тагын кемнәр керә?», «Иптәш Сталинга һөҗүмне кайчанга ниятләдегез?»... Кулга алуның төп сәбәбе исә Гарәфинең Хәсән Туфан һәм Кави Нәҗмиләр турында: «Аларны ни өчен кулга алдылар, ник китапларын яндырдылар? Мондый шагыйрьләр бүтән булмаячак»,—дигән сүзләренә килеп тоташа иде. Классташы, баянчы Рифкать бу сүзләрне киракле җиргә тиз җиткерә...

Вакыт үтә. Беркөнне тикшерүче кабинеты янындагы бәдрәф бүлмәсендә ул үзен көзгедән күреп ала. Йөзе сары, башы карбыз кебек зур. Дүрт ай эчендә ул танымаслык булып үзгәргән. Мөгаен, бу көн саен шырпы кабыгына салып бирелгән тоз аркасындадыр.Суны да күп эчте. Бу хәл үлемнең якынлыгы турында сөйли. «Юк, үземне кулга алырга кирәк»,—ди ул. Тозны күпләп ашаудан тыела, камера буйлап күбрәк хәрәкәтләнә башлый. Ишек сакчысы якынлаша башлагач кына туктап тора. Сүз уңаеннан, ул чакта төрмә сакчылары киез итекләрдән йөргән. Аларның якында икәнлеген күңел күзе белән генә күреп булган.

1941 ел бара. Гарәфи Хәсәновка 20 яшь тула.

***

—Синең кайда һәм ничек дөмегүеңне беркем дә белмәячәк,—диде кипкән балыкка охшаган—кечкенә буйлы, коры, аксыл чәчле прокурор Надеев. Шулай диде һәм револьверга охшаган салкын бармагын Гарәфинең чигәсенә терәде. Тикшерү барган ярты ел эчендә егет бер генә кәгазьгә дә кул куймый. Әле ул гына түгел, ризыктан баш тартырга да батырчылык итә. Дөрес, үсмер егет ачлык тотучыга су эчүнең мәҗбүри икәнлеген белми. Юк инде, ач торам икән, димәк, тамактан бернәрсә дә үтмәскә тиеш дип уйлый ул.

Гарәфи ачлык тотуы турында игълан да итми. Тиешле 300 грамм ипине кабул итеп ала да, аны карават астына тыгып куя. Ашны парашага түгә. Ачлыкның җиденче көнендә ул үзендә гадәттән тыш җинеллек тоя. Әйтерсең лә син ятмыйсың, түшәм буйлап очасың. Аның ризыкларын карават астына яшерүен сакчы белеп ала. Камерага төрмә начальнигы килеп керә:

—Сәбәп нидә?

—Ни өчен иректән бернәрсә дә тапшырмыйсыз?

—Килгәннәрен каян беләсең?

—Сизәм...

Ул үзенә кайчан килгәннәрен генә түгел, ничәмә айлар берьялгызы бүлмәдә яткан килеш әтисе вафат булган көнне сәгатенә һәм минутына кадәр төгәл сизә. Балалар арасында иң олысы буларак, Гарәфи сигез кешелек гаиләне туендыручы бердәнбер кеше була.

Ике сакчы кулыннан кысып тотып аны кабинетка алып килә. Надеев ысылдый. Сакчылар камерада тентү үткәрә һәм яшерелгән паекларның барысын да алып килә. Рукавичников классташы Рифкать белән күзгә-күз очрашуны оештыра.

Аларны кабинетның төрле почмакларына утырталар. Күз белән «сөйләшмәсеннәр», янәсе. Бу очракта исә мондый саклыкның кирәге дә булмый.

—Гарәфи, гаебеңне таны, нәрсә, сиңа җәл мәллә? Карап та тормый кулыңны куй. Барыбер суд булачак.

Шулчак Гарәфи уянып киткәндәй булды. Чыннан да, суд булачак бит! Нәрсәдә генә гаепләсәләр дә, кулны куярга кирәк! Судта мин барысын да сөйләрмен!

Ул кәгазьләргә кул куя. Ничәмә-ничә айлар буе баш тартып килгән гаепләүләрнең барысы белән дә ризалаша. Надеев шундук чыгып югала, Рифкатьне алып китәләр. Бу кабинетта күпне күргән Рукавичников шаккатып кычкырып җибәрә: «Һай, тинтәк тә соң син!».

Дөресен әйтергә кирәк, тикшерүче монда каяндыр, ничектер килеп эләккән малайны әнисе янына куып кайтарырга дип хәл иткән була. Террорчылык оешмасы белән элемтә тотуын раслап, Гарәфи эшне көтелмәгән якка борып җибәрә. Егетнең эше хөрти. Хәзер инде аны әнисе түгел, төрмә һәм гомерлек Себер көтә. Әле атып үтермәсеннәр дип Ходайга ялварырга онытмасын. Аңлашыла ки, берниндә дә суд

булмый. Ә аңа хөкемне махсус кинәшмә читтән торып кына чыгара...

Гарәфигә 8 ел төрмә һәм 5 ел сөрген билгелиләр. Ун кешегә исәпләнгән камерада алар кырыктан арта. Цемент идәндә ян белән йоклыйлар. Диварлар юеш. Почмакта—параша. Урамга чыгармыйлар. Бер кешегә 200 грамм ипи бирәләр. Кемдер үлсә, аны яшерергә тырышалар. Мәет белән янәшә ятучы аның паегын үзләштерә. Тик мәетне өч көннән артык тотып булмый шул.

Гарәфине Плэтән төрмәсенә билгелиләр. Монда да, Калинин исемендәге заводтагы кебек үк, туп ядрәләре өчен корыч коелмасы ясарга мәҗбүр итәләр. Станоклар иске, аларда эшләү газап була. Гаепләнүчеләр ачлыктан һәм арудан аякларын көчкә өстериләр.

...Бервакыт Гарәфи кемнеңдер койма артында Тукай шигырьләрен көйләгәнен ишетеп ала. Ул җырлаучының тавышына тәэсирләнеп төрмәнең монарчы аяк басмаган җиренә үк үтеп керә. Тыңлаганда күзенә яшь килә. Кире кайтканда исә мәетләр әрдәнәсенә юлыга. Никтер аларның барысының да башы киселгән була.

Бу юлларның авторы, КГБ архивында әтисенең эше белән танышкан чакта, хәзерге чекистлардан шул хакта сорашырга тырышып карады. Шундый хәл булырга мөмкинме? Аларның башын кисү кемгә кирәк иде? Офицерлар моны бердәм рәвештә кире какты: «Алай булырга мөмкин түгел. Андый алым гамәлдә булмаган». Әмма мин алдый белми торган әтиемә ышанмый булдыра алмыйм. Архангельск зиратында каберләрне казыганда мин мәетләрнең баш сөягендә бер ядрә эзе булуын үз күзем белән күргәнем бар. Мөгаен, башы атылганнарны (мәетне танымасыннар өчен?) монда да китергәннәрдер...

Җырга тәэсирләнеп кичке тикшерүгә соңлаган Гарәфигә иртән ипи бирмиләр. Әмма Себергә сигез елдан түгел, алты ел ярымнан үк җибәрәләр. Ел ярым ул лагерьларда була. Сәяси тоткыннар Себердә япон хәрби әсирләре белән бергә тимер юл сала. Гарәфине бигрәк тә японнарның пөхтәлеге сокландыра. Урманда да беренче эш итеп барак төземи, бәдрәф кора алар.

«Халыклар атасы» бакыйлыкка күчкәндә Гарәфи ирекле, әмма күчеп йөрүдән мәхрүм ителгән авылда була. Ул еш кына гомерен куркыныч астына куя. Кичен Ачин вокзалына бара һәм иртән кайтып житәргә ашыга. Монда баруның максаты бер генә: вокзалда ялгышып булса да туган телен ишетергә насыйп булмасмы?

Гарәфи монда Себер гүзәлен очрата һәм аның йөрәген яулый. Ул аңа ике ул бүләк итә. Гарәфи аны туган ягына кайтырга өнди. Тик хатын ашыкмый. Гарәфи иң элек үзе генә кайта. 59нчы елда гаиләсе артыннан килә. Бер елдан тагын бер улы туа. Шуннан соң гаилә Себердән Казанга юл тота.

***

Хәзер әти өстенә ауган, әмма аны исән калдырган җиде нарат турында сөйләшик. Төгәлрәге, Ходайның аны ни өчен саклап калуы турында сүз йөртик.

Үсмер чагында ук Гарәфи «Рафаэль» исемле роман яза башлый. Тик ул аны Себердә генә тәмамлый. Данлы чекистлар, әлбәттә, чит телдәге кульязманы, өстәвенә латин хәрефләре белән язылганны халык дошманы кулында калдыра алмый. Алар аны тартып ала һәм, әти фикеренчә, яндыралар да. Кульязмаларның янмавына шулкадәр ышанасы килә! Язмыш бу кешене иҗат өчен саклап кала һәм ул табигатькә бурычын китаплары белән кайтара.

Гарәфи Хәсәнов 1992 елның апрелендә Казанның Яңа татар зиратында җирләнде. Шулай да аның иҗат биографиясенә нокта куярга иртә әле...

**Аяз ХӘСӘНОВ**

## ТУКАЙ ЕЛЫ

***

Татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган күптөрле чаралар, соңгы айларда үзенең иң югары ноктасына күтәрелеп, республикабызда, Мәскәүдә, Россиянең башка төбәкләрендә, чит илләрдә үткәрелгән халыкара дәрәҗәдәге зур бәйрәмгә әверелде.

Сөекле шагыйребезнең туган көнендә—26 апрель иртәсендә башкалабыз үзәгендәге Г.Тукай һәйкәленә чәчәкләр салу мәрасимендә Татарстан Президенты Р.Миңнеханов, Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин, Премьер-министр урынбасары З.Вәлиева, мәдәният министры А.Сибагатуллин, Казан шәһәре мэры И.Метшин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе И.Ибраһимов, министрлыклар һәм ведомстволар җитәкчеләре, республика парламенты депутатлары, шагыйрь юбилеена Россиянең төрле шәһәрләреннән, чит илләрдән килгән кунаклар, әдәбият һәм сәнгать әһелләре, шигырь сөючеләр катнашты.

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы янындагы мәйданда уздырылган Шигърият бәйрәме быел шул ягы белән үзенчәлекле булды: анда Г.Тукайның 125 еллыгы уңаеннан Казанда оештырылган Халыкара фәнни-гамәли конференциягә чакырылган галимнәр, Халыкара «Юнеско» һәм «Тюркской» оешмалары вәкилләре һәм, гомумән, Россиянең һәм дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыелган рәсми вәкилләр, әдәбият белгечләре, каләм әһелләре катнашты.

Шигърият бәйрәмен Татарстан Премьер-министры урынбасары З.Вәлиева ачып җибәрде. Ул үзенең чыгышында бөек шагыйребезнең бүген дә татар мәдәнияте һәм тугандаш халыклар символы булып калуын, 2011 ел—Г.Тукай елында республикада, Россиядә, чит илләрдә әле бик күп чаралар үткәреләчәген әйтте.

Аннары З.Вәлиева ТР Президенты Р.Миңнехановның 2011 елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турындагы Указын игълан итте, яңа лауреатларны котлап, аларга иҗат уңышлары һәм саулык-сәламәтлек теләде. Шуннан соң быелгы бүләк ияләре—җырчы А.Шаһиморатова, рәссам Р.Килдебәков, шагыйрьләр Л.Шагыйрьҗан, М.Мирза, иҗатларының югары дәрәҗәдә бәяләнүе өчен, җәмәгатьчелек алдында республикабыз җитәкчелегенә, әдәбият һәм сәнгатьне зурлый һәм бәһали белгән халыкка ихлас рәхмәт сүзләрен белдерделәр. «Мин төрле сәхнәләрдән чыгыш ясаганда, гастрольләр белән Көнбатыш илләрен гизгәндә дә, үземнең беркайчан да татар кызы, Казан кызы икәнлегемне онытмыйм»,—диде дөнья күләмендә танылырга өлгергән җырчы А.Шаһиморатова.

Бәйрәмнең шигъри-музыкаль өлешендә хөрмәтле кунаклардан Россия Язучылар берлеге сәркәтибе Н.Переяслов, Төркиянең Стамбул шәһәре губернаторының беренче урынбасары Ә.Сәламәт, Евразия Язучылар оешмасы рәисе Я.Делиәмироглы (Төркия), Әзәрбайҗан Язучылар берлеге рәисе А.Рзаев, шагыйрь һәм тәрҗемәче А.Акбаш (Төркия), «Наш современник» журналының баш мөхәррире, шагыйрь С.Куняев, Халыкара Язучылар берлекләре бердәмлеге башкарма комитеты сәркәтибе М.Переяслова һәм башкалар чыгыш ясады. Бәйрәм мөнбәреннән шулай ук шагыйрьләр Р.Харис, А.Остудин, Р.Бохараев, И.Иксанова, Р.Миңнуллин, З.Мансуров, А.Хәлим, Г.Морат, Н.Сафина, М.Кәримов (Башкортстан), В.Тургай (Чуашстан), Б.Бедюров (Алтай), В.Ар-Серги (Удмуртия), К.Таңгалычев (Мордовия), М.Әхмәтов (Дагыстан), И.Машбаш (Адыгей), Н.Лугинов (Саха-Якутия), Б.Ибраһимов, Й.Миңнуллина, Л.Фәтхетдинова һәм башкалар үзләренең шигырьләрен укыды, сәламләү-котлауларын ирештерде. Шигърият бәйрәмендә нәфис сүз осталары тарафыннан Г.Тукай әсәрләре яңгырады, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле, «Бәрмәнчек» дәүләт керәшен татарлары фольклор ансамбле, шулай ук җырчы Г.Имамиева, башка сәнгать осталары башкаруында җырлар тәкъдим ителде, җырлы-биюле тамашалар күрсәтелде.

***

Шушы ук көнне тарихи вакыйга булды—Мәскәүдә Г.Тукайга һәйкәл ачылды. Әлеге тантанада катнашкан ТР Дәүләт Советы Рәисе Ф.Мөхәммәтшин шагыйрь юбилееның Татарстанда гына түгел, күп кенә халыклар өчен дә мөһим вакыйга булуын искәртеп үтте, ә һәйкәл ачылу гамәле, спикерыбыз фикеренчә, XX гасыр башында ук татар, рус һәм башка милләтләрнең бердәмлеге турында кайгырткан Г.Тукайны олылау, аның истәле-

ген мәңгеләштерү ул.

Мәскәүдә Г.Тукайга һәйкәл ачу мәрәсимендә ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе, шагыйрь Р.Вәлиев, шулай ук шагыйрьләр Р.Фәйзуллин, Р.Зәйдулла, Р.Мөхәммәтшин, Э.Һадиева, җырчылар, Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры артистлары, башка сәнгать коллективлары катнашты.

***

Менә унҗиде ел инде апрель аенда Балтач районында Шигърият бәйрәме оештырыла. Быелгы тантанада Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары В.Нуриев, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең Каракалпак бүлеге Тел һәм әдәбият институты директоры А.Әлниязов (Нукус), шагыйрьләр Г.Мөхәммәтшин, Ш.Җиһангирова, Р.Җамал, ТДГПУ доценты, әдәбият белгече Л.Минһаҗева катнашты. Алар иң әүвәл Г.Тукайның Сасна Пүчинкәсе зиратында җирләнгән әнисе Бибимәмдүдә абыстайның каберенә чәчәк салдылар, ә Җәлил хәзрәт Фазлыев аның рухына дога багышлады. Шуннан соң Субаш авылы Мәдәният йортында Г.Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Анда Балтач районы күләмендә үткәрелгән балалар иҗат конкурсларына йомгак та ясалды, җиңүчеләргә истәлекле бүләкләр тапшырылды.

***

26 апрельдә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында бөек шагыйребез Г.Тукайның 125 еллыгына багышланган тантана булды. Анда күпсанлы мәртәбәле кунаклар—ТР Президенты Рөстәм Минниханов, РФ мәдәният министры Александр Авдеев, «Тюркской» генераль секретаре Дюсен Касеинов, «Юнеско» эшләре буенча Россия комиссиясе, Төркиянең мәдәният һәм туризм министрлыгы вәкилләре, РФ төбәкләре делегацияләре һ.б. катнашты. Тантанада катнашучыларны, татарстанлыларны бөек Тукайның олуг юбилее белән ТР Дәүләт Советы, Хөкүмәте исеменнән Президент Рөстәм Минниханов котлады.

Республика башлыгы ассызыклавынча, татарның Тукай шигырьләреннән һич югы бер юлын гына булса да белмәгән улы һәм кызы юк. Шагыйрьнең кыска гына гомер эчендә тупланган иҗади мирасы һәрвакыт иҗатка һәм хезмәткә рухландырган. «Габдулла Тукай чын мәгънәсендә халык шагыйре булды. Халыкка, аның чәчәк атуы өчен хезмәт итү сәяси чакыру гына түгел, ул аның яшәеше һәм иҗатының мәгънәсе дә иде. Ул туган төбәген һәм аның табигатен ярата, күңел түрендәге иң җылы хисләрен ана телендә белдерә. Аның «Туган тел» шигыре татар халкының милли гимнына әйләнде. Бүген үз халкыңның тугрылыклы улы булу—ул аның бердәмлеген кайгырту, туган телне саклау, милли мәдәниятне үстерү дигән сүз. Татар мәдәниятенең урыны гел югарыда булды. Татар теле дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелде, туган телдә белем алу законнар белән гарантияләнгән. Татар әдәбияты, театры, музыкасы зур уңышларга ирешә. Бүген татар теле спутник телевидениесе һәм Интернет аша Җир шары буйлап тарала. Татарстан үзгәрешләр авангардында булу һәм шул ук вакытта традицияләрне саклау үрнәген күрсәтә»,—дип белдерде Президент.

Тугандаш төрки халыкларның классик шагыйрьләре Тукайны үзләренең остазы дип санаган. «Татар мәдәниятенең үзендә дә шагыйрьләр, рәссамнар, язучылар, композиторларның, зыялыларның аннан соң килгән буыннарына Тукай кадәр көчле йогынты ясаган шәхес әлегә юк,—дип белдерде Президент.—Безгә төрки халыкларның бердәмлеген ныгыту мөһим. Бу—күпмилләтле Россиягә аеруча кирәк». Президент Тукай иҗатының XXI гасырда да бик актуаль булуын искәртеп, шагыйрь мирасын киләчәк буыннарга җиткерү—безнең изге бурыч, дип искәртте.

Тантанада шулай ук РФ мәдәният министры Александр Авдеев, «Тюркской» генераль секретаре Дюсен Касеинов, Финляндия татарлары ислам оешмасы рәисе Окан Таһир һ.б. чыгыш ясады. Соңыннан тантанада катнашучылар Р.Әхиярованың Р.Харис либреттосына иҗат ителгән «Шагыйрь мәхәббәте» операсын тамаша кылды. Төп рольләрне танылган опера йолдызлары Әхмәт Агади белән Альбина Шаһиморатова башкарды.

***

«Габдулла Тукай мирасы һәм миллимәдәни бәйләнешләр» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция Казандагы «Корстон» мәдәни-күңел ачу комплексында үтте. Гыйльми җыенны Татарстан Мәдәният министрлыгы, Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Фәннәр академиясе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оештырды. Конференция эшендә БДБ һәм ерак чит илләрдән—Германиядән, Польшадан, Төркиядән, Финляндиядән, Швейцариядән, Россия төбәкләреннән вәкилләр, галимнәр, язучылар, укытучылар, журналистлар—җәмгысе 400ләп кунак катнашты. ТӘҺСИ директоры Ким Миңнуллин конференциянең пленар утырышын ачып җибәргәндә әйтеп үткәнчә, Габдулла Тукай халкыбыз өчен бөек шагыйрь генә түгел, ул—милләтебезнең ерак тарих төпкеленнән күтәрелгән әрнүле-фаҗигале язмышы: аның үткәндәге барча хәсрәт-шатлыгын туплаган йөрәк пәрәсе дә, бүгенге яшәешнең өметхыялы да, вөҗданы-иманы да, киләчәк көннәргә озата баручы рухи остазы—пәйгамбәре дә. «Шагыйрьнең даһилыгы—чор куйган иң четерекле сорауларга берданбер дөрес җавап таба алуында, милләте өчен иң кирәкле сүзне иң кирәкле вакытта әйтеп бирә

белүендә»,—диде ул.

ТР Премьер-министры урынбасары Зилә Вәлиева конференциядә катнашучыларны Татарстан Президенты, Хөкүмәте һәм Дәүләт Советы исеменнән котлау чыгышында шагыйрьнең юбилеена багышланган тантаналарның «Юнеско» канаты астында узуын искәртеп үтте. «Тюркской» оешмасы 2011 елны Габдулла Тукай елы, дип игълан итте. Бу ел Татарстанда да Тукай елы итеп тәгаенләнде»,—диде З.Вәлиева. Ул искәртеп үткәнчә, шагыйрьнең юбилее Санкт-Петербург, Мәскәү калаларында да зурлап билгеләп үтелә. 26 апрельдә Россия башкаласында Г.Тукайга һәйкәл ачыла. «Пушкин, Тукай кебек бөек шәхесләрнең мирасы шулкадәр зур, ул даими өйрәнүне, фикерләүне таләп итә. Һәр чор, һәр буын Тукайны үзенеке итеп санау белән бергә, рухи, мәдәни, интеллектуаль үсештә алга бару өчен аның мирасына таяна ала»,—диде З.Вәлиева.

РФ Тышкы эшләр министрлыгының Халыкара оешмалар департаменты директоры урынбасары, РФнең «Юнеско» эшләре буенча комиссиясе җаваплы сәркәтибе Геннадий Орджоникидзе конференциядә катнашучыларга РФ тышкы эшләр министры Сергей Лавровның тәбрикләвен ирештерде. Шагыйрьнең иҗатын югары бәяләгән бу котлауда: «Күренекле шагыйрь Габдулла Тукайның олуг йөрәгендә тәэсирләр һәм хисләрнең тулы бер галәме урын алган»,—дигән юллар бар иде. ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров исә: «Олы әдипнең мәшһүр иҗаты һәм колачлы эшчәнлеге, гражданлык позициясе бөекләр мирасына лаек булырга тиешлегебезне искәртә»,—диде.

Мәскәү кунагы, Халыкара гуманитар башлангычлар агентлыгы генераль директоры, шагыйрь-тәрҗемәче Сергей Главюк, Германиянең Гиссен университетыннан тюркология профессоры Рут Бартоломэ, Каракалпакстан башкаласы Нукус шәһәреннән Н.Дәүкәрәев исемендәге Тел һәм әдәбият институты директоры Айтморат Әлниязов, Финляндия татарлары оешмасы рәисе Окан Таһир, Әзәрбайҗанның халык шагыйре Сабир Рөстәм, Әзәрбайҗанның Низами исемендәге Әдәбият институтының әйдәп баручы фәнни хезмәткәре, филология фәннәре докторы Манзар Гасанова, ТДГПУ профессоры, филология фәннәре докторы Фоат Галимуллин һ.б. Тукаебызны һәрьяклап ачып, иҗатын югары бәяләп чыгыш ясады. Төрек лингвистика җәмгыяте директоры, профессор Шүкру Халүк Акалын әйткәнчә, Төркия университетында Тукай иҗаты буенча диссертацияләр яклана, күпсанлы көндәлек матбугатта шагыйрьгә багышланган мәкаләләр, әсәрләреннән өзекләр басыла, аны искә алу чаралары үткәрелә. «Анкарада мин яшәгән йорттан ерак түгел Габдулла Тукай урамы да бар»,—диде галим.

Конференциядә катнашучылар игътибарына Г.Тукайның төрле елларда чыккан китаплары, аның тормышына, иҗатына багышланган басмалар күргәзмәсе дә тәкъдим ителде.

Гыйльми җыен кысаларында Г.Тукайның татар һәм башка телләрдә чыккан китапларын да тәкъдим итү булды. Әйтик, аның ТӘҺСИ галимнәре әзерләгән академик 6 томлыгының 1 һәм 2нче басмалары, шагыйрьнең татар, рус, мари, удмурт, чуаш, башкорт телләренә тәрҗемә ителгән шигырьләре тупланган җыентык, Чуашстанның халык шагыйре Валерий Тургай тәрҗемә иткән «Халахам сона юратам», удмурт теленә Вячеслав Ар-Серги тәрҗемә иткән «Габдулла Тукай шигырьләре», фин теленә Фәридә Низаметдин белән Фазилә Насретдин тәрҗемә иткән, Пуула Королайнен әдәби эшкәрткән «Су анасы», әзәрбайҗан теленә шагыйрь Мамед Кязым тәрҗемә иткән «Тукай шигырьләре» китаплары һәм башка басмалар конференциядә катнашучыларда зур кызыксыну уятты.

Пленар утырыштан соң гыйльми җыен секцияләргә бүленеп дәвам итте.

## РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ КОТЛАВЫ

Россия Федерациясе Президенты Дмитрий Медведев Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган тантанада катнашучыларга һәм кунакларга телеграмма юллады.

«Кадерле дуслар! Сезне—шагыйрь һәм гуманист Габдулла Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган тантаналы кичәдә катнашучыларны котлавыма шатмын. Аның иҗаты—күпмилләтле Россия мәдәниятенең аерылгысыз өлеше. Тукайның туган җиренә ихлас мәхәббәт белән сугарылган тирән эчтәлекле әсәрләре илебездә дә, чит җирләрдә дә үз укучысын таба.

2011 ел Татарстанда Габдулла Тукай елы дип игълан ителгән. Ышанам ки, бу хәл мәшһүр татар әдибенең шигъри һәм фәлсәфи мирасын популярлаштыруга хезмәт итәчәк. Тантанада катнашучыларга һәм кунакларга якты тәэсирләр, уңышлар телим»,—диелә әлеге телеграммада.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә:* Мәскәүдә Г. Тукайга куелган һәйкәл.

*Дүртенче биттә:* Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, шагыйрә **Лена ШАГЫЙРЬҖАН**.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ



Татарстанның әдәби җәмәгатьчелеге авыр югалтуга дучар булды. Күренекле шагыйрь, балалар язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт, А.Алиш исемендәге әдәби бүләкләр иясе, Г.Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом лауреаты, Татарстанның халык шагыйре **Шәүкәт Галиев** 7 май көнне 83нче яшендә вафат булды.

Ш.Галиев 1928 елның 20 ноябрендә Татарстан АССРның Апас районы, Бакырчы авылында дөньяга килгән. Сугыш елларында—үсмер чагында туып-үскән авылында колхоз бригадиры ярдәмчесе, агач әзерләүчеләр бригадиры, хисапчы һәм район статисты вазыйфаларында эшли. Шуннан соң Кайбыч район газетасының җаваплы секретаре, редакторы, «Чаян» журналының әдәбият бүлеге мөдире вазыйфаларында хезмәт куя, 70нче елларда Татарстан китап нәшриятының нәфис әдәбият редакциясен җитәкли. Әдәбиятка ул Бөек Ватан сугышы тәмамланганнан соң килә. 1948 елдан республика матбугатында лирик шигырьләре дөнья күрә башлый. Ш.Галиев 1961 елда Мәскәү шәһәрендә СССР Язучылар берлегенең Югары әдәби курсларын тәмамлый. Тормышны яхшы белүе һәм шигърияткә җаны-тәне белән бирелүе, рухи ихтыяҗларының киңлеге шагыйрьдә табигый сәләтенең бик тиз ачылуына ярдәм итә. 60нчы елларда Ш.Галиев укучыларга үзенчәлекле юморист буларак ачыла. Балалар өчен иҗат ителгән зирәк һәм нечкә юмор белән өртелгән шигырьләре Ш.Галиевнең иҗат биографиясендә аерым бер сәхифә били. Аларда ул үзенең нәни укучылары психологиясен аңлап, бик җитди әйберләр турында да кызыклы, рәхим-шәфкатьле, мавыктыргыч итеп сөйли белде. Ш.Галиев, лирик, юморист һәм балалар язучысы буларак, татар шигъриятенең реалистик традицияләренә, Г.Тукай мирасы, халык шигърияте җәүһәрләренә тугрылыклы калды. Фикер зирәклеге, кыска, үтә аңлаешлы телдә язылган тирән мәгънәле шигырьләр—Шәүкәт Галиевнең иҗади уңышларының сере әнә шунда. Аның шигърияте лирик аһәңнәре, шәхеснең рухи дөньясына үтеп керүнең психологик яңалыгы белән генә түгел, бәлки, әхлакый бөтенлеге, сафлыгы белән дә укучыларны җәлеп итте.

Ватаныбыз Ш.Галиевнең казанышларын югары бәяләде. Ул «Почет билгесе» ордены, Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале, Татарстан Республикасы Мактау грамотасы, медальләр белән бүләкләнде, Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хатына лаек булды.

Талантлы язучының якты истәлеге күңелләребездә һәрчак сакланыр.

**Р.Миңнеханов, М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин, И.Халиков, Ю.Камалтынов, А.Сибагатуллин, М.Моратов, И.Метшин, Р.Заһидуллин, Җ.Гаффаров, И.Ибраһимов.**



Лена Шагыйрьҗан

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZANUTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)